# ХАКОВСКИЕ ЧТЕНИЯ – 2019

**Материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова**



# ХАКОВ УКУЛАРЫ – 2019

**Яшь галимнәрнең Казан университеты Атказанган профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаков истәлегенә багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары**


**КАЗАНЬ**
**2019**

**УДК 811.512.145**
**ББК 81.2Тат**
**Х16**

**Под общей редакцией**
доктора филологических наук, профессора **Г.Р. Галиуллиной**

**Ответственные редакторы и составители:**
кандидат филологических наук, доцент **Х.Х. Кузьмина;**
доктор философологических наук, профессор **Ф.Ш. Нуриева;**
кандидат педагогических наук, доцент **Г.Р. Шакирова**

**Х16** **Хаковские чтения – 2019** [Электронный ресурс]: материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова (Казань, 21–23 ноября 2019 г.) / под общ. ред. Г.Р. Галиуллиной. – Электрон. сетевые данные (1 файл: 2972,6 КБ). – Казань: Издательство Казанского университета, 2019. – 270 с. – Систем. требования: Adobe Acrobat Reader. – Режим доступа: https://kpfu.ru/portal/docs/F_1510959888/Sbornik_Khakovskie_Chteniya_2019.pdf. – Загл. с титул. экрана.

Сборник включает в себя работы участников Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова, проведенной в Институте филологии и межкультурной коммуникации КФУ 21–23 ноября 2019 года.

Адресован научным работникам, преподавателям вузов и ссузов, аспирантам, студентам, а также широкому кругу читателей.

Ответственность за аутентичность и точность цитат, имен, названий и иных сведений, а также за соблюдение законов об интеллектуальной собственности несут авторы публикуемых материалов. Материалы публикуются в авторской редакции.

**УДК 811.512.1**
**ББК 81.2Тат**

**© Издательство Казанского университета, 2019**

**Х.Х. КУЗЬМИНА**
*Казанский федеральный университет, Казань*

# О ЖИЗНИ И НАУЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ЗАСЛУЖЕННОГО ПРОФЕССОРА КАЗАНСКОГО УНИВЕРСИТЕТА ВАХИТА ХОЗЯТОВИЧА ХАКОВА

**Аннотация.** Статья посвящена описанию жизни и деятельности Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова, являющегося основателем научного направления по истории татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** Вахит Хаков, история татарского литературного языка, стилистика

**Abstract**. The article describes the main stages of life and activities of the founder of Tatar literary language history school, Kazan University professor Vahit Khozyatovich Khakov.

**Keywords**: Vahit Khakov, the history of Tatar literary language, stylistics

«История каждой научной дисциплины знает два способа подхода к изучаемым явлениям. Один способ, очень решительный и смелый, направлен на то, чтобы свести всю пестроту и многообразие фактов мира, природного или общественного, к одному закону, одной формуле, одному понятию. Другой способ, более скромный, не столь броский, как первый, состоит в тщательном собирании фактов, скрупулезном их описании и систематизации и не предполагает скорого достижения окончательных результатов, хотя конечная цель его та же: объединить пестрое многообразие явлений, физических или социальных, в единую систему», − пишет известный ученый Г.В. Степанов [Степанов, 1984]. Именно такой деятельностью занимаются теоретики и практики науки, великие ученые, первооткрыватели, изобретатели-творцы. Доктор филологических наук, академик Российской академии Гуманитарных наук, заслуженный деятель науки Республики Татарстан, участник Великой отечественной войны, почетный профессор Казанского государственного университета Вахит Хозятович Хаков (1926-2008) является и теоретиком, и практиком в области истории татарского языка − вся его жизнь и научная деятельность свидетельствуют об огромном вкладе выдающегося ученого в сокровищницу татарского языкознания [Нуриева, 2013].

В данной статье мы попытаемся воссоздать историю становления личности как ученого. Интерес к знаниям о персоналиях, внесших значительный вклад в историю развития науки, остается актуальной и для современной науки. Хаков Вахит Хозятович является основателем научной школы по истории татарского языка,

и факты его жизнедеятельности как ученого всегда останутся востребованными при создании энциклопедических трудов по персоналиям тюркологической науки.

Вахит Хозятович Хаков родился 16 августа 1926 года в деревне Среднее Лаще (Күзби) Буинского района Республики Татарстан в семье учителя. Будучи семнадцатилетним юношей, был призван на фронт, сражался в Монголии, в Китае, где впервые увидел тексты рунических надписей. Проработав после демобилизации учителем в сельской школе Буинского района, поступил на историко-филологический факультет Казанского государственного университета, окончил аспирантуру при Институте языка, литературы и истории Казанского филиала Академии наук СССР (1960). В 1961 году успешно защитил кандидатскую диссертацию по истории татарского литературного языка начала XX века, а в 1971 году − докторскую на тему "Образование и развитие татарского литературного языка и его стилей" В 1965 году ему было присвоено ученое звание доцента, а в 1974 году − звание профессора. В 1989-1994 годах работал заведующим кафедрой татарского языка КГУ.

Основные научные интересы Вахита Хозятовича Хакова сосредоточены в области истории тюркских (главным образом татарского) литературных языков, развития их стилистических категорий, а такңе языка древних и старотатарских писҗменных памятников. В разные годы занимался также общими вопросами языкознания, проблемами лексикологии, терминологии, фразеологии, орфографии, этимологии, методики и изучения языка художественных произведений в школе, в вузе. В монографиях «Вопросы языка и стиля» (1961), «Введение в стилистику татарского языка» (1963), «Очерки по истории татарского литературного языка», «Образование и развитие национального литературного языка» (1972), «Стилистика и искусство слова» (1979), «Развитие татарского литературного языка в советский период» (1985), «История татарского литературного языка (дооктябрьский период)» (1993), «Татарский литературный язык (Стилистика)» (1999), «Язык – зеркало истории» (2003) и других публикациях исследуются вопросы развития лексических, фонетических, грамматических норм и стилистических категорий татарского литературного языка. [Туган як..., 2007] Вахит Хозятович также известен своими учебниками для школ, учебными пособиями для учителей, такие как «Изучение стилистики в школе» (1970), «Стилистика татарского языка» (1984), «Изучение языка татарских писателей в школе» (1984), «Навыки чтения и письма на латинской графике» (1993) и др., также опубликовано 27 книг: монографий, учебников, учебных пособий и более 500 научных и научно-методических статей. В годы преподавания университете Вахит Хаков читал лекции по истории тюркско-татарского литературного языка и стилистики, а

также ряд спецкурсов «Историко-лингвистический анализ тюрско-татарских письменных памятников», «Функциональные стили», «Основы социолингвистики» и др., являлся научным руководителем темы «Лингвистическое изучение старотюркских и старотатарских памятников XIII XIX веков и их роль в формировании норм и стилей татарского языка».

Вахит Хозятович Хаков являлся основателем научной школы по истории татарского языка и приоритетного направления изучения вопросов истории тюркских языков. В рамках этой деятельности он много сил отдавал воспитанию молодого поколения исследователей. По его руководством защищены около 20 кандидатских диссертаций, являлся научным консультантом 3 докторских диссертаций. Долгие годы ученый работал в составе Ученого совета по защите кандидатских и докторских диссертаций, участвовал в создании «Татарской энциклопедии» по разделу «Языкознание».

Вахит Хозятович вел общественную работу по реализации Закона о языках народов Республики Татарстан и Государственной Программы РТ по сохранению и развитию татарского языка как государственного, являлся членом различных комиссий по татарскому языкознанию и народного просвещения. Более 30 лет по республиканскому радиовещанию под его руководством и непосредственным участием велась научно-популярная передача по татарскому языку и культуре речи «Тел күрке – сүз» («Красота слова в языке»), рукописные материалы которого составляют более 10 томов.

Научно-педагогическая и общественная работа профессора отмечена восемнадцатью орденами и медалями, многими почетными грамотами и благодарностями. В 1987 году ему было присвоено почетное звание «Заслуженный деятель науки ТАССР», в 1994 году награжден «Почетной грамотой Республики Татарстан». За большие достижения в области науки и техники Вахит Хозятович был удостоин звания Лауреата Государственной премии Республики Татарстан (2006). В том же году профессиональная деятельность ученого-педагога была отмечана почетным званием «Заслуженный профессор Казанского университета».

20 июня 2008 года в возрасте 81 года профессора не стало... Память о нем сохранится в наших сердцах на долгие годы не только как о большом ученом-педагоге, но и великодушном, отзывчивом человеке.

**ЛИТЕРАТУРА**

Степанов Г.В. О филологии и филологах // Энциклопедический словарь юного филолога (языкознание) / Сост. М. В. Панов. М.: Педагогика, 1984. С. 5–11.

Нуриева Ф.Ш., Кузьмина Х.Х. Жизнь и деятельность профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова // Филология и культура. Fhilology and culture. 2013. № 3 (33). С. 342–346.

Туган як һәм туган тел хисе (сост. Х.Х. Кузьмина). Казан: КДУ нәшр., 2007. 220 с.

**Л.В. АХМЕТВАЛЕЕВА**

*Дочь проф. В.Х. Хакова*

*Казанский государственный*

*энергетический университет, Россия*

# С ЛЮБОВЬЮ ОБ ОТЦЕ – ПРОФЕССОРЕ КАЗАНСКОГО УНИВЕРСИТЕТА В.Х. ХАКОВЕ

Ляля Вахитовна Ахметвалеева – кандидат педагогических наук, доцент Казанского государственного энергетического университета. Под её руководством на кафедре «Промышленная электроника и светотехника» проводится научно-исследовательская работа по проблемам проектирования, создания и внедрения в учебный процесс новых компьютерных информационных технологий и инновационных решений, встраиваемых приложений на основе современной микропроцессорной техники. С огромной любовью и теплотой она вспоминает об отце – профессоре Вахите Хозятовиче Хакове.

Сагынабыз сине, әтием...

Әгәр әтиебез исән булса, 16 августта аңа 93 яшь тулган булыр иде. Ул – Татарстанның Атказанган фән эшлеклесе, Россия гуманитар фәннәр академиясе әгъзасы, Казан университетының Атказанган профессоры, филология фәннәре докторы, Татарстан Республиканың Дәүләт премиясе лауреаты. Әтием югары дәрәҗәдәге кадрлар әзерләүгә үзеннән зур өлеш кертте. Аның укучылары бик күп. Татарстанның күренекле тел белгечләре аны үзләренең укытучысы итеп санады, шуңа күрә әтиемнең якты хатирәсе алар күңелендә саклана.

Иң якын һәм сөекле кешебез булган әтиебезне югалтканга унбер ел үтте инде. Ул көтмәгәндә, аяк өстендә йөргәндә мәңгелеккә китеп барды. Үзенә 81 яшь булуына карамастан, эшен ташламады. Вафаты алдыннан да әле ул читтән торып укучы студентларга лекцияләр укыды, мәкаләләр язды. «Россиянең атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем алу өчен документлар әзерләде, әмма алар Мәскәүгә җибәрелмичә калды. Ул үзенең эшен яратып башкарды, үз уңышларына ихластан куанды. Татар телен саклау һәм аның үсеше өчен күп көч куйды, тормыш юлын чын күңеленнән шуңа багышлады. Казан дәүләт университетында ярты гасырга якын укыту һәм фән эшләре белән бергә, әтием радиода «Тел – күрке сүз» тапшыруын да әзерләргә

өлгерде, балалар журналларында татарча өйрәтә торган дәресләр алып барды. Бик җентекләп, яратып материаллар җыя иде. Казан университетын, факультетын, кафедрасын, китапханәдә эшләп утыруын бик ярата иде ул. Бер генә көн дә эшенә бармаса, борчылып кала иде.

Әтием минем өчен гади генә әти түгел, остазым һәм фәнни җитәкчем, дустым да булды. Тыныч кына, иплəп кенә бергә сөйләшергә ярата иде. Безнең арадан киткәч, мин шуны аңладым: әле күпме сөйләнмәгән сүзләр, алышасы фикер калган икән...

Әтием бик көчле рухлы кеше иде. Ул, зур тормыш юлы үтеп, гаҗәеп сабыр, итагатьле, пөхтә кеше булды. Авыр фронт юлларын узгач, әтием хезмәт юлын туган ягы Буа районында башлап җибәрә. Ул чакта да гади, кайгыртучан, игътибарлы кеше булган өчен, аны туган ягында да якташлары хөрмәт итә.

Без әтиемне «аяклы энциклопедия» дип атый идек. Биргән бер генә сорауны да җавапсыз калдырмый иде ул. Кызыклы, аңлаешлы итеп сөйли торган иде. Искиткеч бик күп белә иде ул. Әтием балаларны, мине, улы Илдусны, Алсу, Камил, Гадел оныкларын, Мәдинә, Лэйлә, Гаделия оныкчыкларын бик ярат-ты. Аларга әкиятләр укый, төрле кызык хәлләр сөйли, алар белән бергә уйный да иде. Әтием үзенең соңгы көннәренә кадәр һәрбер эшендә безнең өчен үрнәк булды. Ул һәрвакыт пөхтә киемнән – күлмәк белән галстуктан йөрде. Аның эш өстәле дә һәрвакыт тәртиптә торды. Киштәдәге китапларының кая куелганын да төгәл белә иде ул. Әтием китапларны кадерләп саклады. Ул гомере буе газета-журналлар яздырып алды. Безнең өйдә ниндиләре генә юк иде аларның. Китапка, туган телгә мәхәббәтне безгә әтием-әнием тәрбияләде. Гаиләдә барыбыз да татарча сөйләштек, хәзер дә, өйгә кайткач, әнием белән татар телендә аралашабыз. Кызым Алсу бабасы юлыннан китте, күп телләрдә сөйләшә. Ул – филология фәннәре кандидаты. Әтием горурлана, бик ярата иде Алсуны.

Әтием белән әнием Хөррия 56 ел тату гомер кичерде. 2008 елда Хаковлар Татарстанның иң яхшы гаиләсе буларак танылган иде. Әнием әтиемнең иң якын киңәшчесе булды. Ул пешергән ризыклар әтиемнең иң яраткан ашлары иде. Аларның бер-берсен аңлап яшәүләре безгә дә үрнәк булды. Гаиләбез дә һәрвакыт кунакчыллыгы белән аерылып торды. Әле дә хәтеремдә: әтием безне бик еш спектакльләргә йөртте. Алар әнием белән театр премьераларының берсен дә калдырмыйлар, юбилей кичәләренә йөриләр иде.

Әтием инде унбер ел безнең арада юк. Аның акыллы киңәшләре, тирә-юньдәгеләргә хөрмәт белән каравы истән чыкмый. Ул туган ягы Буа районы Күзби авылы зиратына җирләнде. Каберенә Г.Тукай сүзләрен яздырдык: «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле…»

**С.Н. АБДУЛЛАЕВ**
*Иссык-Кульский государственный университет, Киргизия*
**Н.Ш. ЭРКЕБУЛАНОВА**
*Международный университет Кыргызстана, Киргизия*

## ЛИНВОДИДАКТИЧЕСКИЙ ПОТЕНЦИАЛ ПОСЛОВИЦ

**Аннотация.** В статье рассматриваются лингвокультурологические аспекты изучения языка иностранцами. Авторы отмечают роль национального менталитета. Большое значение имеют пословицы как носители лингвокультурных концептов. Пословицы интерпретируются как готовые средства языка, которые обладают большой изобразительной силой.

**Abstract.** The article deals with linguistic and cultural issues of language learning by foreign speakers. The authors note the role of national mentality. Proverbs play an important role as carriers of linguistic and cultural concepts. Proverbs are interpreted as ready-made means of language that have great pictorial power.

**Ключевые слова:** картина мира, концепт, менталитет, пословица.

**Keywords:** worldview, concept, mentality, proverb.

Мысли о том, что языку свойственна образность, были высказаны учеными-лингвистами разных стран, жившими в разное время. Корни языковой образности лежат не в семантике, а в тезаурусе, в системе знаний. В процессе понимания речи на изучаемом языке у иностранных учащихся активизируются накопленные знания, необходимые для построения речи, «работает» сформировавшаяся общеязыковая картина мира. Картину мира исследователи В.И. Постовалова, Б.А. Серебренников рассматривают как «концептуальное образование – результат человеческого опыта в конкретных языковых и культурно-этнических условиях» [Постовалова, 1988: 11]. При освоении иностранного языка, как считает В.И. Постовалова, происходит «либо сосуществование двух картин мира, опосредованных в одном случае родным, в другом случае – изучаемым (русским и др.) языками, либо «креолизация» этих двух картин. Последний случай означает несовершенное владение вторым языком» [Постовалова, 1988: 11].

«Языковая картина мира может быть представлена в глобальном тексте, то есть всей совокупности текстов, порождаемых и порожденных обществом», – отмечал В.Г. Колшанский [Колшанский, 1990: 93].

С таким аргументом перекликается позиция и Э.Д. Сулейменовой, которая подчеркивает, что «само по себе понятие картина мира включает в себя признак целостности и может быть реализовано в языке только в виде текста

как длительного акта общения людей, поскольку изолированное слово неспособно выполнить функцию общения» [Сулейменова, 1996: 93].

О существующей универсальности законов картины мира пишет В.М. Сергеев: «Абсолютизация роли языка в познании приводит к пониманию его концептуальной системы, особой системы знаний, которая существует как нечто вне человека, вне его познающей деятельности. Именно поэтому так важна общность картины мира для всех людей: универсальность законов ее формирования и существование создает базу для взаимопонимания. Картина мира у отдельного человека и человечества в целом меняется, и законы этой динамики универсальны: это правила формально-логического вывода, логика естественных рассуждений и др.» [Сергеев, 1987: 15-17].

Преподавание изучаемого языка в иностранной аудитории чаще всего строится в лингвокультурологическом аспекте и тесно связано с явлением концепта. Концепт – это идеальная сущность, формирующаяся в сознании человека, и согласно Ю.Е. Прохорову, представляет собой «совокупность разноуровневых элементов, объединенных для обозначения определенных фрагментов картины мира, устойчиво реализуемых в общении представителей тех или иных культур» [Прохоров, 2004: 12]. Он может выступать в вербальных и в невербальных формах. Обычно концептом-репрезентантом выступает слово, получившее статус имени концепта – языкового знака, через которое содержание концепта передается наиболее полно и адекватно (*пасха, вера, любовь, золото, копейка, счастье* и т.д.). Невербальное средство выражение концепта может быть через символ (ср.: *красный цвет* – у многих народов обозначает «запрет» или цвет платья у невесты в Индии, *белый цвет* - платья невесты у европейцев и большинства стран мира *белый цвет* - платья вдовы на Востоке). Невербальные концепты могут отразиться на стереотипах поведения людей, позволить определить принадлежность человека к «своему» этносу или к «чужому». Например, в Китае и Корее *белый рис* – больше, чем продукт, он символизирует достаток, чистоту души и т.п.

При обучении иностранных студентов языку и культуре учет особенности традиций намного облегчает осмысление получаемой информации. Раскрывается значение некоторых слов и выражений чаще всего на уровне коммуникации, в процессе ситуации общения. Концепты в процессе коммуникации могут вызвать прямые и обратные связи, вызываемые у участников коммуникации. Ю.Е. Прохоров называет их «пучками» представлений, ассоциаций, образов, воспоминаний, действий и т.д., пробуждающих прямое и обратное движение смыслов, которые, попадая во все новые контексты, расширяют число налич-

ных и возможных сочетаний и связей. Ряд концептов, рассмотренных в своей совокупности, образует концептосферу языка, в которой отражается культура нации (национальная концептосфера)» [Прохоров, 2004: 182].

Диалог культур, выражаемый в коммуникативном поведении, способствует развитию человечества, является непременным условием нормального сосуществования человечества, необходим для всех членов общества в целях формирования взаимопонимания и сотрудничества. В диалоге культур большое внимание уделяется двум основным факторам: национальному характеру и национальному менталитету, которые ярко выражаются в языковых единицах и в коммуникативном поведении. Национальный характер, будучи следствием отражения в психике людей общих своеобразно сложившихся условий существования нации, определяет совокупность психологических свойств и черт, которыми обладает большинство представителей нации и которые отличают ее от других наций и народов. В социальной среде формируется национальный характер, который во многом зависит от специфических природных, экономических, исторических условий страны и сохраняется у каждого народа, передается от поколения к поколению, характеризуя глубину коллективного сознания, представляя особое мышление, эмоционально-волевую и поведенческую сферу. В национально-языковой картине мира каждого народа находит свое непосредственное воплощение менталитет нации, отражающий опорные концепты, понятия, образы, символы, присущие данной нации, приоритеты и идеалы, отчасти подвергаясь изменениям под воздействием исторических обстоятельств, все-таки сохраняют свою форму и значимость в ценностях, нормах. Каждый народ отличается своеобразным видением мира (иная вера, иной менталитет, другие традиции и обычаи, культура). В другой языковой среде обучаемые находят доступ к творениям другого национального духа, реалии других культур, изучая которые расширяют свой кругозор и формируют доброжелательное чувство интернационализма на основе взаимопонимания и взаимоуважения. В основе взаимопонимания лежит культура в разных аспектах. Например, в процессе соизучения русского языка и культуры иностранные студенты учатся быть способными воспринимать культурное разнообразие как норму сосуществование культур в поликультурных сообществах, видеть культурные сходства и различия между представителями различных лингвокультурных групп, осознавать свое место, роль и значимость в глобальных человеческих процессах.

Формирование коммуникативной компетенции иностранных учащихся осуществляется в нашей практике на материале пословиц, фразеологизмов

и языковых афоризмов, поскольку в них ярко отражается национально-культурный способ восприятия и осмысления окружающей действительности, познавательный и социальный опыт людей. В национально-культурном колорите языка как когнитивной памяти народа отражается опыт его многовековых раздумий и наблюдений, духовные ценности и традиции. Для того, чтобы понять культурные концепты народного творчества необходимо научиться понимать содержащийся в нем особый глубокий смысл, как многовековой опыт многих поколений, поскольку в каждом языке содержится особый глубокий смысл, наработанный не одним поколением людей, благодаря чему можно постичь индивидуальное национальное своеобразие людей, что в каждом слове отражается «внутреннее языковое сознание нации.

Поэтичность характеризует язык на всех этапах его развития. В выражениях типа «лицо – белый снег», или, «лицо, как молоко», «кремень-человек», «добрый молодец», «красна девица» он видел проявление «образного поэтического мышления». Словесный образ создается с помощью языковых средств, но вызывает в нашем сознании наглядные представления, позволяющие ярко и глубоко понять качественную сущность одних предметов (лицо, человек) на основе их сопостовления с другими (белый снег, молоко, кремень): *белизна лица* – на основе представления об удивительно белом, чистейшем, только что выпавшем *снеге*. Мысль о непреклонной воле человека, о его непоколебимости – на основе представления о *кремне* - камне таком прочном и твердом, что из него скорее можно высечь огонь, чем его разбить, разрушить.

Наиболее распространенный разряд всесторонне устойчивых фраз составляют пословицы, играющие большую роль в формировании и дальнейшем развитии литературного языка, так как они часто используются как в устной литературной, так и художественном тексте. Пословицы-параллели могут оказать существенную помощь при преподавании языков инофонам [Абдуллаев, Балтаева, 2017: 8].

Пословицы как яркое языковое явление привлекали и привлекают к себе внимание многих лингвистов и литературоведов различных стран. Сторонники литературоведческого подхода к пословицам отмечают народное происхождение пословиц, их лаконичность, остроумие, общеупотребительность, возможность переосмысления значения. Для пословиц, по их мнению, характерны следующие черты: ясность, краткость, образность, обобщенность смысла, законченность мыслей, сжатость и т.д.

С середины XX в. в связи со становлением фразеологии как самостоя-

тельной лингвистической дисциплины проблема соотносительности пословиц и поговорок с другими видами фразеологических оборотов решается с качественно новых позиций. Это вызвано, в первую очередь, стремлением фразеологов уточнить границы фразеологии. Вопрос о том, относятся ли пословицы к фразеологии, решается учеными по-разному в зависимости от понимания ими сущности фразеологического оборота как языковой единицы. По данному вопросу среди ученых нет единого мнения.

Противники признания пословиц фразеологическими единицами исходят в основном из их структурного своеобразия. Если пословицы имеют структуру предложения, то так называемые номинативные фразеологические обороты – структуру словосочетания. На этом основании исследователи, считающие фразеологическими оборотами только единицы номинации, исключают пословицы из состава фразеологии. Не все исследователи включают пословицы во фразеологию на том основании, что они отличаются от других фразеологических единиц синтаксической завершенностью и представляют собой грамматически оформленное суждение; в основе их целостного смыслового содержания лежат не понятия, а суждения, тогда как в основе лексического значения фразеологизма то или иное понятие; смысл их может быть передан только предложением (нередко развернутым), тогда как значение фразеологизма передается словом или словосочетанием; в состав фразеологии входят только поговорки, так как пословицы как фольклорный жанр во всей их совокупности не могут являться объектом толкования во фразеологическом словаре. Большинство лингвистов разделяет мнение о том, что отнесение к фразеологическим оборотам или, наоборот, выведение за пределы фразеологии тех или иных устойчивых сочетаний, обусловлено не тем, номинативные или коммуникативные это единицы, а тем, соответствуют ли они основным признакам фразеологичности. Признание пословиц и поговорок единицами фразеологического фонда прослеживается в работах многих языковедов.

Мы разделяем мнение исследователей, включающих пословицы, поговорки и простые выражения во фразеологический состав языка. Отнесение тех или иных сочетаний слов к фразеологии или, напротив, выведение их за пределы фразеологических оборотов обуславливается не тем, номинативные это единицы или коммуникативные, а тем, извлекаются они из памяти целиком или создаются в процессе общения. В речи носители языков не создают пословицу, а берут ее в готовом виде такой, какая она есть в системе языка [Абдуллаева, Акбембетова, 2017:5]. Все номинативные фразеологические единицы характеризуются тем, что имеют обобщенную и целостную семантику. Посло-

вицам также все это присуще, т.к. они не членимы и обладают обобщенным актуальным значением, причем обнаруживая некоторую специализацию своей семантики.

**ЛИТЕРАТУРА**

Абдуллаев С.Н., Акбембетова А.Е. _Лингвистическая типология пословиц как объект изучения // И.А. Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика Труды и материалы Международной конференции. В 2 томах. Под общей редакцией К.Р. Галиуллина, Е.А. Горобец, Д.А. Мартьянова, Г.А. Николаева. 2017. С. 3-6.

Абдуллаев С.Н., Балтаева К.И. Пословицы-параллели с зоонимами на русском и киргизском языках // Ономастика Поволжья. Т.2 . Ульяновск, 2017. С. 3-9.

Колшанский Г.В. Объективная картина мира в познании и языке. М., 1990. 108 с.

Постовалова В.И. Картина мира в жизнедеятельности человека //Роль человеческого фактора в языке. Язык и картина мира / Под. ред. Б.А. Серебренникова. М.: Наука, 1988. С.8-26.

Прохоров Ю.Е. В поисках концепта. М., 2004. 176 с.

Сулейменова З.Д. Казахский и русский языки: основы контрастивной лингвистики. 2-е изд. Алматы: «Демеу», 1996. 208 с.

**А. Т. АБЕЙДУЛЛОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ДИАЛЕКТАЛЬ ЛЕКСИКАНЫ ДӘРЕСЛӘРДӘ КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** Данная статья посвящена изучению диалектов, выделению слов в тематические группы. На уроках языка и литературы важно их внедрение, применение, создание методов разъяснительной работы с детьми.

**Abstract.** This article is devoted to the study of dialects, the allocation of words in thematic groups. Their introduce, apply, create methods of explanatory work with children are important at the lessons of language and literature.

**Ключевые слова**: диалект, татарский язык, татарская литература.

**Keywords**: dialect, Tatar language, Tatar literature.

Дәресләрдә диалектларны өйрәнү яшь буында иҗади эзләнү омтылышы тудыра, милли горурлык, патриотизм хисе тәрбияли, аның танып – белү сәләтен үстерә. Диалекталь лексиканы өйрәну мәктәп укучыларының сөйләм телләрен баетуга, мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен булдыруга, телдән һәм язма сөйләм өчен кирәкле чараларны сайлап алуга китерәчәк.

Туган телне өйрәнгәндә сүзне дөрес куллана белү зур урын алып тора. Сүзләрне мәгънә ягыннан бүленеш типологиясенә таянып кайбер күнегү

төрләрен аерып чыгарырга була: сүз мәгънәләрен аңлату, әзер материалны анализлау, тел материалын үзгәртеп кору, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү.

Татар теле дәресләрендә диалекталь лексиканы куллану лексик-семантик принципны кулланып тормышка ашырыла: экстралингвистик – диалекталь һәм реаль күренешне туры китерү; парадигматик – синоним һәм антонимик рәтләрне аңлату аша; синтагматик – лексик берәмлекләрнең сөйләмдә кулланылуын күрсәтү. Күрсәтелгән принциплар лексик-семантик, лексик-грамматик, лексик-стилистик күнегүләрнең нигезен тәшкил итә алалар. Мисал өчен:

1. Фотографиядәге предметларны карагыз. Сезнең төбәктә бу предметлар ничек атала? Әдәби телдә аларның исемнәре бармы? Диалекталь сүзләргә гомуми кулланыштагы сүзләр уйлагыз. (Көнкүрештә кулланыла торган кием атамалары, бизәнү әйберләре төшерелгән рәсемнәр тәкъдим ителә).

2. Диалекталь сүз кайсы сүз төркеменә карый? Морфологик анализ ясагыз. Әлеге бердәнбер салам түбәле *ызбага* күптән эче пошып йөри аның. Инженер минем белән *гадук* булса да, бик *крута* һәм *халир* кеше иде. *Праулкыда* Алсу күренде. Аның *кылагалкасы* бик матур. Әбинең *түмәсе* бар. Аңлатма бирү: ызба – өй (дом); гадук – яшьтәш (одногодки); крута – кискен (крутой); халир – булдыксыз (холера); праулка – тыкрык (переулок); путалак – түшәм (потолок), кылагалка (алка), түмә (төймә, муенса).

3.Текстны укыгыз. Мәгънә ягыннан туры килә торган сүзләрне, текстның теге яки бу стильдә икәнен исәпкә алып, тиешле формада куегыз. Белешмәләр өчен сүзләрне карагыз. Сөйләмнең кайсы стилендә диалекталь сүзләр куллану урынлы? ... , чакыр әле урамга ... , минем яңа ... күрсеннәр! (Дуслар сөйләшүеннән). Мин монысына бик ышанмадым, ... арттырып сөйләргә ярата бит, үзегез беләсез [Зәйдуллин, 2008: 302]. Без аның белән бик тату яшәдек, туган көнемә алтын ... бүләк итте. (Дуслар сөйләшүеннән). ... яратып чиертә ул! (Дуслар сөйләшүеннән). Бу кыз бала ... гына кулларында нәрсәдер китерә үзенең йортына [Бурнаш, 1959: 182]. Кайттым илләремә ... гына, кайттым яшерен генә, тын гына [Бурнаш, 1959: 73]. Белешмә өчен сүзләр: кыз-хатын, күрше-арышы, ортын, мунчак, тайым, айбагар, ызба, кәмир шәл.

4. Бирелгән диалектизмнарның лексик мәгънәсен һәм барлыкка килүен аңлатыгыз. Лексик мәгънәне аңларга сезгә нинди морфемнар ярдәм итте? Барига (бияләй), начнуй (калын пәрдә), йакмыш (кыстыбый), алка (кабартма).

5. Бирелгән диалектизмнар кайсы сүз төркеменә карый? Нинди морфемнар моны билгеләргә ярдәм итте? Ут (чүп үлән), йөзлек (сөлге), милчә (тегермән), жар (кызу, эссе), кырил'ца (өйалды баскычы), зәрә (таң), ләдән (астына боз катырып ясалган шугыч, ледянка).

6. Диалекталь сүзләргә морфемик анализ яса. Морфемик анализның сүзнең лексик мәгънәсен ачыклауга ярдәм иткәнен исбатла. Тайчан (оялчан), маскарцы (шаяртырга яратучан), минек (мунча себеркесе), түмә (муенса), партык (алъяпкыч), касаклы (чүпрәк кисәкләрен корамап сырган киез).

7. Бирелгән диалекталь сүзләргә синонимнар һәм антонимнар тап. Йерәкләнү (ачулану), аухатлы (көчле), карсак (тәбәнәк), мыгын (аз сүзле), пыжу (шиңү), батула (чүбектән яисә иске – москыдан сугылган палас).

8. Төп сүз буларак бирелгән диалектизмнар белән сүзтезмәләр төзе: ләкшә (өйдә ясалган токмач), игәц (бертуган апа), кукыль (пирог), паңгы (гөмбә), ызба (өй), әпәй (ипи), сәләскә (кечкенә чана), чип (чылбыр).

9. Диалектологик сүзлектән бирелгән лексик диалектизмнарның мәгънәләрен тап. Безнең авылда бу сүзләр нинди мәгънәдә кулланыла? Алма, нук, ылан, мижин, алҗакма, салма, дустыган.

Әзер материалны анализлаганда укучыларга сүзләрнең төрле тема буенча классификациясен төзергә тәкъдим итәргә була: көнкүреш әйберләре – начнуй (калын пәрдә), партык (ялъяпкыч), кыйыкча (кечкенә савыт), чирәп (балчык савыт), кием-салым – кашпау(энҗе-мәрҗәннәр, тәңкәләр тезеп эшләнгән хатын-кыз баш киеме), милли ашлар – әпәй питырасы (ипи), чигелдәк (төш, камыр ашы).

Үзләштерүне җиңеләйтү өчен һәм сүзләрнең мәгънәләре тиз истә калсын өчен, аларны сүзтезмә һәм җөмләләр эчендә куллану мөһим, шуңа күрә мондый төр күнегүләр күп кулланылырга тиеш.

Шулай итеп,  укыту һәм тәрбиядә диалектларны кулланып түбәндәге нәтиҗәләргә ирешеп була:

1) үз халкына, аның теленә, тарихына һәм мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү; 2) укучыларның сүзлек хәзинәсе баету; 3) ана телендә логик фикерләү сәләте үстерү; 4) укучыларның иҗади көчен, танып – белү сәләтләрен, мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерү, алар үзлекләреннән белем алуга әзерләнә.

### ӘДӘБИЯТ

Бурнаш Ф. Сайланма әсәрләр. II том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. 280 б.

Зәйдуллин Р. Р. Ташка ордым башны : хикәяләр, эсселар. Казан : Татарстан китап нәшрияты, 2008. 398 б.

**А.Г. ӘБРАРОВА, Г.К.ҺАДИЕВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# КАЗАН ШӘҺӘРЕ УРАМ ИСЕМНӘРЕНӘ СТРУКТУР АНАЛИЗ

**Аннотация.** Городское онимическое пространство формируется по определенным закономерностям, отражающим исторические, этнические, культурные и социально-экономические условия. Совокупность названий улиц, переулков, площадей, проездов принято обозначать терминами городская топонимия или урбанонимия. В статье рассматривается транслитерация и структурный анализ названий улиц города Казани.

**Abstract.** Onymic urban space is formed according to certain laws, reflecting historical, ethnic, cultural and socio-economic conditions. The totality of the names of streets, lanes, squares, thoroughfares is accepted to name by the terms urban toponymy or urbanonymy. The article deals with transliteration and structural analysis of street names of Kazan.

**Ключевые слова:** городская топонимия, урбанонимия, названия улиц, структурный анализ.

**Keywords:** urban toponymy, urbanonymy, street names, structural analysis.

Урам, тыкрык, проспект һәм мәйдан исемнәре – күп гасырлы, данлы шәһәребез тормышының үзенчәлекле һәйкәлләре, аның революцион көрәше, сәнгате, төзелеше һәм сәнәгате турында күп нәрсә сөйли торган тарих хәбәрчеләре. Менә шуңа Казан урамнарының элекке һәм хәзерге исемнәрен махсус өйрәнү шәһәр төзелешләренең үсеше, үзгәреше, ландшафт үзенчәлекләре, халкының тормыш-көнкүреше, экономикасы һәм культурасы, милли составы, тарихи революцион вакыйгалары, атаклы кешеләре белән яхшырак танышырга, шәһәр һәм шәһәр халкы тарихын ачыграк итеп күз алдына китерергә булыша [Саттаров, 1971: 47].

Казан шәһәре башкарма комитетының «Казан шәһәре атамалар реестры турында» карары нигезләмәсендә башкаладагы һәр урам, проспект, мәйдан, проезд, тыкрык, шоссе, тракт атамалары кертелгән. Реестрда шулай ук, урам-юл челтәре элементлары атамалары; административ район; шәһәрнең кайсы өлешендә урнашуы турында кыскача мәгълүмат; урамга исем биргәндә расланган норматив акт турында мәгълүматлар да китерелгән. Реестрда 2146 урбаноним бирелә.

Реестрда күпчелек урбанонимнар транслитерация ысулы белән бирелгән, чөнки урам атамалары тәрҗемә ителми. Транслитерация ысулы бер телнең язылышын икенче телнең аналог хәрефләре ярдәмендә күрсәтүгә нигезләнә. Урбанонимнарның язылышлары, оригиналдагы аффикслары сакланган килеш, икенче тел материалы белән бирелә.

Әлеге ысулдан файдаланганда, кайбер татар хәрефләренең (ә, ү, ң, ж, һ, ө) рус telендә бирелү юлларына игътибар итеп китү урынлы, мәсәлән:

Ә-Э хәрефе: *Авиатозучелэр, Эбжэлилов, Эпсэлэмов, Эбубэкер, Терегулов, Эгерже, Актубэ, Ак чэчэклэр, Алексей Казымбэк, Алишер Нэвои, Алчэчэк, Элмэт, Эмэт-Хан Солтан, Эмирхан Еники, Этнэ, Эхтэмов, Аяз Гыйлэжев, Вахитов* мэйданы, *Габдулла Рэхимкулов, Галиэсгар Камал, Голшат Зэйнашева, Жэудэт Фэйзи, Зэй, Зэйни Солтан, Кэрим Тинчурин, Мэк, Мидхэт Булатов, Милэш, Тубэн Кама, Беренче Май* мэйданы, *Питрэч, Рэхим Саттар, Рэшит Ваhапов, Ростэм Яхин, Сэйдэш, Тажи Гыйззэт, Тэтеш, Телэче, Хэйдэр Бигичев, Чилэбе, Чирмешэн, Юкэ*;

Ү-У хәрефе: *Авиатозучелэр, Эбубэкер Терегулов, Актубэ, Жэудэт Фэйзи, Тубэн Кама*;

Җ-Ж хәрефе: *Эгерже, Аяз Гыйлэжев, Жэудэт Фэйзи, Тажи Гыйззэт, Энже*;

Ө-О хәрефе: *Авиатозучелэр, Голшат Зэйнашева, Монир Агишев, Ростэм Яхин, Яшь Коч*;

Ң-Н хәрефе: *Туфан Миннуллин, Чынгыз Айтматов*.

Тәрҗемә ысулына килгәндә, ул 1990-2000 нче елларда киң таралышка ия була. Уртаклык исеме белән мотивлашкан рус телендәге шәһәр атамаларының мәгънәләре татар теленә турыдан-туры тәрҗемә ителгән, мәсәлән: улица *Дубравная – Имәнлек* урамы, улица *Родины – Ватан* урамы. Бүгенге көндә әлеге ысул кулланылмый, чөнки урам исемнәре тәрҗемә итеп бирелми. Шул ук вакытта, реестрда кайбер атамаларның татар һәм рус формалары яшәве дәвам итә: улица *Победы – Җиңү* урамы; улица *Связистов – Элемтәчеләр* урамы; улица *Слободская – Бистә* урамы; улица *Приволжская – Идел буе* урамы; площадь *Тысячелетия – Меңьеллык* мәйданы һ.б. Топонимнар нигезендә барлыкка килгән урбанонимнарның телдә кабул ителгән тәрҗемә варианты булса, шуның ярдәмендә бирелә: *Тюлячинская – Теләче* урамы; *Тюменская – Төмән* урамы; *Услонская – Ослан* урамы; *Челябинская – Чиләбе* урамы һ.б. [Татар лексикологиясе, 2017: 294].

Атаманы катнаш ысул белән биргәндә, аның бер өлеше – оригинал телдә, икенчесе – кабул ителгән тәрҗемә формасында килә. Урам-юллар челтәренә караган объектлар тәрҗемә итеп бирелә: улица – урам, переулок – тыкрык, проезд – юл, площадь – мәйдан, слобода – бистә. Алынма булып торган сүзләр тәрҗемә ителми: проспект *Ибрагимова – Ибраһимов* проспекты; *Аракчинское* шоссе – *Аракчино* шоссесы; *Оренбургский* тракт – *Оренбург* тракты. Составында сан булган атамалар да өлешчә тәрҗемә ителә: *5-я Давликеевская – 5 нче Дәүләки* урамы; *8-я Залесная – 8 нче Залесная* урамы

һ.б. Шулай ук урбанонимнар составында булган поперечно-, большая, малая, старая, право-, лево- компонентлары кайбер очракларда тәрҗемә ителә: *Поперечно-Азинская – Аркылы Азино* урамы (ләкин *Поперечно-Боевая – Поперечно-Боевая* урамы); *Большая Мухаметшина – Зур Мөхәммәтшин* урамы (ләкин *Большая Заречная – Большая Заречная* урамы); *Малая Армавирская – Кече Армавир* урамы (ләкин улица *Малая – Малая* урамы); *Старо-Аметьевская – Иске Әмәт* урамы (ләкин улица *Старая – Старая* урамы), *Право-булачная – Уңъяк Болак* урамы, *Лево-Булачная – Сулъяк Болак* урамы һ.б. [Татар лексикологиясе, 2017: 295].

Төзелеш-ясалыш ягыннан урам исемнәрен түбәндәге төрләргә бүлдек:

Тамыр урбанонимнар: *Амур, Дружба, Дулкын, Ландыш, Лачын, Мирас, Намус, Сабан, Сандугач, Саф, Сөенеч, Тасма, Театр, Тормыш,Тургай, Уңыш, Урман, Уртак, Хыял, Өмет, Энҗе, Юмарт* һ.б.;

Ясалма урбанонимнар:

а) кушма урбанонимнар: *Аккош, Алмачуар, Алчәчәк, Балачак, Гөлбакча, Казансу, Наратбаш, Сабантуй, Ташлыяр* һ.б.;

ә) тезмә урбанонимнар: *Абдулла Алиш, Адмирал Ушаков, Ак каен, Казансу елгасы яры, Зур Крыловка, Ерак Кабан, Казан яшьләре, Красный Химик, Латыш Укчылары, Кече бистә, Матур* тыкрык, *Су Анасы, Таллы яр, Тар Урам, Эш Урам* һ.б.;

Ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган урбанонимнар:

-лык/-лек: *Агачлык, Азатлык, Батырлык, Дуслык, Сафлык, Туганлык, Яшьлек, Изгелек, Яктылык, Тынлык* һ.б.;

-чы/-че: *Елгачылар, Күперчеләр, Тамчы, Игенче* һ.б.;

-лы/-ле: *Наратлы, Затлы, Каенлы, Констлы, Назлы, Нурлы, Яфраклы, Серле* һ.б.;

-даш/-дәш: *Сердәш, Замандашлар, Юлдаш, Якташлар* һ.б.;

-гач/-гәч: *Алмагач* һ.б.

Төзелеш-ясалыш буенча төркемләүдә өстенлек тезмә урбанонимнарга бирелгән. Бу күп кенә урам атамалары теге яки бу өлкәдә танылган кеше исем-фамилияләре белән аталуы турында сөйли. -чы/-че, -лык/-лек, -лы/-ле, -даш/-дәш, -гач/-гәч кебек ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган ясалма урбанонимнар да еш очрый.

Күп урбанонимнар реестрда бер телдә генә бирелә. Андыйларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: *Алмачуар, Алтын Балык, Благополучие, Боевая, Веселая, Вишневая, Военная, Возвышенная, Главная, Дачная, Дуслар, Дуслык, Заречная, Игелекле, Игенче, Изгелек, Иман, Каенлы, Красивая,*

*Красочная, Лучезарная, Лучистая, Маленькая, Малиновая, Матур, Надеждинская, Назлы, Намус, Наратбаш, Наратлы, Нурлат, Нурлы, Озерная, Посадочная, Приозерная, Просторная, Рабочая, Раушан, Сабантуй, Садовая, Саф, Татарстан, Тансык, Ташаяк, Угловая, Центральная, Эш Урам, Юл Урам, Яз, Якташлар, Яфраклы* һ.б.

Танылган шәхесләребез исем-фамилияләре белән аталган урамнарда бары тик фамилия генә язылу, аңлауда кыенлыклар тууга сәбәпче дип саныйбыз. Яңа чор кешеләре күп кенә декабристлар яисә гражданнар сугышында батырлыклар күрсәткән сугышчылар, шулай ук татар милләтендәге кеше чит яисә башка милләтнең сәнгать әһелен, шулай ук татар халкының күренекле ул-кызларын белеп бетермәскә дә мөмкин, ә бары тик фамилия генә язылу бу эшне катлауландыра, чөнки бер үк фамилиядәге башка кеше дә булуы мөмкин. Фамилиясе бирелеп, исеме язылмаган урбанонимнарга түбәндәгеләр керә: *Әпсәләмов (Габдрахман), Адмирал Нахимов (Павел, Айвазовский (Иван), Айдаров (Ситдыйк), Академик Лаврентьев (Михаил), Академик Павлов (Иван), Академик Парин (Василий), Аксаков (Сергей), Әхтәмов (Сабир), Батыршин (Гыйлфан), Бауман (Николай), Бутлеров (Александр), Васнецов (Виктор), Гайдар (Аркадий), Гафиатуллин (Газинур), Левитан (Исаак), Маршал Чуйков (Василий), Пришвин (Михаил), Ибраһимов (Галимҗан)* проспекты, *Ямашев (Хөсәен)* проспекты, *профессор Нужин (Михаил), Райнис (Ян), Репин (Илья), Сәйдәш (Салих), Станиславский (Константин), Суворов (Александр), Сыртланова (Мәгүбә), Фрунзе (Михаил), Четаев (Николай), Шаляпин (Федор), Шишкин (Иван)* һ.б.

Төрле елларда урам исемнәренең реестрда ничек теркәлүен: тәрҗемә, транслитерация яки катнаш ысуллар белән икәнен тикшерү һәр чорга караган үзенчәлекләрне ачыкларга ярдәм итә. Бары тик бер генә ысулны кулланып атамаларны реестрга урнаштыру актуаль проблемаларның берсе булып тора. Бу, иң беренче чиратта, транслитерация ысулы белән бирелгән атамаларга кагыла. Татар хәрефләренең дөрес бирелмәве башка халыкларда үзебезнең милләт турында төрле каршылыклы фикерләр тууга сәбәп булырга мөмкин. Һәм иң әһәмиятлесе, әлбәттә, татар халкының бу күренешкә тискәре карашын да атап узарга кирәк. Мондый каршылыкларга очрамас өчен һәр атаманы рәсми документларга теркәгәнче, тел галимнәре белән берлектә аерым утырышлар булдыру кирәк дип саныйбыз. Урам атамаларының ясалышына килгәндә, өстенлекне тезмә урбанонимнар алып тора. Бу, иң беренче чиратта, күренекле шәхесләребезнең исем-фамилияләре белән аталган урамнарның күпчелекне тәшкил итүе турында сөйли.

**ӘДӘБИЯТ**

Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган? Казан: Татар. китап нәшр., 1971. 127 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘhСИ, 2017. Т. III. 1 кис. 536 б.

**С.Х.АЙДАРОВА, Р.Ф.ЯФАРОВА**

*Российский исламский институт, Россия*

## ИМЕНА ПРИЛАГАТЕЛЬНЫЕ, ОБОЗНАЧАЮЩИЕ ЗВУКИ, В АРАБСКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ

**Аннотация.** В статье рассматриваются имена прилагательные татарского и арабского языков. Дается сравнительная характеристика по некоторым грамматическим категориям. Особое внимание уделяется сравнению прилагательных, обозначающих звуки.

**Abstract.** The article deals with the adjectives of the Tatar and Arabic languages. It is given the comparative characteristic on some grammatical categories. Special attention is paid to the comparison of adjectives denoting sounds.

**Ключевые слова:** имена прилагательные, татарский язык, арабский язык, обозначающие звуки.

**Keywords:** adjectives, the Tatar language, the Arabic language, represent the sounds.

Современная наука рассматривает значение как важнейшую составную часть языка, один из его непременных ингредиентов. Выражение и восприятие смысла представляют, по существу, главную и конечную цель любого языка, обеспечивают его важнейшую функцию – коммуникативную. В отличие от плана выражения языка («внешней формы») план содержания (значение «внутренняя форма») как бы непосредственно обращен к человеку и поэтому долгое время оставался без должного внимания. Значение рассматривалось лингвистами в силу его психической природы как нечто «само собой разумеющееся», а если и изучалось, то «попутно», в связи с описанием словаря и грамматики.

К проблеме сущности языкового значения обращались многие известные лингвисты, среди них – А.И. Смирницкий, Ф. де Соссюр, И.Ричардс, В. А. Звегинцев, А.А. Уфимцева, И.А.Стернин и другие. Например, В.А. Звегинцев в своем труде «Семасиология» пишет: «значение слова – совокупность его лексико-семантических вариантов. Чем больше у слова ЛСВ, тем подробней и многосторонней охарактеризован тот класс предметов, который выражается данным словом, и чем меньше у слова ЛСВ, тем менее определена характеристика этого класса предметов. Но с другой стороны, отмечает В.А. Звегинцев, чем больше у слова ЛСВ, тем шире круг предметов, которое данное слово способно обозначить, и вместе с тем более «общим»

становится лексическое значение слова, делаясь в своем применении почти универсальным и безграничным. То есть, развитие в слове новых ЛСВ может, с одной стороны уточнять значение слова, а с другой – расширять его». [Звегинцев, 1957: 225]. Вопрос о типах лексических значений слов впервые был поставлен В.В. Виноградовым в его работе «Избранные труды» [Виноградов, 1977: 108].

Именно в области прилагательных наиболее очевидна абстрагирующая и анализирующая мыслительная деятельность человека, благодаря которой признак, свойство, качество, любые атрибуты, составляющие неотъемлемую сущность предмета, явления, вещи в самом широком смысле этого слова, что делает прилагательные интересным материалом для сопоставления. Своеобразие прилагательных проявляется в его «семантической мобильности», то есть приспосабливаемости к разным по семантике существительным и развитии на этой основе вторичных, переносных значений, с трудом поддающихся логической интерпретации, в его семантической и синтаксической несамостоятельности; в наличии широко представленного прагматического аспекта (субъективно-оценочных значений разного характера и т.д. [Вольф, 2002]

В рамках этой статьи мы решили изучить различные категории прилагательных, обозначающих звуки в татарском и арабском языках, отображающих реальный признак предмета, воспринимаемый органами чувств, причем осознание (и называние) признака происходит непосредственно на основе восприятия.

Прилагательные в татарском языке выделятся как отдельная часть речи. В отличие от татарского языка, в арабском языке имя прилагательное не может быть выделено в качестве особой части речи, параллельной или противополагаемой имени существительного, согласуясь с ним в падеже, роде и числе.

Имена прилагательные в арабском языке приводятся от глагола, которые строятся по определенным моделям “фуглун”,“фагалун”, “фаглаану” и “афгалу”,“фагилун”, “фагиилун”, ”фагулун”,”фаггалун”, “фаггалатун” и “фугалатун” [Гранде, 1998: 264].

Поэтому имена прилагательные в арабском языке классифицируются по моделям, а не по семантическим группам, как в татарском языке, что является спецификой арабского языка, хотя их и можно подвести под некоторые семантические группы. Так, они обозначают качество, состояние или признак, присущий предмету или лицу, а более сильной форме или часто повторяющийся, а также цвет или телесный недостаток предмета.

Следовательно, качественные прилагательные в исследуемых языках по своему значению можно разделить на следующие основные группы:

а) прилагательные, выражающие определенную характеристику лица, предмета, события, внешний вид, например: [джамийлун] (араб.) – матур (тат.) “красивый”, [уасиймун] (араб.) – сөйкемле (тат.) “привлекательный” и т.д.;

б) прилагательные, обозначающие размер или форму, например: [кабийрун] (араб.) – зур (тат.) “большой”, [сагыйрун] (араб.) – кечкенә (тат.) “маленький” и т.д.;

в) прилагательные, обозначающие цвт, например: [ахмару] (араб.) – кызыл (тат.) “красный”, [азраку] (араб.) – зәңгәр (тат.) “синий” и т.д.;

г) прилагательные, обозначающие вкусовые качества, например: [лазийзун] (араб.) – тәмле (тат.) “вкусный” и другие группы.

В отличие от татарского языка, в арабском языке не выделяются прилагательные, обозначающие возраст, например: карт (тат.) – “старый”, яшь (тат.) – “молодой”. Это значение передается с помощью сочетания имен прилагательных “большой”, “маленький”, и т.д. с именем существительным “возраст”. Например [кабирун синнин] “старый” и т.д.

Прилагательные в татарском языке не имеют категорию рода, числа и падежа. Множественное число имен прилагательных обозначается синтаксический, отражаясь в тех формах имен существительных, признак которых они характеризуют. Например: (ед.ч.) матур рәсем (тат.) “красивая картина”; (мн.ч.) матур рәсемнәр (тат.) “красивые картины” и т.д.

Как отмечает Л.Г.Мингазова, в отличие от татарского языка, имена прилагательные в арабском языке имеют категорию рода, числа и падежа. Имеются свои формулы (модели) для мужского и женского рода. Например, прилагательные обозначающие цвет или телесный недостаток, образуются по модели [афгалу[ (ед.ч., мж.род) – [ фагла’у] (ед.ч., жен. род.) – [фуглун] (мн.ч.) Например: [ахмару] “красный”, [хамра’у] “красная”, [хамрун] “красные” [Мингазова, 2012:50] и т.д.

В татарском языке прилагательных, обозначающих звуки 32, в арабском – 36. Например: *ачык* (тат.) Ачык яңгыравыклы тавыш белән, ул жыр башлап жибәрә, аны бүтәннәр күтәреп ала (Ф. Сафин), *горгылдык* (тат.) Хәзер, хөрмәтле иптәш журналист, күзегезне йомыгыз, - диде тантаналы горгылдык тавыш белән Сәлимов (А. Гыйләжев) (тат.), اشفقة “взволнованный”, بطي “медленный, вялый”, متحزن “скорбный” ( араб.)

Мы решили выяснить количество прилагательных, выражающих положительное качество звука, которое приятно на слух; отрицательное качество,

которое вызывает отрицательные чувства; прилагательные, образованные звукоподражанием; прилагательные, выражающие эмоциональное состояние человека; прилагательные однозначные и многозначные .

В татарском языке положительное качество звука обозначают 8 прилагательных, что составляет 25% от всех прилагательных татарского языка исследуемой группы. Например: иркәләүле, көйле и т.д. и 11 прилагательных, обозначающих положительное качество звука в арабском языке, что составляет 31,4%. Например, لين "мягкий, нежный", مسرور "радостный, обрадованный"и т.д.

В татарском языке отрицательное качество звука обозначают 7 прилагательных, что составляет 19% от всех прилагательных татарского языка исследуемой группы. Например: в арабском языке – 22 прилагательных, что составляет 61%. Например,

Прилагательных, которые выражают эмоциональное состояние человека, в татарском языке 11. Это составляет 34%. Например, *елаулы* "плаксивый", *куркыныч* "страшный". В арабском языке их 30, что составляет 86%. Например, عليل"больной رما"горестный", ملح "вдохновленный" и т.д.

Прилагательные, обозначающие звукоподражание, в татарском языке 14, что составляет 44 %, в арабском языке их 2, что составляет 6%. Например, *гөрләвекле* (звук родника, ручья), *межҗер-межҗер (*звук межер-межер*), мыгырдаулы* (звук ворчания) (тат.) , متموج "взволнованый", صارم "режущий" (араб.)

Что касается лексико-семантических вариантов прилагательных, обозначающих звуки, наблюдается такая картина: 16 прилагательных (50 %) татарского языка, обозначающих звуки, имеют только одно лексическое значение. 16 прилагательных (50%) нашей тематической группы входят в состав многозначного прилагательного. Например, имеют только одно лексическое значение прилагательные *озынлы-кыскалы, кабзыятле, пыскылдык*. Входят в состав многозначного прилагательного такие, как *калын, саңгырау, тыныч*. В арабском языке имеют только одно лексическое значение 21 прилагательных (58%). Это такие прилагательные, как *мотэмэувиж* متموج сф. *дулкынланган* (взволнованный), *нахушнуд* ناخوشنود сф. невеселый, недовольный (күңелез) и входят в состав многозначного слова 15 (42%) прилагательных. Это такие, как *сэрим* صارم сф. 1.Үткен, үткер (режущий, острый). 2. жесткий, строгий; *назик* نازك сф. 1. Нәзек, нечкә. 2. Гүзәл. (тонкий 2. Нежный, мягкий) .

Таким образом, в результате нашего небольшого исследования мы узнали, что

- имена прилагательные, обозначающие звуки в татарском и арабском языках, приблизительно одного количества (32 и 36);

- прилагательных, обозначающих положительное качество звука, в арабском языке больше (25 % в татарском и 31 % в арабском);
- прилагательных, обозначающих отрицательное качество звука, в арабском языке намного больше, чем в татарском (22 % в татарском и 61 % в арабском);
- прилагательных, обозначающих звукоподражание, в татарском языке намного больше, чем в арабском (44 % в татарском и 6 % в арабском);
- прилагательных, обозначающих эмоциональное состояние человека, в арабском больше, чем в 2 раза (34 % в татарском и 86 % в арабском);
- по количеству ЛСВ, однозначных и многозначных прилагательных по нашей тематической группе в татарском языке соотношение равное: 1:1, в арабском однозначных в 1,5 раза больше.

Результаты нашего исследования отражаются в следующей таблице:

| **Критерии прилагательных** | **Прилагательные в тат. языке** | % | **Прилагательные в арабск. языке** | % |
|---|---|---|---|---|
| Положительное качество звука | 8 | 25 | 11 | 31 |
| Отрицательное качество звука | 7 | 22 | 22 | 61 |
| Звукоподражание | 14 | 44 | 2 | 6 |
| Эмоциональное состояние человека | 11 | 34 | 30 | 86 |
| ЛСВ (однозначное прилагательное) | 16 | 50 | 21 | 58 |
| ЛСВ (многозначное прилагательное) | 16 | 50 | 15 | 42 |

Итак, язык антропоцентричен по своей природе, поэтому, отражая мир, она всегда “смотрит” на него с точки зрения человека, что и составляет ядро любого явления в языке. Положительную разницу между татарским и арабским языками мы объясняем разной средой обитания этих народов, разным географическим положением стран, где проживают эти народы, а именно, более суровым, очень жарким климатом, где проживает арабский народ и благоприятным для жизни человека территорией, где проживает татарский народ. Большее количество прилагательных, обозначающих положительное и отрицательное качество звука, эмоциональное состояние человека объясняем именно средой обитания народа, т.к. нам кажется, что татарский народ в среде

своего обитания более защищён, чем арабский народ. Большее количество прилагательных, обозначающих звукоподражание, объясняем богатством разнообразной природы, окружающей среды татарского народа.

Мыслительная деятельность человека, ее наиболее общие проявления влияют на структуру языков, являясь причиной возникновения сходств, но, несмотря на это, абсолютных соответствии в разноструктурных языках не существует, ибо, будучи продуктом длительного исторического развития, структура любого языка глубоко индивидуальна и идиоматична. Однако установление определенных соответствий структурных категорий одного языка структурным категориям другого языка и выявление их соотношений вполне возможны.

**ЛИТЕРАТУРА**

Виноградов В.В. Избранные труды. Лексикология и Лексикография / В.В. Виноградов. М.: Наука, 1977. С. 108.

Вольф Е.М. Функциональная семантика оценки. / Е.М. Вольф. М.: Едиториал УРРС, 2002. 300 с.

Гранде М.Б. Курс арабской грамматики в сравнительно-историческом освещении / Гранде М.Б. М.: Восточная литература РАН, 1998. С. 264.

Звегинцев В.А. Семасиология. / В.А. Звегинцев. М.: изд.Моск. ун-та, 1957. С.225.

Мингазова Н.Г. Особенности выражения категории количества имен прилагательных в английской, арабской и татарской языковых картинах мира / Н.Г. Мингазова // Филология и культура. Philology and culture. – 2012. – №1 (27) – С. 50.

**Ч.Н. АРСЛАНОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## Н. ХӨСӘЕНОВНЫҢ «РОМАН-ГЕРМАН ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ТӨРКИ НИГЕЗЛӘРЕ СҮЗЛЕГЕ» ТУРЫНДА

**Аннотация.** В статье представлена информация о книге Н. Хусаинова «Тюркские основы романо-германских языков», где собраны русские слова с тюркскими корнями и арабско-персидские заимствования, вошедшие в русский язык через тюркские языки.

**Abstract**. The article is devoted to the book "Turkic basis of romance and Germanic languages" by N. Khusainov, where Russian words with Turkic roots and Arab-Persian borrowings, which entered the Russian language through Turkic languages are collected.

**Ключевые слова:** язык, словарь, татарский язык

**Keywords:** language, dictionary, the Tatar language

Сезнең игътибарыгызга мин бер бик күләмле хезмәт турында мәгълүмат бирергә алындым. Дөресрәге, бер циклдагы ике хезмәт турында.

Беренче хезмәт – Хөсәенов Нурмөхәммәт Нури улының “Рус теленең төрки нигезләре сүзлеге”. Аның 5нче басмасы 2012 елда 650 биттә дөнья күргән иде. Интернетта “Татар электрон китабы” порталында ул бар. Кереш сүзне академик Мирфатыйх ага Зәкиев язган. Рус теленең тамыр сүзләренең 80-85 процентын төрки, төгәлрәк әйтсәк – татар телендәге сүзләрдән чыгышлы икәнен күрсәткән бу хезмәт инде бестселлерга әйләнде.

Бу хезмәтнең төп идеясенең дәвамы булып, шул ук авторның һәм аның улы булган Илдар Хөсәенов авторлыгында 2017 елда 846 биттән торган “Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге” дөнья күрде. Аңа да кереш сүзне академик Мирфатыйх ага Зәкиев язган. Мин бу китапны “Телләр энциклопедиясе” дияр идем. Ул “Роман-герман телләренең...” дип аталса да, монда барлык диярлек финно-угор, шул арада, сирәк кенә кайбер славян телләреннән алынган бик күп сүзләрнең дә татар-төрки нигезләре ачып күрсәтелә, чөнки авторлар күрсәткәнчә, роман-герман телләре ясалышының төбендә татардан алынган финно-угор телләрендәге сүзләр ята булып чыга. Һәм бу чынбарлыкка туры килгәне китапта шундый формада бирелгән ки, - күзеңә ышансаң - моңа дәлилләр һич кирәкми, чөнки төрле телләрдәге бер мәгънәдәге сүзләр шакмаклар эчендә аслы-өсле итеп бирелгән, һәм бер телдән икенче телгә күчкәндә нигездәге сүзнең кайсы хәрефе үзгәргәне күзгә күренеп үк тора. Тагын китапның бик кызыклы ягы – авторлар биредә борынгы этруск һәм, берникадәр генә мисалар белән, шумер телләренең дә төрки-татар теленнән булуын күрсәтеп китәләр. Этруск теленнән биредә 600дән артык сүзе бирелгән. Авторлар әйтүенчә, бүген этруск теленең 700гә якын сүз бәрәмлеге билгеле. Димәк, этруск теле тулаем алганда төрки-татар нигезле икәне күрсәтелә биредә. Китапның тагын бер үзенчәлеге – биредә йөзләп япон сүзе, берничә дистә – кытай һәм корея телләреннән сүзләр, хәтта америка индеецлары телләреннән дә шактый сүзләр аерым-ачык татар-төрки нигезле итеп күрсәтелә.

Бу хезмәттә күләме зур булмаган, әмма бик тирән эчтәлекле бүлек бар. Ул антропонимнар турында. Авторлар шушы ук ысул белән бик борынгы дип исәпләнгән исемнәрнең ничек ансат кына итеп берсеннән берсе ясалуы серен ачып бирәләр. Бу ачышның артында исә борынгы дип аталган тарихның нигездә ялган булуын күрсәтә. Хәер, әлеге хезмәткә кыска гына таблицада тарихның кайсы өлешләре ничек ясалганы да күрсәтелә. Бу дәлилләрне инкар итү бик читен.

Хәзерге заманның шактый галимнәре телләрнең кайчандыр бер телдән үсеп чыкканнарын инкар итмәсәләр дә, бүгенге көнгә кадәр беркем дә моны

конкрет хезмәт белән исбатлап күрсәтмәгән иде әле. Әлеге авторлар – аталы-уллы Хөсәеновлар – моны бик күләмле хезмәт белән исбатладылар.

**ӘДӘБИЯТ**:


Хусаинов Н.Н., Хусаинов И.Н. Тюркские основы романо-германских языков. Книга 1 (Принципы, технология и приемы изготовления лексических единиц романо-германских языков из тюркских корней. Словарная часть.). Уфа, 2017 г. 636 с.



**Г.Г. ӘСХӘДУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*


## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНДӘ АГАЧ ОБРАЗЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ


**Аннотация.** В данной статье рассматривается преподнесение образа дерева в татарской культуре. Отмечается их употребление в татарских народных пословицах, поговорках, фразеологизмах, крылатых выражениях. Даются суеверия татарского народа, связанные с деревом..

**Abstract.** This article discusses the presentation of the image of trees in Tatar culture. Their use in the Tatar national proverbs, sayings, phraseologisms, winged expressions is noted. The superstitions of the Tatar people about trees are given.



**Ключевые слова:** язык, образ, символ.

**Keywords:** language, image, symbol.


Элек-электән үк үсемлек, агач образлары татар халкында билгеле бер символны аңлатып, гәүдәләндереп килгәннәр. Шул рәвешле, бу образлар халык авыз иҗатында – экиятләрдә, риваятьләрдә, легендаларда, җырларда, табышмакларда, мәкальләрдә, тапкыр сүзләрдә, фразеологизмнарда чагылыш тапканнар. Алар күп вакытта илаһи көч буларак та кабул ителгәннәр, һәм бу очракта аларга билгеле бер сыйфатлар, үзенчәлекләр күчерелгән, иңдерелгән. Шунлыктан алар гади бер агач яисә үсемлек итеп кенә түгел, ә билгеле бер образ итеп каралганнар. Күпчелек очракларда агачлар күчерелмә мәгънәдә килгәндә кешене, аның тышкы кыяфәтен, буй-сынын, холкын сурәтләгәндә очрыйлар.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «агач» атамасы түбәндәгечә тәкъдим ителгән:

1) Каты кәүсәле, ботаклары ябалдашланып торган күпъеллык үсемлек. Яфраклы агачлар. Ылыслы агачлар. Җимеш агачлары.

2) Төзүгә һәм әйберләр ясауга китә торган агач материал; үзагач.

3) күч. гади с. хур. Аңсыз, аңгыра, надан [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1 том, 1977: 14].

Өченче билгеләмәдә агач сүзенең күчерелмә мәгънәсе китерелгән. Бу исә татар халкының агачларга карата үз мөнәсәбәте бар икәнен белдерә.

Теләсә кайсы халык билгеле бер тирәлектә яши, һәм аны географик яктан шушы тирәлеккә яраклашкан үсемлек, хайваннар дөньясы чолгап ала. Мәсәлән, без яши торган Татарстанда катнаш һәм куе яфраклы урманнар күп. Шуңа күрә бу урманнарда үсә торган каен, нарат, чыршы, имән, тал, усак, тирәк кебек агач атамалары татар халкының сөйләмендә канатлы әйтелмәләр, тотрыклы сүзтезмәләр, мәкаль һәм әйтемнәр, фразеологизмнар составында кулланылалар. Бу атамаларда татар халкының, милләтенең үзенчәлеге сурәтләнә, чагыла. Мисал өчен, шушы ук тирәлектә яшәүче башка берәр халыкны алсак, шул ук агач атамасының бу тел фразеологизмнарында башка төрле кулланышын күрер идек. Чөнки бу халыкларның диннәре, ышанулары, көнкүрешләре төрле була, шунлыктан алар агач атмаларына да башка төсмер бирәләр.

Беренче каен агачына тукталып китик. Каен – яфраклары йөрәк рәвешле, ак кайрылы агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2 том, 1979: 17]. Сөйләмдә дә, төрле әдәби әсәрләрдә дә каен агачы киң кулланыла. Төрле халыкларның аңа мөнәсәбәте төрлечә. Мәсәлән, славяннарда ул бик хөрмәтле агач булып санала: чисталык, яктылык, нәфислек символы булып тора. Якутлар карт каен агачларында олы яшьтәге зирәк хатын-кыз – җир хуҗабикәсе – яши дип ышанганнар. Хакаслар бу агачта сәламәтлек, уңыш, якты киләчәк чыганагы күргәннәр. Ә кайбер халыклар, киресенчә, каенны үлем һәм сагыш белән тиңләштергәннәр. Ә безнең татар халкына килгәндә, алар өчен каен агачы матурлык символы булып торган. Каен төз, матур булганлыктан, аңа зифа, буй-сынлы кызны сурәтләгәндә мөрәҗәгать иткәнннәр. Каен агачы элек-электән күп мәгънәгә ия булган: яучы килгәч, кәләшнең кияүгә чыгарга ризалыгын бирүе дә, җәзалауны белдерү дә аның төп мәгънәләре булып тора.

Имән – яфраклары челтәр кырыйлы, каты үзагачлы зур юан агач (аның ачы чикләвекләре була) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1 том, 1977: 269]. Имән агачы бик күп халыкларда изге агач дип саналган. Кешеләр анда төрле аллалар яши дип ышанганнар. Алар тарафыннан имән тереләр һәм үлеләр дөньясын тоташтырып торучы булып кабул ителгән. Аны ут һәм яшен белән бәйләп караганнар, зур-зур имәнлекләр утыртканнар, шунда аллаларга корбан китергәннәр, бөтен көч шунда җыела дип уйлаганнар. Чыннан да, имән бик көчле агач. Ул көч, түземлек, озын гомер, дан һәм киң күңеллелек символы булып саналган. Бигрәк тә татарлар өчен. Алар аңында имән агачы көчле, тәэсирле булып күзалланган. Һәм шуңа да бу агачны ир-атлар белән, аларның холкы белән бәйләп карау танылган.

Тал – гадәттә су буйларында куак булып үсә торган, озын һәм сыгылмалы чыбыклы, озынча тар яфраклы агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 том, 1981: 7]. Тал агачы озын гомерне, яшәү көчен гәүдәләндереп килгән. Япониядә ул нәфислек, гүзәллек билгеләрен чагылдырган. Ә Кытайда яз, уяну, хатын-кыз матурлыгы, шатлык, ә кайбер очракларда җавапсыз мәхәббәт буларак гәүдәләндерелгән. Тал агачы кайбер халыкларда, киресенчә, тискәре яктан чагылган: ул йомшаклык, бирешүчәнлек, сагыш хисләрен күрсәткән. Татарларда тал атамасы күпчелек очракта сылу, матур, төз гәүдәле хатын-кызга карата кулланылган.

Юкә – хуш исле вак саргылт чәчәкле, кабыгыннан мунчала алына торган яфраклы агач. Юкә бик күп халыкларда нәфислек, назлылык, матурлык символы булып тора. Ул хатын-кыз башлангычын гәүдәләндереп килә. Юкә агачы кешеләр тарафыннан көнкүрештә дә бик еш файдаланылган: анардан савыт-саба ясаганнар, өйләр төзегәннәр, сугыш кораллары эшләгәннәр. Юкә агачы юмартлыкны, киң күңеллелекне, яктылыкны һәм чисталыкны аңлаткан.

Нарат – күркәләре зур булмаган, ылыслы, мәңге яшел агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2 том, 1979: 201]. Нарат агачы озын гомер, үлемсезлекне гәүдәләндерә. Ул шулай ук батырлык, уңыш, тәвәккәллек, кыюлык символы да булып тора. Нарат агачының атамасын имән кебек үк көчле агач булганга ир-атларны сыйфатлаганда кулланалар.

Чыршы – наратлар семьялыгыннан ябалдашы конус сыман булган мәңге яшел ылыслы биек агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 том, 1981: 200]. Чыршы агачы батырлык, кыюлык, тугрылык, үлемсезлек, горурлык символы булып тора. Ул шулай ук ел башын, яңа тормыш башлангычын гәүдәләндереп килгән.

Усак – аксыл яшел төстәге шома кайрылы, киртләч яфраклы йомшак агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 том, 1981: 53]. Усак агачының, җилдә җелфердәп, “калтырануы” мәгълүм. Кешеләр, агачның шушы билгесен күз алдында тотып, усакны курку һәм тәвәккәлсезлек символы дип саныйлар. Бу агачны кара көчләр белән дә бәйләп караганнар. Шуңа күрә аны төзелештә кулланмаганнар, өй яннарына утыртмаганнар.

Зирек – каеннар семьялыгыннан үзагачы бераз кызгылт төсле, тиз сынучан, иртә чәчәк ата торган агач (дымлы урыннарда, яр буйларында үсә) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1 том, 1977: 214]. Борынгы заманнарда бу агач кешеләр өчен изге итеп, теге һәм бу дөньяны тоташтырып торучы булып саналган. Зирек гаилә агачы булып та торган. Гаиләдә күбрәк балалар булган

саен, ул аларны көчлерәк, яхшырак саклаган дип тә ышанганнар. Зирек туганлык җепләрен ныгыткан, нәселне тотып торган.

Тирәк – талсыманнар семьялыгыннан тиз үсә торган куе яшел яфраклы агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 том, 1981: 21]. Тирәк бик зур һәм биек. Шунлыктан аны ирек, ышаныч һәм җиңү белән символлаштырганнар. Шулай ук тирәк агачы кеше ике төрлелеген, ике йөзлелеген дә аңлатып килгән.

Әйтеп кителгәннәрдән күренгәнчә, агачларның халык, кеше тормышында бик зур роль уйнаганын күрәбез. Бу факт кешенең яшәү тирәлегендә аларның бик күп булуы белән аңлатыла. Агач кеше белән чагыштырып карала, чөнки ул шул ук тирәлектә тереклек итә, һәм агачларга хас булган сыйфатлар кешеләргә дә хас дип карала. Шунлыктан агач атамалары фразеологик әйтелмәләрдә чагылыш таба. Алар кешеләрнең тормышына кагылышлы төрле хәлләрне һәм вакыйгаларны, аларның эчке һәм тышкы сыйфатларын, холыкларын, көнкүрешләрен сурәтләгәндә кулланылалар. Мондый фразеологик әйтелмәләрдә татар халкының бай тормыш тәҗрибәсе, әхлакый идеаллары һәм кануннары чагыла.

**ЛИТЕРАТУРА**

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 1 том. / Төз. И.А. Абдуллин, Л.Т. Махмутова, М. Г. Мөхәммәдиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 476 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 2 том. / Төз. И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, М. Г. Мөхәммәдиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979 414 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 3 том. / Төз. И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, М. Г. Мөхәммәдиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 375 б.

**А.Р. БОЛГАРОВА**

*Казанский федеральный университет, Россия*

## МЕЖДОМЕТИЯ В ТАТАРСКОМ И АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются междометия и междометные фразеологизмы татарского и английского языков. Также дается классификация видов междометий, указывается частота употребления в сопоставляемых языках.

**Abstract.** In this article interjections and interjective phraseological units of Tatar and English languages are considered. The classification of the types of interjections is also given, the frequency of use in the compared languages is indicated.

**Ключевые слова:** татарский язык, английский язык, междометия, фразеологизмы.

**Keywords:** Tatar language, English language, interjections, phraseological units.

Как средства выражения чувств и эмоций, волеизъявления, желаний говорящего, междометия часто употребляются в разговорной речи. Однако фразеологический фонд татарского и английского языков также обогащен междометиями. Для выявления их роли во фразеологическом фонде данных языков мы опирались на фразеологический словарь татарского языка, составленный Н. Исанбатом, и большой англо-русский фразеологический словарь А.В. Кунина.

Фразеологические единицы – это устойчивые выражения, свойственные какому-то определенному языку. Фразеологизмы лексически неделимы, они не подлежат разложению и обычно не допускают внутри себя перестановки своих частей. Фразеологические единицы попадают в нашу речь в готовом виде и выполняют функцию отдельной лексемы.

В татарском языке достаточно много междометий, которые в устойчивом виде укрепились в составе фразеологизмов. Среди них междометия *ай-һай, өф, ә, эһ, уф, ах* являются самыми часто употребляющимися в составе фразеологизмов, например: *Ай-яй, (син) ничек* [Исәнбәт, 1981: 41]. Данный фразеологизм используется для выражения восхищения, возможно иронии. Междометие *ай-яй* в этом случае использовано для усиления экспрессии. *Ых та итми* [Исәнбәт, 1990: 263]. Фразеологизм о человеке, который не показывает никаких эмоций: либо ему все безразлияно, либо он очень стойкий. Междометие *ых* в этом случае употребляется как название эмоции жалобы.

Императивные междометия татарского языка реже употребляются в составе фразеологических единиц. Например: *Мә аягың, бир таягым* или *"мә сиңа" да "бир миңа* [Исәнбәт, 1990: 28]. Эти фразеологизмы синонимичны и употребляются при старании вернуть обратно совершенное добродеяние другому. При этом междометие *мә* является прямым переводом русского *на (бери). Мә бишне* [Исәнбәт, 1990: 28]. Фразеологизм употребляется при рукопожатии среди молодых людей.

Также среди междометий есть такие, которые используются в ряде фразеологизмов. Смысл междометия может варьироваться, а может оставаться неизменным в зависимости от того, в составе кагого фразеологизма оно использовалось. Например: *ай-һай, вай-һай күп булу* (восхищение); *ай-һай да юк* (горестный ропот)*; ай-һай ла* или *ай-һай ләбаса* (сожаление); *ай-һай салу* (сожаление, недоумение); *ай-һай телең, тел очында безең* (восхищение)*; ай-һай, Шәйхел, төлке микән, койрыгы озын* (подозрение) [Исәнбәт, 1989: 41-42].

При рассмотрении татарских фразеологизмов и междометий внутри них, мы обнаружили интересное явление. Среди татарских фразеологизмов очень

много рифмованных единиц. Например: *йа рабби ходаем, үзең китер уңаен, ат бир, бия бир, өсте өстенә өя бир* [Исәнбәт, 1989: 310].Это устойчивое выражение, упование на Бога, мольба о всем хорошем используется в разговорной речи татар с давних времен. В данной фразеологическом обороте использовано производное междометие *йа рабби ходаем.* С одной стороны, она выражает мольбу и упование, а с другой играет важную роль при рифмовке выражения.

Выше было отмечено, что слова, выражающие уважение, благодарность, приветствие и прощание, которые также рассматриваются внутри междометий. Такие слова как *рәхмәт (спасибо), гафу итегез (извините)* встречаются в составе фразеологизмов, однако своего значения не меняют. Например: *рәхмәте рәхмәт; рәхмәте үзеңә булсын, тияр хакын бирерсең; рәхмәтен белеп картай, кәкрәеп янтай; рәхмәттән тун теген булмый; рәхмәт төшкере (яугыры); рәхмәт уку; рәхмәт яңгыры; рәхмәт – әйтүеңә рәтләп; гафу итегез, егылыгыз аякка* и др [Исәнбәт, 1989], [Исәнбәт, 1990].

В татарском языке производные междометия также часто встречаются в составе фразеологических единиц. Например: *ай әттә, ай әттә генәсе (для выражения недовольства); шайтан алгыры! шайтан алгырысы (для выражения недовольства, проклятия); валлаhи, и валлаhи (выражение восхищения)* [Исәнбәт, 1989], [Исәнбәт, 1990].

По сравнению с татарским языком, во фразеологическом фонде английского языка междометия встречаются редко. Проанализировав большой фразеологический словарь А.В. Кунина, мы обнаружили несколько примеров, в составе которых имеются междометия. Например: *hurra(h)'s (hurray's) nest* [Кунин, 1984]. Данный фразеологизм в *американской разговорной речи* употребляется для выражения полного беспорядка, кутерьмы. Если перевести – *всё вверх дном.* Междометие *hurrah (ура)* в данном примере используется для обозначения беспорядка. O*h my ears and whiskers* [Кунин, 1984].*!* Это шутливое *восклицание, которое было создано Л. Кэрроллом в его известном произведении «Алиса в стране чудес» в речи Белого кролика:* 'Oh my ears and whiskers, how late it's getting!' – „О мои бедные усы, мои бедные уши! Как я опаздываю!" *В данном фразеологизме междометие oh употребляется для усиления эмоций. Can't say bo (boh или boo) to a goose* [Кунин, 1984]. *Фразеологизм, довольно часто употребляющийся в разговорной речи для описания очень робкого, застенчивого или пугливого человека. Аналогом в русском языке служит фразеологизм и мухи не обидит.* Междометие *bo (boh или boo)* в этом фразеологизме используется в своем основном значении: для выражения угрозы, устрашения. *Hum and haw*

[Кунин, 1984]. Данный фразеологизм употребляется в значении мямлить, запинаться; не решаться, колебаться, тянуть. Междометие *hum* употреблено для выражения неуверенности.

Как видно из этих примеров, междометия в английском языке употребляются в составе фразеологизмов в устойчивой форме. По сравнению с татарским языком, в английском языке не так много фразеологизмов, в составе которых имеются междометия. Однако лингвисты выделяют в английском языке междометные фразеологизмы.

Междометные фразеологизмы – это фразеологизмы, которые служат для выражения различных чувств, эмоций, волевых побуждений. Так же как и другие междометия, они обладают целостным переносным смыслом, образностью и экспрессивностью. Однако отличие междометных фразеологических единиц – быть средством выражения ментального или эмоционального отношения говорящего к предмету. То есть для них, так же, как и для междометий, характерно нивелирование функции номинации. Они называются междометными из-за своей функции, а не из-за присутствия в их составе междометия. Напротив, сами междометные фразеологизмы обычно не содержат в себе междометия.

В большом англо-русском фразеологическом словаре А.В. Кунин отдельно выделяет междометные фразеологизмы [Кунин, 1984]. Рассмотрим несколько примеров. *Good Lord! – видит бог!, боже (мой)!* – восклицание, выражающее удивление, досаду и т. п.; *by the Lord Harry*! – *чёрт возьми!* В данном фразеологизме *the Lord Harry* – это шутливое прозвище дьявола. *By golly! – ей-богу! бог мой!, честное слово!; о, чёрт!, чёрт возьми!; не может быть! – восклицание, выражающее удивление, досаду и т. п.*

В английском языке некоторые источники рассматривают слова *Good morning, Good afternoon, Good evening, Good night* так же, как междометные фразеологизмы.

Среди междометных фразеологизмов английского языка можно найти эквиваленты татарским фразеологическим единицам. Например, фразеологизм *damn it (all)! – к чёрту! чёрт подери! тьфу, пропасть!* (восклицание, выражающее удивление, досаду и т. п.) имеет аналог в татарском языке: *шайтан алгыры!*

Итак, проведенный нами сопоставительный анализ роли междометия во фразеологическом фонде татарского и английского языков выявил, что роль междометий среди фразеологизмов татарского языка более существенна, чем английского. В татарских фразеологических единицах междометия встречаются гораздо чаще и имеют устойчивый характер. Их употребление можно класси-

фицировать в зависимости от видов междометий и частоты употребления. В английском языке чаще употребляются междометные фразеологические единицы, которые также выражают чувства и эмоции говорящего.

### ЛИТЕРАТУРА

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1 том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. 495 б.

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 2 том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1990. 365 б.

Каушанская, В.Л. Грамматика английского языка. Пособие для студентов педагогических институтов. М.: Айрис-пресс, 2008. 384 с.

Кунин А.В. Англо-русский фразеологический словарь. М.: Рус. яз., 1984. 944 с.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. 3 нче басма. Казан: Мәгариф, 2006. 407 б.

**Р.И. ВӘЛИУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА «КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР» ТЕМАСЫН АҢЛАТКАНДА УЕН ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ

**Аннотация.** В данной статье раскрываются особенности применения игровых технологий при изучении сложных предложений, рассматриваются возможности игровых технологий в деле полноценного развития сознания личности учащегося. Применение игры на уроке даёт возможность учителю выйти на новый, творческий уровень взаимодействия с учащимися.

**Abstract.** This article reveals the features of the use of game technologies in the study of complex sentences, examines the possibilities of game technologies in the full development of the consciousness of the student's personality. The use of games in the classroom allows the teacher to reach a new, creative level of interaction with students.

**Ключевые слова:** сложное предложение, игровые технологии, коммуникативные технологии, метод.

**Keywords:** complex sentence, game technology, communication technology, method.

Сөйләм практикасында катлаулы кушма җөмләләрне актив куллану татар сөйләмен камил белүнең чагылышы булып тора. Укучылар сөйләмнәрендә катлаулы конструкцияләрне күбрәк кулланган саен фикерләре катлаулырак, баерак һәм тәэсирлерәк була. Катлаулы кушма җөмлә нәкъ менә бердәм катлаулы фикернең бербөтен синтаксик чагылышы. Шул ук вакытта, тәҗрибә күрсәткәнчә, мәктәпне тәмамлаучылар әлеге нормаларга һәм осталыкка ия

түгел, бу пунктуацион хаталарның, бигрәк тә күп компонентлы катлаулы кушма җөмләләрдә, шулай ук язма һәм телдән сөйләшүдә катлаулы җөмләләрнең күп төрлелеген актив кулланмауда. Бу шул исәптән катлаулы җөмләләргә уку процессында игътибар җитмәү белән дә бәйле.

Федераль дәүләт стандарты буенча төп укыту ысулы коммуникатив технология булып тора, ягъни телне аралашу аша һәм ана телен исәпкә алып өйрәнүдә. Шул исәптән, дәрестә коммуникатив технология белән берлектә уен технологияләрен кулланып укучыларның эшчәнлеген нәтиҗәлерәк оештырырга була. Уен эшчәнлеге телләрне укыту процессында сизелерлек ярдәм итә, чөнки ул даими аралашуны, эмоциональ күтәрелешне булдыра һәм чикләнелгән вакыт аралыгында кинәт уйлап табучанлык белән характерлана. Педагогларның күзәтүләре буенча, уен баланың эмоциональ, интеллектуаль, физик, коммуникатив һәм әхлакый өлкәләренә йогынты ясый. Уен укытуның нәтиҗәлелеген арттыруга һәм бер үк вакытта укучының шәхесен үстерүгә юнәлдерелә. Ул дәрестә укучыларның потенциалын мобильләштерергә, уңай атмосфераны булдырырга, игътибар, реакция, коммуникатив күнекмәләрне, иҗади сәләтләрне үстерергә, шуның өстәвенә, уен укучыларны психологик яктан бушатуга, киеренкелекне бетерүгә, куркудан арынырга ярдәм итә. Димәк, авыр булып тоелган синтаксисның бер бүлеген дә җәлеп итәрдәй кызыклы итеп тәкъдим итәргә була.

Аралашу бурычы уен формасында куела, ягъни сюжет аша кертелә, шулай ук уен кагыйдәләре турында сөйләшенә. Команда эчендәге хезмәттәшлек татар телендә аралашуга нигезләнә. Мисал өчен, “Күренекле шәхес” уены ярдәмендә укучыларның коммуникатив эшчәнлеге, логикасы, фантизиясе һәм иҗади фикерләве эшкә җигелә. Бирем: “*Катлаулы кушма җөмләләрне кулланып, берәр данлыклы шәхес турында рольне танытмыйча беренче заттан сөйләргә”.* Бер укучы такта янына чыгып үзенең ролен башкара, ә калган укучылар сорау-җавап формасында үзләренең белгәннәрен тикшерәләр. Шуның белән беррәттән “Интервью алу” уены да укучылар өчен кызыклы һәм мәгълүмати булачак. Сорау-җавап формасында катлаулы конструкцияле җөмләләрне кулланып укучылар үзләре теләгән мәгълүматны белә алалар. “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” дәрес-уен формасын теманы үтеп бетергәч, белем-күнекмәләрен тикшерү максатыннан кулланырга мөмкин.

Дәреснең аерым бер этабында яки тулы бер дәрестә викторина оештырырга була. Түбәндәге уен төрләрен кулланырга мөмкин:

“Сүзләр ярышы” уены. Укучыларга командаларга бүленергә тәкъдим ителә. Һәр комманда катлаулы кушма җөмләләр уйлап язырга тиеш була.

Җөмләдә сүзләр күп булган саен балл өстәлә. Әлеге уен форматы укучыларның сүзлек баен арттырырга һәм коммандада эш итәргә, бер-берсен ишетергә мөмкинчелек бирә.

“Дөрес яки ялган” уенында укучылар кәгазьдә үзләре турында өч җөмлә язалар. Аларның берсе дөрес, калган икесе ялган. Укучыларга әлеге җөмләләргә кагылышлы сораулар бирергә тәкъдим ителә. Әлеге эш төре грамматика күнекмәләрен генә түгел, шуның белән бергә укучылар турында күбрәк мәгълүмат җыярга ярдәм итә.

“Мозаика” уены аша укучының логикасы үстерелә һәм теоретик белеме гамәлдә кулланыла. Карточкада җөмләләр язылган була, укучылар шул карточкаларны тоташтырып текст төзиләр.

“Җөмләләрнең өен тап” уены ярдәмендә укучының логик һәм иҗади фикерләве арта. Бирем: *Бирелгән җөмләләрне туры килгән схемага урнаштыр. 1. Тел сөяксез: кая бөксәң, шунда бөгелә. (Мәкаль) 2. Инде кыш башланса да, күлләр, елгалар боз белән капланса да, кар әле төшмәгән иде. (Н. Фәттах)*

Укучыларның кызыксынуын арттыру өчен әдәби әсәрләрдән билгеләмәгә туры килгән мисаллар эзләтергә мөмкин. Мисал өчен:

1) Мөнәсәбәтле сүз белән бәйләнгән аналитик иярченле кушма җөмлә; 2) *ләкин* теркәгечле тезмә кушма җөмлә; 3) каршы кую интонациясе аша бәйләнгән аналитик иярченле кушма җөмлә.

Шулай ук дәреснең аерым бер этабында сингапур методы ярдәмендә укучыларның игътибарын арттыру һәм җәлеп итү нисбәтеннән КОНТИНИУС РАУНД РОБИН алымын кулланырга мөмкин. Укучылар сәгать теле уңаенда үзләренең төзегән катлаулы кушма җөмләләрен бер-берсенә әйтеп чыгалар, бер-берсенең хаталарын төзәтәләр. Бу эш төре укучыларны бер-берсен тыңлый белергә, аңларга өйрәтә, төркемдә эшләү аларга уңай тәэсир ясый, үзләренең фикерләрен әйтергә өйрәнәләр.

Уен ярдәмендә балалар, бер яктан, үзара аралашырга, бер-берсенә хезмәт күрсәтергә, үз командаларының мәнфәгатьләрен якларга өйрәнәләр, ә икенче яктан, ярыш шартларында тәнкыйди фикер белән алмашыналар. Балаларның уен ситуацияләрендә үзара эш итүе аркасында еш кына дуслашып китәләр. Уен нәтиҗәсендә балалар арасында гына түгел, балалар һәм укытучы арасында да үзара бәйләнеш барлыкка килә, шул сәбәпле тел материалын нәтиҗәле үзләштерүне тәэмин итә.

**ЛИТЕРАТУРА**

Гиниятуллина Л.М. Исследование аналитических конструкций в грамматиках татарского языка XX века. Казань: Отечество, 2016. 158 с.

Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. Татар теле (кагыйдәләр, методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). Абитуриентлар, укытучылар, студентлар өчен. Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2017. 191 б.

Нәбиуллина Г.Ә. Кушма җөмлә синтаксисы: теоретик мәгълүматлар, күнегүләр, контроль эшләр, тестлар. Методик кулланма. Казан: КГУ, 2006. 91 б.

Сәгъдиева Р.К., Кадирова Э.Х. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 9 нчы сыйныф Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2017. 143 б.

**Ә.Ф. ВИЛДАНОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

# Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫНДА ҺӘМ АНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ АЛЫШТЫРУ ЮЛЫ БЕЛӘН ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛГӘН СИНОНИМНАР

**Аннотация**. В данной статье рассматривается проблема перевода синонимов в художественных текстах. На примере произведения Г.Абсалямова «Белые цветы» исследуются виды переводческих трансформаций синонимов, их замена эквивалентной лексикой; выявляются их достоинства и недостатки.

**Abstract.** This article discusses the problem of translating synonyms in literary texts. A translation by replacing the equivalent is considered in more detail, considered its advantages and disadvantages.

**Ключевые слова:** перевод, способ перевода, синонимами, замена

**Keywords:** translate, synonyms translation, translation by replacement.

Тәрҗемә итү ихтыяҗы кешеләр башка халыклар белән аралаша башлагач, сәүдә элемтәләре урнаштырырга кирәк булгач туа. Башта кешеләр көнкүреш сүзләрен генә тәрҗемә итсәләр, тора бара инде әдәби, мәдәни мирас белән дә алмашу теләге барлыкка килә. Тәрҗемә белеме зур тизлек белән алга барса да, бүгенге көндә тәрҗемә әсәрләрендә төгәлсезлекләр шактый. Бигрәк тә телнең сүз байлыгын күрсәткән синонимнарны бер телдән икенче телгә күчергәндә аларның шактый булуы күренә. Беренчедән, телдә сүзләр арта бара, синонимик оялар төрле алынма, телнең үз закончалыклары белән барлыкка килгән сүзләр исәбенә тулыланып тора, ә бу тәрҗемә вакытында кирәкле берәмлекне сайлауны кыенлаштыра. Икенчедән, тәрҗемә әсәрләрендә синонимнарның бирелешен тикшерүчеләр бүгенге көнгә кадәр юк. Теманың актуальлеге дә шуннан гыйбарәт.

Г. Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы - иң күп укыла торган әсәрләрнең берсе. Әсәрдә синонимнарның роле гаять зур, алар шактый күп

кулланылган. Рус теленә тәрҗемәдә дә алар, нигездә, сакланганнар. Моны исбатлау өчен, без әсәрнең беренче бүлекчәсен анализладык һәм анда булган синонимик берәмлекләрне исәпләдек. Кечкенә генә әлеге өзектә барлыгы 9 синонимик оя, 21 синоним берәмлек очрый. Ә әсәрнең тәрҗемәсенә исә 11 синонимик оя һәм 22 синоним сүз кулланылганлыгын күрергә мөмкин. Күренә ки, тәрҗемә әсәрендә синонимик оялар һәм синоним берәмлекләр күбрәк. Бу, әлбәттә, бер тел берәмлекләрен икенче телдә бер сүз белән генә аңлатып булмау, чынбарлыктагы күренешләрне төрле яклап ачыклауга бәйле. Ләкин төп нөсхәдә бирелгән барлык синонимнарның да тәрҗемәдә бирелмәү очраклары да күзәтелә. Димәк, синонимнарның тулысынча, алыштырып тәрҗемә ителгән, яки, гомумән, тәрҗемә ителмәгән төрләре бар. Синонимнарны тәрҗемә итүдә билгеле бер кагыйдәләр юк. Алар бары тик урынлы кулланылырга һәм төп нөсхәдә әйтелгән фикерне, эчтәлеккә зыян китермичә, тәрҗемәдә дә җиткерергә тиеш. Алар аша укучы геройның тышкы кыяфәтен, характер-холкын, күңел хәләтен; вакыйгалар барган чорның, урыннарның үзенчәлеген күзаллый.

Синонимнарны алыштыру юлы белән дә тәрҗемә итү еш күзәтелә. Мондый ысул, әлбәттә, уңышлы да, уңышсыз да булырга мөмкин, чөнки тәрҗемәче алыштыру ысулын берничә очракта куллана. Беренчедән, синонимнарның үзгәртелеп, сүзлектә күрсәтелмәгән вариант белән тәрҗемә ителүе тәрҗемәченең нәкъ шушы вариантка өстенлек бирүе, нәкъ үзгәртелеп бирелгән синонимның гына автор әйтергә теләгән фикерне җиткерә алуы, ягъни үзгәртеп тәрҗемә итүнең эчтәлеккә зыяны булмау белән бәйле булырга мөмкин. Мисал өчен, *“Әнкәй гел **янасың, пешәсең** дип әрли” [АЧ:40]* җөмләсе – *“Мама причитает, что все время **в огне горю**”[БЦ:39]*дип бирелә. Әлеге мисалдан күренгәнчә, *янасың, пешәсең* синонимнары *гореть в огне* фразеологизмы белән алыштырып тәрҗемә ителгән. Безнеңчә, моның сәбәбе – татар телендәге *пешәсең* сүзенә рус телендә уңышлы тәрҗемә булмау, чөнки сүзлекләрдә ул *вариться, свариться; печься, испечься; обжигаться, обвариться* дип тәрҗемә ителгән. Күргәнебезчә, бу контекстта аларны куллану дөрес булмас иде.

Шулай ук түбәндәге мисалда да синоним алыштырып тәрҗемә ителгән: *“И **юләр**, и **сантый**! – диде ул кызганып та, битәрләп тә” [АЧ:141] – “Вот **глупец**, вот **простак**!” [БЦ:135]. Юләр* сүзе сүзлекләрдә *дурак, дурачок, глупый, ненормальный, умалишённый, душевнобольной* дип тәрҗемә ителә, тәрҗемәче *глупый* вариантын ала, ләкин аны иркәләйтү-кечерәйтү формасында *глупец* дип бирә. Шулай ук *сантый* сүзе дә сүзлекләрдә *дурачок, дуралей* дип

тәрҗемә ителгән, ә тәрҗемәче аны *простак* сүзе белән алыштыруны кулай күргән. Контексттан чыгып карасак, әлеге алыштырулар, дөрестән дә, бик уңышлы, чөнки автор монда геройның беркатлы булуын күрсәтергә тели, тәрҗемәче авторның әлеге фикерен *простак* сүзе белән тулырак күрсәтә.

Икенчедән, синонимнарның үзгәртелеп, сүзлектә күрсәтелмәгән вариант белән тәрҗемә ителүе тәрҗемәченең әйтелергә теләгән фикерне, җөмләне дөрес аңламавына бәйле булырга мөмкин. Шулай ук авторның нөсхә язылган телне камил белмәве, сүзлек запасының ярлы булуы да синонимнарны үзгәртеп, үзе аңлаганча тәрҗемә итүгә китерергә мөмкин. Мисал карап үтик. "*Ләкин егерме алты яшьтә күңел моның белән һич тә килешергә теләми, сагынулар белән генә дә яшәргә риза түгел ул" [АЧ:14] – "Но – в двадцать шесть лет – сердце никак не хотело примириться с этим, не хотела жить только горькими воспоминаниями" [БЦ:15].* Нөсхәдәге килешергә теләми һәм риза түгел синонимнары тәрҗемәдә не хотела фигылен кабатлау белән генә бирелгән. Безнеңчә, тәрҗемәче нөсхәдәге фигыльләрне тәрҗемә итеп, не согласно һәм не хотело яки не хотело соглашаться кебек фигыльләр белән дә тулыландырган булса, тәрҗемә отышлырак булыр иде. Ләкин тәрҗемәче кабатлау алымын кулланган, шуңа күрә тәрҗемәдә синонимнар юкка чыккан.

Түбәндәге мисалда да алыштырып тәрҗемә ителгән фигыльне күрергә мөмкин. "*Тыкрыкларны казып, актарып бетергәннәр – бөтен җирдә газ, су, җылыту торбалары үткәрәләр" [АЧ:16] – "А переулки изрыты, загромождены – всюду прокладывают газовые и водопроводные трубы" [БЦ:17]. Казып, актарып* синонимик берәмлекләренә игътибар итсәк, *казып – изрыты*, ә *актарып* сүзе *загромождены* дип тәрҗемә ителгән. Күргәнебезчә, *актарып* һәм *загромождены* бердәй мәгънәгә ия түгел, аларның аермасы бар. Загромождены, киресенчә, өеп куелган мәгънәсенә туры килә, чөнки рус теленең аңлатмалы сүзлегендә *"загромоздить, зжу, здишь; ождённый (ён, ена); сов., что. Заставить, заполнить чем-н. громоздким. З. квартиру вещами. З. вход. З. рассказ подробностями (перен.)"* дип бирелә. Ягъни, актару сүзенең мәгънәсе югала, төшә. Ә казып берәмлеге, киресенчә, актарып сүзенең мәгнәсенә якынрак сүз белән тәрҗемә ителгән, чөнки казылган сүзе вскопанный дип тәрҗемә ителә, димәк, дөрес тәрҗемә *вскопано, изрыто* булырга тиеш. Ләкин тәрҗемәче башкача күрсәтә һәм эчтәлеккә бераз зыян килә.

Әлбәттә, карап үтелгән очраклардан тәрҗемәдә синонимнарны үзгәртеп бирелүнең беренче очрагы гына уңай күренеш. Ни өчен дигәндә, тәрҗемәченең синонимны үзгәртеп, алышытырып бирүе укучының фикерне аңлавына

комачау итмәскә һәм эчтәлеккә зыян китермәскә, киресенчә, укучыга төгәлрәк мәгълүмат бирергә, эмоциональлекне югалтмаска тиеш. Ә икенче очрак киресенчә эчтәлеккә зыян китерә, күзалларга комачаулый. Татар телендә булган синонимнарның тәрҗемәдә булмавы романның телен ярлыландыра, әсәр татар телендә дә шундый ярлы телле, укучыга үтемсез дигән тәэсир калдыра.

**ӘДӘБИЯТ**

Абсалямов А.С. Белые цветы: Роман. / Пер. С татарского К. Горбунова. Казань: Тат. кн. изд-во, 1987. 560 с.

Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 575 б.

**Ф.Х. ГАБДРАХМАНОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘРЕНДӘ *КУНАК* КОНЦЕПТЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

**Аннотация.** В данной статье приводится паремиологический анализ концепта *кунак* (гость) в татарской лингвокультуре.

**Abstract.** There are paremiological analyses of the concept of kunak (guest) in Tatar linguistic culture in this article.

**Ключевые слова:** татарская лингвокультура, концепт *кунак* (гость), пословицы и поговорки

**Keywords:** Tatar linguistic culture, concept kunak (gest), proverbs and sayings

Халыкның күп гасырлар дәвамындагы күзәтү һәм уйланулары нәтиҗәсе, аның хыял-өметләре мәкальләрдә гәүдәләнеш таба. Мәкальләрдәге фикерләр халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсен гомумиләштерәләр, кешенең гамәлләрен, вакыйгалар һәм күренешләрне эмоциональ-экспрессив яктан бәялиләр.

*Кунак* концептының үзәген тәшкил иткән кунак лексемасы кергән мәкаль-әйтемнәрне анализлау барышында, аларны ике төркемгә бүлергә мөмкин: беренчесе – кунак кешенең сыйфатларын, икенчесе – кунак каршы алучының сыйфатларын бәяләү. Беренче төркемгә түбәндәге мәкальләрне кертергә мөмкин: *Кунак аз утырыр, күп сынар. Казан кайный алты ай, кунак көтә җиде ай. Самовар кайный алты ай, кунак көтә җиде ай. Кунак булсаң, куркак бул. Ашның бәрәкәте кунак белән*. Икенче төркемгә исә, түбәндәгеләр: *Безгә кунак килми, килсә, китә белми. Кунак килә, капка ач, ал кулыңа табагач. Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә. Кунак килсә казан ас, кунак ялгыз ашамас. Аша, кунак, аша, кайсы тәмле – катыгын аша. Бирер кешем килгәндә,*

*биш кайныйдыр казаным. Әйдә, төш, миндә кунак булып китәрсең. Ит булмаса, тозын аша, дигән ди берәү. Килгән кеше китәргә дип ишек бавын тоткач, утыр дип кыста. Кунакны озаттык, инде ашарга утырыйк. Килегез безгә, самавыр куярбыз, сез килгәч куярбыз, сез киткәч эчәрбез. Идәнеңне кеше таптасын, үзеңне кеше мактасын. Килгән кошка куак бар, кунакчыл йортта кунак бар. Килгәнне өеңә керт, алдына тоз-икмәк куй. Дуга килсә, дога килә. Кунак сөйгән өйдә бәрәкәт бар. Кунак – хуҗаның иркәсе. Кунак – уҗаның сандугачы* һ.б. Күргәнебезчә, әлеге мәкальләр кунак кешенең никадәрле кадерле, иркә булуын һәм кунакның үзенең дә кеше өендә ничек тотарга кирәклеген күрсәтә. Ә кунак каршы алучының исә, ачык күңелле булуын, кунакка иң тәмле сый-нигъмәтләрен генә әзерләргә тиешлеген искәртә.

Кунак кеше төрки халыкларда элек-электән үк аерым урынны алып тора. Кунакка йөрү – татар кешесе өчен үзе бер бәйрәм төсле кабул ителә. Әлбәттә кунакка йөрүнең үз тәртибе һәм закончалыклары бар. Концептның әлеге төре психологик яктан бары тик уңай итеп тасвирлана. Кунак татар кешесенең бусагасын атлап керсә, сыйга һәм матур сүзләргә күмелә. Хуҗа кеше үз чиратында кунагын төрле яктан юмалый: үзенең иң тәмле сыйларын табынга тезә, сөйкемле сүзләрен дә җәлләми.

Хуҗа кеше һичшиксез кунак итү процессында аерым урынны алып тора. Кадерле кунакны өйгә керткәнче, барлык әзерлекләр дә җиренә җиткерелеп, төгәлләнгән булырга тиеш. Әлбәттә, өй хуҗасының нинди булуына карап, кунакны кабул итүдә шул дәрәҗәдә башкарыла.

Алда бирелгән мисалларга күз төшерсәк, хуҗаның да төрлесе булганына инанырбыз. Мәсәлән, килгән кунакларны озатканнан соң гына тәмле сыйларны өстәлгә чыгару, яисә, өстәл алдында утырганда саранлыгыңны күрсәтеп, кирәкмәс сүзләр өстәп җибәрү.

Кунак итү процессы хуҗа өчен үтә җаваплы эш. Кунакка килгән кеше үзен уңайлы хис итсен өчен хуҗа игътибарлы булырга тиеш. Хуҗа тиешенчә сыйласа һәм назга күмсә, кадер-хөрмәт, ачык йөз күрсәтсә, һичшиксез, кунак кешенең күңеле булачак (*Кунагына күрә хөрмәте. Кунак кашыгына күз ияртмә, кызганды дияр. Кунакка сый әзерлә, тиешенчә кадерлә. Кунак чакырсаң, өч шартын онытма: дошманы янына утыртма, агу белән сыйлама, төрмәгә япма).*

Кунакка йөрешкәндә, кунаклар да үз-үзен дөрес тотырга тиеш. Хуҗа кешенең өенә килеп керү белән үзеңне тыйнак тоту турында онытырга ярамый. Һәрнәрсәнең үз тәртибе булган кебек, мәкаль-әйтемнәрдән кунакка йөрешүнең дә үз кагыйдәләре барлыгы аңлашыла: 1) хуҗа кеше белән киләсе көнне алдан

билгеләү яхшы булыр. Чакырылмаган кунакны бар җирдә дә өнәп бетермиләр. Үзегез турында начар фикер уянуы бар; 2) килешелгән вакыттан иртә һәм соң килү – шулай ук хуҗаның кәефен төшерергә мөмкин; . 3) табын алдында үзеңне тыйнак тотарга кирәк; 4) барлык өстәл аша тәмле ризык артыннан үрелү – үтә оятлы күренеш; 5) хуҗа тәкъдим иткән аш-сыйдан баш тартмау; 6) аш өстәле янында үзеңне әдәпле тоту; 7) вакыт турында онытмау: иң кадерле кунак – вакытында китә белгән кунак (*Ашамасаң аш гаебе булыр, алдыңа килгәнне сыпыру лаеклы булыр. Аш кадерен белмәгән, өй хуҗасын оялтыр. Авыз ит тә, рәхмәт әйт. Биргәндә аша, куганда кит. Әдәплелек билгесе – иелеп сәләм биргәне; Якын итү билгесе – кичектерми килгәне. Ишек ачкачтын түргә узма. Ишек ачык булса да, рөхсәтсез кермә. Ишектән кереп, түр минеке димә. Коймак булгач, ипи сорамыйм. Кунак булсаң, җыйнак бул. Кунакның килгән көне алтын, икенче көне көмеш, өченче көне бакыр, дүртенче көне кайтыр, кайтмаса , көл-күмергә кала. Кунакның көне өч, аннан артса хуҗага көч*).

Билгеле булганча, кешеләрнең төрлесе булган кебек кунакның да төрлесе була. Мәкаль-әйтемнәр арасында «әрсез кунак» кебек төшенчә йөри. Әгәр алда китерелгән мисалларга күз салсак, кунак кешенең шактый әдәпсез һәм намуссыз булганына ышанырбыз. Әрсез кунак вакытны белмичә, теләгән чакта килә, кешеләр алдында үзен тота белми, хуҗаны һәм аның кардәшләрен уңайсыз хәлгә куя: *Вакытсыз кунак – таракан. Көтелмәгән кунак – караңгы төн. Айда килгән аяулы, көн дә килгән кисәүле. Авыл кунагы айда-елда бер килә. Бирсәң, биреп ашый, бирмәсәң, талап ашый. Әрсез кунакка сый әрәм. Әрсез кунак оят өлешен алып ашаган. Иягәнде бер бигә, көн дә килә бу өйгә. Килә ява, килә ява, иягәнде бер болыт! Кайда коймак – шунда кунак. Сирәк бар, сөеклерәк булырсың. Тәмен тойган бу кортка, Тагын килгән бу йортка.*

Татар мәдәниятендә гореф-гадәтләр шактый күп. Аларның күбесе безнең көнгә кадәр килеп ирешмәсә дә, кунакка килгәндә күчтәнәч алу гадәте әле дә сакланып килә. Бу очракта күчтәнәчнең әһәмияте аеруча зур – хуҗага ихтирам күрсәтү һәм аны олылау. Нинди генә булмасын ул, зурмы әллә кечкенәме, өй хуҗасының күңеленә, күчтәнәч май булып ятыр. Нәкъ шушы фикер алда бирелгән мисалларда чагылыш тапкан: *Аш бирсәң, еракка бир, ни күргәнен әйтә барыр. Безгә кунак килми, Килсә китә белми, Күчтәнәчен бирми. Бүләге кыйбат түгел, яратуы кыйбатрак. Күчтәнәч күп булмас. Күчтәнәчне хуҗасы белән ашасаң тәмлерәк була. Үз күчтәнәчен ашаган гомерле булыр. Юл кунагы килә белсен, Күчтәнәчен бирә белсен.*

Кунак өстәле турында сүз алып барсак, татарлар элек-электән үк муллылыкны яраткан. Көтеп алган, иң сөйкемле кунаклары өчен барлык

малларны, сыйларны өстәлгә тезгәннәр. Әлбәттә, һәрвакытта да өстәл тулы ризык булмаган. Әмма шуңа да карамастан, хуҗа кеше кунак чакырудан яисә кунак кабул итүдән бер дә баш тартмаган. Иң мөһиме кунакчыл булу һәм кунагыңның күңелен күрә белү: *Аз да булса аш булыр, Кунак күңеле шат булыр. Коры ашъяулыкка дога булмас. Коры табынга кунак утыртмыйлар. Мәҗлес яме кунак белән, Табын яме коймак белән. Мәҗлес көй белән, Табын сый белән яхшы. Туемлык түгел, күңеллек. Түгәрәк өстәлнең түре юк. Ипи-тоз, якты йөз. Итем булмаса чәем бар, Чәй янына маем бар, Кунак кертер җаем бар.*

Шулай итеп, татар халкының мәкаль-әйтемнәреннән *кунак* концептының кыйммәти компоненты ачыклана. Мәкальләрдә кунак кешенең никадәр кадерле, иркә булуын һәм кунакның кеше өендә үзен ничек тотарга кирәклеге күрсәтелә. Ә кунак каршы алучының исә, ачык күңелле, юмарт булырга тиешлеге, кунаклы йортның хөрмәтле йорт булуы, андый йортка бәрәкәт иңгәнлеге искәртелә.

**ӘДӘБИЯТ**

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 т-да. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 1015 б.

**И. М. ГАЙФУЛЛИНА**
*Казан федераль университеты, Россия*

## ОНОМАСТИК МАТЕРИАЛНЫ МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮНЕҢ АКТУАЛЬЛЕГЕ

**Аннотация.** Статья посвящена разделу языкознания – ономастика. Показана актуальность использования ономастического материала на уроках татарского языка, обозначена связь ономастики с историей, географией, этнографией, социологией. Предложены примеры мероприятий, которые будут способствовать освоению теоретических понятий ономастики.

**Abstract.** The article highlights the actuality of onomastic material and names a number of reasons why onomastics, as an important and often used in practice branch of linguistics, should be studied in the lessons of the Tatar language; the connection of onomastics with history, geography, ethnography, sociology. Examples of activities that will contribute to the study of theoretical concepts of onomastics are proposed.

**Ключевые слова.** Ономастика, ономастический материал, лексикология, семантика, актуальность, семантика, ученики.

**Keywords.** Onomastics, onomastic material, lexicology, semantics, relevance, semantics, students.

Кешелек дөньясы предмет, процесс, сыйфат һәм күренеш атамаларының үзгәндә яши. Сүзләрнең күплеге һәм төрлелеге, яңа чор-буынның һәрдаим яңалыкка, яңа сүз барлыкка китерүгә омтылышы шәхескә, бер типтагы сүзләргә, аерым алганда, ялгызлык исемнәргә игътибар артуга этәргеч ролен үти. Кайсы гына халыкның атамалар дөньясын алып карасак та, әлеге өлкәнең шактый кызыклы һәм күпкырлы булуы игътибарны җәлеп итә. Халык өчен аеруча мөһим булган урыннар махсус географик атамалар – топонимнар – ярдәмендә билгеләнә. Географик атамалар, тарихи барыш дәвамында чагыштырмача аз күләмдә үзгәреш кичергән категория буларак, халыкның теле һәм тарихына кагылышлы әһәмиятле чыганак вазифасын да башкара.

Россиядә ономастиканы өйрәнү белән Н. Алифиренко, В. Бондалетов, М. Горбаневский, Л. Дмитриева, А. Суперанская, А. Ю. Филькова, татар галимнәреннән Г. Ф. Саттаров, Ф. Г. Гарипова, Г. Р. Галиуллина һ.б. галимнәр шөгыльләнә. Кызганыч ки, ономастиканың уку-укыту өлкәсендәге әһәмияте, аны мәктәп курсында өйрәнү проблемасы җентекле өйрәнелмәгән.

В. Бондалетов фикеренчә, ономастик материал аерым бер үсеш дәрәҗәсенә ия теләсә кайсы телнең мөһим һәм берәмлекләренең саны ягыннан иң күләмле өлешен тәшкил итә, шунлыктан лингвистиканың әлеге тармагы башка җәмгыяви һәм табигый фәннәр белән бергә өйрәнелергә лаек һәм тиеш. Бу очракта ономастик материалны укучыларга җиткерү өчен укытучының әзерлеге таләп ителә [Бондалетов, 2000: 17].

А. В. Суперанская үзенең *«Ялгызлык исемнәренең гомуми теориясе»* дип аталган хезмәтендә ялгызлык исемнәрнең төрле сөйләм һәм язма стильләрдә очравын ассызыклый. Әлеге тел берәмлекләреннән башка, мисал өчен, изложение, рецензия, хатны күз алдына китерү мөмкин түгел. Шул сәбәпле, укучылар мондый төр сүзләр запасын баетырга, аларның үзенчәлекләрен өйрәнергә, ялгызлык исемнәрнең охшашлыкларына һәм аларның төрләргә бүленеш принципларына төшенергә тиеш [Суперанская, 1973: 262].

Галимәнең фикерләрен дәвам итеп, Т. М. Майорова *«Туган якны лингвистик өйрәнүдә ономастика»* мәкаләсендә ономастик материалны җыю, әлеге эшне мәктәп һәм югары уку йортларында оештыру зарурлыгы хакында бәян итә. Тикшеренүче билгеләвенчә, *«ономастик язып алу ялгызлык исемнәрнең үзара бәйләнешен, бер-берсенә тәэсирен ачыкларга ярдәм итәчәк»* [Майорова, 2000: 44].

Мәктәп курсында *ономастика* сүзе *«гомуми белем бирүдә тел (рус теле) дәресендә җирле тел материалын тематик һәм лингвистик яктан тел дәресенә систематик һәм эзлекле кертү»* буларак аңлатыла [Благова, 1993: 17].

Күп кенә методистлар ономастик материалны тел өйрәнүне тирәнәйтү чарасы буларак кабул итәләр һәм аларны тел дәресләрендә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да куллану зарурлыгын билгелиләр. Бу эш төре мәктәптә укытыла торган башка предметлар, аерым алганда, география, әдәбият, җәмгыять белеме, тарих дәресләре белән бергәлектә алып барылганда, нәтиҗәсе югарырак булуга өмет бар. Мисал өчен, дәрестән тыш чара буларак *«Туган ягым тарихы», «Авылым атамасы этимологиясе», «Минем исемем нәрсә аңлата?»* һ.б. темаларга докладлар яклау үткәрергә мөмкин. Бу, бер яктан, балаларның сөйләм телен үстерү, ораторлык осталыкларын камилләштерү булса, икенче яктан, әлеге эш укучыларга фәнни эш язу күнекмәләрен бирә, ономастик материал белән тирәнтен таныштыру чарасы да булып тора. Моннан тыш ялгызлык исемнәрне шул рәвешле өйрәнү укучыда күзәтүчәнлек, кызыксыну хисләрен уята, чөнки бу очракта укучының шәхесенә, биографиясенә зур игътибар бирелә. Укытучыга, үз чиратында, әлеге алым шәхескә якын килеп укыту, индивидуальләштерү принцибын тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирүе белән әһәмиятле.

Масс-медиа, реклама, маркетинг өлкәләре бүгенге көндә шактый зур үсеш алган тармаклардан саналалар. Шунлыктан, үзенчәлекле кафе, ресторан, оешма атамалары да укучыларга ономастиканы өйрәтүдә мисал булып тора ала. Шуның белән бергә укучы үзенең тирә-юнендәге төрлелеккә игътибар итәргә, сүз һәм аның семантикасындагы бәйләнешне аңларга, билгеләрне анализларга да өйрәнә. Татар теле дәресләрендә я булмаса махсус оештырылган тел түгәрәгендә, мисал өчен, Казан шәһәрендә очраган кызыклы исем-атамаларны туплау, аларны анализлау, мәгънә бирелеше һәм сүз язылышындагы хаталарны табу, аларны төзәтү эше аеруча уңышлы булыр дип уйлыйбыз.

Йомгаклап, түбәндәге нәтиҗәләрне тәкъдир итәргә мөмкин: ономастика гомуми урта һәм төп белем бирү оешмаларында укытыла торган бик күп дисциплиналар белән үзара бәйләнештә тора. Ялгызлык исемнәрне укучыларга өйрәтү, аларның әһәмиятен аңлату мәсьәләсе бүгенге көндә актуаль, чөнки әлеге тел тармагын уңышлы үзләштерү – укучы шәхесенең төрле яклап үсешенә уңай йогынты ясаучы факторларның берсе, һәм аны уку-укытуда нәтиҗәле куллануның методикасын булдыру мөһим мәсьәләләрнең берсе булып кала.

**ӘДӘБИЯТ**

Алефиренко Н. Ф. О природе ономастической семантики// Ономастика Поволжья: тез. Докл. VIII междунар. Конф. Волгоград, 8-11 сент. 1998 г./ Отв. Ред. В. И. Супрун. Волгоград: Перемена, 1998. С.165-168.

Благова Н. Г. О концепции обучения русскому языку с учетом регионального компонента (Для средней общеобразовательной школы) / Н. Г. Благова, Л. А. Коренева, О. Д. Родченко // РЯШ, 1993. №4. С. 16-19.

Бондалетов В. Д. Русская ономастика. М.: Просвещение, 2000. 312 с.

Майорова Т. М. Ономастика в лингвокраеведческой работе // Русский язык в школе. 2000. №4. – С. 43-46.

Суперанская А. В. Общая теория имени собственного. М.: Наука, 1973. 366 с.

**А.А. ГАЛИЕВА,**

*МБОУ «Ямашурминская СОШ*

*Высокогорского муниципального района РТ», Россия*

*Науч. рук.: учитель русского языка и литературы*

*Р.К. Сибгатуллина, учитель тат. языка и литературы Р.Х. Сираева*

## ВАХИТ ХАКОВНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ТЕЛ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Аннотация.** Ученых, изучающих родной язык, много. Один из них – В.Х.Хаков. В этой статье освещается жизнь ученого, дается описание его научных трудов. Также показана роль ученого в развитии тюркологии.

**Abstract.** We have a lot of scientists which learned the Tatar language. F.H.Hakov is one of them. The article reveals the life of the scientist, gives an assessment of his scientific works. The role of the scientist in the development of Turkology is also shown.

**Ключевые слова:** Ученый, история языка, лексикология, стилистика, татарский язык

**Keywords:** Scientist, history of language, lexicology, stylistics, Tatar language

Татарстанның иң гүзәл җирендә Ямаширмә авылы урнашкан. Шул авылда туган гади татар кызы мин! Исемем – Әдилә. Бүгенге көндә Гафур Коләхмәтовның энесе Габделкаюм Коләхмәтов нигез салган, 100 елдан артык тарихы булган Ямаширмә гомуми урта белем мәктәбенең 11нче сыйныфында анам телендә белем алам. Чын татар кешесе үзенең туган телен, мәдәниятен, динен, гореф-гадәтләрен белергә һәм татарлык сыйфатларына ия булырга тиеш, дип уйлыйм. Ананың балага бирелгән иң зур бүләге – тел. Туган телен саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – һәр кешенең изге бурычы. Татар кешесе туган телен белергә, белмәсә, өйрәнергә, көчле, батыр, максатчан һәм гадел булырга тиеш.

Телнең тарихын, үсеш юлларын, матурлыгын, аһәңлеген аңларга безгә татар галимнәре ярдәм итә. Алар арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен Вахит Хаков алып тора. Ул – тюркологиядә исеме киң танылган галимнәребезнең берсе. Мин үземнең чыгышымда Вахит Хаковның тормыш

юлын, иҗатын һәм тел өлкәсендәге эшчәнлеген күрсәтүне максат итеп куйдым. Аның гыйльми хезмәтләре – татар халкының кадерле, кыйммәтле хәзинәсе. Тел белеме өлкәсендә яңа фәнни эзләнүләр өчен нигез булып тора.

Дөньякүләм танылган тел белгече, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының атказанган профессоры, Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Гуманитар Фәннәр Академиясенең академигы, Австралиядәге «Җир шарында Гуманизм һәм Гаделлек өчен» дигән Халыкара Рыцарьлар Конфедерациясенең әгъзасы һәм башка бик күп мактаулы исемнәргә лаек бөек шәхес Вахит Хөҗҗәт улы Хаков 1926нчы елның 16нчы августында Татарстанның Буа районы Күзби авылында туа. Башлангыч белемне үз авылында ала. 8нче сыйныфны күрше Килдураз авылында тәмамлый. Аннары Бөек Ватан сугышы башлана, 17яше дә тулмаган егет гаскәри хезмәткә алына. Япониягә каршы сугышларда катнаша, яралана. Монголиянең Чойбалсан шәһәрендә башланган хәрби поход аның өчен Кытайдагы Сары диңгез буенда тәмамлана. Хәрби хезмәттән кайткач, ул Тәтеш педагогия училищесын, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында аспирантура тәмамлый. 1960нчы елдан башлап, Вахит Хаковның фәнни- педагогик, методик эшчәнлеге Казан дәүләт университеты белән бәйле: ул татар теле кафедрасында ассистент, доцент, профессор, мөдир булып эшли. 1961нче елда “XX йөз башы әдәби теле тарихы” дигән темага кандидантлык, 1971нче елда “Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм аның стильләре үсеше” дигән темага доктырлык диссертациясен яклый. Карап торышка басынкы, тыныч кына, салмак кына күренгән бу кешегә каян килгән икән шулкадәр зур егәр- көч? Бу сорауга җавапны мин Вахит ага турында язылган истәлекләрдән укып таптым.

Бабасы Габделхак – Буа районының Күзби авылы мулласы. Аның китапханәсе була. Андагы Кол Гали, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г.Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый китапларын укырга өйрәнә Вахит. Үскәч кем булу теләге мәктәпкә кергәндә үк ачыкланган була инде- этисе шикелле укытучы булачак ул. 30нчы еллар шаукымы аларны читләтеп узмый, гаиләләрен туздырып ташлый, әнисе дә, этисе дә имам балалары- укытучылар. Язмыш аларны төрле якларга илтеп ташлый. Аларның берсе Урта Азиягә китеп югала. Икенчесе Оренбург якларында укып кайта. Вахит үзенең әбисе белән генә кала. Башта Күзбидә, аннары Килдураз урта мәктәбендә укыган малай баш-аягы белән иҗатка чума. Шул елларда басылган балалар газетасына беренче иҗат җимешләрен җибәрә. Басылып чыккан язмаларын саклый. Сугыш елларын да

үз җилкәсендә татый Вахит ага. Башта тылда хезмәт куя: колхозда да эшли, окобын да казый, урман да кисә. 1943нче елдан 1949нчы елга кадәр фронт юлларын уза. Туган ягының матурлыгы, хезмәт сөючән тату гаиләдә тәрбияләнү, укытучы әтисенең төпле киңәшләре, күңеленең сафлыгы, максат ачыклыгы профессор дәрәҗәсенә ирешүгә зур этәргеч бирә. Хыялы – фәнгә кереп китү. Вахит аганың хыялы тормышка аша. Татар әдәби теле тарихы мәсьәләләренә багышланган кандидатлык диссертациясе яклый. «Төрки телләрдә әдәби тел тарихы катлаулы һәм кызыклы. Аның тарихы бик борынгы заманнарга барып тоташа.Татар язмачылык тарихы мең ел ярым вакытны, аннан да элегрәк дәверне үз эченә ала. Тикшерүнең катлаулылыгы шунда, төрки-татар язма ядкарьләре төрле алфавитларда язылганнар. Алар арасында рун, уйгыр, гарәп, латин, әрмән, славян хәрефләре белән төрле жанрларда язылган матур әдәбият әсәрләре, фәнни һәм иҗтимагый-публицистик әдәбият, дипломатия, канцелярия документлары, эш кәгазьләре бар», – ди Вахит абый.

Вахит Хаков – «Татар әдәби теле тарихы» фәненә нигез салган галим. «Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар» (1965), «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» (1972), «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше. 20-30 нчы еллар» (1985), «Татар әдәби теле тарихы» (1993), «Тел – тарих көзгесе» (2003) хезмәтләре зур урын алып тора. Әдәби тел тарихын төрки дөньядагы халыкларның әдәби тел үсеше белән бәйләп карый. Үзенең хезмәтләрендә В. Х. Хаков Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», С. Сараиның «Гөлестан бит-төрки», Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» поэмаларының, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки, Гәбделҗаббар Кандалый, Газизә Сәмитова, Заһир Бигиев һ.б. язучылар әсәрләренең тел- стиль үзенчәлекләрен тикшерә, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Гафур Колахмәтов кебек әдипләрнең иҗатларын тел һәм стиль ягыннан өйрәнә.Татар әдәби теленең үсешен чорларга бүлеп өйрәнү аның хезмәтләренә нигезләнеп алып барыла.

«Татар әдәби теле тарихы» монографиясендә революциягә кадәрге татар әдәби теленең нормалары һәм матур әдәбият стиле тикшерелә, шул рәвешле, татар матур әдәбият стиле тарихи җирлектә тулаем өйрәнеп чыгыла.

Татар теле – борынгы язма телләрнең берсе. 2003 нче елда дөнья күргән «Тел – тарих көзгесе» дигән монографиясендә ерак дәверләрдән алып бүгенге көнгә кадәр, аерым чорларга бүлеп, татар теленең тарихи үсеш баскычлары тикшерелә. Борынгы язуга ия булган татар теленең үсеше Болгар дәүләте,

Алтын Урда чорындагы дәүләтләр, Казан ханлыгындагы телләр белән тыгыз бәйләнештә карала, аннан соңгы дәверләрдә татар әдәби теленең нормалары һәм стильләре арасындагы мөнәсәбәт яктыртыла. Тел нормаларын үстерүдә галимнәрнең, язучыларның тоткан урыны һәм язма ядкарьләрнең әһәмияте күрсәтелә. В. Хаков, рун язуларын укый белүче галим буларак, борынгы төрки телнең фонетик, график, орфографик, лексик-семантик үзенчәлекләрен, ул чорда ук стильләрнең аерымлануын ачып бирә, аларны, тарихи- чагыштырма ысул кулланып, хәзерге татар теле белән чагыштыра.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков фәнни тикшеренүләр алып барган тагын бер юнәлеш – татар теле стилистикасы. Ул – стилистика тарихына нигез салган галимнәрнең берсе. «Тел һәм стиль мәсьәләләре» (1961), «Татар теле стилистикасына кереш» (1963), «Стилистика һәм сүз сәнгате» (1979), «Татар әдәби теле. Стилистика» (1999) хезмәтләрендә В.Х.Хаков беренче мәртәбә функциональ стильләрне өйрәнү эшчәнлеген башлап җибәрә. Татар телендә матур әдәбият теле, иҗтимагый-публицистик тел, фәнни яки фәнни-популяр әдәбият теле, эш кәгазьләре теле, эпистоляр яки хатлар теле стильләренең булуын дәлилли, аларга хас үзенчәлекләрне аерып чыгара. В.Х. Хаковның стилистика өлкәсенә караган хезмәтләре фонетик, лексик, грамматик стилистиканы өйрәнү ягыннан да әһәмиятле. Аларда галим телдәге лексик-фразеологик, фонетик һәм грамматик чаралардан дөрес, нәтиҗәле файдалану юлларын ачыклый.

1990 нчы елларда татар телен латин графикасына күчерү турында сүз чыккач, Хаков В.Х. беренчеләрдән эшкә тотынган. Ул «Телен белгән ил ачар» китабында латин графикасының безнең тел үзенчәлекләренә бик туры килүе турында яза.

Вахит абыйның хезмәтләре әдәби тел тарихы, тарихи стилистика белән генә чикләнми, ул бүгенге артистлар, язучылар тәрбияләүгә дә өлеш керткән галим. Хаков заманында театр училищесында укыта, ә Татарстан радиосын тыңлаучылар аны озак еллар «Тел күрке – сүз» тапшыруларыннан ишетеп беләләр. Филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллин: «Тел күрке – сүз» фәнни яктан әтрафлы, формасы ягыннан мавыктыргыч итеп алып барыла. Монда тапшыруларның фәнни консультанты В. Хаковның өлеше зур», – дип яза.

«Тел бакчасы зур, андагы хәзинә бәһа җитмәс кыйммәтле булгач, билгеле, бакчачылар, аның сагында торучылар үзләре дә гадел, көчле, зирәк булырга тиештер. Ватан сугышы утларын кичкән Вахит ага Хаков- тел сагында торучы солдат», – дип яза шагыйрь Равил Фәйзуллин.

Вахит Хаков эшчәнлегенең кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Ул күпләргә үрнәк булырлык галим, җәмәгать эшлеклесе, тирән фикер иясе булган. Яшь буын Вахит Хаковның фәнни эшчәнлеген өйрәнеп һәм хөрмәт итеп яшәсә, милләтебезнең киләчәге якты булыр.


**ӘДӘБИЯТ**

Галиәхмәтова Айсылу. Тел белгән ил ачар. – Мәйдан. – №10. – 2004.

Фәйзуллин Равил. Тел сагында тора солдат. – Казан утлары. – № 8. – 2006.

Хаков В.Х. Әдәби тел тарихы. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993.

Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2003.



**И.И. ГАЛИМБИКОВА**

*Казан федераль университеты, Казан*


# ПЕДАГОГИКА ҺӘМ ПСИХОЛОГИЯНЕҢ ЗАМАНЧА АЛЫМНАРЫ ҺӘМ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ


**Аннотация**. В статье обсуждаются вопросы преподавания педагогики и психологии в современной образовательной системе, конкретизируются основные проблемы в этом направлении.

**Abstract**. The article discusses the issues of teaching pedagogy and psychology in the modern educational system, concretizes the main problems in this direction.



**Ключевые слова**: Педагогика, психология, актуальные вопросы, татарский язык

**Keywords:** Pedagogy, psychology, current issues, tatar language


XXI гасырда укучыларга куйган таләпләрне шактый артканын һәм үзгәрүен күрә алабыз. Бу, әлбәттә, замананың үзгәрүе: техниканын алга китүе, мәктәпләрдә БДИ бирү, мәктәпне тәмамлагач, югару белем йортына кергәндә баллар нәтиҗәсендә конкурс үтү һ.б. Тик шуны да истә тотарга кирәк, югарыда әйтеп үткән сәбәпләр, заманча алымнар ярдәмендә укытуны да тәлап итәләр.

Бүгенге көн вәзгыятен күз алдында тотсак, татар телен ничек итеп саклап калып, аның мәктәпләрдә ничек итеп укытырга дигән сораулар килеп баса. Әлбәттә, бу бүген генә күтәрелгән сорау түгел. Татар телен укыту программалары астында бик күп галимнәр эшләгән, китаплар, методик кулламмалар чыгарылган. Тик, шуңа карамастан, бу эшләр 100% дөрес төзелгәнме дигән сорау килеп баса. Чыннан да, әлеге программалар төзелгәндә татар телен төрле милләт балалары өйрәнгәнен, аларның телне төрле дәрәҗәдә белгәнлекләре тулысынча искә алынганмы? Ничек кенә булмасын, вакытны кире кайтарып алып булмый, безгә киреснчә, яңа алымнар уйлап табарга кирәк, туган телебезне өйрәтүне китапта бирелгән грамматикага гына таянып, аны

такта янына чыгып балаларга аңлату белән генә чикләнмәскә кирәк. Без техниканың бик яхшы үсеш алган чагында яшибез. Нинди генә программалар, нинди генә мөмкинлекләр юк бит бүгенге дөньяда. Иң бернче баскычны алсак, ул 1-2 сыйныф укучысының татар телен өйрәнә башлавы. Бүгенге көнне алсак, кызганычка каршы, саф татарча белгән балалар бик аз, татар гаиләләсеннән булган балалар да аларны рус телле кешеләр арасында булганлыкларыннан күбрәк шул телдә аралашуларын, фикер йөртүләрен беләбез. Шуңа күрә, беренче баскычны татар телен белмәгән, яисә белем дәрәҗәсе түбән булган балаларны алабыз. Психологик, педагогик яктан килсәк тә, 7-8 яшьлек балага китап укып белем алуны кызык түгеллеген әйтә алабыз. Чөнки, бу яшьтә балалар китаплар белән эшли генә башлыйлар, алар аны үзәре укысалар да, аларга башка кеше укып бирсәдә, башларында мәгълүмат бик аз кала, кайбер очракларда калмый дип тә әйтергә була. Шуңа күрә, бу очракта, барлык процессны китапка кайтарып калу отышлы түгел. Татар телен белмәгән балага, иң беренче чиратта сөйләм телен өйрәтү кулайрак буладыр, ә инде аннары язуга, кагыйдәләргә күчсәк тә була. Телне өйрәтүдә шулай ук балаларга сүзләр ятлату да уңай вариант түгел, чөнки күп очракларда ул ятлау процессының нәтиҗәсе бер-ике көнгә генә бара ала. Балаларга элементар әйберләрне өйрәткәндә кызыксындыру уятырга кирәк. Чөнки кызыксыну шул вакытта уянмаса, тел өйрәтүнең нәтиҗәсе юк дигән сүз. Ул укучының аңында автоматик рәвештә нигатив уйлар барлыкка киләчәк. Мин бу телне аңламыйм, мин аны өйрәнә алмыйм һәм шуның нәтиҗәсендә ул миңа кирәкми... Миңа калса, 1-2 сыйныфта китаплар күбрәк укытучыларга кирәк. (буталмыйча, программа буенча бару өчен). Иң уңышлы вариантларның берсе дип, дәресне уен форматында алып бару. Дәрес барышында җырлар, табышмаклар әйтү. Балалар белән диалоглар төзү, балалар белән татарча мультфильмнар карап аларны анализлау, кроссвордлар (башваткычлар) куллану һ.б. Бүгенге көндә “Шаян” балалар телеканалы бик уңышлы үсеш ала, һәм киләчәктә укыту өлкәсенә караган проектлар да чыгу бик ихтимал. Бәлки махсус тапшыру чыгарып, укучылар аны өйләрендә карап, ә мәктәптә анализлый торган да булыр. Бу интерактив дәресләрнең бер алымы булып үсеп китәр иде. Укучыларның ныклы базалары булса, грамматика өлешен дә үзләштерү күпкә җиңелләрәк булыр иде.

Олырак сыйныфларга күчсәк, бүгенге көн яшьләренең глобаль проблемалары ул – үз вакытларының күп өлешен телефонда, интрнетта үткәреп, кулга китап алып карамау. Әдәби әсәрләрне авырлык белән үзләштерү. Алда әйтеләчәк фикерне даими рәвештә һәм барлык очракларда кулланып

булмаса да, кайбер материалларны үзләштергәндә ул бик файдалы алым дип әйтеп була. Программада булган әсәрне театрга барып карау. Моның белән укучылар әдәби әсәрне генә үзләштермичә, рухи азыклык та ала алалар. Электрон (аудио) китаплар барлыкка килү, бу шулай ук әдәби әсәрне укуда зур җиңеллек бирә.

Замана яшьләренең таләпләренә буйсыну җиңел түгел. Тик төрле яктан килеп карасак, чыгу юлын табып була. Бүгенге көндә традицион алымнардан читкәрәк китеп, заманчаларын карарга кирәк.

**ӘДӘБИЯТ**

Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогик технологияләр:Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен уку ярдәмлеге:2 китапта.2нче китап/ Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. Казан: Мәгариф, 2008. 368 бит.

Харисов Ф.Ф. Татар теленең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге: лингводидактик аспект // Прошлое, настоящее и будущее татарского языка: лингводидактический аспект. Казань, 2017. 280 с.

**Г.Н. ГАЛИУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ЛУИЗА ЯНСУАР ИҖАТЫНДА АВТОЛОГИК ҺӘМ МЕТАЛОГИК АЛЫМНАР

**Аннотация.** Луиза Янсуар является представителем «новой волны» в татарской литературе. Особенностью ее творчества является стиль и язык ее стихотворений. Автор в своих произведениях часто использует автологические и металогические приемы.

**Abstract.** Louise Jansoir is a representative of the "new wave" in Tatar literature. A feature of her work is the style and language of her poems. Autological and metalogical techniques can often be observed in her works.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикология, Луиза Янсуар, стиль, язык творчества, металогия, синоним, антоним, метафора, метонимия.

**Keywords:** Tatar language, lexicology, Louise Jansoire, style, language of creativity, metalogy, synonym, antonym, metaphor, metonymy.

Язучы, яки шагыйрьнең профессиональ осталыгы, ул иҗат иткән әсәрнең ни дәрәҗәдә сәнгатьле һәм идея-эстетик яктан кыйммәтле булуында. Бу иң беренче чиратта аның теленә бәйле. Тел – әдәбият дөньясында гаҗәеп корал. Ә инде шагыйрьнең талант иясе булу-булмавы аның телдәге поэтик хәзинәләрдән оста файдалана белүенә бәйле.

Һәрбер талантлы сүз остасы, безнең очракта Луиза Янсуар, сүз белән сурәт ясауда аңа кадәр һичкем белмәгән яңа юллар ачып җибәрә. Шуңа күрә

сүзнең тасвирлау мөмкинлеген өйрәнүе фәкать һәрбер иҗат кешесенең үзенә генә хас индивидуаль иҗат стиленә бәйле рәвештә генә карарга мөмкин.

Шагыйрәнең иҗат үзенчәлеген ул иҗат иткән чордан, төрле социаль вакыйга һәм сәнгать әсәрләренә карата җәмгыятьтә азмы-күпме ныгып алган төрле карашлардан аерып карау мөмкин булмаганлыктан, телнең табигатендә дә бу күреншеләр чагылмыйча кала алмый. Ләкин боларның һәммәсе дә сүз-сурәттә аерым бер шәхеснең-шагыйрьнең күңел күзе аркылы, аның сурәтле фикерләү үзенчәлеге аша үтеп чагыла.

Еш кына әдәби әсәрләрнең тел тукымасында башлыча стилистик төсмерсез, гади сүзләр белән генә язылган, ләкин яңгырашы укучыны дулкынландырырга мөмкин. Сүз әсәр теле тукымасында, ягъни билгеле бер идея-эстетик максаттан чыгып төзелгән сәнгатьле сөйләмдә, үзенең битарафлыгыннан чыга һәм сүз-сурәткә әверелә. Шагыйрь яки әдип, үзе тасвирлый торган күренеш-вакыйгаларга карата нинди мөнәсәбәттә булуына һәм билгеле бер фикерне үзенчәлекле итеп әйбер бирә белүенә карап, сурәт ясауда нигез булган сүзне төрле контекстта – күп төрле сүзләр белән янәшә куллана: сүз берничә мәртәбә кабатлана, яки үзе шикелле гади сүзләр белән уратыла; омонимдаш сүзе, я синоним пары, яки антонимы белән янәшә кулланыла; сүзнең этимологиясе аңлатыла. Бу вакытта сүзнең мәгънә эчтәлеге я киңәя, я тарая, я түбәнәйтелә яки бер дә үзгәртелмичә генә авторның сәнгатьле фикерен әйтеп бирү өчен җайлаша [Хаков, 1999: 93].

Луиза Янсуарның иҗатына килгәндә, шагыйрә үзенең шигырьләрендә автологик һәм металогик алымнарны күп һәм оста куллана. Әлеге терминнарның билгеләмәләрен белик.

Автология (грек теленнән “аутос” - үзе, “логос” - сүз) – сүзнең яки сүзтезмәнең поэтик әсәрдә турыдан-туры мәгънәсендә кулланылуы. Автологик алымнарга антоним, синоним, омоним һәм кабатлаулар керә. [Зәкиев, 2016:167]

Әлеге алымнарның берничә мисалын карап китик.

*Мин тамырым белән Җирне кочам,*
*Җаным белән иңлим Күкләрне.*
*Бер мизгелдә тоям йөрәк аша*
*Еллар, чорлар шаулап үткәнне.*

“Син Күкләрне колачладың...” шигыренең әлеге строфасында шагыйрә ике төрле антоним белән файдалана: саф антоним һәм контекстуаль антоним. Тамырым- җаным – контекстуаль, ә Җир-Күк – саф антонимнар булып килә.

*Ул якта сагыну нәкъ синең төсеңдә –*
*Кырыс та, назлы да...*

*Кимеми, көчендә.* (“Тыюлык”)

*Кырыс та, назлы да* капма-каршылыгын кулланып, автор үзенең сагынуын шулай билгели.

Бер үк әйбер яки билгене, бер үк күренешне, бер үк эш яки хәлне белдерә торган ике яки берничә сүз синонимнар дип йөртелә. Чынбарлыкта бер үк әйбернең, күренешнең, эш яки хәлнең, гадәттә, берничә үзенчәлеге була. Синоним сүз шул үзенчәлекләрнең кайсы да булса берсенә нигезләнә. Синонимнар да берничә төрле була: контекстуаль синонимнар, тел синонимнары, эмоциональ-экспрессив синонимнар, стилистик синонимнар, идеографик синонимнар. Соңгысы – мәгънә төсмерләре белән аерылып торган синонимнар. Әлеге синоним төрләрен Луиза Янсуар иҗатында да күреп була.

*Йөрәгемә яңа җырлар кайта,*

*Кайта шатлык, кайта яңа төсләр.*

*Без офыкка китеп күмеләбез,*

*Җиргә аяк атлаганчы көзләр.*

“Сиңа” шигырендә автор *яңа җырлар – шатлык – яңа төсләр* контекстуаль синонимнарны файдалана.

*Карыйм да сиңа... елмаям,*

*Карыйм да... көләм:*

*Мин сине моннан киткәч тә*

*Сөярем беләм.*

“Очыш” шигырендә шулай ук синонимнарны күрәбез: *елмаям – көләм.*

“Кичерегез” шигырендә автор *тарлык–коллык* контекстуаль синонимнарны файдалана.

*Кичерегез мине! Торам башым иеп,–*

*Булалмадым җир-туфракка алтын орлык.*

*Кичерегез! Мин дә, бәлки, гаепледер,*

*Бу дөньяда әле һаман – тарлык, коллык.*

«Исемсез» шигыренең беренче юлында автор *дус-иш* синонимик парны куллана.

*Дуслары – дус, ишләре – иш иде*

*Әле кичә генә дөньяда.*

*Исем тапмыйм бүген берсенә дә,*

*Әверелеп җансыз кыяга,*

*Басып торам кыл уртада...*

Автор омонимнарга да мөрәҗәгать итә.

*Күңелем назга сусаган –*

*Күбәләктәй очына.*

*Хисләрем сүтелеп киткән,*

*Чыгалмыйм һич очына.*

“Сусадым” шигырендә очына (фигыль) – очына (исем) омонимнары оста кулланылган.

Луиза Янсуар шигырьләрендә кабатлау алымын бик яратып куллана. Берничә мисал карап үтик:

*Син белгәнсең килеремне,*

*Көткәнсең– көн, көткәнсең – ай.*

*Ел көткәнсең...*

*Йөзең шуңа*

*Саргаюлы, моңсу бугай.*

*Сыңар йөзек...*

*Саклагансың...*

*Сакладым бит сине мин дә,*

*Кадереңне белер өчен*

*Килмәсәм дә никтер җиргә.*(“Месса”)

[Янсуар, 2005:67]

Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылуы барлык телләргә дә хас. Сүзләрдән аның үзенә генә булмаган мәгънәдә файдалану ике төрле төшенчәне куллану белән бергә бара. Сурәтләүдә менә шушы төшенчә барлыкка килү, укучы аңында аеруча көчле тәэсир калдырып, сүзнең образлы яңгырашын китереп чыгара. [Бәширова,1974: 78]

Сүзләрне образлы итеп, күчерелмә мәгънәдә куллану металогик алым дип атала. Әгәр дә без барлык сүзләрне дә бер, бары төп-төгәл мәгънәсендә генә куллансак, безнең фикер йөртүебез дә шундый ук яссы, бер мәгънәле генә булыр, иҗади булмас иде. Металогик алымнарга чагыштыру, метафора, эпитет, метонимия, синекдоха, гипербола, юмор, ирония, аллегория керә. Металогик алымнарга Луиза Янсуар еш һәм яратып мөрәҗәгать итә. Берничә мисал карап китик.

*Алар өчен телең дә юк синең,*

*Илең дә юк...*

*Сүндер төшләреңне!*

*Яшьлек хыялыдай*

*Беркатлырак*

*Булганга, ул бик тиз өшәндеме–*

*Безнең ирек?*

(«Онытмаска»)

*Уяулыкны безнең канга*
*Язмыш үзе учлап салган,–*
*Күпме яулар кичкән баштан,*
*Күпме эзләр җанда калган.*

(«Кайгы»)

*Үләннәре, көйләп, каршы йөгерә,*
*Чишмә булып җаны тибәме?*
*Туфрак өне онытылмый ласа,*
*Оныттырмый да кем икәнне...*

(«Балачак тавы»)

Әлеге мисалларда метафоралар кулланылган.

*Бер шагыйрә ханым болай әйтте:*
*«Шагыйрь тиеш җүләр булырга!*
*Ахмак түгел, ә хыялый җүләр,*
*Җырга гашыйк җүләр булырга...»*

(«Бер шагыйрә болай әйтте...»)

Әлеге өзектә Луиза Янсуар “хыялый җүләр” оксюморны куллана.

*Ышанмыйм мин купшы сүзләргә,*
*Алдашучан зәңгәр күзләргә.*
*Үпкә белән миңа карама,*
*Тимә йөрәктәге ярама.*

“Ышанмыйм мин” шигыренең беренче юлларында без “зәңгәр күзләр” метонимиясен күрәбез.

*Тум-тулы ай, тум-тулы.*
*Югыйсә бит инде онытылды:*
*Ул көбә күлмәкне киюләр*
*Һәм хәнҗәр йөзендә биюләр...*

(«Сөембикә»)

Әлеге өзектә тум-тулы ай эпитет булып килә. Гомумән, Луиза Янсуарның шигырьләрнең күбесендә эпитетны күреп була.

*Алтын алма кулларымнан*
*Тәгәрәде учларыңа.*
*...Тетри-тетри сыендым мин*
*Уттай кайнар кочагыңа...*

«Алтын алма» шигырендә автор яраткан кешесең кочагын утның кайнарлыгы белән чагыштыра.

Луиза Янсуарның иҗаты бик кызыклы һәм үзенчәлекле. Эш барышында Луиза Янсуар шигырьләрендә автологик һәм металогик алымнары кулланылуы тикшерелде һәм анализланды. Автор иҗатында әлеге алымнарны бик оста һәм күп куллана. Иң еш автологик алымнардан антоним, синоним һәм кабатлау алымнары, ә иң еш кулланылган металогик алымнардан – метафора, эпитет, метонимия, чагыштыру.

**ӘДӘБИЯТ**


Бәширова И.Б. Сүз белән сурәт ясау. Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. 176 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле. Казан: Тат. кит. нәшр. 1999.

Янсуар Л. Болан кызы: шигырьләр. .Казан: Мәгариф, 2005. 159 б.



**Д. Р. ГАЛЛӘМОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


## ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИК КАТЛАМНАРЫ (1920-1930 НЧЫ ЕЛЛАР ПОЭЗИЯСЕ МИСАЛЫНДА)


**Аннотация.** В статье анализируется лексика поэзии 1920-1930 годов, определяется тенденция их развития. Определена роль и особенности использования выразительных средств в текстах стихотворений.

**Abstract.** The article deals with the lexical layers of the Tatar language. Analysis of trends occurring in the vocabulary of poetry 1920-1930-ies. The course of poetic creativity of speech layers is monitored. Define the purpose of the application of synonyms, antonyms, obsolete words.



**Ключевые слова:** лексик катламнар, 1920-1930 нчы еллар шигърияте.

**Keywords:** lexical layers, poetry of the 1920s and 1930 s.


Сүзләрнең кулланылышы телнең үзенә хас стилистик кануннарына нигезләнә. Кулланылыш ягыннан сүзләр төрле катламанардан тора. Сөйләмдә сүзләр күптөрле мәгънәләргә һәм мәгънә төсмерләренә ия. Бу – контекст, андагы эчтәлек һәм сүзнең нинди сфераларда кулланылуы белән бәйләнгән. Сүзләрдә төрле стилистик бизәкләр барлыкка килә. Кулланылыш активлыгы (дәрәҗәсе) ягыннан сүзләр актив һәм пассив катламнарга бүленә. Сүзләрнең кулланылышы телнең үзенә хас кулланылыш кануннарына нигезләнә. Лексик яктан сүзләр төрле катламнардан тора. Алга таба без аларны аерым карап китәчәкбез.

1) Синонимнар төрле мәгънә төсмерләре бирүдә, стиль үзенчәлекләре барлыкка китерүдә, тел сурәтләү чараларын булдыруда әһәмияте зур. Алар сөйләмнең төгәллегенә, нәфислегенә һәм сәнгатьчә яңгырашына ирешүдә әһәмиятле чара булып торалар, эчтәлекне төгәл һәм дөрес чагылдыруга ярдәм итәләр, телдән файдалану мөмкинлекләрен арттыралар. Мисалларны карап китик, М.Гафури «Аяк» (1919) шигырендә «Җип-җиңел, йомшак басып атлаулары нинди *хозур*» дип яза. Автор махсус “хозур” сүзен кулланган, чөнки киләсе юлда «сокланыр» сүзе белән алар аваздашлык, рифма тудыралар. Өстәвенә, *хозур* сүзе үзенең синонимы булган *күңелле* сүзе белән чагыштырганда, эмоциональлерәк, аның мәгънәсе таррак. Хатын-кыз атлауларын тасвирлау өчен автор нәкъ шул сүзне сайлаган. Үзенең «Аяклары...» (1920) дип исемләнгән икенче шигырендә автор хатын-кызның аякларын «*Нәфис, матур* шушы ике аяк...» дип тасвирлый. Бу очракта тәэсирне көчәйтү максатыннан, аякларны истә калырлык тасвирлау өчен автор ике синоним сүзне янәшә кулланган. Аның берсе (матур) нейтраль төсмерле булса, икенчесе (нәфис) эмоциональлекне күбрәк белдерә. Шул ук шигырендә шагыйрь «аның йөзен» *фәрештә, оҗмах хуры* синонимнары ярдәмендә бәяли.

Кайбер очракта аерым бер сүзләр контекст эчендә генә синонимик рәт төзиләр. Мондый сүзләрне контекстуаль синонимнар дип атыйлар. Үз чиратында контекстуаль синонимнар да градация күренешен хасил итә. Алга таба шундый мисалларны карап китик:

*Изге, ак, пакъ* юл белән барганда булсын җан фида,
Шул вакытта алсаң бу пакъ җанымны, әй хода!

*М. Гафури. Изге юлда (1919)*

2) Антонимнар капма-каршы мәгънәне белдереп, авторлар тарафыннан төрле максталар белән кулланыла. Алар күренеш яки әйберләр арасындагы каршылыкны күрсәтә; хисләрнең, тормышның, мизгелнең катлаулы булуын белдерә; фикерне көчәйтү өчен дә кулланыла. М.Гафуриның «Барчасыннан матур син» (1920) шигырендә күрәбез:

*Күккә* бактым: *ай, кояш* һәм *төнге йолдызлар* матур,
*Җиргә* бактым: монда йөргән хур кебек кызлар матур.

Әлеге өзектә күк – җир һәм ай, төнге йолдызлар – кояш антонимик парлаша. Күргәнебезчә, бу шигырьдә антитеза алымы кулланылган. Җир белән кук үзара антонимнар икәнелеге ачыктан-ачык күренә, шунысы кызыклы – үзе антонимик пар составында килүче берәмлек (күк) эчендә яңа бер капма-каршы мәгънәдәге сүзләр кулланылган (ай, төнге йолдызлар – кояш). Бу очракта

йолдызлар һәм кояш контекстуаль антонимнар булып килә, чөнки, беләбез, кояш ул – үзе дә йолдыз.

3) Искергән сүзләр дип инде көндәлек тормышта бөтенләй кулланылмый торган яисә төрле лингвистик һәм экстралингвистик сәбәпләр аркасында актив кулланылыштан чыккан сүзләрне билгелиләр. Алар шагыйрьләр тарафыннан төрле максатлар белән кулланыла. М. Гафури, Н.Баянның 1920 һәм 1930 еллар иҗатлары мисалында карап киттек. Нигездә, искергән сүзләрне куллану шагыйрьләрнең 1920 еллар иҗатларына хас. М. Гафурида: «Шәүләсе» (1920) шәүләсе алдымда баскан – нәкъ илаһи бер *санәм* (сүрәт), мин шулай *тәгъзый итәм* (хөрмәт итү, олылау); «Җәмал туташка» (1921) – алдыгызга килгән *манигъларны* (тоткарлык, киртә); «Монда, анда» (1921) – анда – тар *мәһбит* эчендә ( төшә торган урын); «Болар кемнәр?» (1922) – болар *хәмлә иткән* һәрбер әйбер (һәҗүм иткән); «Гаҗәпме?» (1922) – *вөҗүдне* чолгап алган кайгы-хәсрәт (гәүдә); «Ертылган Сәхифәләр» (1923) – миңа «иман» *тәлкыйн* кылдылар (аңлатып бирделәр), сиңа *тәкъдир* шулай кушкан (язмыш), берәм-берәм *тәкрар* ачтылар (кабат). 30 нчы елларга күчкәндә инде аларның пассивлашуы күзәтелә. Мәсәлән, Нур Баянда тормыштан төшеп калган сыйныф атамасын күрәбез: Гасырлар буе *паннар* буды, – / Газап белән үлде үбегез; *Паннар* өчен бакча үстердегез / Күз яшьләрен коеп төбенә; Без беләбез сезнең каныгыздан/ *Шляхталар, паннар* симерде («Без бәхетле хәзер», 1939).

4) 1920-1930 еллар аралыгында зур катлам лексика барлыкка килә. Яңа сүзләр тормыштагы, көнкүрештәге үзгәрешләрне чагылдыралар, шул үзгәрешләр белән бергә туалар. Яңа сүзнең гомере төрлечә: кайберләре аларның бүген барлыкка килеп иртәгә юкка чыгарга, икенчеләре, тора-бара яңа сүз булу төсмерен ташлап, төп сүзлек хәзинәсенә күчәргә мөмкин.

1. Телдә күптән кулланылып килгән сүзләргә яңа мәгънә өстәү юлы белән ясалган неологизмнар (семантик неологизмнар):

Н. Баянның «Ант» (1939) исемле шыгыренең һәр строфасында диярлек чорга үзенчәлеге булып торган лексика кулланылган – мин *члены* бөек *партиянең*, өй эчендә *Ильич уты* яна, *партиямә* хыянәт итмәдем, *карьера* өчен *билет* йортмәдем, *революция* чылбыры, илне саклый торган *Сталинчы* уяу *Чека* бар. «Атта килә комсомолец» (1939) – атта килә *комсомолец, комсомолец* ат сикертә.

Индивидуаль неологизмнарны Хәсән Туфан иҗатында бик күпләп очратып була. Эшче хиләрен ул футуристларга, имажинистларга ияреп, татар телендә яңа сүзләр аша җиткерә, «словотворчество» белән мавыга. Мисалларны карап китик:

«Еллар итәгендә» (1925) – Көн *кичәйгәч* / мич астыннан өйгә төн чыга; Язмыш – *марткы* Идел; Йон тәпиле авыл / *Чүкечләнә* ялкын-төтендә; *Динамитла* коллык теракләрен. «Барабыз» (1920) – *Барабанла* / Безнең көн маршын.

5) 1920-1930 елларның тагын бер характерлы үзенчәлеге булып язма әдәбиятта һәм вакытлы матбугатта ***җанлы сөйләм*** стиленең активлашуы тора. Гади сөйләм сүзләренә генә хас лексик-семантик үзенчәлекләр бар. Гади сөйләм сүзләре эмоциональ-стилистик төсмерләр, телдәге мәгънә нечкәлекләрен бирүгә ярдәм итәләр һәм җанлы сөйләм күренеше булып торалар. Гади сөйләм сүзләре, әдәби тел сүзләренә параллель рәвештә аларның бер төре буларак, үзләренә хас мөстәкыйль мәгънәдә кулланыла. Бу яктан алар әдәби телгә якынаялар. Мәсәлән, М. Гафури «Ат» (1933) – Башын иеп, күзен *мөлдерәтеп* / Торуы...; «Болытсыз күк күкрәгәндә» (1932) – Шәһәр шаулый / Халык *гөж килә*; «Диңгез буенда» (1932) – Гайрәт бетеп артка *дүнмәде* (төшмәде), Тауның битен сөеп һәм иркәләп / Ничек *куштанлана, тулгана*; Н. Баян «Москва төне» (1939) – Чәчәк кебек зәңгәр күзләреңне / Син *текәдең* минем күземә; М. Җәлил «Ударниклар» (1930) – Кыенлыклар безне *камап алгач*; «Тирга» (1933) – Кояш, *малай*, / бик төз атучы икән, / Нурын төртте / туры йөрәккә; Х.Туфан «Уралда» (1927) ...Күрәм, сизәм, *кызлар-хәчтерүшләр*, / Уегызны... күзегез аша да.

Чор үзенчәлеге булган алынма сүзләрне әдәби телдән читләштереп, халыкның җанлы сөйләменә җайлаштырып әйтү дә гади сөйләм сүләрен куллануның бер төрен тәшкил итә. М.Гафуридагы ат айлык *жалунья* дә сорамый («Ат», 1933); «Элекке "ул" инде кеше булды» (1933) – "Менә сиңа себерке, пумала, / Ялгаш, көянтә һәм *бидрәләр*; Х. Туфан «Башлана башлады» (1927) – Шулмы *эрбәлүтсе*? (революция) / Тфу! / Җыен кәгазь яка – *кәмитит*! (комитет), Җыен буржуй / *Устау* (устав) йөретә. / Ә без кайда?, *Трибогы* (тревога) бу! – диде Хабул абый.

Чит телдән ачык күренеп торган алынма сүзләр варваризм атамасы астында йөри. Мәсәлән, Һ. Такташның «Кыр казлары» (1926) шигырендә лирик герой һавадагы кыр казларына карап:

«Еллар үтә – менә күрерсез:

Фәнне эшкә җигә белербез,

Күктә *гулять итеп* йөрербез!..» – ди. Шуны ук үзенең «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә (1926) дә кабат тудыра: «Урам буйлап җил бер исрек белән / *Гулять итеп* кайтып килә иде...» Варваризм күренеше телне боза, ләкин әдәби

әсәр тукымасында ул аны җанландыра, тәэсир көчен арттыра, әлеге очракта Һади Такташ шигъриятенең үзенчәлеге, билгесе дә булып тора.

Гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, 1920-1930 еллар поэзиясе теле гаять үзенчәлекле һәм яңарышларга бай тел. 20 нче елларда татар теленең эчке мөмкинлеләреннән файдалану, халыкара сүзләргә мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә меңнәрчә уңышлы яңа сүзләр, яңа берәмлекләр барлыкка килә. Әдәби тел шулар хисабына байый, үзгәрә. Билгеле, әлеге үзгәрешләр тарихи-иҗтимагый шартлар белән бәйле була.

**ӘДӘБИЯТ**

Әхәтов Г. Х. Татар теленең лексикасы. Казан: Татарстан кит. нәшр., 1995. 93 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

Хаков В. Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

Курбатов Х. Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. Казан: Мәгариф, 2002. 199 б.

**Д.Р. ГАРИПОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

# МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ ТЕКСТЛАРЫНДА ФОНЕТИК ВАРИАНТЛЫЛЫК

**Аннотация**. В данной статье рассматриваются слова, которые имеют фонетические варианты и часто используются в средствах массовой информации в разных стилях. До сих пор не установлено, какой из этих фонетических вариантов слов является нормой. В связи с этим, на страницах газет и журналов допускаются неточные значения, орфографические ошибки. В статье указаны причины и предложены пути решения данной проблемы.

**Abstract**. This article discusses words that have phonetic variants and are often used in the media and in different styles. It has not yet been determined which of these phonetic variants is correct to date. In this regard, on the pages of Newspapers and magazines a lot of words with the wrong meaning and spelling errors. Therefore, we have found the causes and solutions to this problem of linguistics in this article.

**Ключевые слова:** фонетика, литературная норма, вариативность, вариантность, орфография, фонетические варианты, орфографические варианты.

**Keywords:** phonetics, literary norm, variability, spelling, phonetic variants, spelling variants.

Хәзерге татар телендә орфоэпик һәм орфографик вариантлылык еш очрый. Аларның кайберләре әдәби әйтелеш нормаларына зыян сала. Орфография тарихын өйрәнгән Х.Х. Курбатов: «Әдәби әйтелешне бозып сөйләү ике төрле сәбәптән барлыкка килергә мөмкин, дип яза. – Беренчесе – әдәби әйтелеш белән дөрес язылыш (орфография) арасында зур гына аерма булуда (сөйләүче авазларны әдәби әйтелешкә түгел, кәгазьдә язылганча әйтә); икенчесе – сөйләүче теге яки бу диалект вәкиле булып, шул диалект үзенчәлекләреннән арынып җитә алмый» [Курбатов, 1998: 135]. Бүгенге көндә татар әдәби теленең орфографиясенә йогынты ясый торган күренешләр орфография һәм диалектлар белән генә чикләнми. Орфоэпиябез күп төрле лингвистик һәм экстралингвистик йогынтылар кичерә. Шул йогынтылар нәтиҗәсендә орфоэпик үзгәрешләр, ә кайчакта бер сүзнең ике төрле, хәтта өч төрле әйтелеш-язылыш вариантлары яки нормадан тайпылышлар барлыкка килә.

Хәзерге татар матбугаты битләрендә бер сүзнең ике-өч төрле язылу очраклары күзәтелә икән, язучыларга һәм журналистларга аларны сайлап алу кыенлыгы туа. Шул ук вакытта вариантлардан стилистик максатта файдалану мөмкинлеге дә төрле була ала. Персонажның белем дәрәҗәсен, социаль чыгышын, тәрбиясен сурәтләгәндә, сүзнең әйтелеш һәм язылыш үзенчәлегеннән оста файдаланырга була, ләкин моның өчен, орфографик номаларны яхшы үзләштерү белән бергә, язылыш нормаларының теге яки бу шартларда үзгәрүчән табигатен аңлый белергә кирәк. Шул нисбәттән, әлеге мәкаләдә татар басма матбугатында еш кулланыла торган фонетик вариантларны туплау, аларда орфографик нормаларның сакланышын тикшерү максат итеп куелды.

Төрле вариантта язылган сүзләрнең вакытлы матбугатта кулланылышын «Ватаным Татарстан», «Мәдәни Җомга», «Шәһри Казан», «Юлдаш», «Акчарлак», «Ирек мәйданы»газеталары мисалында карап китик. Мәсәлән:

***Газета*** сүзенең төрле вариантлары:

Хәзерге татар әдәби телендә *газета* вариантына кануни өстенлек бирелә. Шуңа күрә бу сүз хәзерге орфографик сүзлекләргә: *газета* (Татар теленең орфография сүзлеге, 1983, 45 б.) яки газет, газетча, газетачы, газетачылык (Татар теленең орфография сүзлеге, 2002, 73 б.) дип теркәлеп килә.

1) *«Ватаным Татарстан»* ***газетасының*** *баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров Флорид абыйның күп шәкертләре фикерен яңартты.* (Ирек мәйданы, №7 (289), 2018, 7 б.).

*2) Язмалар* ***гәҗиттә*** *чыкканнан соң, җитешсезлекләр бетереләә, гаделлек тантана итә башлый.* (Юлдаш, №37 (709), 2018, 23 б.).

«Юлдаш» та *газета* сүзенең гади сөйләмдә кулланыла торган варианты очрый. Башка газеталарда исә орфографиягә нигезләнеп язылган варианты кулланыла. Әлеге сүз рекламага багышланган рубрикаларда урын ала. «Юлдаш» газетасында *газета* сүзенең *з – җ* тәңгәллегенә туры китереп язылган варианты күзәтелә, ягъни әлеге сүзгә гади сөйләм теле үзенчәлекләре хас.

***Россия*** сүзенең төрле вариантлары:

Әгәр татар теленең фонетик төзелешен, җанлы сөйләмне орфографиягә нигез итеп алабыз икән, ул чакта Россия сүзенең язылышы *Эрәсәй, Ырусыя* булыр иде, чөнки татар теленең үз сүзләре [р] авазына башланмый. Менә тагын ике вариант. Тик шулай да әлеге сүз сүзлекләргә *Россия* буларак теркәлгән. *Россия* сүзенең яңгырашы-әйтелеше гади сөйләм йогынтысында барлыкка килгән.

*1)* ***Рәсәйнең*** *Соловкидагы Магадандагы төрмәләре бүген дә исән, аларда бүген дә ирек өчен, тел өчен, дин өчен көрәшүчеләр газап чигә.* (Мәдәни Җомга, №29 (1087), 2018, 17 б.).

*2) Күргәзмәне ачу тантанасы узгач, Президент Р.Миңнеханов җитәкчелегендә Татарстан делегациясе* ***Россиянең*** *Ашхабадтагы илчеллегенең яңа бинасы белән танышты.*(Ватаным Татарстан, №150 (27762), 2018, 1 б.).

*3) Моңа* ***Русиядә*** *– Олимпиада, Казанда Универсиада үткәрелү дә йогынты ясады булса кирәк.* (Ирек мәйданы, №12 (294), 2018, 5 б.).

*Россия* сүзенен барлыгы өч төрле вариантын очраттык. Әлеге сүз әдәби өлкәдәге рубрикалардан һәм рекламалардан кала сәясәткә кагылышлы язмаларда кулланыла. «Ватаным Татарстан» газетасында әлеге сүзнең орфографиягә нигезләнеп язылган варианты, ягъни сүзлекләрдә теркәлгән төре күзәтелә.

Тагын бер мөһим момент булып, рус теле аша кергән сүзләрнең фонетик варинатлары кулланылышы. Мәгълүм ки, без, татарлар, рус телендә сөйләшүчеләр белән якыннан аралашып яшибез, һәм шунлыктан үзебезнең туган телебез белән беррәттән, даими рәвештә рус телендә дә сөйлибез һәм язабыз. Шуның өстенә, Россиядә яшәгәнлектән, күп кенә яңа предмет һәм төшенчәләрнең исемнәрен рус теленнән тәрҗемә итеп алырга туры килә. Беренче карашка, моның бернинди дә зыяны юк кебек. Киресенчә, тәрҗемә итү нәтиҗәсендә туган тел оригинал теле хисабына күпмедер дәрәҗәдә байый да

әле. Әмма бу тәрҗемә эшен белеп башкарганда гына шулай. Ирекле тәрҗемә куллану фонетик вариантларны арттырганнан арттыра бара һәм мәгънәне тапшыра алмый. Автомобильне *тимерат* вариантында кертү, мәсәлән, уңышлы түгел. Гади сөйләмдә, матур әдәбият үрнәкләрендә тимерат дип велосипед, мотоцикл да атала. Газета-журналларны укучылар сүзнең нинди транспорт чарасы турында баруын төгәл күзаллап бетермәскә дә мөмкиннәр. Ирекесездән сорау туа, автомобильне *тимерат* диләр, ә нигә солярка *соляр* варинатында кулланыла? Әлеге сүзне кулланылышка кертергә теләүчеләр үзләре үк беләләрме икән сүзнең астрология өлкәсенә каравын?

Ничек кенә булмасын, мондый "новаторлык" матбугат ярдәмендә халыкка дөрес, саф, популяр телдә кызыклы, мәгънәле, файдалы информация бирү, яшьләрне, урта буын кешеләрен үрнәк татар теленә өйрәтүгә ярдәм итү бурычларына һич кенә дә җавап бирми.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, фонетик варинатлардан мөмкин кадәр арынырга кирәк. Бердәй орфографик принципларны булдыру татар тел белеме галимнәреннән зур эш һәм вакыт таләп итә. Моның өчен орфографик варинатларның барлыкка килү сәбәпләрен ачыкларга, орфографиягә һәм орфоэпиягә, үз телебез төзелеше йогынтысы белән бергә, чит телләр йогынтысын, шулай ук экстралингвистик йогынтыларны өйрәнергә кирәк, дип уйлыйбыз.

Димәк, каләм иясенә тел белән иркен файдалану өчен:

1. Газета-журнал битләрендә чыга торган мәкаләләргә игътибарны арттырырга;

2. Сүзләрнең әдәби нормага туры килгән очрагын гына кулланырга;

3. Орфографик вариантларны орфографиянең тупас бозылу очракларыннан аера белергә;

4. Фонетик-орфографик система җентекләп өйрәнелеп, төгәл язылыш үрнәге тәкъдим ителергә тиеш.

Хәзергә әле мәктәп дәреслекләрендә дә, югары уку йорты дәреслекләрендә дә орфоэпия һәм орфографияне өйрәнүгә бик аз урын бирелгән. Бу, берьяктан, проблеманың сәбәпләрен тиешле дәрәҗәдә ачыкланып бетмәүгә бәйле булса, икенче яктан, татар алфавитының тиешле дәрәҗәдә камил булмавына да бәйле. Шул нисбәттән без, массакүләм мәгълүмат чараларында сүзләрнең төрле вариантта язылышын тикшердек. Бу варинатлылыкның сәбәпләрен ачыкладык, киләчәккә йогынтысын билгеләдек һәм бүгенге өчен нәтиҗәләр чыгардык.

**ӘДӘБИЯТ**

Абдуллина Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре: Монография. Казан: Татар. Кит. Нәшр., 200. 215 б.

Курбатов Х.Р. Орфоэпия. Орфография // Татар рамматикася. 1 т. Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер, 1998. Б. 104–112, 134– 52.

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Тулыл. 2 нче басма. Казан: Мәгариф, 2002. 280 б.

Татар грамматикасы / ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ИЯЛИ, 2015. Т. 1. 512 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле (Стилистика). Казан: Тат.кит.нәшр., 1999. 325 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы. Казан: КДУ нәшр., 1993. 325 б.

Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: КДУ нәшр., 1973. 14 б.

Һадиева Г.К. Хәзерге татар әдәби теле фонетикасы: уку-укыту кулланмасы. Казан: Казан ун-ты, 2012. 124 б.



**Г.А. ГАСАНОВА**

*Бакинский Славянский Университет, Азербайджан*


# ОТРАЖЕНИЕ ЭТНОКУЛЬТУРНОЙ СПЕЦИФИКИ В ПОВЕСТИ Л.Н.ТОЛСТОГО «ХАДЖИ-МУРАТ»


**Аннотация.** В настоящее время актуальными остаются вопросы, связанные с сохранностью этнических культур многочисленных народов Кавказа, которые отличаются богатством и разнообразием. Поэтому данная тема, посвященная отражению этнокультурных элементов в художественном пространстве повести Л.Толстого «Хаджи-Мурат» представляется довольно актуальной.

Великий писатель посредством этнографических деталей сумел показать реальный мир горцев, их единство с окружающей природой, их мышление и мировосприятие. Национальное своеобразие и характер наиболее ярко проявились в обыденной речи персонажей и изустном творчестве.

Раскрывается отношение и оценка писателем ментальности кавказцев, их духовно-нравственных ценностей. Толстой призывал уважать другую культуру. В этом залог мирного сосуществования и согласия между народами.

**Abstract.** The story "Haji-Murat" by L. Tolstoy is one of the best creations of the writer.

Characteristic features of mountaineers, their attitude, psychology and national and figurative thinking found expression not only in songs, but also in the mountain speech. Tolstoy sought to reflect a living spoken language, using proverbs, sayings, aphorisms, wishful thinking. The popular wisdom is put into them.

Tolstoy calls for respect for the culture of the people of the Caucasus. Reflection of Muslim traditions help it to state the idea about a possibility of mutual understanding, rapprochement between the people.



**Ключевые слова:** «Хаджи-Мурат», этнокультура, образное мышление, горская речь, языков особенности стиля, заимствованная лексика, языковое чутье.

**Keywords:** "Haji-Murat," ethnoculture, figurative thinking, mountain speech, languages of style features, borrowed vocabulary, language flair.

В повести «Хаджи-Мурат» Л.Н.Толстой продемонстрировал глубокое знание жизни народов Северного Кавказа. Интерес к обычаям и традициям мусульман был не только этнографическим, но и духовным. Описывая быт и нравы горцев, язык и фольклор, он стремился отразить представления об исламских культурных ценностях.

Через образ жизни раскрывается духовная культура народа, в которой сохранились элементы традиционнного религиозного мировоззрения.

Писатель акцентрирует внимание на гуманистических общечеловеческих идеалах, заложенных в мусульманской религии.

«Толстой высоко ценит отношение мусульман к женщине, гостю, к таким чертам, как верность, честность, достоинство, человечность,– отмечает проф. А.Дж.Гаджиев. – В описаниях мусульманских ритуалов и обрядов он показал себя тонким знатоком исламской культуры» [Гаджиев, 2011:127].

Изучение жизненного уклада горских народов привело писателя к осознанию духовных ценностей ислама, утверждающих идеалы высокой нравственности, добра и справедливости. Исламская религия соответствовала его духовному миру, что явствует из многочисленных высказываний Толстого в сохранившейся переписке (в частности, с Е.Е.Векиловой, супругой генерала русской армии Ибрагим ага Векилова) [Толстой].

Коранические выражения нашли отражение и в повести «Хаджи-Мурат» ( *«Бисмиллях ир-рахмани рахим»; «Ля иллаха илл Аллах»; «Я хакк»; «Зикр»; «Я кайюм»; «Мухаммад ун Расуллах»; «Гу»,«Зикр»; «Истихар-намаз»* и др.).

Хаджи-Мурат предстаёт как праведный мусульманин, всецело преданный своей вере, он свято чтит исламские обряды, обязательные для всех правоверных. Поклонение Аллаху – их священный долг.

Глубоко раскрыть образ героя «с богом в душе» Толстому помогло обращение к народному творчеству. Горские песни (о кровомщении, тавлинская сказка о соколе, о джигите Гамзате, песня матери), придающие повести лирически-эмоциональную и одновременно героическую окраску, ещё более усиливают восприятие смелого воина. Они напоминают лучшие образцы азербайджанской фольклорной поэзии. Прославление мужества и героизма в духе народной поэзии и традиций. По словам известного языковеда М.Т.Тагиева, в текстах песен «Толстой сохраняет стиль оригинала, что выражается в «системе фраз и их

сцеплении» [Тагиев, 1961: 213-233].

Народно-образное мышление горцев нашло выражение как в песнях, так и в горской речи. Особый национальный колорит придают ей народные выражения (пословицы, поговорки, приветствия и пожелания). В них находят отражение представления и наблюдения над жизнью. Они тесно связаны с обычаями и горским этикетом и придают национальное своеобразие повествованию (*«Я с Кораном и шашкою приду», «У женщины ума в голове – сколько на яйце волос», «Сыновья твои да чтобы живы были», «Приход твой к счастью», «Да получишь ты радость и жизнь», «Бог да воздаст вам», «Желаю вам вечный мир с богом всемогущим» и т.д.*).

Своеобразие мышления и художественное восприятие мира выражается в сравнительной характеристике персонажей и явлений действительности.

Известно, что писатель тщательно отбирал их и отшлифовывал (что видно из различных редакций повести), приближая к оригиналу. При этом они естественно увязаны с конкретной обстановкой. В этом проявляется поразительная интуиция и фольклорное чутьё великого художника.

Толстой стремился отразить живой разговорный язык, сохранить особенности стиля речи. Как верно подметил проф. А.Дж.Гаджиев, «речь горцев в повести строится весьма своеобразно – в лаконичной, порой завуалированной форме, полунамёками они могут обсуждать самые важные вопросы» [Гаджиев, 2011: 125].

Вкладывая в уста горцев характерный для них язык, писатель вплетал в него русские слова и фразы. В общении с русскими они говорят на «несклоняемом» ломаном наречии и используют смешанные выражения, как и русские (*«Хорош песня,умный песня», «Прощай!.. Кунак булур. Время, – айда пошёл», «Прощай, матушка,.. – спасиб», «Улан якши» и т.д.*).

Как видим, Толстой отражает не все особенности речи персонажей нерусских, а воспроизводит лишь отдельные, наиболее типичные элементы этой речи, являющиеся как бы «условными намёками на реальную речь горцев». И это полностью соответствует принципу типизации речи персонажей, который использовали и другие русские писатели.

Вполне естественно, что горцы, с трудом выговаривающие русские слова, вносили в него элементы своей родной речи и строили фразы по образцу своих: *«Мюрид мой. Элдар имя ему» ; «Это можно, только много, очень много есть чего рассказывать»* и т.д.

Расположение слов в том порядке, какой свойствен тюркским языкам.

Для передачи горской речи и местного колорита писатель широко ис-

пользовал и заимствованные слова, в том числе тюркизмы. По утверждению известного азербайджанского ученого-лингвиста М.Т.Тагиева, тюркская лексика связана не только с кумыкским языком, но и с азербайджанским. Известно, что писатель обучался тюркским языкам в Казанском университете у одного из основателей русского востоковедения Мирзы Казембека.

Не случайно многие устойчивые сочетания повести аналогичны выражениям родного языка. Сказанное можно проиллюстрировать наглядными примерами : Ханефи, чтобы прекратить раздор между семьями и положить конец кровомщению, просил Хаджи-Мурата «принять его братом» (*qardaşlığa götürmək*). Лексический оборот вводится с сопроводительным комментарием: «*Я не брил два месяца головы, ногтей не стриг и пришёл к ним. Они пустили меня к Патимат, к его матери 〈...〉 и я стал его братом*» [Толстой, 1984: 316].

Такого же типа сочетание «лёгкий человек» (*yüngül adam*). Так называет Хаджи-Мурат своего нукера Хан-Магому, имея в виду, что он несерьёзный, поверхностный человек.

В переносном значении употреблено и выражение «взять кровь» (*kiminsə qanını almaq,canını çıxartmaq*). Хаджи-Мурат, не покорившись Гамзату, хотел покончить с ним, уничтожить его: « *〈...〉 Гамзату только мы с братом не хотели покориться. Нам надо было кровь его за ханов. Мы делали вид, что покорились, а думали только, как взять с него кровь*» [Гаджиев, 2011: 317].

Толстой не перенасыщал текст «экзотической» лексикой, соблюдая меру и сообразность в её употреблении. Она органически вплетена в ткань повествования.

Изучение языка и стиля писателя, вживание в мир его идей и образов помогло национальным переводчикам в воспроизведении художественного своеобразия и идейного содержания повести. Переводчики (К.Карабеков (1912), Б.Талыблы (1929), М.Эфендиев (1958)) сумели отобразить реалистические принципы Толстого в изображении горных аулов, пейзажных зарисовок, внешней и внутренней характеристики героев, их индивидуальной речи.

Языковое чутьё и отточенное мастерство помогли им и при переводе образцов устного народного творчества, представленных в повести.

По словам азербайджанского толстоведа Ф.Рзаева, «переводы из фольклора кавказских народов могут служить примером творческого и вдохновенного отношения к работе» (подразумевает последний вариант перевода) [Рзаев, 2009: 76].

Переводы были осуществлены с учётом богатых возможностей родного

языка, его изобразительно-выразительных средств, интонационно-ритмичного строя. Бесспорно, переводчикам помогло не только знание языка, они сумели прочувствовать всю силу и глубину мысли творений художника.

Переняв творческую манеру и язык писателя, его образ мыслей и способ их выражения, переводчики стремились максимально приблизить перевод к тексту повести.

Наиболее ярко творческое восприятие традиций Толстого проявилось и в переводе-инсценировке повести, выполненном классиком азербайджанской литературы, драматургом Джафаром Джаббарлы в 1928 году. Взяв за основу темы и образы фольклора, драматург переработал их по-своему и создал проникновенные поэтические произведения (по мотивам песни матери и песни о Гамзате). Здесь сполна проявился его дар поэта-лирика.

Таким образом, исследование этнокультурных особенностей в повести Л.Толстого «Хаджи-Мурат» позволяет глубже осмыслить влияние великого писателя на литературу и культуру Азербайджана, и тем самым дополнить научные представления о литературном взаимодействии и межкультурном художественном диалоге.

### ЛИТЕРАТУРА

Гаджиев А., Рзаев Ф., Якубова М., Алиева С.Восток в русской литературе. Учебное пособие. Баку, 2011. 175 с.

Рзаев Ф.Ч. Проза Толстого в азербайджанских переводах. Баку: Наука  и образование, 2009. 268 с.

Тагиев М.Т. Заметки о языке и стиле повести Л.Н.Толстого «Хаджи-Мурат» // Учёные записки. Серия филологическая, 1961, №9. С. 213-231.

Толстой Л.Н. Собр. соч.: в 12 т. Т.12. М.: Правда, 1984. 510 с.

Толстой Л.Н., Векиловой Е.Е., 13-16 марта 1909 г. URL: http://tolstoy-lit.ru/tolstoy/pisma/1909-yanvar-iyun/letter-125.htm (дата обращения: 05.09.2019).

**А.М. ГАТИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭНДӘШ СҮЗЛӘРНЕ КАБАТЛАУ

**Аннотация**. Данная статья посвящена проблемам изучения слов обращения в учебном процессе. Тема раскрыта на основе литературных произведений. Выделены актуальные формы использования обращений, представлена система упражнений для каждого класса. Подробно описан процесс формирования  навыков и умений использования обращений в речи в разных ситуациях  на уроках татарского языка.

**Abstract**. This article is devoted to the problems of studying the words of appeal in the educational process. The topic is disclosed on the basis of literary works. Actual forms of using appeals are highlighted; a system of exercises for each class is presented. A lesson in the study of new material is also described in details, aimed at developing the skills and abilities of using words of appeal in speech in different situations.

**Ключевые слова:** слова-обращения, литературные произведения, система упражнений, учебная деятельность.

**Keywords:** words of appeal, literary works, system of exercises, educational activity.

Татар теле дәресләрендә эндәш сүзләр башлангыч сыйныфларда ук өйрәтелә башлый. 5-6 нче сыйныфта эндәш сүзләрне кабатлауга карата берничә күнегү бирелә. Мәсәлән:

- Күнегү 7. Эндәш сүз булган җөмләне табып, дәфтәрегезгә язып куегыз [7 : 7]
- Күнегү 57. Балаларга эндәшкәндә кулланыла торган исемнәр язып килегез [9 : 31]

7 нче сыйныфта эндәш сүзләргә билгеләмә, кулланылыш үзенчәлекләре турында мәгълүматлар бирелә. Түбәндәге күнегүләр укучыларда эндәш сүзләр турында белемнәрне формалаштырырга ярдәм итә:

- ияне эндәш сүзгә әйләндереп, җөмләләрне үзгәртеп языгыз [4: 118]
- эндәш сүзләрне табып, аларның нинди максат белән (мөрәҗәгать итү, бәяләү) куллануын аңлатыгыз [4: 118]
- җөмләләрне күчереп языгыз. Эндәш сүзләрне табып, астына сызыгыз [4: 119]

8 нче сыйныф дәреслегендә эндәш сүзләрне синтаксик яктан тикшерү үрнәге, шартлы билгесе һәм берничә күнегү бирелә [3: 6-7, 147]

Рус мәктәпләрендә укучы балалар өчен төзелгән дәреслекләрдә дә эндәш сүзләрне кабатлага күнегүләр бирелә. Мәсәлән,

- Эндәш сүзне табып әйтегез [8: 11]
- Эндәш сүз кергән җөмләдә нинди фигыль кулланылган [8: 15]
- Бирелгән сүзләр бер очракта – ия, икенче очракта эндәш сүз булырлык итеп, җәенке җөмләләр төзеп языгыз [8: 16]

8 нче сыйныфта укучылар эндәш сүзләрне җөмлә кисәге буларак өйрәнәләр. Биредә эндәш сүзгә билгеләмә, тыныш билгеләре һ.б. кагыйдәләр бирелә [5: 126-131]

Эндәш сүзләр турында өйрәнү һәм ныгыту дәресләрендә тыныш билгеләрен куярга өйрәтүгә игътибар итәргә кирәк: укучылар җөмлә башында килгәндә – эндәш сүздән соң, җөмлә уртасында килгәндә – ике яктан да, җөмлә

ахырында килгәндә, аннан алда өтер куелуын белеп, үз мисаллары белән ныгытып барсыннар.

Мәсәлән, түбәндәге җөмләләрне мисалга китерергә була:

а) җөмлә башында: **Әбекәй,** синең җырың бигрәк кызык, әйеме? [6: 360]

ә) җөмлә уртасында: Сафиуллам белән күрештерден, **Сафиулла,** дим, никләр бер авыз сүз дәшмисең, сиңа әйтәм? [6: 365].

б) җөмлә ахырында: Нәмәгә аптырап калдың, **гөлкәем**? [6: 361]

Күнегүләр эшләткәндә, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр үткәрүгә күбрәк урын бирергә кирәк. Шулай ук дәрестә компьютер технологияләреннән презентацияләрне дә файдаланырга була. Бер грамматик категорияне икенчеләре белән буташтырмасыннар өчен, үткәннәр белән үреп, чагыштырып карарга өйрәтү мөһим.

Түбәндәге кайбер күнегүләрне эшләтеп, укучыларга алган белемнәрен сөйләмнәрендә һәм язма эшләрендә файдалана белү күнекмәләре бирелә:

- Эндәш сүзләрне табып, астына сызу. Лексик-семантик яктан нинди сүзләр белән бирелүен аңлату.
- Җөмләләрдә эндәш сүзләрне табу. Алар янында кирәкле тыныш билгеләрен куеп язу.
- Диктантлар яздыру яки аңлатмалы язу үткәрү.
- Тестлар оештыру.
- Укытучы тәкъдим иткән схемалар ярдәмендә җөмләләр төзеп язу.
- Медиа файллар ярдәмендә төрле биремнәр башкару һ.б.

Мәсәлән укучыларга презентация ярдәмендә түбәндәге күнегүне бирергә була. Г.Тукай шигырьләрендә төшеп калган эндәш сүзләрне һәм тыныш билгеләрен куярга, тыныш билгеләренең куелышын аңлатырга

1. Әйт әле ...
Сөйләшик бергәләп.
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек? (“Бала белән Күбәләк”)
2. Әйдәле ... өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп – туры тор, төз утыр, яхшы утыр! (“Кызыклы шәкерт”)
3. И ... һич юк икәндер мәрхәмәт хисең синең,
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең? (“Шүрәле”)

Файдалану өчен эндәш сүзләрне рәсемнәр аша бирергә дә мөмкин.

Шулай ук дәрестә модель төзү алымын да кулланырга була. Мәсәлән:

1) Эндәш сүз,……. 2) …., эндәш сүз, …….. 3)…., эндәш сүз.

4) Ымлык+эндәш сүз, …….

Бу темага программада бик аз вакыт бирелгән. Шулай да теманы укучыларның яхшы итеп үзләштерүенә ирешү таләп ителә. Соңыннан билгеле инде, укучыларның теманы үзләштерүләрен, тыныш билгесен дөрес куя белүләрен сынау максаты белән, язма эшләр (диктант, изложение, сочинение) үткәрергә, йомшак үзләштерүчеләр белән аерым эшләргә, консультацияләр бирергә дә кирәк була.

**ӘДӘБИЯТ:**


Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиева, Г.Ф.Саттаров. Казан: Раннур, 2000. 455 б.

Максимов Н.В. Татар теле. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Н.В. Максимов, Г. Ә. Нәбиуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 159 б.

Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Г.И. Хәйруллина [рәссамы Л. Хисамова]. Казан: Мәгариф–Вакыт нәшр., 2016. 223 б.

Харисова Ч.М. Татар теле. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ч.М. Харисова, Н.В. Максимов, Р.Р. Сәйфетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 207 б.

Харисов Ф.Ф. Татар теле. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. Казан: Татар. кит, нәшр., 2015. 159 б.



**Р.Г. ГАТИЯТУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# ТАТАР ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕНДӘ ЛИНГВИСТИК НОРМАЛАРНЫҢ САКЛАНЫШЫ


**Аннотация.** В современном мире телевидение является одним из самых быстрых и важных средств массовой информации. Задачей телевидения является сохранение языка, воспитание лингвистических норм и правильное применение их в речи. В статье рассматриваются основные лингвистические нормы татарского языка и их соблюдение в татарском телевидение.

**Abstract.** At the moment, television is one of the fastest and most important media. First of all, the task of television is to preserve the language and bring to society the correct application of all linguistic norms of the language. The article aims to consider the basic linguistic norms of the Tatar language and how they are preserved in the Tatar culture.



**Ключевые слова:** телевидение, телевизионные жанры, лексические нормы, орфоэпические нормы, грамматические нормы

**Keywords:** television, television genres, lexical norms, orthoepic norms, grammatical norms

Җәмгыять тормышында мәгълүмат чараларының – газета һәм журналларның, радио һәм телевидениенең роле зур булуы бәхәссез. Алар кешенең рухи дөньясын баета: фикерен, карашын киңәйтә, аны әһәмиятле, кызыклы вакыйгалар белән таныштыра, файдалы киңәшләр бирә, эстетик зәвык, әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә. Мәгълүмат чаралары бу вазыйфаларын төп бер шарт үтәлгәндә – аларның теле дөрес, табигый, үтемле булганда гына – уңышлы башкара ала.

Телевидение теленең үзенчәлеге шунда: ул тормышта һәр көн саен булган яңалыкны, үзгәрешне ачарга тиеш. Бу үз чиратында телгә яңа сүзләр, яңа төшенчәләр, яңа формалар алып килә. Һәр ачыш, үзгәреш, вакыйга телевидение аша киң җәмәгатьчелеккә билгеле була. Бу очракта журналистларның телне, аның үсеш закончалыкларын яхшы белүе, әдәби телгә карата сизгерлекләре бик тә кирәк булып чыга. Шулай итеп, телевидение үз укучыларына телгә, стильгә карата зәвык тәрбияли.

Телевидение теле – югары мәдәният һәм әдәби осталыкны сорый торган эш, шуңа күрә аның нәтиҗәсе уңай булсын өчен, ул стиль ягыннан да, тел өлкәсе ягыннан да кимчелексез булуны сорый.

**Орфоэпик нормалар.** Билгеле булганча, татар орфоэпиясе татар телендә нормага салынган әдәби әйтелеш кагыйдәләрнең җыелмасын тәшкил итә. “Татар грамматикасы” (I том) дип аталган академик басмада орфоэпия терминына мондый аңлатма бирелә: “Әдәби телдәгечә дөрес әйтелеш кагыйдәләре орфоэпия (грекча orthos “дөрес” һәм epos “сөйләү” сүзләреннән) дип йөртелә [Татар граматикасы, 2015: 103].

Орфоэпиянең нигезен һәрвакыт теге яки бу телнең фонетик системасы тәшкил итә, ә соңгысына фонемалар составы, фонемаларның көчле һәм көчсез позициядәге үзенчәлекләре керә. Орфоэпия шушы үзенчәлекләрнең кайберләрен генә сайлап ала, аларны гомумиләштерә, теге яки бу әдәби телнең әйтелеш нормасы итеп күтәрә [Сафиуллина, 2001: 96].

Татар телевидениесе алып баручыларының сөйләме, нигездә, татар орфоэпиясе нормаларына туры килә. Бигрәк тә “Татарлар” тапшыруын алып баручы Инсаф Абдулла, “Адәм белән Һава” тапшыруы дикторы Ләйлә Дәүләтова, “Әдәби хәзинә” тапышыруының алып баручысы Рания Юнысова сөйләмнәре камил, аһәңле, әдәби тел нормаларына туры килә.

Ләкин аерым очракларда әдәби нормалардан тайпылыш очраклары да күзәтелә. Мисал өчен, алдагы җөмләләргә игътибар итик:

*Атнаның иң мөһим, хәлиткеч вакыйгалары һәм аларга галимнәр карашы.* ("Адымнар", 17.04.2018). [мөһим] һәм [хәлиткеч] сүзләренең икесендә дә [х] авазы әйтелә.

Тележурналистлар телендә очрый торган орфоэпик нормаларның чираттагысы – гарәп теленнән кергән сүзләрдә очрый торган [ʾ] – һәмзә авазын дөрес әйтмәү. Мисалга игътибар итик:

*Карлар эрү белән, авылларда да юл мәсьәләсе баш калкыта.* ("Туган җир", 13.04.2018).

**Лексик нормалар.** Татар теле сүзлек хәзинәсенең үзенә генә хас үзенчәлекләре, аерымлыклары бар. Татар теленең төрле стильләрендәге кебек, иҗтимагый-публицистик стильдә дә туры мәгънәсендә йөргән гомумкулланылыштагы (нейтраль) лексика зур урын алып тора. Моннан тыш публицитик стильдә иҗтимагый-сәяси лексика киң кулланыла [Хаков, 1963: 54].

Татар телевидениесе тапшыруларында урын алган сүзләрне хөкүмәтнең һәм аерым сәяси оешмаларның эшчәнлекләре, сәяси юнәлешләре белән бәйле лексика, яшьләр тематикасына карган лексика, әдәбият, театр, сәнгать, мәдәният өлкәсенә караган лексика, фән, мәгариф, нәшрият өлкәсенә караган сүзләр, дәүләт төзелеше, җәмгыять, хөкүмәт, дәүләт оешмалары һ.б. бәйле лексикага караган сүзләр очрады. Мәсәлән:

*Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Төркиягә ике көнлек эш сәфәре кылды. Ул Әнкара һәм Истанбул шәһәрләрендә булды, дип хәбәр итә Президентның матбугат хезмәте. Эш сәфәре кысасында республика башлыгы Төркия Премьер-министры Бинали Йылдырым белән очрашкан.* ("Татарстан хәбәрләре", 27.04.2018)

*Нурбәк Батулла "Алтын битлек" премиясен барлык татар халкына багышлады.* ("Яшьләр тукталышы", 22.04.2018).

Алар арасында төрки сүзләр дә, алынма сүзләр дә еш очрый. Бигрәк тә гарәп-фарсы һәм рус-европа алынмалары. Без анализлаган тапшыруларда калькаларны еш ишетергә мөмкин. Кайберләре уңышлы кулланылса, икенчеләре сөйләм кытыршылыгына китерә.

*Коръән Кәримдә Аллаһ Раббыбыз мөэминнәрнең догаларын зәкер итә.* ("Нәсыйхәт", 30.03.2018).

*Ел башы белән чагыштырганда, "дөнья пәрәвезе"ндәге хезмәттән файдаланучылар биш тапкыр арткан.* ("Манзара"04.03.2018)."Дөнья пәрәвәзе" – "всемирная паутина".

**Грамматик нормалар.** Туган тел кагыйдәләре, сөйләм нормалары, билгеле булганча, морфологиядә, ягъни грамматик формаларда да чагылыш

таба. Морфологик нормалар дигәндә исә, төрле сүз төркемнәренең грамматик формаларын дөрес куллану үзенчәлекләре күз алдында тотыла. Морфологик норма сүз ясалыш һәм сүз төрләнеш үзенчәлекләрен үз эченә ала. Морфологик нормаларның үтәлмәве, ягъни бозылуы төрле сөйләм хаталарына китерә.

Тапшыруларның телендә сүз төркемнәре, аларның грамматик категорияләре нигездә хәзерге татар әдәби тел нормаларына туры килә. Аерым очракларда гына фамилияләр төрләнешендә башка форма кулланылган:

*Бәйге нәтиҗәләренә йомгак ясалып, Шәмсиевлар гаиләсе бүләкләнде.* (“Манзара” 19.04.2018).

Шулай ук Ияртүче сүзе тартым кушымчасы белән килгән күплек мәгънәсендәге исемле исем (изафә) сүзтезмәләрендә ияруче сүз берлек формасында йөри. Әмма мондый характердагы сүзтезмәләрдә рус теле берәмлекләренең интерференциясе нык чагыла: еш кына чыганак тел йогынтысында ияруче сүз күплек формасында кулланыла.

*“Стиль” тегү предприятиесендә эшләнгән хатын-кызлар пальтолары һәм баш киемнәре ярминкә-сәүдәсе булып узды.* (“Хәбәрләр” 03.03.2018)

Фигыль формаларын дөрес кулланмау очраклары да мисалларда теркәлде. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, тапшыруларда -*учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыль затка карамаган очракта да кулланыла. Мәсәлән:

*Сез “Яңа гасыр” каналында авыл, андагы яшәеш һәм аграр тармакта барган үзгәрешләрне яктыртучы “Туган җир” тапшыруын карыйсыз.* (“Туган җир”, 13.04.2018)

Гомумән алганда, татар телевидениесе телендә гомум кабул ителгән орфоэпик, лексик һәм грамматик нормалар саклана. Безнең тарафтан күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү эфирга чыга торган тапшыруларның сыйфатын күтәрергә ярдәм итәр һәм телеаудиторияне киңәйтү мөмкинлеге бирер иде.

**ӘДӘБИЯТ**

Татар грамматикасы: өч томда / проект җитәкчесе М.З.Зәкиев; ред. Ф.М.Хисамова. Тулыландырылган икенче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 512 б.

ТНВ-Яңа гасыр. – URL: https://tnv.ru/tat / (мөрәҗәгать итү вакыты: 1.10.2019)

Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. Казан: ТАРИХ, 2001. 383 б.

**И.И. ГАФУРОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# ОНОМАСТИК МАТЕРИАЛНЫ ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЯРДӘМЕНДӘ ӨЙРӘНҮ

**Аннотация**. Ономастический материал составляет значительную часть лексики любого высокоразвитого языка. Изучение отрасли ономастики на каждом этапе образовательного процесса является актуальным. Использование проектного метода в образовании – это систематизация полученных знаний и навыков.

**Abstract.** Onomastic material is a significant part of the vocabulary of any highly developed language. The study of onomastics is relevant at the each stage of the educational process. The using project in education is the systematization of the acquired knowledge and skills.

**Ключевые слова**: ономастика, проект

**Keywords:** onomastics, the project

Телнең лексик системасында башка төр лексик берәмлекләрдән үзләренә генә хас мәгънәви, төзелеш-ясалыш үзенчәлекләре, үсеш һәм кулланылыш закончалыклары, система барлыкка китерергә сәләтле механизмнары белән аерылып торган берәмлекләр – ялгызлык исемнәре бар. Бу төр берәмлекләрне өйрәнә торган фән ономастика дип атала. Ономастика (грек теленнән onomastike – исем кушу сәнгате) – тел белеменең ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармагы. Шул ук вакытта бу термин белән ялгызлык исемнәре җыелмасын да атыйлар (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 347).

Телнең сүзлек составында аерым урын билгеләгән ономастик берәмлекләрне өйрәнү һәм белем бирү системасында куллану мәсьәләсе әһәмиятле санала.

Ономастика, лингвистиканың бер тармагы буларак, лингвистик тикшеренү методларына нигезләнә, шул ук вакытта, өйрәнү объектының төренә, тикшеренү өлкәсенә һәм юнәлешенә карап, башка фәннәрнең, аеруча тарих, география, этнография, культурология, социология, әдәбият белеме фәннәренең дә методологиясен файдалана. Болардан кала, ономастикада археология, биология, теология, философия, психология фәннәре материаллары, метод һәм алымнары да кулланыла. [Татар лексикологиясе, 2017: 9]

Ономастика тармагын белем бирү процессының һәрбер баскычында өйрәнү актуаль булып тора. Кызганычка каршы, ономастика аерым бер предмет буларак укытылмый. Гәрчә әлеге тармакның фәнара бәйләнешләр булдырудагы роле, башка фәннәр, мәсәлән, тарих, география, математика һәм башкалар белән бәйләнеше билгеле.

Онамастика 5 нче сыйныфта лексикология тармагын өйрәнгән вакытта өлешчә генә карала, ә 9 нчы сыйныфта лексикологияне кабатлаганда тагын бер искә алына. Безнең карашыбызча, бүгенге шартларда ономастика тармагын мәктәпләрдә өйрәнү өчен мөмкинлекләр ачылды. Бугенге көндә укучылар ФГОС таләпләре буенча төрле проектлар башкаралар, иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнәләр.

Укучылар әлеге проект эшләрендә ономастиканы кулланып нәрсәләр эшли алалар? Татар телен өйрәнүдә нинди үзенчәлек үтиләр?

Шушы сорауларга җавап эзләү максатыннан, без әлеге мәкалә кысаларында проект технологиясен кулланып, ономастик материалны өйрәнү мөмкинлекләрен ачыклауны максат итеп куйдык.

Билгеле булганча, хәзерге белем бирү системасында проект технологиясен куллану бик популярлашты. Гомумән, тормыш-яшәештә әлеге сүзне төрле очракларда очратабыз, мәсәлән, “Телевизион проект”, “Җыр проекты”, “Бию проектлары”, “Ана теле проекты”, “Интернет-проектлар” һ.б. Проект сүзенең мәгънәсенә килгәндә, ул булмаган нәрсәне (мисал өчен, яңа бинаны, программаны) барлыкка китерүгә юнәлтелгән һәм аның тормышка ашу процессын күзаллаган бер идея, уй-теләкне белдерә. Шуның өчен дә проект алдына куелган максат төзү, барлыкка китерү, булдыру, иҗат итү, ирешү һ.б. кебек фигыльләр ярдәмендә формалаштырыла. Шулай итеп, проект – ул:

1) нинди дә булса механизмның яки корылманың планы;

2) ниндидә булса документның алдан әзерләнгән тексты;

3) теләгеңне тормышка ашыру планы.

Белем бирүдә проект методын куллану – ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, «белү һәм белмәү» зонасында мөстәкыйль эшчәнлек кору, фәннәр арасында бәйләнеш табу, дулкынландырган проблеманы билгеләү, чишү юлларын табу, эш нәтиҗәсен тәкъдим итә алу, дигән сүз ул.

Проект методының асылы: укучылар укытучы җитәкчелегендә эзлекле рәвештә проектлар эшлиләр, проект өстендә эшләгәндә өстәмә мәгълүмат туплыйлар һәм һәр этапка рефлекция ясыйлар.

Проект эше укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ача. Шулай ук төркемдә эшләү күнекмәләре булдыра, үзе сайлап алган кызыклы проблеманы ачу өстендә эшли һәм хезмәтен яклый.

Проект методын укыту процесының төрле баскычында кулланып була. Мисал өчен, Башлангыч сыйныфларда проект методын кулланып, ономастикага караган проект эшләре эшләтеп була. Аерым алганда, туган авылыңның

ономастикасын: ягъни елга атамаларын, чишмәләрнең атамаларын, сыйныфташларыңның исемнәренең килеп чыгышларын өйрәнү проектын эшләү. Башлангыч сыйныф укчыларына түбәндәге төрдәге проект темаларын тәкъдим итәргә мөмкин: Исемнәр ни сөйли?

1. Кушаматларда халкым тарихы;
2. Авылым ономастикасы (тыкрык, тау, елга, чишмә, кое, күл, ерганак, үр, басу һ.б. исемнәренең тарихы)

Ономастиканың бер төре антропонимикага караган проект эше тәкъдим итәргә була. Антропонимика – кешеләргә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган исем, ата исеме (отчество, патроним), фамилия, кушамат, криптоним, псевдонимнарны өйрәнә торган тармак [Татар лексикологиясе, 2017: 10]. Мәсәлән, татар исемнәре, аларның катламы, килеп чыгышлары, мәгънәләре турында проект эше эшләгәндә, укучы үзенә бик күп мәгълүмат ала, интернетта, матбугат битләрендә мавыктыргыч мәкаләләр белән очраша. Эш буенча түбәндәге нәтиҗәләргә килергә була:

- килеп чыгышы буенча кайсы телдән, ничә исем алынган;
- иң таралган исемнәр;
- Сирәк очрый торган исемнәр: испан, борынгы грек, инглиз, рус теленнән кергән исемнәр;
- мәгънәләре ачыкланмаган, сирәк очрый торган исемнәр;
- мәгънәсез, ятышсыз, заманга гына ияреп кушылган исемнәрнең булу-булмавы.

Кушаматлар темасына язылган проектлар укучыларда зур кызыксыну уята. Әлеге теманы өйрәнгәндә, Г.Ф.Саттаровның хезмәтләре аеруча әһәмияткә ия. Бу очракта, кушаматларны барлау максатыннан, миниэкспедицияләр оештыру; кушаматларны классификацияләү (шәхси, нәсел һ.б.), сыйныфтагы кушаматларны барлау, сораштырулар үткәрү, кушаматларны күрше керәшен (яки башка халык) кушаматлары белән чагыштыру кебек эшләр оештырырга мөмкин.

Мондый проект эшләрен 5 нче сыйныфтан дәвам итеп, зур йомгаклау проекты буларак 9 нчы сыйныфта якларга була. Шуңа күрә әлеге хезмәтләрнең әһәмияте зур. Беренчедән, ономастикага кагылышлы проектлар укучыда кызыксыну уята, эзлекле һәм нәтиҗәле эш алып барырга өйрәтә. Икенчедән, туган телне һәм төбәк тарихын өйрәнүгә зур этәргеч ясый. Эзләнү вакытында укучылар китаплардагы күп төрле яңа сүзләргә тап булалар һәм аларны истә калдырырга тырышалар. Шул рәвешле алар татар тел белеме өлкәсендәге белемнәрен тирәнәйтәләр. Шулай ук әлеге темаларга язылган хезмәтләр Туган

якны өйрәнү музейларына да бай материал булып тора. Димәк, укучылар эзләнү эше генә алып бармый, ә татар телен дә ныгыта, баеты һәм тирәнтенрәк өйрәнә дигән сүз.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге татар ономастикасы комплекслы эзләнүләр таләп итә. Чөнки ул тел белеменең киң катлам фәнара метод һәм алымнарга нигезләнеп өйрәнелә торган катлаулы структура хасил иткән тармагы булып тора. Ә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә ономастиканы проектлар методын кулланып өйрәнү – укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә этәргеч булып тора. Аларда яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну уяна. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә.

**ӘДӘБИЯТ**

Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Казан: “Раннур” нәшрияты, 2000

Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 1 кис. 536 б.

Харисов Ф.Ф. Хәзерге шартларда татар лексикасына өйрәтү мөмкинлекләре // Международная научно-практическая конференция «Тюркская ономастика: от истоков до современности» (Казань, 11-14 октября 2018 г.). Казань: КФУ, 2018. С. 245-251.

**А.Д. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ ЛИНГВИСТИК ЛАНДШАФТЫ

**Аннотация.** Статья посвящена анализу лингвистического ландшафта города Казани. В ней рассматривается использование татарского языка в лингвистическом ландшафте Казани. Дана краткая характеристика языковой ситуации в Татарстане.

**Abstract.** The article is devoted to the analysis of the linguistic landscape of Kazan. The use of the Tatar language in the linguistic landscape of Kazan is considered in this article. A brief description of the language situation of Tatarstan is given.

**Ключевые слова:** лингвистический ландшафт, эргоним, языковая ситуация.

**Keywords:** linguistic landscape, ergonym, language situation.

Әйләнә-тирәбезнең бөтен җирендә төрледән-төрле алтакталарны (вывескаларны), белдерүләрне, юл күрсәткечләрен, плакатларны һәм реклам щитларын адым саен очратырга мөмкин. Менә шулардагы һәртөрле тел тамгаларын лингвистик ландшафт (тел ландшафты) термины белән атап

йөртәләр. Әлеге термин чагыштырмача яңа булып санала. Беренчеләрдән булып, 1997 елда лингвистик ландшафт терминының билгеләмәсен канад социолингвистлары Р.Лэндри белән Р.Бурхис тәкъдим итәләр: лингвистик ландшафт ул – шәһәр пространствосының иҗтимагый киңлегендә теге яки бу телнең төрле язма тамгаларда тасвирлау ысулларының берсе, ягъни тел ландшафты – ике төп мәгълүмати һәм символик функция үти торган плакатларның, урам исемнәренең, реклам щитларының, юл күрсәткечләренең, кибет, дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый оешма атамаларының теле ул.

Тикшеренү эшебезнең максаты – Казан шәһәренең лингвистик ландшафтына күзәтү ясау һәм татар теленең Казанның лингвистик ландшафтында кулланылыш ролен ачыклау.

Чит ил галимнәре тарафыннан лингвистик ландшафтка караган актуаль мәсьәләләр еш күтәрелә, бик күп хезмәтләр языла (П.Бакхауз, Р.Лэндри, Р.Баурхис, Д.Гортер, К.Торинктон, Д.Фрисби, С.Милгред). Соңгы елларда рус галимнәренең дә билгеле бер шәһәрнең, регионның лингвистик ландшафтын өйрәнүгә кызыксынулары уяна һәм хәтта 2015 нче елдан бирле лингвистик ландшафтка багышланган махсус халыкара журнал да нәшер ителеп килә (Л.Л.Федорова, И.А. Астафьева, А.В. Беспалова, М.В. Голомидова, Л.В. Грибанова, С.В. Земскова, Р.И. Козлов, И.В. Крюкова, М.Я. Крючкова, А.М. Мезенко, М.Е. Новичихина, Е.А. Трифонова, Н.В. Шимкевич, А.Г. Широков, Д.А. Яловец-Коновалова).

Татар социолингвистикасында исә тел ландшафтының аерым бер аспектларын гына Г.Р. Галиуллина, О.Ф. Хисамов, Р.М. Амирова, М.И. Солнышкина, А.Р. Исмагилова хезмәтләрендә күрергә мөмкин.

Лингвистик ландшафт шәһәрдә, регионда барган иҗтимагый күренешләр тәэсирендә формалаша. Белгечләр фикеренчә, халыкның аңында кайсы телнең роле әһәмиятлерәк булуын ачыклауда лингвистик ландшафт ап-ачык күрсәткеч булып тора. Р.Лэндри билгеләп үткәнчә, күптеллек, икетеллелек һәм глобализация күренешләре дә лингвистик ландшафтны барлыкка китерүдә зур роль уйнылар һәм шунысын да әйтергә кирәк, билгеле бер шәһәрнең лингвистик ландшафтына тел сәясәтенең дә эзе булмыйча кала алмый.

Казан шәһәренә килгәндә, аның лингвистик ландшафты Татарстан Республикасының көнбатыш илләре белән тыгыз иҗтимагый-сәяси, иктисади-мәдәни элемтәләр булуын күрсәтеп тора. Моның сәбәбе төрле өлкәләрдә халыкара хезмәттәшлекнең ныклап үсүе, башка илләрдән күпләп туристларның агылуы һәм ел саен диярлек Казанда дөньякүләм спорт чаралары үтүе булып тора. Шуңа бәйле рәвештә Казанның лингвистик ландшафтының

вестернизацияләнүен, ягъни европалашуын күзәтергә мөмкин. Европалашу ул – европа илләре стандартларының төрле өлкәләргә үтеп керүе. Тел өлкәсендә вестернизация чит тел берәмлекләренең (хәзерге вакытта бигрәк тә инглиз теленнән) үтеп керүе күздә тотыла. Без моны Казан шәһәренең лингвистик ландшафтында да күрә алабыз. Биредә чит тел берәмлекләр кулланылышының ике төп ысулы бар. Ул да булса, кодлар күчеше һәм транслитерация.

Кодларның күчеше вакытында элмә такталарда Татарстан республикасының дәүләт телендә язылган текстында чит тел берәмлеге өстәлә. Мәсәлән, *Ultra ReD2 Казань, Праздничное агентство* ***Fantasy Day****, АГЕНТСТВО Rusart wedding, АГЕНТСТВО Festival d'lux, Праздничное агентство wedding-vip, Априори PR АГЕНТСТВО, "Hes Group" (Хес груп) – ПРАЗДНИЧНОЕ АГЕНТСТВО,VIp зона, АКВАПАРК РИВЬЕРА. ВСЕ ВКЛЮЧЕНО. ГОРКИ, БАССЕЙНЫ, SPA-КОМПЛЕКС, Event. Агентство "Праздничный рай".*

Транслитерация ысулы белән бирелгәннәре дә Казанның лингвистик ландшафтының күпчелеген тәшкил итә: *Квестория, Агентство Торжеств Дабл Ю, Концертное агентство «Смайл», Миссис Хадсон, Агентство фея Винкс, Макдоналдс.*

Европа стандарларының тәэсире йогынтысында кыйммәтләрнең алмашынуы сәбәпле шәһәр объектларын тискәре төсмергә ия номинацияләү хас. Казан шәһәренең лингвистик ландшафтында пейоратив, ягъни тискәре ассоциатив образлы атамалар да күп: *кафе Обжорный ряд, бар MadHouse (англ. сумасшедший дом), кафе Три толстяка, бар Дикий Койот, Детские праздники в научном стиле СумаСшедшая наука, кафе Остап Бендер, центр релаксации Мумия.*

Шулай итеп, Казан шәһәре лингвистик ландшафтының һәрьяклап европалашуын күрдек. Әлеге күренеш шартларында татар теленең Казанның тел ландшафтында кулланылышы нинди дәрәҗәдә икән соң?

Беренче чиратта, эргонимнарны карап үтик. Эргонимнар Казан шәһәре лингвистик ландшафтының зур өлешен тәшкил итә. Мәгълүм булганча, эргонимнар ул – эшлекле оешмаларны, предприятиеләрне, учреждениеләрне атый торган ялгызлык исемнәре.

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы закон кабул ителгәннән соң, оешма атамаларының ике телдә дә язылуы катгый таләп ителә башлады. Бу күренеш бюджет оешмаларының атамаларында аеруча ачык чагылыш таба. Әлеге төр эргонимнарда, кагыйдә буларак, ике компонент та күпчелек очракта татарчага тәрҗемә ителә, татар телендә языла, яисә денотат

гомум кулланылышта йөри торган халыкара сүз белән бирелә. Шунысын да искәртергә кирәк, татарча эргонимнарда беренче компонент, ягъни аерып атаучы компонент, еш кына, денотатны ачыклап килә, ә денонат, кагыйдә буларак, тартым кушымчасы ала, мәсәлән: *Институт филологии и межкультурной коммуникации имени Льва Толстого – Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Татарское книжное издательство – Татарстан китап нәшрияты, Детская республиканская клиническая больница – Республика балалар клиник хастаханәсе һ.б.*

Коммерция оешмаларының атамаларында ике компонентның да татар телендә булуы чагыштырмача сирәк күзәтелә. Кайбер очракта беренче кисәге, ягъни ялгызлык исеме татарча булып та, денотат русча бирелергә мөмкин. Мәсәлән: *«Кояш» фирменный магазин, «Акташ» продукты, «Саулык» аптека, сеть кафе «Алан аш», «Катык» сеть магазинов кулинарии, кафе «Сөембикә», «Файда» сеть магазинов һ.б.*

Шулай ук эргонимнар арасында алынма сүз + *ханә* яисә *лар/ләр* формалары белән ясалганнары да күзәтелә: *бургерханә,сушилар, автозапчастьләр.*

Төрле оешмаларның элмә такталарында эш вакты турындагы мәгълүмат *эш сәгатьләре, эш режимы, эш вакыты* кебек тезмәләр белән бирелә.

Урам һәм тукталыш исемнәренә килгәндә исә, биредә без өч телнең дә чагылыш тапканын күрә алабыз. Беренче нәүбәттә, мәгълүмат рус телендә, аннан соң татар телендә һәм соңыннан инглиз телендә китерелә: *остановка мост "Миллениум - "Миллениум" күпере тукталышы - "Millenium" bridge stop, Мәскәү.ур – ул. Москва – Moscow str.* Бүгенге көндә күпчелек очракта годонимнарны язуда транслитерация ысулы кулланыла – урам атамалары тәрҗемә ителми. Урбонимнарның язылышлары, оригиналдагы аффикслары сакланган килеш, икенче тел материалы белән бирелә.

Күп кенә урамнарда годонимнар татар һәм рус телендә генә бирелә: *Пушкин ур. – ул. Пушкина, Ленина ур. – ул. Ленина, Космонавтлар ур. – ул. Космонавтов.* Шулай ук Казанның кайбер урыннарында татарча атама латин графикасы ярдәмендә китерелгәннәре дә күзәтелә: *Safiullin ur. – ул. Сафиуллина, Profsoyuz ur. - ул. Профсоюзная.*

Юл күрсәткечләрендә мәгълүмат күбесенчә русча һәм инглизчә язылган: *пр-т Ф. Амирхана – ave. F.Amirhana, ул. Мусина – str. Musina Астронимическая улица, университетская улица, хинкальная кафе*

Татар телендә белдерүләр дә сирәк булса да күзәтелә: *эчәргә чиста кофе ;парковканың эш вакыты: 7:00 дән 21:00 гә кадәр якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә түләү алынмый.*

Граффити һәм рәсми булмаган язулар да татар телендә бик аз: *уңышлы көннәр, Асылъяр; Агач – җимеше белән, адәм – эше белән.*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Казан шәһәренең лингвистик ланшафтында тел ассеметриясе күзәтелә. Бу беренче чиратта рус һәм инглиз телләрен күп куллануда чагыла. Алар мәгълүмат тапшыруда төп тел булып торалар. Бу исә татар теленең Казан шәһәренең лингвистик ландшафтында мәгълүмат тапшыруда ихтыяҗы аз булуын һәм бирелә яшәүчеләрнең күбесенең татар телен камил дәрәҗәдә белмәүләрен күрсәтеп тора.

**ӘДӘБИЯТ**


Кузнецова И. И., Дерюшева А. С. Сопоставительный анализ использования эргонимов на центральных улицах г. Казани и г. Ижевска // Научный альманах. 2016. № 3. С.289–293.

Солнышкина М. И., Исмагилова А. Р. Топонимы и антропонимы в эргонимиконе г. Казани // Вестник Вятского государственного университета. 2017. № 8. С. 54–57.

Backhaus, P. Linguistic Landscape. A comparative Study of Urban Multilingualism in Tokyo / P. Backhaus // Multilingual Matters. — New York ; Ontario ; Clevalon, 2007. 158 p.



**А.Н. ГЫЙЛӘҖИЕВА**

*МБОУ СОШ №127, Казань, Россия*


# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШ


**Аннотация**. *В статье рассматриваются вопросы обучения татарскому языку русскоязычных учашихся начальной школы. Предметом изучения являются виды работ с аутентичными текстами из учебника и детских журналов.*

**Annotation**. *The article is devoted to the issues of teaching the Tatar language to Russian-speaking students in elementary school. The subject of study is how to work with authentic texts from a textbook and children's magazines.*



**Ключевые слова.** *Татарский язык, младшие школьники, обучение¸ текст, работа с текстом.*

**Keywords.** *Tatar language, primary school students, teaching¸ text, work with text.*


Чит телгә өйрәтүдә катлаулы, әмма бик әһәмиятле эш төре булып текст белән эш санала. Галим һәм методистлар, укытучылар текст белән эш аша зур уңышларга ирешү мөмкинлеген ассызыклыйлар. Т.М.Корнейчук чит телдәге текст белән эшләүне Федераль дәүләт белем бирү стандартлары куйган таләп,

максатларга ирешү чарасы буларак тикшерә [Корнейчук 2017: 31 – 40], К.П.Словохотов текстны тәрҗемә итү һәм эчтәлеген сөйләүне сөйләм күнекмәләрен автоматизмга җиткерүнең үтемле чарасы дип саный [Словохотов 2017: 41 – 47], Н.И.Торунова, А.Н.Капустина чит телне өйрәнү дәрәҗәсе белән шул телдә укылган, өйрәнелгән текстларны күләме һәм сыйфаты белән турыдан-туры бәйләнеш булуын күзәтәләр [Торунова, Капустина, 2016: 54–59]. Телне үзләштерүдә текснық шундый әһәмиятле роле текст сайлау, текст белән эләү мәсьәләсенә аерым игътибар бирүне таләп итә. Рус яки инглиз телен чит тел буларак укытуда текст белән эшләү мәсьәләсе бүгенге көндә фәнни рәвештә тикшерелсә дә, татар теленә өйрәтүдә әлеге юнәлештә яңа тикшеренүләрне таләп итә торган бушлык, ак таплар әле шактый. Шуңа күрә ул бүгенге көндә актуальлеген югалтмый.

Күп кенә галимнәр чит телле аудиториядә татар телен укыту проблемасына багышланган мәкаләләрендә татар телен өйрәтү нәтиҗәләләренең көтелгәннән күпкә начаррак булуның төп сәбәпләреннән татар теленә укытуның методик яктан дөрес оештырылмавы, укыту-методик чараларның заман таләпләренә туры килмәвен атыйлар. Моның сәбәбе булган факторлар күп булса да, телне үзләштерүдә мотивация булдыру, республикада телнең статусын күтәрү кебек сәяси шартларның да әһәмияте зур булуны искәртергә кирәк. Әмма теләсә-кайсы предметны өйрәткәндә укыту әсбабы булган дәреслекнең роле гаҗәеп зур булуны онытырга ярамый. Телне чит тел буларак укытканда исә дәреслектәге текстларга һәм текст белән эшләү үзенәлекләренә аеруча зур таләпләр куела. Шунысы ачык: соңгы елларда чит телгә өйрәтүне максат итеп куйган татар теле дәреслекләренә һәм уку-укыту ярдәмлекләренә матур әдәбият әсәрләре бик аз санда кертелә. Ешрак дидактик материал сыйфатында дәреслек авторлары үзләре төзегән текстлар бирелә. Мондый текстлар, гадәттә, экспрессиягә ярлы булулары, эчтәлекләре бертөрле булулары белән аерылып торалар. Аларда игътибар этикет формулаларына, театр, мәктәп, китапханәләрдә очрый торган көнкүреш ситуацияләренә юнәлтелә. Мондый типик ситуацияләр белән эш, әлбәттә, кирәк, әмма уку-укыту процессын алар белән генә чикләргә ярамый, текстларның аутентик булулары укучыны көндәлек тормышка яраклашырга өйрәтергә тиешлекне онытмаска кирәк.

Рус төркемнәрендә укучы башлангыч сыйнылар өчен өчен төзелгән татар теле дәреслекләрендә халык авыз иҗатына, бигрәк тә аның кече жанрларына – табышмак, мәкаль, әйтем, сынамыш, мәзәкләргә урын бирелә. Укучыларның игътибарын җәлеп итү максаты белән еш кына халык авыз иҗатының

үзенчәлекле төре – мәзәкләр дә кулланыла. Мисал өчен, Р.Хәйдәрова авторлыгындагы дәреслектә мәзәк “Бергәләп көлик!” рубрикасында тәкъдим ителә: *Мәзәкне укыгыз*

*Укытучы дәрестә бер малайга авазлар турында сөйләргә кушкан. Малай:*

*– Тартыклар: б, в, г, д, ж. Сузыклар: а, ә, ү, у, я... – дип туктаган.*

*– Ә калганнар (остальные)?*

*– Калган авазлар тартылмый да, сузылмый да, – дигән малай* [Хайдарова, Ахметзянова, Гиниятуллина, 2014: 16].

Китерелгән һәм дәреслекләрдә урын алган кайбер башка мәзәкләрне өйрәнү нәтиҗәсендә шундый фикергә килдек: авторлар мәктәп темасына караган мәзәкләрне уку материалы буларак куллана. Дәреслектә бирелгән мәзәкләр текст белән аерым эшләүне күзалламый, бары укып чыгуны, аңлауны гына күздә тота. Әмма мәзәкләрне куллануның уңай ягын чит телне өйрәтү методикасы өлкәсендәге белгечләр иң элек шунда күрәләр: “мәзәк – һәрвакытта да җанлы сөйләм теле чыганагы, ә телне өйрәтүнең төп максаты – коммуникация корырга өйрәтү. Мәзәкләр ярдәмендә укучы очраклы диалогтагы стандарт башлам һәм ахыргы фразаларны, сөйләм клишеларны үзләштерә” [Щеголихина, 2018: 194].

Әдәби текстлар, жанр үзенчәлекләреннән чыгып, шигырь, хикәя, драма әсәрләре текстлары булырга мөмкин. Болар дәреслек авторлары тарафыннан эшкәртелгән аутентик текстлар да, чыганак телдәгечә бирелгән текстлар да була ала. Мәсәлән, шигъри текстлар, аларны үзгәртү мөмкин булмаганлыктан, тыелганлыктан, саф аутентик текстлар (шигырьне кыскартып бирү очракларын чыгарма дип карыйк) буларак тәкъдим ителәләр. Әлбәттә, аларны аңлау рус балалары өчен беркадәр катлаулы да. Әмма әлеге факт та дәреслек авторлары тарафыннан искә алына. Мисал китерик. Р.З.Хәйдәрова авторлыгындагы өченче сыйныф дәреслегендә Бари Рәхмәтнең “Аш вакыты” дигән шигыре бирелә. Шигырьне укыгыз дигән бирем тәкъдим ителә. Шигырь, беренче карашка катлаулы булмаса да, рус баласы аңлавы, бигрәк тә текстның эчтәлеген сөйләве өчен авырлыклар тудыра ала. Каршылык зур булмасын өчен, дәреслек авторлары тарафыннан авыр аңлаешлы сүз яки сүзтезмәләргә аңлатма бирелә: “чайкыйбыз – полощем; дәшмибез, эндәшмибез – не говорим, молчим; түкмибез, чәчмибез – не проливаем, не высыпаем; урынына куябыз – ставим на место” [Хайдарова, Ахметзянова, Гиниятуллина, 3 класс, 1 часть, 2013: 54].

Дәреслекләрдә җыр һәм шигырь текстларына аеруча күп урын бирелү башлангыч сыйныф укучыларына кирәкле материалны истә калдыру өчен уңай мохит тудыра. Шигырь һәм җырлар – материалны үзләштерергә ярдәм итә

торган, укучы тарафыннан эмоциональ уңай итеп кабул ителә торган текст материалы булып тора. Аутентик әдәби яки фольклор материалы телне мәдәни контекстта үзләштерергә ярдәм итә. Поэтик текстлар һәм җырлар чит тел сөйләмендә ритм, интонация өстендә эшләргә ярдәм итә. Дәреслеккә уңышлы кертелгән поэтик текстка мисал итеп, Ш.Галиевнең "Кунаклар" шигырен дә атарга була. Әлеге текст җиңел, йөгерек укыла һәм өченче сыйныф укучылары тарафыннан уңай кабул ителер, дип фаразларга була. Икенчедән, биредә лингвокультурологик кыйммәте булган лексик берәмлекләр күп: укучылар татар халык ашлары – чәкчәк, бавырсак, кош теле, сумса, бәлеш, өчпочмак, гөбәдия, коймак, кыстыбый дигән атамаларны искә төшерәләр. Дәрестә матур төсле сурәтләр кулланып эшләү әлеге текстның дидактик потенциалын тагын да арттыра алыр иде.

Галимнәр фикеренчә, шигъри текстлар ярдәмендә, бер модель буенча төзелгән гыйбарәне берничә мәртәбә кабатлап хәтердә калдыру мәсьәләсен чишәргә була. Кайбер шигырьләр бер модель буенча төзелгән җөмләне кабатлау формасында иҗат ителәләр. Мәсәлән, Р.Миңнуллинның "Әни кирәк" шигыре *(....булсын өчен) [кирәк]* моделе буенча төзелгән иярченле максат җөмләләрне төзергә өйрәтә. Бу эшне катлаулы синтаксик элемент буларак карамыйча, бары тотрыклы грамматик форма буларак карау укучыларга тел өйрәнгәндә нык ярдәм итә.

Чәчмә текстларга хикәя, повесть, романнар, әдәби экиятләр һ.б.лар керәләр. Әлбәттә, башлангыч сыйныфлар өчен язылган дәреслекләрдә алар тулаем түгел, ә бер кечкенә генә өзек – микротекст буларак китереләләр.. Мәсәлән, башлангыч сыйныф укучыларына Рабит Батулла («Чикыл белән Мырый»), Газиз Мөхәммәтшин («Ак песи») һ.б.лар язган текстлар белән эшләргә тәкъдим ителә. Шулай ук дәреслекләрдә тәрҗемә текстлар да урын ала. Мисал өчен, Л.Н.Толстой әсәреннән өзек («Әбисе белән оныгы») татарчага тәрҗемә ителеп бирелә. Аларны уку беренче карашка укучыларда авырлык тудырса да, тел берәмлекләре белән танышу, кызыклы, мавыктыргыч эчтәлекне аңлау уку процессын җиңеләйтә.

Күзәтүләребез күрсәткәнчә, дәреслекләрдә лингвокультурологик яктан кыйммәткә ия текстлар бар. Алар башлыча «Салават күпере» кебек вакытлы матбугат битләреннән алынып, адаптацияләнеп тәкъдим ителә. Мәсәлән, өченче сыйныф дәреслегендә «Тәмле сүзләр», Сабантуй бәйрәме турында һ.б. текстлар шундыйлардан. Текстларның укучылар өчен кызыклы темаларга каравы тәрбияви максатка ирешүгә дә ярдәм итә. Чын дус булырга, дуслык-туганлык мөнәсәбәтләрен сакларга һәм кадерен белергә, туган якка һәм туган

телгә хөрмәт, горурлык, ватанпәрвәрлек хисен уятырга булыша. Текстлар хәзерге заман укучысы кызыксынуларын чагылдырса, аларны укуда, укытучы өчен телгә өйрәтү процессы да күпкә җиңел булыр иде. Текстка карата бирелгән биремнәрне төрләндерү, аларның яңа вариантларын тәкъдим итү исә дәресләрне мавыктыргыч алып баруны тәэмин итәр иде.

## ӘДӘБИЯТ

Юсупов Р. Рус мәктәбендә татар теленә өйрәтү мәсьәләләре // Мәгариф. – 2009. – № 8. – Б. 24–27.

Корнейчук Т.М. Формирование метапредметных умений учащихся основной школы через работу с текстом на уроках английского языка // Английский язык в школе. – 2017. – №1. – С. 31–40.

Словохотов К.П. Перевод и пересказ текста как средства формирования автоматизма речевых навыков учащихся среднего уровня // Английский язык в школе. – 2017. – №1. – С. 41–47.

Торунова Н.И., Капустина А.Н. Художественный текст: лингвистические и лингводидактические аспекты // Педагогический имидж. – Разд. Педагогические науки. – 2016. – №2. – С. 54–59.

Щеголихина М.А. Тексты анекдотов как потенциальный дидактический материал для изучения русского языка как иностранного // Диалог культур. Теория и практика преподавания языков и литератур: VI Международная научно-практическая конференция (9 – 11 октября 2018 г.): Труды и материалы / Под. ред. В.В. Орехова, Е.Я. Титаренко. Симферополь: ИТ “АРИАЛ”, 2018. С. 191–194.

**А. ДОСАНОВА**

*Университет Туран-Астана, Казахстан*

*«Тұран-Астана» университеті «Қазақ тілі мен әдебиеті» мамандығының білім алушысы, Нұр-Сұлтан қ.*

*Ғылыми жетекшісі: «Тұран-Астана» университеті*

*Профессоры, ф.ғ.к Г.Т. Карипжанова*

# АБАЙДЫҢ ДІННИ-ФИЛОСОФИЯЛЫҚ ОЙЛАРЫ ЖӘНЕ ОЛАРДЫҢ МӘНІ

**Аннотация.** В данной статье освещаются религиозно-философские взгляды казахского акына, писателя Абая.

**Annotation**. This article devoted to the religious and philosophical views of the Kazakh akyn, writer Abay.

Тәуелсіздік жылдары алға қойылған міндеттер біртіндеп күрделене түсіп, бүгінгі таңда бәсекеге қабілетті болу жаңа Қазақстандық жол ретінде

айқындалып отыр. Әлемге өзін терезесі тең ел ретінде таныту тек қана дамыған ел тағдыры үшін дін тиімді, сондай-ақ тәуелсіз елдің азаматы ретінде өзін мақтан ете көрсете алатын қоғам мүшесінің жағдайын жасауға бағытталған тәрбиелік, әлеуметтік саясаттың дамуымен, саяси жүйені жетілдірумен және ұлтаралық, конфессияаралық келісімдердің, діни төзімділік принциптерінің қамтамасыз етілуімен байланысты. Осы орайда рухани астарларды, дінге негіздеген жүйесін өздеріне басты ұстаным ретінде тиімді пайдаланып отырған мұсылман мемлекеттерінің тәжірибесін зерттеу және соның негізінде Қазақстанның даму ерекшелігіне баға беру өзекті болып табылады.

Абайтану ісіне, оның өзі айтқандай, қырын, қиғаш келмей, тура келу, сыңаржақтамай, айла-қалтықсыз, әділ жүрекпен, таза ниетпен кірісу керек.

Шыншыл ғадалатты Абайдың есімін атақ үшін, мансап үшін пайдалану адамдық ардың алдында зор қылмыс болмақ.

«Адаспай тура іздеген хакімдер болмаса, дүние ойран болар еді» деген Абай қағидасын осы тұрғыда түсінсек.

«Отыз сегізінші сөзде» Абай: «Хакім, ғалым асылда бір сөз, бірақ дүние тануда басқаланады», дейді.Ол басқалану Абайдың түсінігінде бұрыннан айтылып келе жатқан қағидалы өсиет (нақыл) сөзге жүйріктер ғалым аталады. Олар нақылияға ерушілер болмақ.

Хакімдер бұрыннан келе жатқан нақылия қағидаларды, өсиеттерді жақсы біледі. Сонымен қатар сол білумен қоймайды. Дүниедегі заттардың себепсіз жаралмайтынын біледі. Сол себебін іздейді. Бұл табиғат дүниесінен шындық іздеушілер. Бұлар әрнәрсенің себебін білу арқылы шындық пен жалғандықтың арасын айыра білушілер. Сол арқылы олар адам баласын тура жолға салушылар. Сол жолда олар қанша қиындық болса да соған шыдаушылар; олар алдымен көптің қамын ойлаушылар.

Осы тұрғыдан алып қарағанда Абайдың айтқаны: «Адаспай тура іздеген хакімдер болмаса, дүние ойран болар еді» дегені. Өйткені анық пен танықтың арасын айыра білмеген адам, білмеген халық адаспай бара алмақ емес. Адасқан адам апатқа ұшырауы оңай.

Абайды әрі қарай оқып көрейік:«Бұл заманның молдалары хаким атына дұшпан болады. Бұлары білімсіздік, бәлки бұзық пиғылы...» Ғылым Алланың бір сипаты... Бастың аты –хақ, хақтың бір аты –Алла».

Демек, Абайдың ең басты жұмбағының шешуі іздеушілік, зерттеушілік, ол хакимдік, данышпандық –философтық (Фәлсафалық) жол. Ол даму жолы, ол ғылым жолы... Демек, мұнан келіпшығады: «Өмірдің өзі ақиқат, өмір жоқ жерде камалат жоқ». Дүние де өзі, мал да өзі, ғылымға көңіл бөлсеңіз...Ақыл

сенбей сенсеңіз, бір іске кез келсеңіз... Надандарға бой бермей, шын сөзбенен өлсеңіз».

Абайдың өзімен сөзі екі ұдайы емес, екеуі бір жерден шығады, Абайдың даналығы осында. Абайдың жақсы білетін бір қарттың айтқаны бар: «Абай сынына толмаған сөзді аузына алмайды». Басқаша айтқанда Абайдың аузына алған әрбір сөзінің арғы жағында терең тамырлы, күрделі мағына жатады... «Ақыл, Қайрат, Жүректі бірдей ұста, Сонда толық боласың елден бөлек»...Басқаша айтқанда ойлау-зерттеу әрекеті, оны іске асыру, өмірге лайдалану әрекеті, адамдық сезім, әділеттік іс-әрекет. Немесе іздену, өмір, адамдық. Осылар бас қосқан жерден ғылыми шындық шығады.

Ғылым үйрену, өнер үйрену өзі де жақсылық жолы –ихсан. Бірақ ол өнерді адамдық, әділетті жолға жұмсау шарт. Халықтың қамына жұмсау шарт.

Абайдың ғылым жолдары жөніндегі өсиеттері көптеген өлеңдерінде бар. Ол кісінің 17 және 31, 32, 38 сөздері түгелдей осы мәселеге арналған.

«Білім-ғылым үйренбекке талап қылушыларға әуелі білмек керек...» Талаптың өзіндік шарттары бар:

Абай шарттарының қысқаша мазмұны мынадай:

Бірінші шарт: Білім-ғылымды іздenуде күнделікті ұсақ іске жарата қою үшін, немесе біреуден артылыу үшін, ерекшеленіп мақтану үшін іздену болмау керек. Ғылымға алдымен берік ынта-ынтықтық, білмегенді біле беруге құмарлық, махаббат керек. Білмегеніңді білген сайын сол құмарлық арта береді, жүрегің қанағаттанып, көңіл орнығып, сенім арта бермек. «Адамның көңілі шын мейірленсе, білім-ғылымның өзі де адамға мейірленіп, тезірек қолға түседі. Шала мейір шала байқалады».

Екінші шарт: Ғылымнан ақиқат табу мақсатын қою. Өз айтқанымды ғана болдырам деп, бос сөз таластыру үшін ғылымға қол созба. Пікір таластыру өзі де ғылымның бір жолы, талсатан пікір ашылады, шындық ашылады, көңіл бекиді. Бірақ ол таласта тек өзімдікі ғана дұрыс деп қатып қалу жаман. Ондай өз сөзін ғана іске асыру мақсатын қоюдың түбінен ғылыми шындық тумайды, өзімшілдік, күншілдіктуады. Оның ақырынан адамдыққа да, ғылымға да зиян келеді. Осы арада еске ала кететін нәрсе Абайдың «Мутакаллим, мантығын бекер босқа езе дүр», қағидасын осы мағынада түсіну керек. Бұл мәселеге кейін ораламыз.

Үшінші шарт: Әрнәрсенің шындығына өз көзің толық жеткенде ғана, сенімің берік болғанда ғана, соны ғылым тұт. Сенімің берік болмаса ол ғылым емес. Ақиқатына көзің жетсе, онан ешуақытта айырылма.

Төртінші шарт: Ғылымды үздіксіз зорайтып, молайтып, көріктеп отыратын нәрсе керек, -ол ақыл ойдың ісі. Ақыл ой арқылы көркейіп отырмаса ғылым дамымайды, өспейді, өшеді.

Бесінші шарт: Ғылымда салғырттықтан, еріншектіктен сақ болу керек, ол үшін еңбек ету керек. Сол іске асыруда белгілі болған жақсыларын әрі қарай дамыта беру керек, жарамсыздарын тастау керек.

Алтыншы шарт: Ғылым-білімде ұстамдылық қажет, ақыл ойдың, мінездің беріктігі керек, ол үшін қайрат керек. Ғылымды да, ақылды да сақтайтын сауыт сол ұстамдылық, табандылық мінез.

Сол мінез бұзылмасын, көрсе қызарлықпен, жеңілдік я біреудің орынсыз сөзіне, я бір кез келген қызыққа шайқалып қала берсең мінездің беріктігі бұзылады. Онан соң оқып үйреніп те пайда жоқ, қоярға орны жоқ болған соң, оларды қайда сақтайсың? Қылам дегенін қыларлық, тұрам дегенің тұрарлық, мінезде азғырылмайтын ақылды, арды сақтарлық, беріктігі, қайраты бар болсын. Ол бір ақыл үшін, ар үшін болсын.

Сонымен Абайдың ғылыми жолы: құмарлық –махаббат, шыншылдық, әділет, берік сенімділік, ғылымды дамытатын нұрлы , ойлы парасат, жақсыны іске асырып отыратын батыл еңбек, шындықты сақтайтын ұстамды қайратты мінез: Абайша айтқанда: «ақыл, қайрат, жүректі бердей ұста», «Ғылым сол үшеуінің жолын білмек» дегені осы айтылған шарттардың көркемдік бейнесі болса керек...

Жоғарыда айтылған білім-ғылым шарттарын орындау көрінген адамның қолынан келе бере ме? Тәрбие арқылы адамды тура жолға қоюға бола ма? – деген сияқты мәселелерге Абайдың беретін жауабы бірнеше сатыларға бөлінеді. Алдымен Абай тәрбие ісіне зор мән бергені мәлім.

«Мен, егер закон қуаты қолымда бар кісі болсам, адам мінезін түзеп болмайды деген кісінің тілін кесер едім», -дейді Абай.

Бұл тұжырымға келгендегі Абайдың табиғи тірегі адамның табиғи қасиетіне сену. «аз ба, көп пе білсем екен, көрсем екен деген арау (тілек), бұлардың да басы жибли (табиғи тілек). Ақыл, ғылым –бұлар кәсіби (еңбекпен табылатын нәрсе)».

Діннің уақыт өте келе өріс алып дамуы әрбір адамның және қоғам өмірінің сұраныстарын барынша қамтуға талпыныс білдіретін халықаралық ұстанымдарға сәйкестендіре түсу. Тарихтың тереңіне кеткен рухани мұра туындыларын қайта жаңғыртып, халықаралық деңгейге көтеру керек. Дегенмен, қоғамда орын алып отырған мәселелер де жоқ емес.

Қазақстандағы қазіргі діни ахуалдың күрделі әрі сан-салалы екендігі деректерден белгілі. [1] Өткенінде атеистік идеологияны бастан кешірген қоғам тәжірибесін ескеретін болсақ, мәселе күрделене түседі. Алғашқы кезде оңы мен солын салқын ақылдың сарапшысына салумүмкіндігі болмаған ел, қоғамның рухани сұраныстарын қанағаттандырудан гөрі, материалдық жағдайды көтеруге бар күшін салды.

Ислам дінін зерттеуде атап кетерлік жай, исламдық, не христиандық, арабтық не американдық болып бөлінбеуі. Қоғамның қатынастар жүйесі ретінде діни ұлттық ерекшеліктерге байланысты туындайтын мәселелерге негізделмей жалпы адамзат игілігіне жол бастауы тиіс, ягни ел мүддесін ескеретін қатынастар негізінде бір ғана қағида болу керек, ол–адамдық пен әділеттік, адамдар арасындағы, мемлекеттер арасындағы әлеуметтік, экономикалық қарым-қатынастарды шешудегі адалдық. Қай істе де, не нәрсеге де адал да әділ болу–бұл исламның бірден-бір негізі болып табылады. Және бұл қағида исламның тәрбиелік-әлеуметтік жүйесінің іргесі болып табылады.

Қоғамда рухани-ізгілікке тәрбиелеудегі исламның ролімен орны жан-жақты, кең ауқымда қарастырылмақ.

Абайдың мұсылман хакимдері деп те ерекше арнап айтып отырған себебін дұрыс түсіну қажет. Өйткені адам баласының бәрі досың деген Абай бұл арада мұсылмандықты неге алға қойған? Оның себебі ислам діні ең ақырғы дін. Ол адам баласының тарихи, табиғи, ғылыми, рухани, діни өрлеу сатысының шыңына жеткен заманда дүниеге келген. Ол өзінен бұрынғы діндердің адамзатқа ортақ пайдалы жақтарын жинақтаған қорытынды дін, ғылыми дін. Ғылым үйрену исламның зор парызы болып саналады.

**ПАЙДАЛАНЫЛҒАН ӘДЕБИЕТТЕР**

Байтекова Н.Ж. Қазақстан президентінің «Жаңа Әлемдегі жаңа Қазақстан» атты жолдауындағы Қазақстандағы конфессияаралық келісім мәселесін. Халықаралық ғылыми практикалық конференцияның материалдары. Алматы, 2007. Б. 3-7.

Мұханмадияр Орынбеков. Қазақ сенімдерінің бастаулары.–Алматы: Қазақ университеті, 2002.Б. 102-128.

Вебер М. Протестандық этика және капитализм рухы.// Әлемдік әлеуметтану антологиясы. Мәдени мұра бағдарламасы. Алматы: 2006. 480 б.

Мейірбаев Б.Б Қазіргі дәстүрден тыс діни қозғалыстар мен культтер. Алматы: Әрекет-принт.2009. 275 б.

Машанов А. Әл–Фараби және Абай. Алматы «Қазақстан» 1994. Б.173-174.

**Г.А. ҖӘЛӘЕВА, Ф.Ф. ХАРИСОВ**
*Казан федераль университеты, Россия*

# БЕЛЕМ БИРҮДӘ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

**Аннотация.** Объектом данного исследования является здоровьесберегающие технологии в современном учебно-воспитательном процессе. В статье определены основные группы, компоненты, средства, обозначены специфические особеннности и задачи перед учителями в ходе использования здоровьесберегающих технологий в процессе обучения татарскому языку.

**Abstract.** The object of this study is health-saving technologies in the modern educational process. The article identifies the main groups, components, tools, identifies specific features and tasks for teachers in the use of health-saving technologies in the process of teaching the Tatar language.

**Ключевые слова:** метод, сәламәтлек саклау технологиясе, модульле укыту, татар теле, белем бирү, физкультминуткалар

**Keywords:** method, health-saving technology, modular training, Tatar language, knowledge, PE-lessons

Фән һәм техника алга киткән саен, тормышның һәр өлкәсе зур үзгәрешләр кичерә. Алар белем бирү өлкәсен дә читләтеп үтми. Бу эшнең сыйфатын тагын да яхшырту өчен, яңа методлар һәм технологияләр барлыкка килә. Билгеле булганча, технология сүзе грек теленнән алынган. Ул сәнгать, осталык дигән мәгънәне аңлата. Технология – кайсы да булса фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланыла торган методлар, алымнар һәм ысуллар җыелмасы ул. Мәсәлән, педагогик технология укытуны, белемнәр үзләштерүне, идея-фикерне, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала.

Соңгы елларда белем бирү өлкәсендә модульле укыту методы (Т.И. Шамова, П.И. Третьяков, И.В. Сенновский), үстерелешле укыту методы (И.С. Якиманская, Л.В. Занков, А.З. Зәкиев ), уен формасында укыту методы (Ш.А. Амонашвили, О.В. Канарская, Д.Б. Элъконин), проблемалы-эвристик укыту методы (А.В. Хуторской), кечкенә төркемнәрдә укыту методы, проект нигезендә укыту методы, мәгълүмат чаралары ярдәмендә укыту методы (Е.С. Полат), алгоритмнар нигезендә мәгълүмат чаралары кулланып укыту методы (Н.Н. Алгазина) һ.б. бар.” [Шәкүрова, 2012: 15]

Хәзерге вакытта “сәламәтлек саклау технологиясе” дигән төшенчә барлыкка килде. Мәгълүм ки, төрле галимнәр әлеге төшенчәне үзенчәлеклерәк итеп аңлата. Н. К. Смирнов “Белем бирүдә сәламәтлек саклау технологиясе” төшенчәсен беренчеләрдән булып кулланучы дип санала. Аның фикеренчә,

балаларның сәламәтлеген саклау өчен, укытучы табиблардан да күбрәк эшли ала. Ул белем бирүдә сәламәтлек саклау технологияләрен куллану педагогиканың технологик нигезен тәшкил итә һәм аны балаларның сәламәтлегенә зыян китерми торган методлар һәм формалар берлеге дип билгели. [Смирнов, 2002: 78]

Сәламәтлек саклау технологиясен “сәламәтлек куркынычсызлыгы сертификаты” һәм традицион технологияләрне, сәламәтлек саклау бурычлары белән тулыландыра торган педагогик эшчәнлекнең методлар, алымнар һәм принциплар күплеге дип карарга була. [Селевко, 1998: 125]

Педагогика фәннәре докторы, В.В. Сериков фикеренчә, сәламәтлек саклау технологиясе баланың табигый сәләтен: акылын, әхлакын, эстетик тойгыларын, эшчәнлеккә ихтыяҗын, кешеләр, табигать, сәнгать белән аралашуда беренчел тәҗрибәләрен үстерүне тәэмин итәргә тиеш. Ә кайбер галимнәр фикеренчә, сәламәтлек саклау технологиясе ул – баланың мәктәптә белем алу шартлары һәм белем бирүне файдалы итеп оештыру, уку-укыту, физик эш күләменең укучының яшь үзенчәлекләренә туры килүе.

Шулай итеп, сәламәтлек саклау технологиясен белем бирү мохитенә начар йогынты ясый торган факторлардан укучы һәм укытучыларны саклаучы гына түгел, бәлки барлык методлар, алымнар, технологияләр күплеге ярдәмендә балаларда сәламәтлек культурасы булдыру дип тә аңларга кирәк.

Татар теленнән белем һәм тәрбия бирү процессында кулланыла торган сәламәтлек саклау технологияләрен дүрт төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Белем бирү процессында оптималь-гигиеник шартлар булдыра торган технологияләр.
2. Укучыларның физик активлыгын һәм белем бирү процессын оештыруны оптимальләштерергә ярдәм итә торган технологияләр.
3. Дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек вакытында укытучы һәм тәрбиячеләр куллана торган психологик-педагогик технологияләр.
4. Сәламәтлек саклау юнәлешендәге белем бирү технологияләре.

Сәламәтлек саклау технологиясенең төп компонентлары:

- аксиологик, балалар аңына сәламәтлекнең төп кыйммәт булуын сеңдерү һәм сәламәт яшәү рәвеше алып бару кирәклеге турында ышанганлык тәрбияләү;
- гносеологик, үз сәламәтлегеңне кайгырту һәм саклау буенча белем алу, сәламәтлеккә тискәре тәэсир итәргә мөмкин булган хәлләрне алдан кисәтү;

- эмоциональ, эмоциональ-психологик механизмнарның күренеше; алар шәхеснең җәмгыятьтә яшәвен тәэмин итәләр, аерым кешенең һәм барлык коллективның сәламәтлеген саклау;
- экологик, табигатьтә кешенең биологик төр буларак тереклек итүе;
- физкультура-савыктыргыч компонент, актив хәрәкәтне арттыруга юнәлдерелгән алымнарны күз уңында тоту.

Татар теле дәресләрендә кулланылырдай сәламәтлек саклау чараларын биш төркемгә бүләргә мөмкин.

1. Педагогик-оештыру чаралары. Аларга СанПиНга нигезләнеп оештырылган белем бирү процессын оештыра.
2. Педагогик-психологик чаралар. Әлеге төркемгә укытучының белем бирү процессында укучыларга ясаган йогынтысына бәйле чалалар карый.
3. Уку-укыту, тәрбия чаралары. Белем бирү оешмаларында кулланылган барлык программалар сәламәтлек культурасын формалаштыруга, начар гадәтләрне кисәтү, сәламәт яшәү рәвеше алып баруга өнди.
4. Шәхси-үсеш алу һәм җәмгыятькә җайлашу чаралары. Укучыларның психологик җайлашуын, формалашуын һәм ныгуын истә тота.
5. Дәвалау-савыктыру чаралары. Укучыларны санитар-гигиеник яктан белемле итә, медицина хезмәтенә караган профилактик чаралар арасында дәвалау физкультурасы һәм дәвалау педагогикасы да була ала.

Уку-укыту процессының үзгәреше сәламәтлек саклау технологиясен куллануның нәтиҗәсе булып тора һәм аларда түбәндәгеләр күзәтелә:

- баланың яшь һәм шәхси үзенчәлекләренә туры килгән белем бирүнең күләме;
- расписание һәм белем бирүнең тиешле таләпләргә туры килүе;
- уку-укыту процессының физик эшчәнлек белән чиратлашып баруы;
- балаларның физик активлыгын үстерү;
- адекват мидицина һәм психологик ярдәм алуга мөмкинлек тудыру;
- ата-аналарны актив мәктәп тормышына җәлеп итү;
- укучыларда сәламәт яшәү рәвешенә карата кызыксыну арттыруда системалы эш алып бару;
- укытучының сыйныфта уңай психологик климат булдыруы;
- укучыга шәхси якын килү;
- коррекцион эшне даими рәвештә алып бару;
- методик һәм белем бирү технологияләрен яшь үзенчәлекләреннән чыгып куллану.

Безнең фикеребезчә, рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен өйрәткәндә, сәламәтлек саклау буенча төрле технологияләрне кулланып була:

- физкультминутлар;
- арттерапия;
- психогимнастика;
- релаксация (“биш минут тынлык”);
- сулыш гимнастикасы;
- күз, кул, арка һәм муен гимнастикасы;
- “табигать тавышларын”, “океан көйләрен” тыңлау һ.б. [Харисов, 2018: 45]

Шулай итеп, хәзерге заман мәктәбендә сәламәтлек саклау технологияләренең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- сәламәт яшәү рәвешенә юнәлгән сәламәт шәхес тәрбияләү;
- уку-укыту процессын баланың сәламәтлегенә зыян китерми торган итеп оештыру;
- укучының сәламәтлеген үстерү һәм саклау чараларын актив һәм даими акуллану мөмкинлеге булу.

Белем бирүнең яңа сыйфаты бары тик сәламәтлек саклауда аерым шартлар булдырылганда гына тормышка ашарга мөмкин. Болар барысы да мөгаллимнәрдән белем бирү процессына аерым якын килүне таләп итә. Сәламәтлек саклау һәм үстерү буенча белем бирә алу хәзерге заман укытучысының һөнәри компетенциясе дәрәҗәсен билгели. Димәк, укытучы уку-укытуда сәламәтлек саклау технологияләрен һәрвакыт киң кулланып, барлык технологияләр арасыннан укучыны уңышлы белем алуга китерә торганын сайлап ала белсен иде.

## ӘДӘБИЯТ

Селевко П.К. Современные образовательные технологии: Учебное пособие. М.: Народное образование, 1998. С. 189.

Смирнов Н.К. Здоровьесберегающие образовательные технологии в работе учителя и школы. М.: АРКТИ, 2003. С. 178.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр) / Научное наследие методики преподавания татарского языка (конец XVIII – нач. XX вв.). Казан: Ихлас, 2012. Б. 15

Харисов Ф.Ф. Татар теле: теория һәм практика. Монография. Казан: Ак бүре нәшр., 2018. Б. 341.

**Г.Р. ЗАКИРОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# А.С. ПУШКИН ӘКИЯТЛӘРЕНЕҢ КАЗАХ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

**Аннотация.** В данной статье рассмотрены лексические особенности в переводах сказок А. Пушкина на казахский и татарский языки. Для анализа были взяты сказки А.С. Пушкина «Золотой петушок» и «Сказка о рыбаке и рыбке» и их переводы на казахский и татарский языки.

**Abstract.** This article discusses the lexical features in translations of A. Pushkin's tales into the Kazakh and Tatar languages. For analysis, fairy tales by A.S. Pushkin's “The Golden Cockerel” and “The Tale of the Fisherman and the Fish” and their translations into Kazakh and Tatar languages.

**Ключевые слова:** трансформация, лексические трансформации, особенности перевода, сказки А.С. Пушкина

**Keywords:** transformation, lexical transformations, translation features, tales of A.S. Pushkin

А.С. Пушкинның 1834 нче елда язылган «Сказка о золотом петушке» әкияте татар теленә ике тапкыр тәрҗемә ителгән. Беренче тапкыр Г.Тукай тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Алтын әтәч» исеме белән 1908 нче елда И.Н. Харитонов матбагасында аерым китап итеп басылып чыккан. Аның беренче битендәге астөшермәдә «Пушкинның "Сказка о золотом Петушке" нам хикәясеннән алынмыш» диелгән юллар бар. Әкиятнең икенче тәрҗемәсе 1934 Ш.Маннур тарафыннан «Алтын әтәч турында әкият» исеме белән ясалган. Ә казах теленә тәрҗемәсе Әхмәт Байтурсынов тарафыннан “Алтын әтеш” әкияте исеме белән ясалган.

Күренекле әдипнең «Сказка о рыбаке и рыбке» әкияте дә иң күп тәрҗемә ителгән әсәрләреннән санала. Бу әсәрнең татар телендә дүрт тәрҗемәсе билгеле: Г.Рахманкулый «Балыкчы һәм балык» (1901), И.Байчераков «Алтын балык» (1919), Ф.Кәрим «Алтын балык белән балыкчы карт турында әкият» (1946), Ә.Исхак «Балыкчы һәм балык турында әкият» (1949). Ә казах телендә бер тәрҗемәсе билгеле: Ә. Байтурсынов “Балыкшы мен балык”. Әлеге әкиятләр шулкадәр мавыктыргыч ки, аларны хәтта тәрҗемә әсәр булуларын да тиз генә аныклап булмый.

Әлеге хезмәттә А.С. Пушкинның «Сказка о золотом петушке» һәм «Сказка о рыбаке и рыбке» әкиятләренең татар һәм казах теленә тәрҗемәләрендә урын алган лексик сурәтләү чаралары тикшерелде һәм аларны

тәрҗемә итү үзенчәлекләрен ачыклау максат итеп куелды. Тикшерү нәтиҗәләреннән түбәндәгеләр мәгълүм булды.

1. Әкиятләрдә метафоралар зур урынны алып тора. Метафораларны тәрҗемә итүдә иң күп кулланылган ысул - сүзгә-сүз тәрҗемә. Мисалларга мөрәҗәгать итик: ***Золотая рыбка*** *– алтын балык (Ә.Исхак тәрҗ.); алтын балық (Ә.Байтурсынов тәрҗ.);* ***Черная буря*** *– кап-кара давыл (Ә.Исхак тәрҗ.*), *қара дауыл (Ә.Байтурсынов тәрҗ.);* ***Золотые перстни*** *– алтын йөзекләр (Ә.Исхак тәрҗ.), алтын жүзік (Ә.Байтурсынов тәрҗ.);* ***Красные сапожки*** *– кызыл читекләр (Ә.Исхак тәрҗ.) оюлы етік (Ә.Байтурсынов тәрҗ.) һ.б.*

2. «Сказка о золотом петушке» әкиятенең рус вариатында файдаланылган күп кенә метафоралар казахчага һәм татарчага тәрҗемә ителгәндә гадиләштерелгәннәр. Мәсәлән:

| *А.С. Пушкин* | *Ш.Маннур* | *Г. Тукай* | *Ә.Байтурсынов* |
|---|---|---|---|
| *“Ан с востока лезет рать! Справят здесь, —* ***лихие гости*** *Идут от моря. Со злости”* | *“Алар көтсә көньяктан –* ***Яулар*** *килгән төньяктан.”* | *“Мәмәт хан гаскәре көткәндә таудан йә тигез җирдән, — Карыйлар:* ***бихисап дошман*** *килеп тә җитте диңгездән.”* | *«Оңнан күтсе, жау солда, Қырдан күтсе, жау суда, Сырттан десе, құбыладан. Жан-жағынан* ***жау*** *ұрды...”.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *“Вот мудрец пе-ред Дадоном Стал и вынул из мешка* ***Золотого петуш-ка****.”* | *“Менә карт шул чагында Баса Дадон алдына Һәм ала килеп җиткәч, Капчыктан* ***алтын әтәч****.”* | *“Хәкимгә: «И хәким! мин бик авыр хәлләргә калдым! — ди, Йә күрсәт хикмәтеңне, кыйлчы бер эш, кыйлчы ярдәм», — ди, Хәким, бер капчык аузына кулын сала да сызганып, Куя хан алдына шуннан гаҗәп* ***Алтын әтәч*** *алып.”* | *“****Алтын әтеш*** *шығарды Аузын шешіп дорбадан.”* |

3. "Сказка о золотом петушке" әкиятендәге чагыштурылар тәрҗемәдә үзгәртелеп биреләләр. Мәсәлән:

| *А.С. Пушкин* | *Ш.Маннур* | *Г. Тукай* | *Ә.Байтурсынов* |
|---|---|---|---|
| *“В сарачинской шапке белой, Весь* ***как лебедь поседелый****, Ста-рый друг его, скопец.”* | *“Каршысына ак чалмалы,* ***Аккоштай ак чәч-сакаллы*** *Теге дус карты баса.”* | *“Карап күрсә: йөзе нурлы бер аппак бүрекле карт —* ***Җитен төсле сакалы ак,*** *кыяфәтчә күрекле карт.”* | *“Ақ бөркі бар басында. Ет жоқ, ұрты суалған,* ***Сақал, мұрты қуарған, Қара қыл жоқ шашында.”*** |
| *“Чуть опасность где видна, Верный сторож* ***как со сна*** *Ше-вельнется, встрепенется, К той сторонке обернется”* | *“Шик күренсә әз генә, Туры сакчы* ***тиз генә*** *Кузгала да канат кага, Борыла шул якка таба:”* | *“Ханның мәсҗеде башына бәс Алтын әтәче кунды; Карый һәр якны: алны-артны, өстне-астны, уң-сулны. Кагынмый һәм чыгармый тын да — һәр якны тыныч* | *Тәрҗемә итмәгән.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *күрсә;*<br>***Уянгандай йокыдан,***<br>*кагынадыр — куркыныч күрсә. “* | |

«Сказка о рыбаке и рыбке» әкиятендә рус телендәге чагыштыруларны казах һәм татар телләренә сүзгә-сүз тәрҗемә итү өстенлек алган: ***море слегка разыгралось, помутилося синее море, неспокойно синее море*** *– диңгез аз гына чайкала, зәңгәр диңгезнең өсте болганган, диңгезнең өсте тынычсызланган, диңгезнең өсте тәмам каралган (Ә.Исхак тәрҗ.), жыбырлап судың беті шимайланып, бұзылып судың түсі лайланып (Ә.Байтурсынов тәрҗ.);* ***так и вздулись сердитые волны, так и ходят, так воем и воют*** *– улап һәм үкереп йөри дулкыннар (Ә.Исхак тәрҗ.), Сапырып теңіз суын, желдетеді (Ә.Байтурсынов тәрҗ.).*

4. «Сказка о золотом петушке» әкиятендә файдаланылган фразеологизмнар бик уңышлы тәрҗемә итеп биреләләр: *«Царь скопца благодарит,* ***Горы золота сулит»*** - "*«Кат-кат аңа рәхмәт ди,* ***Вәгъдә итә тау-тау алтын.****» (Ш. Маннур тәрҗ.); “ Риза болып, айтар хан:* ***Бүйым алтын, күміс пе? Басқа мүдде, жұмыс па?****” (Ә. Байтурсынов тәрҗ.) һ.б.* «Сказка о рыбаке и рыбке» әкитендә фразеологизмнарны тәрҗемә итүдә сүзгә-сүз тәрҗемә ысулы кулланылган: «***Не садися не в свои сани****»* – "***Утырма кеше чанасына***" *(Ә.Исхак тәрҗ.); “****Болмаса өзін шанан, отырма»*** *(Ә. Байтурсынов тәрҗ.)*

5. А.С. Пушкин "Сказка о золотом петушке" әкиятендә кулланылган синонимнар һәм антонимнар тәрҗемәчеләр бик уңышлы файдаланганнар, төп мәгънәсе аңлауга зыян китерә торган һәртөрле кабатлауларга урын калдырмаганнар. Мәсәлән: ***угомонился, утих, умолк*** - *тына, бетә, тынды (Ш.Маннур тәрҗ.);тынды, тукталды, тын алмыйча каткан (Г.Тукай тәрҗ.); тыныш, тоқтатылды (Ә. Байтурсынов тәрҗ.);* ***молвил, сулит, говорит*** - *ди, вәгъдә итә (Ш.Маннур тәрҗ.); ди, әйтә (Г.Тукай тәрҗ.); айтар, дейді, деді (Ә. Байтурсынов тәрҗ.);* ***бранится, ругает, бунтует, вздурилась, осердилася*** *– тиргәгән, кыздырган, акырган, ярсыган, гаугалый, боерган (Ә.Исхак тәрҗ.); дурачина, простофиля – юләр, ахмак, беркатлы (Ә.Исхак тәрҗ.); ақымақ, алжыған (Ә. Байтурсынов тәрҗ.).*

Югарыдан күренгәнчә, антонимнар казах һәм татар телләренә сүзгә-сүз ысулы белән тәрҗемә ителгәннәр. Шунысын әйтү дә бик мөһим: әсәрдә антонимнар күп түгел.

"Сказка о рыбаке и рыбке" әкияте контекстуаль антонимнарның күп кулланылуы ягыннан аерылып тора. Казах һәм татар телләрендә алар барысы да чагылыш тапканнар. Мәсәлән: ***разбитое корыто - новое корыто*** *– ярык тагарак - яңа тагарак (Ә.Исхак тәрҗ.); жаңа астау – жарылған астау (Ә. Байтурсынов тәрҗ.);* ***ветхая землянка - изба со светелкой*** *– искереп беткән землянка - кирпеч морҗалы, чарлаклы бер өй (Ә.Исхак тәрҗ.).*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, А.С. Пушкин әкияте казах һәм татар телләрендә дә бик кызыклы, аһәңле яңгырый. Тәрҗемәләр төрле авторлар тарафыннан башкарылган булуга карамастан, алар бер-берсен кабатламыйлар һәм оригинал текстка зыян китермиләр.


**ӘДӘБИЯТ**

Байтұрсынұлы А. Алтын әтеш // UPR: http://bilim-all.kz/olen/146-Altyn-atesh

Байтұрсынұлы А. Балықшы мен балық // UPR: http://bilim-all.kz/olen/150

Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. 6 томда/ Академик басма. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908)/ төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М.Кадыйров, З.Г.Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш.Хисамов, З.З.Рәмиев. Казан: Тат. кит. нәшр., 2011. 407 б.

Пушкин А.С. Балыкчы һәм балык турында әкият (Ә.Исхак тәрҗемәсе) / А.С.Пушкин. Казан: Татгосиздат, 1949. 19б.



**А.И. ЗИННӘТОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


## Ә. ЕНИКИ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ЯЛГЫЗЛЫК ПРОБЛЕМАСЫ


**Аннотация.** Многочисленные рассказы и повести, публицистические выступления Амирхана Еники и сегодня привлекают читателя красотой родного языка, изящностью стиля, искренностью чувств, правильностью характеров и поразительной современностью. Данная статья посвящена выявлению темы одиночества в произведениях писателя. Приведены примеры проявления темы одиночества в его работах.

**Annotation.** Numerous stories and tales, publicistic speeches by Amirkhan Enika still attract readers with the beauty of their native language, graceful style, sincerity of feelings, correct characters and amazing modernity. This article is devoted to identifying the topic of loneliness in the writer's works. Examples of the manifestation of the theme of loneliness in his works are given.



**Ключевые слова:** одиночество, война, свобода, трудности, жизнь.

**Keywords:** loneliness, war, freedom, difficulties, life.


Татар әдәбиятында сугыш темасын чагылдырган әсәрләр күп. Сугыш елларындагы ачлык, ялангачлык, сугыш кырларында ятып калган корбаннар, фашистлар тоткынлыгында хурлыклы һәм мәсхәрәле үлемен көткән әсирләр язмышы татар язучыларын тетрәндерә, уйланырга мәҗбүр итә.

Шундый тетрәнүләргә битараф кала алмаган язучыларыбызның берсе Әмирхан Еники. Ул 1909 нчы елның 17 февралендә элекке Өфә губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстанның Болгавар районы) Яңа Каргалы авылында таза хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Ә. Еники үз гомерендә бик күп авырлыклар аша уза, иң зур сынауларның берсе – ул Бөек Ватан сугышы. Сугыш – күпләрне ялгыз калдыра һәм бу мәсьәлә аның сугыш чоры һәм сугыштан соңгы, мөстәкыйль һәм тотрыклы эчтәлек-форма компоненты, ялгызлык мотивы буларак урын ала. Сугыш һәм сугыштан соңгы чор иҗатында Ә.Еники сугыш алып килгән котылгысыз фаҗигаләр, югалтулар булып дәвам иткән күренешләр, хәлләр турында яза. Аеруча сугыш һәм сугыштан соңгы елларда кичерелгән ялгызлык, сугышта алган тән җәрәхәтләре өстенә авыр җан газапларының сурәтләнеше булган – ялгызлык проблемасы – бер генә укучыны да битараф калдырмый. Аның «Ялгыз каз» (1944) һәм «Мәк чәчәге» (1944) кебек хикәяләре татар психологик прозасының матур үрнәкләре булып саналырга хаклы. Аларда сугыш вакытларында гади кешенең рухи чыдамлыгы, тыйнаклыгы, юлындагы авырлык-кыенлыкларны батырлык белән кичерүе һәм тормышка, яшәүгә булган тирән ышанычы сурәтләнә.

Ә.Еникинең сугыш чорында иҗат ителгән хикәяләренең берсе – «Ялгыз каз» дип атала. «Ала казның хуҗасы ялгыз торучы Маша исемле бер хатын була. Әсәр башыннан безгә Машаның ире фронтка киткәнлеге, ә җитеп килгән бердәнбер кызы шәһәрдә эштә булганлыгы беленә . Машаның әнә шул ялгыз казыннан башка янә ике бәрәнле ак кәҗәсе һәм янып торган кып-кызыл мәһабәт этәч җитәкчелегендә биш тавыгы да бар. Болар барысы да ялгыз Маша өчен йорт байлыгы гына булмыйча, аның күңелен юаткан гаилә» [Еники, 1991: 45-46]. Хикәядә каз образы сынландырылып бирелә. Без аның ялгызлыгын, аны чолгап алган кош-кортларның, кешеләрнең сугыш нәтиҗәсендә газап чигеп яшәргә тиеш булуларын күрәбез.

Әсәрдә нинди ялгызлык турында сүз бара соң? Немецлардан азат ителгән авылда безнең солдатлар бер каз күреп гаҗәпләнәләр. «Әгәр безнең солдатлар Калинин урманнарында тәвә кошын очратсалар, бу кадәр гаҗәпләнмәсләр иде: меңләгән авылларны фашистлар коллыгыннан азат итеп, безнең беренче тере каз күрүебез иде» [Еники, 1991: 45]. Күп авылларда нәселләре дә калмаган сирәк очрый торган, могҗизага әйләнгән каз турында сүз бара. Ул повар Иван белән дуслашып китә, аңа ияреп, «эшкә бара, эштән кайта», үзе туктаусыз сөйләнә, нәрсәдәндер зарлана яки дәртле тавыш белән күкрәк кага. Бер көнне каз, дустына иярмичә, өй ишеге төбендә ялгыз басып кала, чөнки ул өйдән үзенә бик таныш тавышлар ишетә. Менә Маша, алъяпкычына салып, тавык

астыннан чебиләр алып чыга. «Ләкин каз ни күзе белән күрсен, яшел чирәмдә тавык чебиләре түгел, ә каз бәбкәләре иде. Бу күренештән ала каз тәмам таңга калды. Ул бәбкәләргә карап бөтен барлыгы белән йотылган, һич айный алмаслык булып сихерләнгән иде. Бичараның йөрәгендә бу могҗизалы күрендештән нинди хисләр уянды икән? Әгәр каз кеше кебек булса, һичшиксез, бу минутта аның ике күзеннән сөенеч яшьләре мөлдерәп агып киткән булыр иде» [ Еники, 1991: 51-52]

Кечкенә генә бу хикәядә фәлсәфи фикер-нәтиҗә бар: ана каз бәбкәләрен ияртеп су буена төшеп киткәч, табигатьнең кечкенә бер хатасы төзәтелгән кебек була. «Шулай итеп немецлар явыннан япа-ялгыз торып калган ала каз семьялы булып алды... киләсе язда инде аңа бер көтү бәбкәле, тигез бәхетле тормыш килер» [Еники, 1991: 54]

Табигать җан ияләрен шулай итеп яраткан: кешеләр дә, тереклек тә үзенең дөньясында – нәселе, «оясы» белән яшәгәндә генә бәхетле була, кешеләр арасында, әмма чит мохиттә калса да җан иясе – ялгыз, бәхетсез. Табигатьнең гармониясе-гаделсезлеге шуннан гыйбарәт бит.

Авторның «Мәк чәчәге» нәсере 1944 нче елда басылып чыга. Шулай ук, Ә.Еникиның бу нәсерендә без ялгызлык проблемасы белән очрашабыз. Мәк образы җанландырылып бирелгән. Нәсердәге лирик образ тормышның һәм табигатьнең ваклыклардан өстен торган бер хакыйкате булып гәүдәләнә. «Киң авызлы тирән бомба чокырының төбендә үсеп утырган ялгыз мәк чәчәге чокыр кырына килеп туктаган узгынчы бер солдатка карап сүз башлады». Нәсердә мәк чәчәгенең монологы бирелә: «Бик күптәннән инде кеше заты күргәнем юк, һаман ялгызым, һаман ялгызым! Ичмасам, янымда берәр үләнчек булса иде!..» [Еники, 1991: 55] Мәк чәчәгенең япа-ялгыз калуы – ялгызлыкны символаштыра. Димәк, нәсернең авазы да әнә шул ялгызлык.

Мәк чәчәге җирдән аерылмаган, аны сугыш чорында тыңлап торучы солдат бар, шуның өстәвенә, яз килү белән үләннәрнең яшәрү ихтималын да күрәбез. Моннан дошман яңа узган, әмма вакыт үтү белән тереклек дөньясы аякка басачак. «... Гадәттә исә менә шулай беркемсез... Әйе, мин ялгыз, минем баш өстемдә еракта, бик еракта нурлы күк» [Еники, 1991: 56]. Ялгыз мәк чәчәгенең өмет йолдызы ерак булса да яна, яшәү яме белән тулы киләчәккә ышаныч барлыкка килә.

Дөрестән дә, ялгызлык проблемасы «Ялгыз каз» хикәяләре һәм «Мәк чәчәге» нәсеренең үзәгенә куеп символлаштырыла. Әлеге хикәяләре белән Ә.Еники Язучылар берлегенә дә кабул ителә, әсәрләре аерым китап булып басылып чыга.

Өйрәнүебез шуны күрсәтә: автор әсәрләрендә дәһшәтле сугышны турыдан-туры үзен түгел, ә аның кеше күңелендә калдырган эзе, тудырган хисләре тасвирлана. Сугыш китергән – күңел ярасы – ялгызлыкның төрле төсмерләрдә бирелүе – Ә.Еникинең сугыш һәм тормыш, яшәү һәм үлем, дәһшәт һәм матурлык фәлсәфәсен сәнгать дәрәҗәсенә күтәрүдәге осталыгын дәлилли.

**ӘДӘБИЯТ**


Айзетулова Г. Әмихан Еники иҗатын өйрәнү үзенчәлекләре // Ачык дәрес. – 2009. – № 9. – Б. 4–8.

Еники Ә. Мәк чәчәге / Әсәрләр. 3 томда. 3 том: Хикәяләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 1991. Б. 55–58.

Еники Ә. Ялгыз каз / Әсәрләр. 3 томда. 3 том: Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 45–54.



**Э.И. ИБРАҺИМОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


## ТАТАР СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНДӘ РЕДУПЛИКАЦИЯ КҮРЕНЕШЕ


**Аннотация.** В статье дан краткий обзор истории изучения редупликации в татарском языкознании.Анализированы семантические и словообразовательные особенности лексических повторов в татарской разговорной речи.

**Abstract.** The article provides a brief overview of the history of the study of reduplication in Tatar linguistics and provides an analysis of the semantic and word-formation features of lexical repetitions in Tatar colloquial speech.



**Ключевые слова:** татарский язык, словообразование, парные слова, редупликация.

**Keywords:** Tatar language, word formation, paired words, reduplication.


Татар телендә синтаксик ысул белән кушма, тезмә, парлы сүзләр ясала. Билгеле булганча, әлеге сүзләр ясалышында ким дигәндә ике яки берничә сүз катнаша һәм алар үзара берегеп бер төшенчә белдерә башлыйлар [Хисамова, 2006: 36]. Үзара тезүле бәйләнештәге сүзләр кушылу юлы белән ясалган сүзләр арасында лексик мәгънәви бәйләнеш була. Парлы сүзләр антоним, синоним, аваздаш сүзләрне парлап, сүзләрне кабатлап ясала.

Татар телендә парлы сүзләрне системалы һәм һәрьяклы өйрәнүче булып Ф.Ә. Ганиев тора. Аның “Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы” хезмәтендә парлы сүзләр куш сүзләр дип бирелә. Компонентлары тезүле бәйләнеш белән, кагыйдә буларак, куш сүзләр ясала, дип күрсәтә ул. Куш

сүзләрнең компонентлары тигез хокуклылар һәм бер-берсенә бәйле түгелләр: *савыт-саба* (савыт+савыт), *бала-чага* (бала+бала) [Ганиев, 2009: 35].

Галим билгеләвенчә, татар телендә компонентлары мондый бәйләнештә булган бик күп сүзләр бар. Куш, ягъни парлы сүзләрнең күбесе бик борынгы вакытта барлыкка килгән, алар составында беренче гарәп-фарсы алынмаларын да очратырга мөмкин. Бүгенге көндә телдә гарәп-фарсы алынмалары катнашында ясалган шактый күп куш сүзләр очрый: *гореф-гадәт, үгет-нәсыйхәт, хәер-сәдака, хәер-фатыйха* һ. б. Шуның белән бергә куш сүзләр бүгенге көндә дә барлыкка киләләр: *урман-дала, тимер-бетон, яшелчә-җимеш* һ. б. [Ганиев, 2009: 23].

Татар телендә күп куш сүзләрнең компонентлары төрле диалектлардан, башка телләрдән дә булырга мөмкин. Мәсәлән, *бала-чага* сүзендә беренче компонент татар теленең урта диалектында, икенче компоненты мишәр диалектында очрый, ике компонент та “бала” мәгънәсен белдерүе билгеле. *Савыт-саба* сүзенең беренче компоненты татар телендә булса, икенче компонент анда очрамый, әмма ул үзбәк, казакъ телләрендә бар, икесе дә савытны, аның төрен белдерәләр. Моннан исә татар теленең лексикасы формалашуында күп кабиләләрнең һәм халыкларның теле катнашуы күренә [Ганиев, 2009: 35].

Парлы сүзнең бер төре буларак редупликация күренеше карала. Р.А. Вафеев, Г. Абдразакова билгеләүләре буенча, редупликация – фоно-морфологик-синтаксик күренеш, ул икеләтү, башлангыч, урта, ахыргы иҗекне яки бөтен тамырны, яки бөтен сүзне кыскарту формасында, яки төрле сүзләрне кушу рәвешендә чагылдырыла [Атышева, 2010].

Галимнәр редупликация күренешенә электән игътибар итеп килгәннәр. Татар тел белемендә мондый сүзләргә беренчеләрдән булып К. Насыйри игътибар итә. Ул аларның берничә төрен күрсәтеп, аларның шактый тулы исемлеген бирүе мәгълүм.

Г. Ибраһимов үзенең грамматикасында “юлдаш сүзләр” исеме белән парлы сүзләр турында шулай ук мәгълүмат бирә: *тау-таш, килем-китем, алыш-биреш, ир-ат*. Сүзләр кабатланып ясалган лексик берәмлекләрне ул сүз җилемнәре дип атый һәм бу төргә *карт-коры* кебек сүзләрне кертә.

Г. Алпаров 1928 нче елда Көнчыгыш белеме институтында ясаган зур докладында, кушма сүзләр белән беррәттән, парлы сүзләргә дә туктала. Парлы сүзләрне ул семантик һәм фонетик принциплардан чыгып төркемли, аларның үзенчәлекләрен күрсәтә. Галимнең докладта китерелгән фикерләре соңыннан төрки телләргә караган күп хезмәтләрдә үстерелә.

Ш.А. Рамазанов *йөри-йөри* кебек хәл фигыль формаларының кабатланып килү үзенчәлекләренә игътибар итә.

В.Н. Хангилдин һәм Д.Г. Тумашева грамматикаларында парлы сүзләр турында шактый тулы мәгълүмат бирелә, аларның структур үзенчәлекләре күрсәтелә. Татар телендә һәм тюркологиядә традицион рәвештә парлы сүзләрне компонентларның лексик-семантик мөнәсәбәтләренә карап төркемләү дә кабул ителә [Тумашева, 1964: 30-31].

Ф.С. Фасиев үзенең хезмәтендә редупликация юлы белән терминнар ясалышын тикшерә, аларның компонентларыннан чыгып төрләрен билгели [Ганиев, 2009: 88].

Сүзләр парланышу, аның бер төре буларак редупликация күренеше татар теленең төрле катламнарына киң таралыш тапкан. Татар сөйләм телендә дә парлы сүзләр бик актив кулланыла, чөнки бу төр сүзләрнең бер өлеше күплекне, җыймалыкны, дәвамлылыкны белдерү өчен кулланыла.

Парлы сүзләр экспрессив мәгънәләрне белдерү, эмоциональ бизәк бирү һәм беркадәр кире мәгънә белдерү өчен хасил булганнар һәм шул нисбәттән кулланылалар. Сүз икенче компонент булып фонетик яктан беркадәр үзгәргән беренче компонент кулланылу турында бара. Бу вакытта куш сүз җыймалыкны һәм беркадәр билгесезлекне белдерә. Икенче компонент чынбарлыкта телдә очрамый, ул лексик мәгънәсе булмаган беренче компонентның аналогын тәшкил итә: *карт-коры, чокыр-чакыр, карчык-корчык*. Бу төрдәге парлы сүзләр күплектәге *картлар, чокырлар, карчыклар* сүзләреннән эмоциональ төсмерләр белән аерылып торалар. Татар сөйләм телендә бу төр лексика киң таралыш тапкан: *Авылга кайткач, шул* ***карт-коры*** *килеп хәлләрне белешә башлый иде инде, хәзер үзебез шулай яшьләрне көтәбез. Элек без җөри идек инде,* ***чокыр-чакырлары*** *да булгандыр инде аның, бер дә исебез китмәде, Аллага шөкер җөрдек үзе.* ***Карчык-корчык*** *шул эскәмиядә гайбәт сатып утыра инде ул кичләрен.*

Күплекне белдерү өчен икенче компоненты беренче компоненткa якын булган аваз ияртемнәре дә ясала: *шарт-шорт, лач-лоч, чаптыр-чоптыр, шап-шоп, шак-шок*. Бу төр куш сүзләрнең икенче компонентлары лексик мәгънә белдермиләр, телдә аерым-аерым кулланылмыйлар, алар бары китерелгән парлы сүзләрдә генә очрыйлар. Әмма бу төр сүзләр татар сөйләм телендә экспрессияне көчәйтү өчен киң кулланыла. Мәсәлән: *Кичләрен шул урамга чыккач, яшьләр учак кабызалар иде инде, менә шунда* ***шарт-шорт*** *килеп янган утынга карау рәхәтлек бирә инде. Әле алар укытучы башы белән* ***лач-лоч*** *сагыз чәйнәп басып торалар. Хәзер алай түгел, безнең дәрес вакытында*

*укытучы апаның үкчәләре белән* ***шак-шок*** *басып җөргән тавышы гына ишетелә иде.*

Без сөйләм теле үрнәкләре тупланган аудиоязмаларыбызны анализлап, сүзләр кабатланып килү очракларында күзәтелгән түбәндәге лексик-семантик һәм кайбер ясалыш үзенчәлекләрен аердык:

1. Компонентлар һәр икесе фигыль сүз төркеменә карап, фигыль кабатлау (редупликация) моделе булдырылу: *Киенергә инде әниләр Казанга барып, шуннан инде саткан әйберләрне* ***җыеп-җыеп*** *алып кайтып үзләре дә, безгә дә шулай киендереп җөрделәр. Берзаманны* ***тарта-тарта*** *яр кырыена кадәр китердем. Шуннан аяк белән капшап, куллар белән, аяклар белән* ***тибә-тибә****, бәрәңге, калган бәрәңге юк микән дип* ***карый-карый****,* ***җыя-җыя****, җыеп үзебезнең өйдәге мал-туарлар өчен, ни инде, ризык була алар өчен.* ***Эзләп-эзләп*** *булса да әчкә үлгән балалар булмады безнең семьяда.* Әлеге мисалларда фигыльләр кабатланып килеп, эш-хәлнең, процессның интенсивлыгын, дәвамлылыгын белдерәләр.
2. Компонентлар һәр икесе сыйфат сүз төркеменә карап, сыйфат кабатлау (редупликация) моделе булдырылу: ***Тәмле-тәмле*** *ризыклар пешерәсең,* ***матур-матур*** *күлмәкләр тектерәсең инде, яшь кызлар бигрәк тә, киенәсең матур иттереп.* Мисалларда кабатлаулар бер предметтагы билгенең барлык башка предметтагы шундый ук билгедән күпкә артык икәнлеген күрсәтәләр.
3. Компонентлар һәр икесе алмашлык сүз төркеменә карап, алмашлык кабатлау (редупликация) моделе булдырылу: ***Шулай-шулай****, үзләрен үзләре йөрткәч, бик яхшы инде әле, үз йомышларына үзләре баралар, әйбәт, бик яхшы.* Әлеге мисалда алмашлыкларның кабатлавы ризалашу мәгънәсенә ишарә итә.
4. Модаль сүзләрнең кабатланып килүе: ***Ярый-ярый****, шулай йөреп торсалар, бик әйбәт.* ***Бар-бар****, берничә көн алдан җыю.* Мисалларда беренче кабатлау ризалашу, икенчесе раслау мәгънәсендә килә.
5. Компонентларның лексик мәгънәләре тулысынча тәңгәл килгән аваз ияртемнәре: *Гимнастика ясата идек инде, үчтеки итә идек,* ***һоп-һоп*** *дип тез өстендә биетә идек,* ***үс-үс*** *иттерә идек.* Бу очракта ияртемнәрнең кабатлануы экспрессивлык тудыру, милли колоритны чагылдыру өчен кулланыла.

Шулай итеп, татар сөйләм телендә редупликация күренеше парлы сүзләр ясалу һәм кулланылу закончалыкларына буйсына, моннан кала ул фикер алышуның коммуникатив-әһәмиятле элементларын аерып чыгарырга, актуальләштерергә, кешенең иң төрле хис-тойгыларын белдерергә ярдәм итә,

шулай ук күпсанлылык, интенсивлык, озынлык, кабатлану кебек грамматик категорияләрне, сөйләмне стильләштерү чарасы буларак, аннан акрынлап күрсәтелгән категорияләрнең грамматик белдерү формасына әверелдерүне аерым тапшыру чарасы буларак формалашкан борынгы күренеш.

## ӘДӘБИЯТ


Атышева Н.Х. Классификация редупликации. М.: Журнал научных публикаций аспирантов и докторантов, 2010.

Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. Казан: Мәгариф, 2009. 271 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан: КДУ нәшр., 1964. 299 б.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.



**Л.Ю. ИДИЯТОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР АНТРОПОНИМИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛЫШТА ЙӨРГӘН ПОПУЛЯР ИСЕМНӘР


**Аннотация.** В данной статье анализируются популярные имена, функционирующие в современной татарской антропонимии. В статье на материалах управления ЗАГС Республики Татарстан с 2014 по 2018 гг. проанализированы лексико-семантические особенности современных татарских личных имен. Путем статистического анализа выявлены наиболее популярные имена за указанный период.

**Abstract.** The article analyzes popular names functioning in modern Tatar anthroponymy. The article analyzes the lexical and semantic features of modern Tatar personal names on the materials of the registry office of the Republic of Tatarstan from 2014 to 2018. By statistical analysis the most popular names for the specified period are revealed.



**Ключевые слова:** татарский язык, антропонимия, татарские личные имена, популярные имена.

**Keywords:** Tatar language, anthroponymy, Tatar personal names, popular names.


Кеше исемнәре, әтисенең исеме, фамилия, кушамат, тәхәллүс, криптонимнарның (яшерен исем) килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, антропонимнарга хас мәгълүматларны өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы антропонимика дип атала [Татар лексикологиясе, 2017: 40].

Татар халкы элек-электән исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Яңа туган сабыйга кушу өчен исем эзләгәндә, ул исемнең җиңел әйтелешле, яхшы мәгънәле һәм аһәңле булырга тиешлеген истә тоту кирәк. Кеше исеме

шулай ук чорның мәдәни һәм иҗтимагый йөзен күрсәтә, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә кешеләрнең дөньяга карашын ачык чагылдыра [Татар лексикологиясе, 2017: 46].

Татар исемнәре килеп чыгышлары белән гаҗәеп төрле, шул нисбәттән семантик яктан да төрлелек күзәтелә, беренче чиратта, бу халыкның меңьеллык тарихы, гасырлар буена килгән мәдәни гореф-гадәтләр, үзенчәлекләр белән бәйле. Татар исемнәре үзләренең яңгырашы, символик мәгънәләре белән дә аерылып тора. Татар исемнәре составында төрки-татар чыгышлы исемнәр белән беррәттән, алынма исемнәр дә шактый кулланыла [Саттаров, 1990: 9].

Әлеге мәкалә кысасында без популяр исемнәрнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнүне максат итеп куйдык. Моңа ирешү өчен без темага кагылышлы әдәбият белән таныштык, фәнни-теоретик материал тупладык, 2014 – 2018 нче елларда Татарстан Республикасында кулланылышта булган популяр исемнәрне төрле сайтлардан таптык, популяр исемнәрне лексик-семантик һәм ясалышлары ягыннан анализладык.

Популяр исем-киң җәмәгатьчелеккә танылган, хәзерге вакытта актив кулланылышта булган исем ул. Билгеле бер вакыт аралыгында аерым бер исемнәр популяр була. Теге яисә бу исемнең популярлыгына нәрсә йогынты ясый соң? Исем сайлаганда, тарихи дәвер иң беренчел мәгънәне уйный, күп кенә әтиәниләр балаларына оригинал исем кушарга теләп, әлеге факторны читләтеп узалар. Гореф-гадәтләргә игътибар бирү шулай ук исемнең популяр булуына йогынты ясый. Аерым бер исемнәргә мода да тәэсир итүен күрәбез. Шулай ук борынгы, инде онытылган исемнәрнең яңадан кулланышка кереп китүләре дә бүгенге көндә популяр. Әти-әниләр балага, күбесенчә, җиңел әйтелешле исемнәрне сайлап куярга тырышалар, шуңа күрә еш кына европа исемнәре, кыска исемнәр популяр булалар. Дини факторның да исемнәрнең популярлыгына йогынтысы зур әһәмияткә ия. Татар антропонимиясенең даими тулыланып торуына ишарәли торган тагын бер үзенчәлек - телдә яңа исем ясау традициясе киң таралыш тапкан. Әйтик, татар телендә даими рәвештә төрле экстралингвистик сәбәпләр аркасында исем ясау күренеше күзәтелә. Соңгы берничә дистә елда гына да татар телендә моңарчы кулланылмаган исемнәр барлыкка килде һәм популяр исемнәр рәтенә керделәр: *Ясминә, Ралина, Милана, Азалия, Сәгъдиана, Самира, Самир, Радмир,* һ.б. Кагыйдә буенча, исем күпмедер вакыт аралыгында популяр була һәм соңыннан ул урынын башка төрле исемнәргә бирә.

Фактик материал күрсәткәнчә, соңгы биш елда татарлар арасында иң еш кулланыла торган ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре булып *Әмир, Тимур, Кәрим, Камил, Ясминә, Әминә, Азалия* һәм *Самира* иң популяр исемнәр булып чыкты.

Тюрколог-ономатологларның төрки халыкларның кеше исемнәрен мәгънәви (семантик) яссылыкта төрлечә классификацияләүләре билгеле. Иң уңышлы классификация булып атаклы венгр тюркологы-антропонимисты Л.Рашониныкы санала (1953). Аның классификациясен төрки исемнәрне барлыкка килү мотивлары буенча төрле лексик-тематик төркемнәргә аеру тәшкил итә. В.А.Никонов “Личные имена у тюркоязычных народов” дигән мәкаләсендә Л.Рашони классификациясен нигез итеп ала һәм төрки телләрдәге кеше исемнәрен түбәндәге өч төп төркемгә аерып карый: меморатив (багышлау) исемнәр, дескриптив (тасвирлау-сурәтләү) исемнәр. Дезидертив (теләк) исемнәр [Татар лексикологиясе, 2017: 61].

Тасвирлама антропонимнарга баланың физик үзенчәлекләрен, сәләтен, туу көненә бәйле вакыйгаларны гаиләнең социаль торышын билгеләүче исемнәрне кертәләр. Кешенең мәсләген, гаиләнең социаль торышын билгеләүче, ир балага кушыла торган тасвирлама исемнәр. Мәсәлән, хәзерге антропонимиконда да киң кулланылган исем: *Әмир(Әмирхан)*–фарсы-гарәп чыгышлы татар исеме. Әлеге исем 1.Әмер, боерык бирүче. 2.Берәр өлкә яки дәүләт башлыгы, идарәче, эмир дигән мәгънәләрне аңлата [Саттаров, 1998: 314].

Теләк исемнәр дип аталган төркемнең асылында яңа туган балага багышланган төрле теләкләр ята. Болгар-татар антропонимиясендә теләк исемнәр элек-электән кулланылганнар. Әлеге исемнәрнең килеп чыгышын безнең ата-бабаларыбызның төрле ышанулары белән бәйләп карыйлар. Исемнәрнең нигезендә төрледән-төрле теләкләр ята: мәсәлән, балага озын гомер, сәламәтлек, байлык, бәхет, батырлык, кыюлык, акыл, матурлык һ.б.ны теләү [Галиуллина, 2000: 33]. Бу төркемгә кергән популяр исемнәр арасында түбәндәге исемнәрне аердык: *Тимур* (Мәгънәсе: Ир бала тимердәй нык булсын дигән теләктән чыгып кушылган борынгы исем; балалары тормаган гаиләләрдә яңа туган сабыйга “тимерле” исемле биргәннәр) [Саттаров, 1998: 236]. *Камил* (Тулы, бөтен, мәкәммәл килгән, камил) [Саттаров, 1998: 130]. Матурлык, гүзәллек, сафлык, мәхәббәт символы булган гөл-чәчәк атамаларын кыз балага исем итеп бирү, аларның гөл-чәчәк кебек күркәм, чибәр, матур, сылу, мәхәббәтле, саф булып үсүләрен теләү борын-борыннан дөньядагы барлык халыкларга да диярлек хас булган. Күп кенә хатын-кыз исемнәрен чәчәк, үсемлек исемнәре тәшкил итә: *Ясминә* (Ясмин гөле. Төрдәше: Ясмилә) [Саттаров, 1998: 445], *Азалия* (Азалия гөле; эре чәчәкле үсемлек атамасыннан) [Саттаров, 1998: 336].

Багышлау исемнәр төркеменә төрле дини ышануларга, космогоник күзаллауларга, табигать культларына, баланы явыз көчләрдән саклауга, сүзнең магик көченә һәм төрле әкият-легендаларга ышану нигезендә барлыкка килгән антропонимнар керә. Багышлау исемнәрне ике төркемгә аералар: теофор һәм танылган, данлыклы кешеләр хөрмәтенә бирелгән исемнәр. Аеруча исламны, дин әһелләрен мактаган, олылаган ир-ат исемнәре дини характерда булалар [Галиуллина, 2000: 37]. Бу төркемгә караган исемнәр арасында Мөхәммәт пәйгамбәр исеменә эпитет буларак кулланылган *Кәрим* (1.Юмарт, рәхимле, киң күңелле, намуслы. 2.Хөрмәтле, кадерле. газиз) исемен мисалга китерергә була [Саттаров, 1998: 151]. Шулай ук биредә Мөхәммәт пәйгамбәрнең якыннары исеменә нисбәтле *Әминә* (1.Ышанычлы,тугры. 2.Тыныч табигатьле. 3.Хәвеф-хәтәрсез урындагы. Мөхәммәт пәйгамбәр әнисенең исеме.) исемен дә керттек [Саттаров, 1998: 447].

Исемнәрнең популярлыгын билгеләү максатыннан, без 2014-2018 елларда кулланылган 11349 исемне тикшердек. 2014–2018 елларда *Әмир (3740), Тимур (3664), Кәрим (3187), Камил(1658), Ясминә (2956), Әминә (2805), Азалия (1229)* кебек исемнәр иң популяр исемнәр булуын ачыкладык.

TatCenter.ru порталы 2014 нче елда Татарстанда балаларга кушыла торган популяр исемнәр буенча икенче тапкыр тулы тикшерү үткәрде. Барлыгы Татарстанда беренче гыйнвардан алып дүртенче декабрьгә хәтле аралыкта 53 меңгә якын сабый дөньяга килгән. Иң күп кушыла торган исемнәр булып *Әмир (878), Тимур (759), Кәрим (662)* исемнәре тора. 2013 нче ел белән чагыштырганда *Азалия (564), Әминә (557), Ясминә (541), Самирә (465),* исемлеләр күбрәк. 70% тан артык балалар үзләренә танылган популяр исемнәрне алдылар. Йөздән артык балага югарыда саналган исемнәр кушылган.

Казанда иң популяр дүрт исем даимилекне саклый. Яңа Савин һәм Идел буе районнарыннан аермалы буларак, Киров районында алдынгылыкны *Әминә* (65) исеменә караганда *Азалиягә (81)* күбрәк бирәләр. Яңа Савин районында *Әминә (94), Азалия (75*), Идел буе районында *Әминә (66), Азалия (45*) исемле. Казанда һәр өченче ир бала *Әмир* яки *Тимур*.

Районнарда популяр исемнәр унлыгына – *Ислам, Самир, Марьям, Камилә, Заринә, Ралинә* һәм башкалар керә. Кукмарада ата-аналар балаларына күбесенчә *Ислам (12), Әмир (10), Самир (8)* һәм *Ралинә (12)* диеп исем бирәләр [TatCenter.ru].

Татарстан Республикасында 2015 нче елда 52 меңгә якын бала туган. Туучылар саны күбесенчә июль һәм октябрь айларына туры килә (2015 нче елның 10 ае өчен бирелгән мәгълүматлар буенча). Кызлар белән чагыштырганда

ир-егетләр бер меңгә күбрәк туган. Дөньяга *Тимур (764), Әмир (668), Кәрим (667), Ясминә (592), Әминә (581)* исемле балалар килгән. Бер ел эчендә җир йөзенә 2357 исемле ир һәм кыз бала аваз салган, шуларның 1211е – сирәк очрый торган исемнәр [TatCenter.ru].

Татарстанда 2016 нчы елда 11 ай эчендә 52 меңгә якын бала туган. Шуларның 26840 сы малай һәм 25150сы - кыз бала. 2016 елда Татарстанда яңа туган балаларга кушылган иң популяр исемнәр булып: малайларга – *Тимур (791), Әмир (733), Кәрим (671), Камил (388), Самир (378)* ә кызлар өчен – *Ясминә (663), София (656), Әминә (601), Ралинә (479), Азалия (441)* исемнәре тора. 6-7 елдан соң 27 кешелек сыйныфта, һичшиксез, бер *Тимур* һәм бер *Ясминә* булуы ихтимал [TatCenter.ru].

Татарстанда 2017 нче елда ир-егетләр арасында, алдагы еллардагы кебек популяр исемнәр булып *Әмир, Тимур* һәм *Кәрим* тора. Шулай ук хатын-кызлар исемлегендә дә артык зур үзгәрешләр юк. Ир-егетләр исемлеге: *Әмир (701), Тимур (689), Кәрим (645), Камил (342).* Хатын-кызлар исемлеге: *Ясминә (632), София (612), Әминә (598), Ралинә (435), Азалия (412).*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсе 2017 нче елда Татарстанда туган яңа балалар өчен популяр ир-егетләр һәм хатын-кызлар исемнәренең ахыргы исемлеген билгеләде. Егетләр арасында иң популяр исемнәр булып, элеккечә, *Әмир* һәм *Тимур* кала бирә. Кызлар арасында иң популяр исем булып *Ясминә* тора. Шуны искәртеп үтәргә кирә: егетләр исемлегеннән 2014 нче елдан бирле популярлык казанган *Кәрим* исеме, әйдәп баручы өчлектән, ә кызлар исемлегенең популяр унлыгыннан *Ралинә* исеме төшеп калган [TatCenter.ru].

2018 нче елда Татарстанда 46793 сабый туган : 23960 малай һәм 22833 кыз. Исемлектә зур үзгәрешләр күзәтелмәгән. Ир-егетләр арасында иң популяр исемнәр – *Әмир* (758), *Тимур* (661), *Кәрим* (542), *Камил* (355). Хатын-кызларга *Ясминә* (593), *София* (584), *Әминә* (528), *Алисә* (485), *Азалия* (376) исемнәре кушылган [TatCenter.ru].

Йомгаклап, шуны әйтергә мөмкин: соңгы дүрт елда Татарстан Республикасында кулланылышта булган популяр исемнәр булып ир-егетләр өчен – *Әмир, Тимур, Кәрим, Камил* хатын-кызларга - *Ясминә, София, Әминә, Ралинә, Азалия* исемнәре алдынгылыкны алып тора. XXI нче гасырда дин белән бәйле исемнәрнең активлашуын күрәбез [TatCenter.ru].

Бүгенге көндә исемнәр ныклы үзгәреш кичерсә дә, электән килгән, традицион исемнәребез сакланмаган диеп әйтеп булмый. Шулай итеп,

тикшерүдән күренгәчә, популяр исемнәр рәтенә гарәп-фарсы чыгышлы исемнәрнең татар антропонимиясендә активлашуын күрәбез.

**ӘДӘБИЯТ**

Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций: монография. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 352 с.

Галиуллина Г.Р. Личные имена татар в XX веке. Казань: Матбугат йорты, 2000. 114 с.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? Казан: Раннур нәшр., 1998. 487 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 1 кис. 536 б

Рейтинг детских имен в Татарстане: http:// tatcenter.ru/ multimedia/ infographics/ rejting-detskih-imen-v-tatarstane (мөрәҗәгать итү көне: 25.10.2019)

**Ә.Ф. ИЛЬЯСОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

# ТАТАР БАЛАЛАРЫН АНА ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТКӘНДӘ ФОЛЬКЛОР ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН БАЛАЛАР ШИГЬРИЯТЕНЕҢ РОЛЕ

**Аннотация.** В статье рассматривается роль татарского народного фольклора при изучении татарского языка. Большое внимание в педагогической деятельности уделяется прививанию национальных традиций и духовно нравственной культуры на уроках татарского языка в дошкольном возрасте. С целью приобщения детей к татарской культуре проводятся национальные праздники «Сабантуй», «Мы и Тукай – едины!», «Народные поговорки» и др. Дети с большим интересом принимают участие в национальных играх.

**Abstract.** My article discusses the role of Tatar folklore and the influence of modern society on the development of children in the study of the Tatar (native) language. In order to familiarize children with the Tatar national culture, we conduct lessons, for example, on the celebration of the national holidays “Sabantuy”, “We-people G.Tucay, different sayings and others, where children with great desire take part: recite poems, sing songs, play different national games. Thus, in our pedagogical activity we pay great attention to the preservation of national traditions and spiritual and moral culture in the lessons of the Tatar language.

**Ключевые слова:** татарский фольклор, родной язык, современное общество, культура, развитие детей, обучение.

**Keywords:** Tatar folklore, native language, modern society, culture, child development, education.

Соңгы елларда республикабызда булган уңай үзгәрешләр нәтиҗәсендә тарихыбыз, халкыбызның рухи хәзинәләре, традицияләре, гореф-гадәтләре белән кызыксыну көчәйде. Мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында кабат татар теле кертелә башлагач, мин уземдә рухи туплану тойдым һәм бик сөендем. Татар теле искиткеч бай, матур тел. Сабыйлар бишек җырларын, мәкальләрне,

әйтемнәрне, тел осталыгының матур үрнәкләрен иң беренче булып өлкәннәрдән ишетәләр. Боларның барсында исәпкә алып, мин сабыйларны ана теленә өйрәткәндә ярдәмчеләрем итеп халкымның бай фольклорын һәм матур шигъриятен сайладым.

Мин үзем балалар бакчасында тәрбияче булып эшләдем. Хәзерге вакытта балаларга татар теле дәресен укытам. Укытучы һөнәре бик авыр хезмәт булуына укыта башлаган дәверемнән инандым. Сабыйларны ана теленә өйрәтүдә халкыбызның фольклоры һәм матур шигърияте бик зур әһәмияткә ия. Кабинетта күргәзмә әсбаплар, китаплар туплау, халкыбызның үткәнен чагылдырган почмаклар булдыру барлык төркемнәр өчен дә бик мөһим таләп булып тора хәзерге вакытта. Иң элек укытучы, тәрбияче үз алдына татар баласын чын татар, милли рухлы шәхес итеп тәрбияләргә теләсә, киләчәк буын иң беренче ата-бабаларыбызның рухи мирасын, гореф-гадәтләрен белергә тиеш, дигән максат куела. Эшне шушы олы хәзинәнең бер өлеше – балалар фольклоры белән таныштырудан башларга кирәк. Беренче эш итеп, һәр төркемнәрдәге балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алырга һәм татар халык фольклоры үрнәкләре белән таныштыру үткәрелергә тиеш.

Балаларны телгә мавыктыргыч өйрәтүдә иң отышлы алым дип татар халык уеннарын саныйм. Аларны балаларның яшь үзенчәлекләренә карап сайлау – бик мөһим чара. Татар халык уеннарының күбесе шигъри юлларга салынган, җырлы-такмаклы булулары белән дә өйрәнергә җиңел. Уеннар баланың сөйләм телен үстерә, хәрәкәтен яхшырта, игътибарлылыгын арттыра. Халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, көнкүренеше чагылыш тапкан уеннар балаларда үз көченә ышану, күмәклек, ярдәмләшү тәрбияли. Һәрбер шөгельне татар халык фольклоры элементлары һәм шигъри юлларны кулланып эш итсән зур унышларга ирешеп була. Шөгыльләрдә арып, талчыгып китүгә, татар халкының җырлы-сүзле уеннары ярдәмгә килә. *Чума үрдәк – чума каз, Ал кирәк – гөл кирәк, Түбәтәй* – безнең балаларның яраткан уеннары. Ә уенга аларны кызыклы сынамышлар чакыра. Мәсәлән:

Берәм, икәм,
Җиккән атым
Чыгып киткән.
Йөгереп барып
Тотып алдым,
Бу уенда син калдың...

Хәзерге заман балалар шигъриятен татар халык фольклоры белән бәйләп шөгыльләнү дә бик отышлы дип саныйм. Мәсәлән *йорт хайваннары* темасы

үткәндә, табышмаклар әйтергә була. *Сакалы бар, акылы юк* – татар халык фольклоры җимеше булса, *Сакаллы булып туган ул, Сакаллы сабый булган. Парикмахерга кермәгән, Сакалын кистермәгән* – бу инде шагыйрь Ш. Галиевның табышмагы. Фольклор ярдәмендә һәр сабыйның күнелендә туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләргә тырышырга мөмкин. Балалар бишек җырларын шулай ук бик яраталар һәм үзләре җырларга тырышалар.

*Әлли – бәлли бәү итә,*

*Бәбәй йокыга китә.*

*Бәбәй йокыга киткәч,*

*Әнкәсе дә ял итә.*

Чын балалар шигъриятенә күз салыйк. Ул бөек шагыйребез Тукайдан башланган. Мин үзем дә, тәрбияче буларак, Габдулла Тукайның иҗаты белән балаларны таныштырырга тырышам. Шәһәребездә Г.Тукайның туган көнендә шигырь бәйрәме уздыру күркәм гадәткә әверелде. Мин эшли торган балалар бакчасында да ел саен бу бәйрәмне якты өметләр белән көтеп алалар. Бакчабызда иҗади сәләткә ия булган балалар булу, аларның туган телебездә шигырьләрне сәнгатьле, матур итеп сөйләве барыбызны да шатландыра. Бакчабызда "Без – Тукайлы халык" дигән бәйрәм кичәсе булдырыла, өлкәнрәк балалар «Кызыклы шәкерт» шигырен сәхнәләштереп күрсәтәләр. Тукай һәйкәле янына барып чәчәкләр салу, шигырьләрен яратып сөйләү, сәхнәләштереп чыгышлар сөйләү – бакчабыз өчен бик мөһим күренеш чарасы.

Сабыйларга кече яшьтән үк ана теленә мәхәббәт уяту, аларны үз телләрендә аралашырга өйрәтү – иң мөһим бурычларның берсенә әверелде. Бүгенге көндә төп юнәлешләрдән тайпылмыйча балаларны ана теленә һәм татар телен өйрәтүне дәвам итү, төрле методик чыганаклардан (Мәгариф, Ачык дәрес, Тәрбия) файдалану бик зур әһәмияткә ия. Төрле методик чыганаклардан кызыклы алымнар кулланып, халкыбызның бай фольклорына таянып эшне тагын да камилләштерү өлкәсендә эшләргә кирәк.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә, белем бирүнең төрле алымнары, чаралары кулланыла. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын раслыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда, балалар, эчтәлегенә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү − болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия.

**ӘДӘБИЯТ**


Юсупов Ф.Ю., Борһанова Р.А. Гөлбакча. Казан, 1990. 295 б.

Юсупов Ф.Ю. Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен. Казан, Раннур нәшр., 2003. 200 б.

Гәрәфиева Г.З. Сөмбеләне кем белә? Казан: Тарих, 2003. 278 б.

Закирова К.В., Мортазина Л.Р. Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак. Балалар бакчасында уеннар. Казан: РИЦ, 2002. 350 б.



**Ә.Ф. ИЛЬЯСОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ ТАТАР БАЛАЛАРЫН ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮДӘ КУЛЛАНЫЛГАН АЛЫМНАР, ЫСУЛЛАР ҺӘМ ШАРТЛАР


**Аннотация.** В данной статье раскрываются критерии, используемые при обучении родному языку детей дошкольного возраста в игровых, речевых технологиях, комплексных задачах и других методиках.

**Abstract.** This article describes the criteria used in teaching the native language (Tatar) of preschool children in games, speech technologies, complex tasks and other methods.



**Ключевые слова:** обучение, родной язык, дошкольники, методики.

**Keywords:** teaching, native language, preschoolers, methods.


Балаларга татар телен өйрәтүдә гаиләнең җитди игътибары мөһим. Шуңа күрә балалар бакчасында планның «Ата-аналар белән эш» бүлегенә «Без татар теле өйрәнәбез» дигән пункт кертү, анда шушы юнәлештә төрле чаралар үткәрүне күздә тотып эш итү мөһим.

Бүген мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре өчен алты юнәлештә татар телендә яңа укыту-методик әсбаплар, методик һәм күрсәтмә материаллар,

балаларның танып-белү һәм фикерләү сәләтен үстерергә ярдәм итәрлек яңа заманча уеннар, эш дәфтәрләре әзерләнде һәм бүгенге көндә бу эш дәвам итә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телен өйрәтү аларның билгеле бер күләмдә сүз байлыгын булдырудан башлана. Иң элек, билгеле, аларны көндәлек тормышта бик еш кулланыла торган сүзләр белән таныштырырырга кирәк: «Исәнмесез!», «Сау булыгыз!», «Хәерле иртә!», «Рәхмәт!», «Тыныч йокы!» һ.б. Бу сүзтезмәләр гел кабатланып тора һәм алар инде балаларның актив сүзлек байлыгын тәшкил итә, ә тәрбиячеңең сөйләмендә очрый торган бик күп яңа сүз әле алар өчен пассив сүзлек була. Балалар бу сөйләмне ишетәләр, аңлыйлар. Тора-бара, билгеле, алар инде тәрбиячеңең кайбер боерыкларын (мәсәлән: басыгыз, утырыгыз, керегез; мә, бир, ал, куй, китер һ.б.) аңлап, төгәл үти башлыйлар. Бу сүзләр дә шулай ук еш кабатлана һәм актив сүзлеккә кертелә бара.

Балалар телне яратып өйрәнсен өчен, шөгыльләрне уеннар ярдәмендә үткәрергә, күрсәтмә әсбаплар һәм пиктограммалар куллану файдалы. Ә иң яхшы алымнарнаң берсе – хәрәкәт һәм ишарә белән сөйләү. Бу алым балаларга бик ошый. Чөнки кайбер балалар үзләренең уй-фикерләрен татар телендә әйтергә куркып калалар, аларны «дөрес әйтмәм» дигән уй борчый. Ә менә хәрәкәт һәм ишарә белән сөйләү нәтиҗәсендә бу уй юкка чыга. Балалар үзләрен ышанычлы итеп хис итә. Алар сүзләрне тиз истә калдыралар, җөмләне дөрес төзиләр, бер − берсе белән татар телендә аралаша башлыйлар. Шулай итеп аларның сөйләм теле үсә. Шуны да истә тоту зарур, сөйләмне үстерүдә тәрбиячеләрнең тырышлык көчләре бик зур әһәмияткә ия. Уен һәм күнегүләр өчен материал сайлаганда, җиңелрәктән авырракка күчү принцибын истән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, башта аваз ялгыз ишетелсен: яфрак кыштырдый - ш-ш-ш, самолет оча -р-р-р; аннары сузык авазлар кушып әйтәбез: шу-шу-шу, ра-ра-ра. Соңыннан исә, бу авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтергә кирәк. Мәсәлән, шугалак, ракета һ.б.

Эш барышында тәрбиячедән бары тик татар телендә генә сөйләшү сорала. Бу уңай шарт булып тора. Ләкин телне яңа гына өйрәнә башлаган очракта балаларга биреләсе сорауларны башта – татарча, аннары рус теленә тәрҗемә итеп бирергә дә була. Балаларга темадан тыш артык сүзләр, уеннар, җырлар, шигырьләр бирелергә тиеш түгел. Бала татар телендә сүзне дөрес әйтмәгән очракта, тәрбияче баланы тыңлап сүзнең дөрес үрнәген күрсәтергә тиеш. Балалардан авазларның дөрес әйтелешен катгый таләп итмәскә кирәк. Тәрбияче сөйләмендә акцент, җирле диалект, аваз кимчелекләре булмаска тиеш. Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә

таянып эш итә ала. Тәрбияче үзенең эшенә иҗади якын килергә, төрле алымнар, чаралар эзләп, аларны кулланырга тиеш.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Яңа сүзләр үзләштерү процессында махсус сайлап алынган күнегүләр төп чара булып тора. Юнәлеше һәм характеры ягыннан лексик күнегүләрне икегә бүлеп карыйлар: әзерлек күнегүләре һәм сөйләм күнегүләре. Әзерлек күнегүләре балаларны яңа сүзләрне файдаланып сөйләргә әзерли. Бу күнегүләр лексик берәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр. Сөйләм күнегүләре лексик күнегүләрнең бер төре буларак, үзләштерелгән лексик берәмлекләр җирлегендә ситуацияләргә бәйле сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерәләр.

Яңа сүз өйрәтү төп методик алымнарның берсе булып тора:

– яңа сүз тәрбияче тарафыннан ачык, төгәл итеп күрсәтмә рәсем ярдәмендә әйтелә;

– аудиоязмадан тыңлатыла, кабатлатыла;

– ишеткән сүзне бала рәсемнән табып күрсәтә һәм әйтә;

– сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә;

– төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә;

– уеннар кулланып («Ватык телефон», «Кайтаваз»...) ныгытыла;

– яңа сүз, таныш булган сүзләр белән грамматик конструкцияләрдә ныгытыла, мәсәлән: зур туп, чиста туп;

– аралашуда кулланыла (бала өйрәнгән яңа сүзләрне, конструкцияләрне бары аралашуда аңлап куллана).

Программаның төп асылы булып аралашуга чыгу тора. Аралашуга чыгу өчен диалогик сөйләмнең әһәмияте бик зур. Диалогик сөйләмдә иң отышлы алым – сорау-җавап рәвешендә (сорау-информация алу берәмлеге) һәм теләк белдерә торган: теләк, үтенү, тәкъдим итү, ризасызлык төсмере булырга мөмкин. Тәрбияче балалар сөйләменә керерлек кирәкле формаларын эшләргә һәм төрле шартларда куллану мөмкинлеген исәпкә алырга тиеш. Тәрбияче, сөйләмгә эмоциональ бизәлеш өстәү өчен, төрле формаларны кулланырга; эш эчтәлегенә туры килә торган интонация, ишарәләр, мимикалардан файдаланырга һ.б. өйрәтергә тиеш. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар тора. Аудиоязмалар яңа сүз өйрәтү, сөйләм үрнәкләре үзләштерү, уеннар, кыска җырлар өйрәтү, өстәл театры күрсәтү вакытларында куллану өчен төзелде.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү мәсьәләләрен чишкәндә, өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе — бармак уеннары. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Тәрбияче "якындагы үсеш зонасының" баланың яше белән генә түгел, ә шәхси үзенчәлекләре белән дә бәйле булуын истә тотарга тиеш. Белем бирү барышында баланың фикерләвенә зур игътибар бирү сорала. Бу яшьтә дә шулай ук эшчәнлек төрләрендә сөйләмдә сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычлары хәл ителә.

Икенче кече яшьтәге балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик принципка нигезләнә. План ел дәверендә "Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!", "Көз", "Мин һәм минем гаиләм", "Минем йортым, минем шәһәрем", "Яңа ел бәйрәме", "Кыш", "Ватанны саклаучылар көне", "Сигезенче март", "Халык җәүһәрләре", "Яз", "Җәй" кебек темалар үзләштерүне күздә тота.

5-7 яшьтәге балалар ана телен камил белергә, аның нечкәлекләренә төшенергә, башка милләт халыклары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә, ә инде тәрбиячеләр балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыру бурычларын хәл итәргә тиеш.

«Танып белү» белем бирү өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләр белән экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында белемнәрен тирәнәйтүне максат итеп куя. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.

«Аралашу» белем бирү өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара-каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра.

«Матур әдәбият» белем бирү өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өнди, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирә, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтә торган, балаларның яшь

үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән таныштыруны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.


**ӘДӘБИЯТ**

Зиннурова Ф.М. Үз илемдә, үз телемдә: логопедлар, тәрбиячеләр һәм укытучылар өчен методик кулланма / Ф.М. Зиннурова. Казан: Мәгариф, 2009. 167 б.

Шәехова Р.К. Авазларны уйнатып: методик кулланма: мәктәпкә әзерлек төркемендә эшләүче тәрбиячеләр өчен. Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2011. 44б.

Галиева Р. Мәктәпкәчә тәрбия. Сөйләмдәге кимчелекләрне төзәтү // Мәгариф. – 2013. – №7.

Хәрәкәттә – бәрәкәт: методик ярдәмлек /З.М. Маһиярова. Казан: КДТУ, 2009. 24 б.

Шаехова Р. К. Раз – словечко, два – словечко... : занимательное обучение татарскому языку. Казань: Хәтер, 2011. 96 с.



**З.Ф. КАМАЛОВА**

*Казанский федеральный университет, Россия*


# ПРОБЛЕМА ГОЛОДА В ПРОИЗВЕДЕНИИ Г. ИБРАГИМОВА «АДӘМНӘР»


**Аннотация.** В данной статье рассматривается тема голода в повести великого писателя Г.Ибрагимова «Люди». Приведены примеры из повести, которые отображают всю суть голодной жизни во время военных лет, в которых автор затрагивает самые щепетильные моменты голодания.

**Abstract.** This article discusses the problem of hunger in the story of the great writer G. Ibragimov "People". Examples are given from the story, which reflect the whole essence of hungry life during the war years, in which the author touches on the most sensitive moments of fasting.



**Ключевые слова:** война, голод, люди, трудности.

**Keywords:** war, famine, people, difficulties.


Әдәби мирасыбызга мөнәсәбәтнең үзгәрүе, мәдәни байлыкка игътибар арту, моңа кадәр күләгәдә калып, өйрәнелми яткан әдәби катламнарның халыкка кайтуы әдәбият тарихында, аерым әдипләр иҗатында тикшерелми килгән яки берьяклы бәяләнгән куренеш – ачлык темасына яңача карарга мөмкинлек бирде. Татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңарыш идеяләре әдәбиятта ачлык темасын башкачарак тикшерүне алга чыгаруга юл ачты. Татар милли әдәбиятында тирән эз калдырган Г.Ибраһимов иҗатында ачлык афәтен сурәтләү – шундый темаларның берсе.

Г.Ибраһимов иҗаты әдәбият белемендә ике дәвергә бүлеп өйрәнелә: Октябрь инкыйлабына кадәрге (1907-17 еллар) һәм совет чоры (1917-38 еллар) иҗаты. Беренче чор иҗаты, бигрәк тә башлангыч дәвере, романтик пафос

өстенлек алу, реаль тормышны романтик хыял дөньясына каршы кую белән аерылып торса («Диңгездә», «Сөю-сәгадәт» һ.б), инкыйлабтан соң инде язучы «әдәбият тормыш-чынбарлыкның көзгесе булырга тиеш» дигән принциптан чыгып эш итә башлый, ягъни икенче чор иҗаты традицион реализм алымнарына нигезләнә. Шундый әсәрләренең берсе – «Адәмнәр» повесте.

Г.Ибраһимов Идел буена килгән ачлык афәтен читләп үтә алмый, аның әдиплек вөҗданы, олуг кыюлык белән, татар әдәбияты тарихына кала торган ачлык турындагы повестен иҗат итүгә этәрә [Җәләлиева, 2001: 26].

Г.Ибраһимовның тарихның иң авыр фаҗигасен чагылдырган психологик повесть «1921-1922 елларда Идел-Урал буйларында булып үткән трагедияләр» турында сөйли. Шул исәптән ул бик күп кире кагуларга, үзгәрешләргә, дучар була, берничә кат кире басылып чыга. «Адәмнәр» тулысынча кара, дәһшәтле картиналардан гына тора.

Повесть беренче җөмләләре белән үк укучыны дәһшәтле вакыйгалар эченә алып кереп китә: «Үлем үзенең кара канатларын җәйде. Җир йөзе гүя шуның астында капланып калды. Тирә-як куркыныч караңгы каберлекләр, ләхетләр белән бер үлгәч терелеп чыккан җанлы мәетләр белән тулды. Адәмнәрнең йөрәге моңа чыдамады, урыннарыннан кузгалырлык куәте булганнар, куркышып, дөньның төрле ягына качтылар. Төркестан, Кавказ, Себер далаларын шуннан таралган хәлсез шәүләләр басты» [Ибраһимов, 2007: 286].

Авылның иң хәлле кешесе, рибачысы (ростовщигы) Намаҗан үзенең бертуганы Галим картның хәлен белергә килә. «Ачы җил яман ыжгырып уйнады. Картны буран каплады. Ул, бәлки, язганча шунда яткан булыр иде, агасы Намаҗан ике көннән соң ниндидер бер эш белән бу тирәгә килгәндә:

- Тукта эле, Галимнең хәлен белим, – дип, аңа кереп чыгарга уйлады» [Ибраһимов, 2007: 286-287]. Шунда ачлыктан читән буенда егылып җан биргән картны бер карт ала эт талап, актарып ятканын күрә. Ул да ач: «үлекнең эчен актарып, эчәген, бавырын ашап ята!» [Ибраһимов, 2007: 287]. «Намаҗан аптыраашта калды. Халык чакырырга барса, бу эт үләксәне ашап бетерәчәк иде. Бәлки, берәрсе ишетеп килер дип кычкырырга тотынды» [Ибраһимов, 2007: 287]. Ачлык бөтен илгә афәт булып ябырыла. Авыллар бигрәк тә ачлык афәтеннән интегә. Ач халык кая барырга, ни кылырга белми. Җан асрау өчен актын әйберләрен чыгарып сала.

Сюжетта берсеннән-берсе җан өшеткеч картиналар кинокадр кебек алмашынып торалар. Алга таба Г. Ибраһимов ачлыктан адәм баласының хәтта кеше ашау дәрәҗәсенә барып җитәргә мәҗбүр булуын сүрәтли. Ач халык

алтмыш яшьлек, өс-башы җүнле генә, йөзе тирән җыерчыклы карчык өенә җыелалар. Зәйнинең сүзләренә караганда, бу өйгә ике бала кереп китә, ләкин чыкканы күренми. Зәйни бу күренешне үз күзләрем белән күрдем дип ышандырмакчы була. Халык җыела, карчыкның өен тентиләр һәм баздан кеше ите табалар. « Халык, телен, акылын югалтып таш кебек катып калды. Аларның барлык сизенүләре чынга ашты: ватылган чүлмәк эченнән кисәк-кисәк тозлы ит идәнгә чәчелде, болар барысыда бер-берсе өстенә рәтләп төзелгән кечкенә-кечкенә куллар, эчендә кызгылт көенчә сакланган ботлар, бармаклар бар. Моны һәммә кеше ачык курде, шик калмады, үлем килеп басты»

Шуннан соң вакыйгалар Гәрәйләр йортына күчә һәм төп фаҗига шунда башкарыла. Язучы әнә шул бер гаилә мисалында авыр трагедияләрнең дәһшәтле күренешләрен укучыларга җиткерә. Автор ачлыкның бик тә куркыныч икәнлеген белдереп болай ди: «Ачлыкның баштагы биш-алты көне бик үткен, бик газаплы, бик чыдамсыз була, аннан соң адәм ни туры килсә шуны бетергәнче ашый, булмаса, ярты үлек кебек үзен дә, дөньясын да оныта торган бер машинага әйләнә» [Ибраһимов, 2007: 308]. Шулай итеп ачлыктан үз-үзен белештермәс дәрәҗәсенә җиткән Гәрәй «Нәфисәнең йөзен чүпрәк белән каплады да пычакны каты кулдан берничә мәртәбә бугазга ышкып җибәрде» [Ибраһимов, 2007: 318-319]. Шул рәвешле, повестьның башыннан ахырына кадәр кан, дәһшәт, җан өшеткеч сурәтләр, коточыргыч тасвирларның ургылышы бара. Фәрит Бәшир фикеренчә, «Адәмнәр»не «дәһшәт әсәр», «фаҗигаи әсәр» дип билгеләргә мөмкин [Бәшир, 2001: 75].

Повесть 1931 елда кабат басыла. Бу басмада әсәр язучы тарафыннан тагын бер кат редакцияләнеп чыгыла. XV бүлекнең уртасына кадәр (повесть ун сигез бүлектән тора) үзгәрешсез диярлек бара. Аерым җөмлә төзелешенә кайбер төзәтмәләр кертелә һәм кайбер персонажларның исемнәре үзгәртелә (Сабирә- Сатирә). XV бүлек уртасыннан исә «Адәмнәр» бөтенләй үзгәртеп языла. Биредә ач авылга ярдәм килү күренеше өстәлә. Галимҗан Ибраһимов ачлыкның тетрәндергеч картиналарын тагын да калкурак итеп сурәтләүгә ирешә. 1921-1922 елгы ачлык вакыйгаларына багышланган әсәр дәһшәтле сурәтләүдән башланып, фаҗигале ноктада тәмам була. Бу повесть ил тарихында мондый дәһшәтле фаҗига бүтән кабатланмасын өчен кешелекне кисәтү буларак яңгырый. «Адәмнәр» – тарихта булып узган ачлык афәтенең бер сәхифәсе генә әле.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте сюжеты белән катлаулы әсәр түгел. Ләкин психологик яктан гаять катлаулы. Әсәрдә ачлыкка дучар булган кешеләр психологиясе натуралистик

планда бирелә. Ачлык күренешләренең шаһите булган Г. Ибраһимов шул елларның ачлык афәтен бөтен тулылыгы белән күрсәтүгә ирешә. Ачлык кешене физик яктан гына түгел психологик яктан да гариплəндерә. Автор фикеренчә, шактый гына яхшы көн күрүчеләр дә ачлык афәтеннән котыла алмый. Ачлык бик яман нәрсә, ачлыкның баштагы биш-алты көне бик үткен, бик газаплы, бик чыдамсыз була, аннан соң адәм ни туры килсә шуны бетергәнче ашый, булмаса, ярты үлек кебек үзен дә, дөньясын да оныта торган бер машинага әйләнә. Әсәрнең төп идеясе шунда бирелә, ләкин сәбәпләре күрсәтелми.

## ӘДӘБИЯТ


Бәшир Ф. Егерме беренче ел авазы // Бәшир Ф. Сөйлә, каләм! Әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 75.

Җәләлиева М.Ш. Әдип Галимҗан Ибраһимов // М.Ш. Җәләлиева. Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 26.

Ибраһимов Г. Адәмнәр // Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман / Галимҗан Ибраһимов; төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 286–319.



**И.Ф. КӘРИМОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# РӘВЕШЛӘРНЕ ӨЙРӘТҮДӘ ЯҢА МЕТОД ҺӘМ АЛЫМНАР КУЛЛАНУ


**Аннотация.** Проблема приобщения к языку другого народа, изучения национальных культур и активного их пользования в системе педагогического образования является наиболее актуальной. Использование нетрадиционных форм уроков, новейших технологий, современных методов приводит к тому, что учащиеся с интересом изучают данный язык, интеллектуально и нравственно взрослеют.

**Abstract.** The problem of familiarization with the language of another people, deep study of national cultures and their active use in the system of pedagogical education is the most urgent. The use of non-traditional forms of lessons, the latest technologies, modern methods leads to the fact that students are interested in learning this language, intellectually and morally grow up.



**Ключевые слова:** познавательная деятельность, обратная связь, творческая личность, игра, речевые умения.

**Keywords:** cognitive activity, feedback, creative personality, game, speech skills.


Бүгенге уку-укыту процессы укытучылар алдына педагогик технологияләрнең принципларына таянып эшләү, уку-укыту эшендә әлегә кадәр булган технологияләрнең барсын да теге яки бу дәрәҗәдә куллану максатларын куя.

Педагогик технологияләр – укыту эшчәнлеген билгеле бер эзлеклелектә оештыру һәм фаразланган нәтиҗәгә ирешү юлларын билгеләү ул.

Аңлатмалы-күрсәтмәле технологияләр укыту эшендә аерым роль һәм урын билгели, төп игътибарны белемнең ни дәрәҗәдә үзләштерелүен тиз арада тикшерү мөмкинлеге булган тышкы күрсәткечләргә, ягъни өлгереш процентына, уку процессының дидактик яктан ничек җиһазланган булуын ачыклауга юнәлтә. Әмма шул ук вакытта бала аңында бара торган үзгәрешләр, аның үсешендәге интеллектуаль үзенчәлекләр белән бәйле эчке күрсәткечләр, эзлекле рәвештә өйрәнелмичә, укытучының игътибарыннан читтә кала.

Үстерелешле технологияләр белән эшләүче мөгаллимнәр исә уку-укытуны шәхеснең аң үсеше чарасына әверелдерүгә ирешә. Яңа технологияләр укучыларга мәгълүмат җиткерүне кире какмый, бары тик мәгълүматның әһәмияте генә үзгәрә. Ул хәзер укучының, белемне үзләштерүдән һәм хәтердә калдырудан бигрәк, үз иҗат җимешен булдыру юлында зарури булган шартлар һәм тирәлек сыйфатында кирәк. Мәгълүм булганча, шәхес бары тик үз эшчәнлеге барышында гына рухи яктан үсә, җитлегә. Баланы да эшчәнлек барышында гына эш-гамәлләр кылырга өйрәтергә була.

Хәзерге вакытта мәктәпләргә кертелә торган барлык яңалыклар, башлыча, күнегелгән технологияләр кысасына керми торган уку фәннәре эчтәлеген, укыту рәвешен һәм алымнарын үзгәртүгә кагыла. Аның максаты укучыларның күпчелеге танып белүнең арта барган ихтыяҗы дәрәҗәсендә укый алырдай шартлар тудырудан гыйбарәт. Бары тик аз бала өчен генә, искәрмә буларак, теләк-омтылыш уятуның өстәмә чараларын күрү таләп ителә. Шәхесне үстерүне игътибар үзәгендә тоткан технологияләргә түбәндәге яңа педагогик алымнар керә:

* белемне тулысынча үзләштерү;

* төрле дәрәҗәдәге укыту;

* күмәк төстә үзара ярдәмләшеп укыту;

* модульле укыту технологияләре

Алар уку-укыту процессын балаларның шәхси сәләтенә, төрле дәрәҗәдәге аралашуга, һәр мәктәпнең үзенчәлекләренә яраклаштыру мөмкинлеге бирә.

Заманча педагогика өлкәсендә яңа алымнар һәм методлар гаять күп. Дәреснең кайсы этабында нинди алымнар куллану, укучының белем һәм кызыксыну дәрәҗәсенә китереп кайсы методтан файдалануны билгеләү укытучыдан педагогик осталык таләп итә. Хәзер шулар белән рәвешләрне өйрәтү мисалында танышып үтәрбез.

*“Плюс-минус-кызыклы” алымы.* Әлеге алым дәреснең барлык этапларында да кулланыла ала.

«П» - “плюс” графасына укучылар дәрес барышында ошаган барлык әйберләрне язалар – уңай тәэсир калдырган эш формалары, мәгълүмат һ.б.

«М» - «минус» графасына тискәре хисләр тудырган, укучы фикеренчә, кирәксез, файдасыз дип саналган барлык әйберләр языла.

«К» - «кызыклы» гграфасына укучылар үзләре өчен күңелле һәм мавыктыргыч булган фактларны, тагынниләр белергә телиләр – шуларны язалар.

Әлеге таблицаны Кембридж университетының медицина фәннәре докторы Эдвард де Боно уйлап тапкан. Бу алым укытучыга дәрескә укучы күзлегеннән карарга мөмикнлек бирә, һәр укучының фикерен анализларга булыша.

*“Беләм – белергә телим – белдем” алымы* теманы үзләштерү дәвамында тутырылып барыла.

Мәсәлән:

| Беләм | Белергә телим | Белдем |
|---|---|---|
| Мөстәкыйль сүз төркеме<br>Эш-хәрәкәтнең билгесен белдерә<br>Төрләнми торган сүз төркеме<br>Синтаксик роле – хәл | Рәвешне башка сүз төркемнәреннән ничек аерырга?<br>Рәвешләр гел кушылып язылалармы?<br>Рәвешләр ничек барлыкка килгәннәр? һ.б. | Рәвешне башка сүз төркемнәреннән аермасы – төрләнми торган сүз төркеме |

*«Кластер» алымы* - материалны график рәвештә оештыру. Эш тәртибе бик гади:

1. Кәгазь бите яки такта уртасына бер теманы язып куялар. Безнең очракта ул – рәвеш.

2. Кырыйдагы буш урыннарга әлеге төшенчә (җөмлә, әйтем дә булырга мөмкин) белән бәйле идеяләр, фактлар,образлар, предметларны язалар (“Планета һәм аның иярченнәре” моделе).

3. Әлеге сүзләрне төп төшенчә белән тоташтыралар. Һәр “иярченнең” үз “иярчене” дә барлыкка килергә мөмкин. Нәтиҗәдә, укучыларның фикерләре, уйларыннан торган структура барлыкка килә. Әлеге структура өйрәнелә торган

теманың мәгълүмати кырын билгели. Буалым теманы бик тиз аңларга һәм истә калдырырга ярдәм итә.

Кластер алымы белән эшләгәндә берничә кагыйдәне истән чыгармаска кирәк: башка килгән барлык фикерләрне дә курыкмыйча язарга; вакыт һәм идеяләр бетмичә эштән туктамаска; булдыра алганча күбрәк бәйләнешләр төзергә тырышырга.

Бу алымны дәреснең рефлексия өлешендә куллану бик отышлы. Максаттан чыгып, эш төркемнәрдә, парларда, яки индивидуаль рәвештә башкарылырга мөмкин.

*"Дөрес һәм ялгыш фикерләр алымы".* Укучылар әгәр дә әйтелгән фикер белән килешәләр, аны дөрес дип саныйлар икән – җөмлә кырыена "+" тамгасы куялар, ә килешмәсәләр – "-". Бу алым теоретик материалны үзләштергәннән соң кулланыла. Мәсәлән, рәвеш сүз төркемен өйрәнгәннән соң түбәндәге фикерләрне бирергә була.

1. Рәвеш – мөстәкыйль сүз төркеме. +
2. Рәвеш предметның билгесен белдерә аламы? -
3. Рәвешнең чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләре бар. -
4. Рәвеш нишли? соравына җавап бирә. -
5. Охшату-чагыштыру – ул билге рәвеше. +
6. Рәвеш җөмләдә хәл генә булып килә ала. -
7. Рәвеш ничек? дигән сорауга җавап булып килә аламы?+
8. *Алпан-тилпән* – парлы рәвеш. +
9. Рәвеш эш-хәрәкәтнең билгесен белдерә. +
10. Хәл рәвешләре ул – урын, вакыт,сәбәп-максат рәвешләре. +

Яңа белем һәм күнекмәләр алуга, акыл эшчәнлеген башлап җибәрүгә әзерлек максатыннан, дәрес башында эвристик разминка үткәрү алымын уңышлы дип санала. Алар үз эченә кечкенә вакыт аралыгында үткәрергә мөмкин булган дидактик уеннарны алалар. Мәсәлән:

1. Мәкальләрне дәвам итү.
2. " Кем тизрәк?" уены.

Укытучы табышмакларны укый. Укучылар катнашучылар аларның җавапларын табалар. Аннан соң табышмак составында булган рәвешләрне, мәгънәләренә карап, төркемчәләргә бүлеп язалар.

Күргәнебезчә, татар теле дәресләрен нәтиҗәле итеп үткәрерү өчен уңайлы алым һәм методлар бик күп. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку

материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур.

### ӘДӘБИЯТ

1. Харисова Ч.М. Татар теле. Морфология: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2010. 128 б.

2. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. 302 б.

**С.Л. КУТАЛМЫШ**

*Санкт-Петербургский государственный университет, Россия*

## К ВОПРОСУ О СОДЕРЖАНИИ ПОНЯТИЯ «ФОНЕМА»

**Аннотация.** Фонология – область языкознания, которая активно развивается в наше время. Эта сфера лингвистики начала складываться лишь во второй половине XIX в.; многие термины, составляющие ее понятийно-терминологический аппарат, продолжают уточняться в наши дни под влиянием развития общей научной мысли. Область психического имеет физическую основу, а следовательно, и фонема имеет физическую природу. Звук, или фон, и буква, или графема, являются лишь выражением фонемы в устной и письменной речи.

**Abstract.** Phonology is an active developing field of linguistics nowadays. This sphere of linguistics started to form at the second part of XIX century. A lot of terms making up its conceptual apparatus continue to be defined more exactly under the influence of the general science development. Mind has a physical nature; therefore the nature of a phoneme is physical too. A sound (or a phone) and a letter (or a grapheme) are only representations of a phoneme in verbal or written speech.

**Ключевые слова:** фонема, фон, графема, фонология, репрезентация

**Keywords:** phoneme, phone, grapheme, phonology, representation

Одним из популярных и активно развивающихся направлений в области языкознания в целом и тюркологии в частности является фонология – наука о фонеме и фонетическом строении языка. Специалисты в области фонологии стремятся определить фонемный состав языков и провести межъязыковое сравнение [Трубецкой, 1987 (1932)]. Подобного рода исследования вызывают интерес в том числе у специалистов-тюркологов.

В современном языкознании понятие «фонема» зачастую ассоциируется со звуковым образом. Так, в лингвистическом словаре О.С. Ахмановой встречаем следующее определение данного термина: «Фонема – это 1) кратчайшая (минимальная) единица системы выражения звукового языка, представляющая собой определенную совокупность одновременно реализующихся дифференциальных признаков и способная различать звуковые оболочки (звуковую сторо-

ну, звучание) разных слов и морфем; 2) класс фонетически подобных звуков (аллофонов), неспособных к взаимному противопоставлению и выбираемых согласно определенным правилам дистрибуции; 3) в психофонетической трактовке – представление звука речи в качестве психического эквивалента реально произносимых звуков; 4) абстракция второй степени, представляющая собой отвлечение от всех позиционных вариантов и индивидуальных особенностей произнесения данного звука» [Ахманова, 2004: 494]. Как видно, все данные определения рассматриваемого термина имеют отношение прежде всего к звуковой сфере языка.

В первую очередь со звуком связывал понятие фонемы и И.А. Бодуэн де Куртенэ, объясняя ее природу следующим образом: «Фонема – языковедческий термин: психически живая фонетическая единица. Пока мы имеем дело с преходящим говорением и слушанием, нам достаточно термина звук, обозначающего простейшую фонационную, или произносительную, единицу, вызывающую единое акустическо-фонетическое впечатление. Но если мы встанем на почву действительного языка, существующего в своей непрерывности только психически, только как мир представлений, нам уже не будет достаточно понятия звука, и мы будем искать другого термина, могущего обозначать психический эквивалент звука. Именно таким термином и является термин фонема» [Бодуэн де Куртенэ, 1963 (1899): 351].

Об «акустическом образе» писал и Ф. де Соссюр. Так, в трактате этого выдающегося исследователя находим: «В языке /…/ не существует ничего, кроме акустического образа, который может быть передан посредством определенного зрительного образа» [Соссюр, 1999: 23]. Именно благодаря этому передовому взгляду сформировалась возможность развития языкознания во второй половине XIX в. и организации фонологии как научной дисциплины. Такой взгляд на вещи был необходим, так как в XIX в. для многих исследователей «буква» и «звук» представляли собой единое, неделимое целое. Более того, буква довлела над звуком, о чем упоминает в своей работе Ф. де Соссюр [Соссюр, 1999: 37-38]. Подчеркивая значение звука, Ф. де Соссюр и И.А. Бодуэн де Куртенэ дали возможность «букве» и «звуку» разделиться и оформиться в два самостоятельных языковых понятия. Именно это событие и стало отправной вехой в становлении фонологии как научной отрасли.

Языковое явление, которое И.А. Бодуэн де Куртенэ определял как «психический эквивалент звука», а Ф. де Соссюр – как «акустический образ», в современной науке также не получил всеобъемлющего описания. Однако с некоторых пор в физике бытует представление о том, что область психического

имеет под собой химико-физическую подоплеку [Schiffer, 2019]. С точки зрения нашего исследования, это значит, что фонема также имеет физическую природу и должна поддаваться исчислениям в физических величинах. С такой точки зрения, звук, или фон, и буква, или графема, представляют собой реализации фонемы в устной и письменной речи. Так как эти две системы (звуковая речь и письмо) взаимодействуют с разными органами чувств, они представляются равнозначными, равноценными, по крайней мере, до тех пор, пока не доказано преимущество слуховой сенсорной системы перед зрительной, или наоборот.

## ЛИТЕРАТУРА


Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. Изд. 2-е, стереотипное. М.: Едиториал УРСС, 2004. 576 с.

Бодуэн де Куртенэ И.А. Фонема / Пер. с пол. / И.А. Бодуэн де Куртенэ // Избранные труды по общему языкознанию: В 2 т. М.: Изд-во Акад. Наук СССР, 1963. Т.1. С. 351-352 (184 с.). (Первая публикация: 1899.)

Соссюр Ф. де. Курс общей лингвистики / Ред. Ш. Балли и А. Сеше; Пер. с франц. А. Сухотина; Примечания / Пер. с франц. С.В. Чистяковой. Под общ. ред. М.Э. Рут. Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та, 1999. 432 с.

Трубецкой Н.С. Мордовская фонологическая система в сравнении с русской / Пер. с нем. и прим. Н.Л. Сухачева // Избранные труды по филологии / Н.С. Трубецкой, [сост. В.А. Виноградов и В.П. Нерознак, под ред. Т.В. Гамкрелидзе и др.]. – М.: «Прогресс», 1987. С. 63-66 (560 с.). (Первая публикация: 1932.)

Schiffer F.The physical nature of subjective experience and its interaction with the brain // Medical Hypotheses, 2019, no. 125, pp. 57-69.



**И.М. МАКАРОВ, Г.Р. ШАКИРОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ АРТ-ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


**Аннотация.** В статье рассматриваются понятие арт-технология и возможности использования видов данной технологии на уроках родного (татарского) языка.

**Abstract.** The article deals with the concept of art-technology and use of it at the lessons of native (Tatar) language.



**Ключевые слова:** арт-технология, татарский язык, обучение

**Keywords:** art-technology, Tatar language, teaching


Белем бирү системасының төп бурычын, ягъни иҗади һәм креатив фикерләүче, белемле, туган һәм чит телләрдә иркен сөйләшеп аралашучы

билингваль һәм полилингваль шәхес тәрбияләүне күздә тотып, телгә өйрәтү процессында инновацион юнәлешләрне, гамәли белем бирү технологияләрен куллану көн таләбе булып тора. Шулай ук, тиз үзгәрешләр кичерә торган җәмгыятьнең кешеләр психикасына зур йогынты ясавын исәпкә алып, тел дәресләрендә укучыларның физик һәм психологик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту да зур әһәмияткә ия. Укучыларның белем дәрәҗәсен генә түгел, ә рухи, физик һәм психологик сәламәтлекләрен үстерүгә юнәлтелгән шундый технологияләрнең берсе – арт-технология.

Арт-технология ул – уку процессында шәхеснең иҗади мөмкинлекләрен үстерүгә юнәлдерелгән төрле иҗат төрләренә хас булган метод, алымнар җыелмасы. Арт-технологияләрне шулай ук сәнгати һәм иҗади технологияләр дип тә атыйлар [Лелявина, 2016: 87] .

Күп уртак яклары булуга һәм охшаш чараларны куллануга карамастан, арт технология белән арт терапияне бутарга ярамый. Арт-терапия психологик яктан дәвалауга юнәлдерелсә, арт-технология белем алу максатына ирешүдә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Арт-технология уку-укыту эшчәнлегендә чагыштырмача яңа күренеш. Мөстәкыйль юнәлеш буларак ул XX гасыр урталарында АКШ һәм Бөек Британия алдынгы арт-педагоглар, психологлар һәм сәнгать эшлеклеләренең тәҗрибәләренә нигезләнеп үсә башлый. Сәнгатьнең белем бирү юнәлешендәге уңай тәэсире турында чит ил галимнәре Э. Сеген, Ж. Демор, О. Декроли һәм рус галимнәре Л.С. Выготский, А.И. Граборов, Е.А. Екжанова, Т.С. Комарова үз фикерләрен белдергәннәр. Алар карашынча, туган тел дәресләрендә укучыларның төрле сәнгать әсәрләренә мөрәҗәгать итүләре, аларның өйрәнелә торган тел белән кызыксынуларын арттыра, кабул итү, игътибарлык һәм фикерләү сәләтен үстерә, аралашу күнекмәләрен камилләштерә.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларының (ФДББС) нигезендә укучыларның белем, күнекмәләрен үстерүдән тыш, шәхесне төрле яклап үстерү, шул исәптән иҗади яктан үстерү дә, ята. Шуннан чыгып, арт-технологиянең ФДББСка туры килгән бурычлары билгеләнә:

- иҗади сәләтне үстерү;
- эмоциональ, әхлакый потенциалны үстерү;
- үзбәяне һәм үзаңны үстерү һ.б.

Технологияне төркемләү мәсьәләсенә килгәндә, төрле фикерләр яшәп килә, әмма без барысы өчен дә уртак һәм күпмедер дәрәҗәдә

тулыландырылган һәм төгәлләштерелгән классификацияне тәкъдим итәбез. Әлбәттә, мондый бүленеш шартлы рәвештә билгеләнә:

- библиотехнология;
- музыкаль арт-технология;
- драматехнология;
- экияти арт-технология;
- визуаль арт-технология

Шушы төрләрнең асылын аңлау өчен, аларның эчтәлеге белән танышып китү зарур.

*Библиотехнология* – сүзнең тәэсир итү көченә нигезләнгән арт технологиянең бер юнәлеше. Әлеге юнәлештә сүз белдерә торган семантик мәгънәдән тыш, аның төрле бәйләнешкә кереп, сүзтезмә һәм җөмләләр эчендә белдерә алган функциональ мәгънәләре игътибарга лаек. Библиотехнология кысаларында туган тел дәресләренең төренә карап, түбәндәге эш төрләрен кулланырга мөмкин: шигырь иҗат итү, әсәрләр язу, әсәр формасында автобиография язу, түгәрәк буенча экият төзү, әдәби глобус әзерләү һ.б.

*Музыкаль арт-технология* – уку-укыту процессында музыка сәнгате үрнәкләрен куллану. Бу төр сәнгатьнең кеше аңына зур йогынты ясый алу мөмкинлеге инде дистәләгән еллар дәвамында исбатланып килде, һәм укыту эшчәнлегендә әлеге төрне куллану укучыларның хис-кичерешләренә зур йогынты ясый алуы соңгы елларда үткәрелгән тәҗрибәләрдә ачыкланды. Безнең фикеребезчә, туган тел дәресләрендә әлеге технологиянең түбәндәге алымнарын куллану, телне өйрәнү нәтиҗәлелегенә уңай йогынты ясыячак: музыканы рәсемгә төшерү, музыка тыңлау, әңгәмә оештыру һәм башкалар.

*Драматехнология* – үз хис-кичерешләреңне, тойгыларыңны төгәл күрсәтә белүгә нигезләнгән эшчәнлекнең бер төре. Хәзерге көн җәмгыятьтә кеше хис-кичерешләрен башкалардан яшерергә тырыша яки аларны дөрес җиткерә белмәвеннән курка, шушы төр технологияләрне куллану, укучыларга хис-кичерешләрнең кешелек сыфатын билгеләүче төп шарты булып торуын аңлатуга юнәлтелгән [Степанова, 2016: 97]. Аннан тыш әлеге технология укучының эчендә яшерелеп яткан артистлык сәләтен ачуга ярдәм итә. Технология тәкъдим иткән эш төрләре арасында: пантомима, фильм, мультфильмнарны тавышлы итү, әсәрләрне сәхнәләштерү, курчак театры, видеокруиз, импровизация һ. б. бар.

*Экияти арт-технология* шәхеснең иҗади фикерләвен, бәйләнешле сөйләм телен үстерүне максат итеп куя. Бу төр технология башлангыч

сыйныф укучылары белән эшләгәндә төп эш төре буларак билгеләнә һәм туган тел дәресләрендә әкият иҗат итү, әкиятне сәхнәләштерү, әкиятне рәсемгә төшерү, «әкияти сәяхәт», грамматик әкият язу кебек алымнар куллануны күздә тота.

Арт-технологиянең соңгы төре – *визуаль арт-технология*. Бу технология үз эченә сынлы-сәнгать, рәсем сәнгате, фото сәнгатен һ. б. ала. Визуаль арт технологиянең күптөрлелеге аның алымнарының төрлелегенә дә йогынты ясый. Мәсәлән, бирелгән темага төркемнәрдә рәсем ясау, «Триптих» («Мин үзем», «Мин башкалар күзлегеннән», «Мин нинди булырга телим»), сүз сәнгатен рәсемләштерү, ирекле рәсем, коллаж ясау, грамматик конструкцияләр төзү, ассоциатив рәсемнәрне сурәтләп бирү һәм башкалар.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, туган телне өйрәтү процессында арт-технологияләр куллану укучыларның кызыксынуын арттыра, аларның хисләренә уңай йогынты ясый, физик һәм психологик сәламәтлекләрен үстерүгә шартлар тудыра. «Балалар матурлык, уен, әкият, җыр, рәсем, иҗат дөньясында яшәргә тиеш» – дип язган бөек педагог В. А. Сухомлинский.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Лелявина К.И., Клименко Г.А. Арт-технологии в образовательном процессе средней школы // В сборнике: Перспективы развития науки и образования: III международная научно-практическая конференция. – 2016. – С. 87-90.

2. Степанова А.В., Жданова С.Н. Арт-технологии в социализации учащихся // В сборнике: Современные проблемы и перспективы развития педагогики и психологии. Сборн. материалов 9-ой Международной научно-практической конференции. – 2016. – С. 95-98.

**З.Н. МӨБӘРӘКШИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

# ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ ТӨС АТАМАЛАРЫНЫҢ МӘГЪНӘЛӘРЕ (ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР МИСАЛЫНДА)

**Аннотация.** Мәкаләдә татар һәм рус фразеологизмнарында очраган төс мәгънәләрен чагыштырып өйрәнү карала. Моңа нисбәтле фразеология өлкәсендә булган тикшеренүләр аерым кызыксыну тудыра. Алар татар һәм рус халкының тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, гореф-гадәтләрен, йолаларын чагылдыра. Шуның өчен дә фразеологик берәмлекләрне белү телне өйрәнүнең мөһим аспекты булып санала.

**Abstract.** The article deals with the comparison of color values found in the Tatar and Russian phraseological units. Of particular interest are studies in the field of phraseology. They reflect the life, culture, art, traditions and customs of the Tatar and Russian people. Therefore, knowledge of phraseological units is an important aspect of language learning.

**Ключевые слова.** Татар һәм рус фразеологизмнары, төс мәгънәләре.

**Keywords.** Tatar and Russian phraseological units, color meanings.

Төснең роле төрле халыклар символикасында югары мәгънәгә ия. Төс кешенең психикасына йогынты ясый, шуның өчен төрле халыкларның телләрендә һәм мәдәниятендә билгеле бер төсләрнең символик әһәмияте күзәтелә. Монда барлык телләргә хас булган уртаклыклар бар һәм шул ук вакытта бер-берсеннән аерылып торган үзенчәлекләр дә очрый.

Дөньяны төсләр аша кабул итү телнең лексик һәм фразеологик системаларында чагылыш тапкан. Халыклар символикасында төсләр бик мөһим роль уйный. Аларның оптик йогынтысының аермасы кешенең кәефендә чагыла. Төсләрнең психикага булган тәэсире, якты һәм караңгы төсләр арасындагы аермасы (контраст) – боларның һәммәсен кеше үзенең хис-кичерешләрен, күзаллауларын белдерү өчен куллана.

Төсне тасвирлаучы сүзләр күпчелек фразеологик әйтемнәрдә таралган һәм җәмгыятьтә киң кулланыла. Семантик яктан алар фразеологизмнарга эмоциональ-экспрессив сыйфат һәм образлылык өсти. Шуны да онытмаска кирәк: кара төс күпчелек очракта күчерелмә мәгънәдә тискәрелекне белдерүенә карамастан, аның уңай төсмерләре дә татар телендә бар. Боларның барысын да без мисалларда китереп үтәрбез.

Татар һәм рус фразеологизмнарында еш кына кара төс кешенең начар сыйфатын белдереп килә. Мәсәлән, кара төс татар һәм рус телләрендә начар, ямьсез мәгънә, ачулыкны, үч алу теләген белдергән очраклар:

*Зәһәр (кара) елан* – 1. Җан дошманы. Эчендәге агуы чагарга урын-вакыт күзәтүче, үлем теләүче, кара эчле, зәһәр дошман. Змея подколодная – Коварный, опасный, неблагодарный человек. Татар телендә кулланылган кара коелу сүзтезмәсе рус телендә позеленеть дип бирелә. Димәк, рус телендә ачу мәгънәсе яшел төс белән дә кулланып аңлатыла:

Татар һәм рус фразеологизмнарында еш кына кара мәче (песи) символы кулланыла. Ул образ кычкырышу, ызгышу, кеше белән кеше арасында начар мөнәсәбәтне, дошманлыкны белдерә:

*Кара мәче үтү (кәҗәләре сөзешкән)* – арага дошманлык шаукымы керү. (Между ними) пробежала черная кошка – между лицами, находившимися в дружеских отношениях, проихошла внезапная размолвка, переросшая в ссору)

*Әлеге дә баягы, кара сыер аягы (бер балык башын чәйнәү)* – бер үк әйбер турында берничә тапкыр сөйләү. Сказка про белого бычка – одно и то же.

Күпчелек очракта кара төс кергән фразеологизмнар татар телендә дә, рус телендә дә бер үк мәгънә белдерә дип әйтергә мөмкин. Кара төс аерым алганда

рус фразеологизмнарында “страшный” (куркыныч), “грязный” (пычрак), “тяжкий” (авыр), “бестолковый” (мәгънәсез), “хмурый” (караңгы чырайлы) сүзләре белән килә. Нигездә, сүзгә-сүз ягъни калькалашкан фразеологизмнар тупланган.

Ак – барлык яктан да идеаль һәм табигый төс. Гомуми күзаллауда ак төс салкынлык, чисталык, ихласлык сыйфатларына туры килә. Семантик яктан, ак төс иң яхшы төс дип бәяләнә. Кызыл төс кебек актив диярлек, әмма шактый йомшак төс. Татар теленең фразелогик берәмлекләре арасында ак төснең тискәре мәгънәләрне белдергән очраклар да күзәтелде. Мәсәлән, ак төс ялкаулыкны, физик хезмәт белән эшләргә теләмәүне символлаштыра:

*Ак кул* – эшләми, хезмәт итми, кеше көченнән файдаланып яшәүче; кул хезмәте белән шөгыльләнмәүче; эш сөйми торган кеше. Белоручка – тот (или та), кто чуждается физической или вообще трудной, грубой работы

Татар телендә юлга яки сәфәргә чыгар алдыннан хәерле юл яки юлың уңсын, исән-сау, исән-имин барып җитәргә язсын дип теләп әйтү киң таралган. Рус телендә исә әлеге гыйбарә ике мәгънәне белдерә. Тарихи яктан аның килеп чыгышы хәерле юл теләүне аңлаткан, әмма соңрак ул тискәре төсмер дә алган. “Проваливай, без тебя обойдемся” – дигән гыйбарә белән бертигез мәгънәдә йөри. “Бу сүзләр белән Россиядә ерак юлга озатканнар һәм бернинди дә тискәре мәгънә әйтмәгәннәр.

*Юлыңа ак җәймә* – хәерле юл теләп әйтем. Скатертью дорожка – имеется в виду, что говорящий не нуждается в дальнейшем присутствии лица или группы лиц, желает избавиться от общения с ними, говорится с неодобрением.

*Кар кебек ак чәчле* – ап-ак сакаллы, кып-кызыл чырайлы картларны шулай әйтәләр. Седой как лунь – совершенно седой.

*Ак май* – сыер мае, гөбе мае. Сливочное масло – пищевой продукт, изготавливаемый сепарированием или сбиванием сливок, полученных из коровьего молока

Ак төс татар фразеологизмнарында бәхет һәм шатлык төшенчәләрен символлаштыра, кешенең ихласлык, гаделлек, тәртиплелек һәм олы җанлылык кебек уңай сыйфатларын тасвирлый:

*Ак бәхетләр теләү* – керсез, тапсыз, якты бәхет. Ак бәхетләр тели-тели озатканда Карап калам күз керфегем талганчы. М.Фәйзи. – Мин сезгә эшегездә уңыш, ак бәхет телим. Желать безоблачного счастья – счастливое состояние, безмятежное счастье, огромное счастье

Нәтиҗәдә, ак төс кергән рус фразеологизмнары татар теленә калькалашып кергән дип әйтергә нигез бар. Татар телендә очраган фразеологик

әйтелмәне укып карасак, аның күпчелек өлеше рус теленнән алынган дип әйтергә мөмкин. Кайбер очракларда, әйтик, “белые воротнички” – “ак якалар” гыйбарәсе иң элек инглиз телендә барлыкка килә һәм, калькалашып, рус теле сөйләменә кереп китә. Ә руслар татар халкы белән тыгыз мөнәсәбәттә торганлыктан һәм бер мохиттә яки тирәлектә булып, аралашу-сөйләшүдән ул татар теленә дә җиңел кереп китә. Әмма бер үк мәгънәне белдереп, сүзгә-сүз тәрҗемә ителмәгән фразеологизмнар да юк түгел.

Кызыл төс татар һәм рус фразеологизмнарында мәсхәрәләүдә, оят-хурлыкка калдырганда кулланыла. Кешене кызартырлык хәлгә җиткерү – кимсетүне, көнләшүне аңлата яисә кешенең организмында булган эчке психологик халәте дә моңа сәбәпче булырга мөмкин:

*Биткә кызыллык китерү* – кешене оялту, оятка калдыру, кеше алдында кызарырга мәҗбүр итү. *Дөрес, биткә кызыллык китерерлек итмәс. М. Фәйзи. Ярый, бу юлы мин сезне яклап калам, сине дә биткә кызыллык китермәссең дип уйлыйм. Заставить покраснеть – опозорить на весь свет*

Табигатьтә булмаган *“кызыл кар”* татар телендә нәрсәнең дә булса мөмкин була алмавында әйтелә, ә рус телендә исә ул берничә төрле вариантта килгән:

*Кызыл кар яугач (яуганда)* – һичкайчан, беркайчан да үтәлмәячәк коры вәгъдәләр, булмый торган эш хакында. Мортаза йөз тәңкәне кызыл кар яугач түләрмен дип... алган. Г. Тукай. *Когда на горе рак свистнет (когда песок в камень войдет, когда солнце задом оборотится, когда солнце взойдет от заката, когда на осине груша вырастет)* – неизвестно когда, в неопределенном будущем времени, никогда

Сары төс актив, әмма йомшак төс дип бәяләнә. Ул яктылыкка якын төс. Сары үзенең югары чисталыгында якты табигате, назлылыгы, сафлыгы белән аерылып тора. *Сары,* мәсәлән, кеше тәненең төсен белдергәндә әйтелә һәм моңсулык хисен чагылдыра:

*Йөзгә сары коелу* – сагынып саргаю, бик күрәсе килеп, гыйшыктан зарыгып сарыга сабышу яки ачлык, әсирлек, авыр газап кичерүләрдән саргаю. Алтын балдак кия-кия Бармакларым уелды; Син җаныйны уйлый-уйлый йөземә сары коелды. Җыр. Үлем лагерьлары да йөзенә сары коя алмаган түгәрәк битле... Ш.Маннур. *Покрыться желтизной* – тосковать, печалиться, сохнуть от тоски

*Тел төбеңә сары май* – рәхмәт белдерү әйтеме. Ул сүзең өчен тел төбеңә сары май! Ш.Камал. *Твоими устами да мед пить* – хорошо, если бы все было так, как вы говорите; ответ на добрые предсказания

Шулай итеп, сары төс семантикасы татар һәм рус фразеологик берәмлекләрендә кайгы-сагышны, борчуны, хасталануны, мыскыллауны белдерә. Бу очракта калькалар сирәк очрады дип әйтеп була. Татар телендә сары төс кергән фразеологизмнар рус телендә икенче эквивалентта кулланылган: “желтизна”, “желторотый”, “праведник”, “мед”.

Галимнәр татар һәм рус телләренең күп еллар дәвамында бәйләнештә булганлыкларыннан, аларда күп санлы семантик-структур фразеологик тәңгәллекләр урнашуын дәлилли. Ягъни рус телендә иркен сөйләшкән татар кешесенең сөйләмендә рус фразеологизмнарын үзе тәрҗемә итеп, татар теленең кулланылышына кереп киткәндер дип тә фаразлап була. Һәрхәлдә, рус һәм татар фразеологик тәңгәллекләренең кайсы татар теле, кайсы рус теленең үзенеке булуын билгеләү кыен, кайбер очракта бөтенләй дә мөмкин түгел.

Шулай итеп, төсләр безнең тормыш-көнкүрешебездә гаять күп төрле роль уйный. Төсләрнең символикасын һәм үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнү безгә мәдәниятне, сәнгатьне, төрле илләрнең тарихын һәм эшлекле мөнәсәбәтләрне үстерүгә ярдәм итә. Төсләрнең төп мәгънәләрен ачыклау киләчәктә бихисап сорауларга җавап табарга булыша: халыкның гореф-гадәтләрен, менталитетын, тарихын, фәлсәфәсен һәм мәдәниятен өйрәнгәндә кулланыла.

## ӘДӘБИЯТ


*Татар телендә:*

Зәкиев М.З. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. Казан: Тат. кит. нәшр., 1957. 245 б.

Зәкиев М.З. Туган тел үсеше. Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. 84 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. I том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. 915 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. II том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. 959 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. III том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. 1013 б.

Гыйззәтуллина-Старцева Р.Г. , Гыйззәтуллин И.Г. Татарча-русча мәкальләр сүзлеге. Уфа: Вагант, 2011. 274 б.

*Рус телендә:*

Мокиенко В.М. Загадки русской фразеологии / В.М. Мокиенко. М.: Высш. шк., 1990. 160 с.

Гёте И.В. К учению о цвете (хроматика) / / Избранные сочинения по естествознанию / Пер. с нем. И.И. Канаева. Л.: Изд-во АН СССР, 1957. С. 261–358.

Закиров Р.Р Феномен цвета во фразеологии (на примере английского, русского и татарского языков): Монография. Казань: ТГГПУ, 2009. 247с.

Сафиуллина Ф.С. Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1996. 285 с.

Балли Ш. Очерк стилистики. Москва., 1905. 183с.

**Л. Р. МӨБӘРӘКШИНА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КОМПЬЮТЕР ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

**Аннотация.** В статье раскрываются возможности применения компьютерных технологий в процессе изучения или контроля знаний учащихся в общеобразовательных учреждениях. В статье компьютерная технология рассматривается как один из видов инновационных технологий, а именно способствующий активизации деятельности учащегося на протяжении всего урока; побуждающий обучающегося к самостоятельной и творческой деятельности, способствующий прямой и обратной связи учителя и ученика, создающий условия для организации интересного и эмоционально насыщенного урока.

**Abstract.** The article reveals the possibilities of using computer technologies in the process of studying or controlling students' knowledge in educational institutions. The computer technology in the article is revealed as one of the types of innovative technologies, namely, contributing to the revitalization of the student throughout the lesson; encouraging the student to independent and creative activity, promoting direct and feedback of the teacher and student, creating the conditions for organizing an interesting and emotionally rich lesson.

**Ключевые слова:** Инновация, компьютерные технологии, обучающийся, обучение.

**Keywords:** Innovation, computer technology, learner, training.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килүне таләп итә. Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр куя.

Укыту-тәрбиянең бүгенге көндәге уңышы укытучының бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып-белү процессы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәнүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле. Әйләнә-тирәне, кешелек дөньясын өйрәнү һәм аны укучыга дөрес аңлату, укучыны тормышка яраклаштыру – укытучылар алдына куелган мөһим бурыч [Камаева, 2012: 5].

Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы да артты. Дәресләрдә элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә.

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыру процессында уңышка ирешергә ярдәм итә.

Технология – (грек теленнән алынган сүз; сәнгать, осталык дигән мәгънәне белдерә) фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланылучы методлар, алымнар, ысуллар җыелмасы ул [Камаева, 2012: 6].

Бердәм белем бирү оешмаларында җаваплы, дисциплиналы, эзләнүче сыйфатларына ия булган укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа, ягъни инновацион педагогик технологияләр, метод, алым һәм чаралар куллану ярдәмгә килә. Шундый инновацион технологияләрнең берсе – компьютер технологияләре.

Компьютер – мәгариф өлкәсенә бик күп яңалыклар алып килә. Иң мөһим билгеләреннән берсе – интерактив такталар, алар ярдәмендә дәресләрдә графика, схема, диаграмма, карта, рәсем, фото һ.б. куллану мөмкинлеге [Захарова, 2003: 29].

“Инновация” (яңа, заманча) термины XIX гасырдан уку кулланылышта йөри. Аны, төрле халыкларның мәдәниятләре бер-берсенә йогынты ясый, хезмәттәшлек итә башлагач, америка галиме Джеймс У.Боткин тәкъдим иткән, чөнки XX гасыр башы җитештерү өлкәсенә яңалыклар кертү турындагы фән барлыкка килү белән мәгълүм. Педагогика өлкәсендәге яңалык проблемалары белән шөгыльләнә башлау узган гасырның 50 нче еллар ахырына туры килә.

Фәнни әдәбиятта “яңалык” һәм “инновация” төшенчәләре төрлечә аңлатыла. Яңалык – ул укыту процессына караган яңа чара (яңа метод, яңа методика, яңа технология һ.б.). Әлеге чараны үзләштерү процессын инновация дип саныйлар. Хәзерге заман таләпләренә туры килә торган белем бирү шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш ситуацияләренә, фән нигезләрен ныклы үзләштерүгә әзерләүне күздә тота. Соңгылары исә, яңа технологияләрне файдаланып, иҗади мөмкинлекләрне, фикерләүне, аралашу күнекмәләрен үстерү исәбенә, программаларда каралган. Заманча технологияләрне кулланганда, өйрәтү процессы буларак дәрес системасыннан укучыларның “төп яшәү формасына” күчүе күзәтелә (дәрес-иҗат, дәрес-очрашу, дәрес-хезмәт, дәрес-аралашу, дәрес-дуслык, дәрес-концерт, дәрес-әңгәмә, катнаш дәрес, дәрес-түгәрәк өстәл, дәрес-остаханә һ.б.)[Харисов, 2002: 260].

Компьютер технологияләрнең өстенлекле яклары:

- информацион технологияләр укыту материалын үзләштерүне киңәйтәләр. Биредә төс, графика, тавыш, анимация кебек чараларның кулланылышы ярдәм итә;

- укуга карата мотивацияләрен күтәрәләр;

- укучыларны мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итәләр, акыл эшчәнлеген активлаштыралар;

- рефликсия формалаштыралар (укучы эшчәнлек нәтиҗәләрен күрә ала, хата ясаган этапны табып, төзәтә ала) [Пугачев, Газенаур, 2009: 33].

Татар теле дәресләрендә компьютер технологияләр ярдәмендә түбәндәге эшләр башкарырга мөмкин:

- яңа материалны аңлатуны мультимедиа чараларын куллану ( мәсәлән, Power Point презентация программалары белән);

- өйрәтү программалары белән виртуаль контроль эшләр башкару;

- өйрәнелгән теманы кабатлау, ныгытуда төрле программалар куллану (тестлар һ.б.);

- укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегендә (өйрәтү программалары, электрон дәреслекләр, методик әсбаплар һ.б.);

- видео- һәм телеконференцияләр үткәрү.

Эш тәҗрибәсен хәзерге вакытта компьютер технологияләреннән башка күз алдына китерүе дә кыен. Белем һәм тәрбия бирүдә компьютер технологияләрнең өстенлекле яклары күп. Беренчедән, дәрес материалын мультимедиа мөмкинлекләргә ия булган югары сыйфатлы күрсәтмәлелек ярдәмендә җиткерү аң үсешенә уңай тәэсир итә. Икенчедән, хәтерләү сәләтен, укучының шәхси сыйфатларын үстерүгә, шулай ук укытуны интенсивлаштыруга ярдәм итә. Төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдырып, укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү нәтиҗәсендә, дәресләрнең эчтәлеге байый, кызыклырак була. Контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлекләр арта, чөнки материалны кабат укып, хатаны төзәтергә, проблема чишүнең берничә вариантын файдаланып карарга була. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, хаталарын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен компьютер технологияләре уңайлы. Укыту процессында алгы педагогик технологияләрне куллану яңа метод-алымнарны үстереп укытытучыларга, эш стилен үзгәртеп, яңача укытырга, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу исә педагогик процессны оештыруга һәм аның белән идарә итүгә үзенчәлекле бурычлар куя. Шулай итеп, татар телен компьютер технологияләре белән укыту-уку процессын яңача оештыру дигән сүз. Аның мөһим мәсьәләләре булып өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уяту, танып-белү активлыгын үстерү, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү тора.

## ӘДӘБИЯТ

Захарова И.Г. Информационные технологии в образовании: учеб. пособ. для студ. высш. пед. учеб. завед. М: «Академия», 2003. 192 с.

Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. Алабуга: АИ КФУ нәшрияты, 2012. 136 б.

Пугачев Г.М., Газенаур Е.Г. Роль информационных технологий в науке и образовании // Вестник Кемеровского государственного университета. – 2009. – № №. – С. 31–34.

Харисов Ф.Ф. Инновационные технологии на уроках татарского языка // Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар / 6 нчы Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе мтериаллары (Казан, 20 нче февраль, 2015 нче ел). Казан: Отечество, 2015. С. 171 – 174.

**А.И. МӨГЪТӘСИМОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ БАРЫШЫНДА ПРЕДМЕТАРА БӘЙЛӘНЕШ АЛЫМНАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ

**Аннотация.** В данной статье рассматривается вопрос межпредметных связей на уроках татарской литературы. Даются рекомендации по выявлению этой связи, использовании ее в целях гармоничного развития учащихся, расширения их кругозора, активизации мышления. В статье раскрываются метапредметные связи татарской литературы с историей, искусством, музыкой и татарским языком.

**Abstract.** This article deals with the issue of interdisciplinary relations in the lessons of Tatar literature. Recommendations are given to identify this relationship, use it for the harmonious development of students, expanding their horizons, activating thinking. The article reveals the metasubject relations of Tatar literature with history, art, music and the Tatar language.

**Ключевые слова**: татарская литература; межпредметные связи; урок; история; искусство; музыка; метод проектов; татарский язык; махмут хасанов; весенняя зарница.

**Keywords:** Tatar literature; interdisciplinary relations; lesson; history; art; music; method of projects; Tatar language; Mahmut Hasanov; spring lightning.

Предметара бәйләнеш – төрле фәннәр буенча белемнәрне берләштерү һәм нинди дә булса проблеманы чишү өчен махсус оештырылган дәрес. Мондый дәресләр укучыларга файдалы. Алган белемнәрне системага салырга мөмкинлек бирә, фәнгә карата кызыксыну уята. Дәрес барышында укучылар белән индивидуаль эшләргә, хаталарны вакытында төзәтергә мөмкинлек туа. Эш төрләренең чиратлашуы укучыларның игътибарлылыгына, активлыкларына уңай йогынты ясый.

М.Хәсәнов иҗатын өйрәнү барышында әдәбият дәресен татар һәм рус теле, тарих, сәнгать белән предметара бәйләнешләр оештырырга була.

Предметара бәйләнешне тормышка ашыру белемнәрне тирәнтен өйрәнүгә, фәнни терминнарның формалашуына, укыту-тәрбия процессының камилләшүенә уңай йогынты ясый. Интеграль дәресләр предметара бәйләнешне тәэмин итүнең бер чарасы булып тора, укытуның фәннилеген арттыра, белемнәрне системалаштырырга, логик фикерләү сәләтен үстерүгә,

укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүгә ярдәм итә. Гади дәресләргә караганда интегральләшкән дәресләрнең эстетик кыйммәте дә зур [Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТРМүи, 2015. – Б. 65].

«Язгы аҗаган» өйрәнгәндә тарих белән интегральләштерергә була. Мәсәлән: «Язгы аҗаган» әсәрендә сурәтләнгән вакыйгалар 1922-1957 елларга туры килә. Шушы еллар эчендә илебездә булган төп тарихи вакыйгаларны билгеләп була.

«Язгы аҗаган» үзенең күләме белән генә түгел, дәверләрнең, сәяси-иҗтимагый һәм социаль тетрәнүләрнең күп кенә драматик вакыйгаларын, төрле сыйныф вәкилләрнең, һөнәр ияләренең язмышларын киң полотнода чагылдыруы белән чын-чыннан роман жанрының җисемен аклый. Әдип Беренче бөтендөнья сугышы, революция давыллары, Идел-Кама буйларындагы ачлык-корылык еллары, күмәк хуҗалыкларга берләшү кыенлыклары, Бөек Ватаг сугышы героикасы, кама буе нефтҗ ятмаларын үзләштерә проблемалары яки теге-бу дәвердәге тормыш-көнкүрешнең рәвеше, теге-бу һөнәрнең асылы һ.б.ш. турында язамы – бай мәгълһматка таянып, тормышчан яза.

Татар һәм әдәбият дәресләрендә дә предметара бәйләнешләрне оештырырга була. Мәсәлән, сүзлек эше этабында мондый күнегүләрне файдаланырга була:

Романнан алынма сүзләрне табып, сүзлекләрдән аңлатмасын карагыз. Мисаллар: *галлюцинация, мелла, тәкатьсез, бәхил, вагранка, домна, аҗаган* һ.б. Кайсы телдән кергәнен билгеләгез.

Әдәбият һәм сәнгать, музыка предметара бәйләнешләрне дә күрәбез романда. Мәсәлән:

*Без түгел, кошлар моңая,*

*Кайтырга илләренә...*

Бу юллар кайсы җырдан? Аны кем башкара? Туган ил турында тагын нинди җырлар беләсез?

Әлеге җырны аудиоязмалардан тыңларга да була.

Проектлар методы бер яки берничә фән эчтәлегенә нигезләнергә мөмкин. Татар теленнән проект эшләгәндә татар әдәбияты, тарих, экология, география, биология, музыка белән бәйләнеш була ала. Проектлау укучыларның мөстәкыйльэше булса да укытучы җитәкчелегеннән башка уңышлы була алмый [Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм

әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТРМүи, 2015. – Б. 19].

“Язгы аҗаган” әсәрен өйрәнгәндә проектлау методын кулланырга була.

- “Язгы аҗаган”да фольклористик мотивлар.

Әлеге теманы өйрәнү – татар теле, сәнгать предметара бәйләнешләрне урнаштырырга ярдәм итә. Биредәге сынамышларны, җырларны, юрауларны җыю, өйрәнү, анализлау бик мөһим.

- “Язгы аҗаган”да рус алынмалары.

Темага карата проект төзү әсәрдәге бик күп алынма һәм рус сүзләрен өйрәнүгә багышлана. Бүгенге көндә әлеге сүзләрнең кулланылыш үзенчәлеген, сүзлекләрдә, әдәбиятта, матбугатта бирелешен, төрле фикерләрне анализлау эше белән бергә алып барырга була.

- “Язгы аҗаган”да тарих чагылышы.

Биредә илдәге иҗтимагый күренешләрне әсәр белән чагыштырып барырга мөмкин. Тарих дәреслекләрен дә кулланырга була.

Төрле фән укытучыларының иҗади дуслыгы укучыларның фәннәрне үзләштерүенә уңай йогынты ясый, чөнки бер предметны өйрәнгәндә кулланыла торган метод алымнар предметара бәйләнешләр нәтиҗәсендә икенче предметны укыту методикасына да күчә,уңышлы кулланыла башлый.

Предметара бәйләнешле дәресләр укучыны актив танып-белү эшчәнлегенә этәрә, һәр укучыга нинди дә булса бер өлкәдә үзен күрсәтергә мөмкинлекләр киңрәк ачыла. Укучы алган белемнәренең кайсы өлкәдә куллана алачагын тулырак күзаллый.

Укыту нинди төрдә булса да, ул яшь буынга кешелек тарафыннан тупланган белем хәзинәсен тапшыру процессы буларак кабул ителә. Кешелек үсешенең төрле чорларында белембирү эчтәлеге төрлечә булуы мәгълүм, ләкин аларның барысы да шәхес үсешен үзәккә куя.

Фәннең барлык өлкәләре дә үзара тыгыз бәйләнештә тора, шуңа күрә мәктәптә өйрәнелә торган фәннәр дә бер-берсенә белән бәйле.

## ӘДӘБИЯТ

Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм/ төз.: Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. Казан: ТРМүи, 2015. 110 б.

**ORD. PROF. DR. MURATGELDİ SÖYEGOV**
*Türkmenistan İlimler Akademisine bağlı Mahtumkulu Dil, Edebiyat ve Milli Elyazmalar Enstitüsü*
**ÖĞRETİM GÖREVLİSİ ŞAMUHAMMET ÇARIYEV**
*Mahtumkulu Türkmen Devlet Üniversitesi Roman- German Dilleri Kürsüsü*

# 20. YÜZYILIN İLK ONYILLARINDA ARAP ALFABESİYLE NEŞROLUNAN TÜRKMENCE KİTAPLARIN SEKIZ TANESİ ÜZERINE BİR DENEME *(Kısa Açıklamalarıyla Dış veya İç Kapağının Resimlerinde)*

**Özet.** Bildirimizde Arap alfabesiyle Türkmence olarak basılan aşağıdaki seyrek kitaplardan söz ediliyor: "A. Aliyev,Yeni Usul Türkmen Mektebi Türkmen Dili" (Bakı, 1913), "M. Geldiyev, Makal ve Matallar Yıgındısı Babalar Sözi" (Aşkabat, 1925), "A. Niyazî, İtil Boyı" (Kazan, 1905), "Divan-e Mahtumkulı" (Astrahan, 1912), "Devletmammet Azadî, Behiştname" (Buhara, 1914), "Divan-e Hezret-e Mahtumkulı" (Buhara, 1914), "Emir Alişir Nevaî, Muhakemet ul-Lugateyn" (Aşkabat, 1925) ve "Mahtumkulı, Goşguları" (Aşkabat, 1926). Kitaplar üzerine kısa bilgilerle beraber okuyucuya dış veya iç kapaklarının resimleri de sunuluyor.

**Anahtar kelimeler:** ilk Türkmence kitaplar, alfabe, atasözleri, şiirler.

**Аннотация.** Сообщение посвящено краткому описанию восьми туркменских книг, выпущенных на арабской графике в первой трети XX века. Оно также снабжено соответствующими рисунками обложек или титульных листов этих книжных продукций.

Annotation. The article is devoted to a brief description of eight Turkmen books published on Arabic graphics in the first third of the 20th century. It is also provided with appropriate pictures of the covers or title pages of these book productions.

**Ключевые слова:** первые туркменские книги, алфавит, пословицы, стихи.

**Keywords:** first Turkmen books, alphabet, proverbs, poems

Millî tarihimizde 20. asrın 30'lu yılları Türkmen devlet, edebiyat ve bilim insanları ile aynı sırada daha önce yüzyıllar boyunca Arap alfabesiyle kaleme alınan yazmalar ve son yıllarda neşolunan kitapların başına kıyamet kopan facialı bir dönem olarak tanınmaktadır. Çünkü önde gelen yazarlar, bilim adamları tarafından bu asrın 10'lu ve 20'li yıllarında Arap alfabesiyle gerçekleştirilen kitaplar ateşe verilerek yok edildi, yazarları ise "Milliyetçi", "Arapçı", "İslamcı" olarak kurşunlandı. Bundan dolayı Arap alfabesiyle daha önce yayınlanan Türkmence kitaplar günümüze kadar çok az adette ve özellikle yurt dışında korunmuştur.

Önde gelen çağdaş Türkmen kütüphaneci bilgin Prof. Dr. Almaz Yazberdiyev'in hayatı boyunca gösterdiği çabaların neticesi olarak yayınladığı monograflar ve bilimsel makaleler bu konuyu öğrenmekte kaynak eserlerdir [Bkz. 4, 5]. Aşağıda bu alanda Ord. Prof. Muratgeldi Söyegov ile ortak yazar olarak elde

ettiğimiz yeni malumatlardan söz ediliyor. Kaleme aldığımız bu deneme gelecekte yapılacak araştırmalar için sadece bir Giriş halindedir.

**Türkmencenin ilk Alfabe kitabı ve Türkmen atasözleri**

Tecen'de faliyette bulunan Rus-Türkmen okulunun öğretmeni Alişbek Aliyev (1883–1933) tarafından "Yeni Usul Türkmen Mektebi Türkmen Dili" adıyla hazırlanan Alfabe kitabı 1913 yılında Bakı'da bin adetle yayınlanıyor (Resim 1). Kitabın 1914'te Aşkabat'ta yayınlanan 2. baskısı da bin adetle çıkarılmıştır. Aliyev'in okullar için başka da 5–6 tane kitabı neşrolunmuştur. 1926'da okuyucuya sunulan Türkmen halk masallarını il içinden toplayıp bir araya getiren de Aliyev olmuştur [Bkz. 1]. Kendini bir sürü ders kitapların yazarı olarak tanıtan dilci Muhammet Geldiyev (1889–1931) 1925 yılında Aşkabat'ta Türkmen atasözlerini ve bilmeceleri "Makal ve Matallar Yıgındısı Babalar Sözi" adıya okuyucuların dıkkatine sunar. Geldiyev Türkmencenin 1929'da basılan ilk bilimsel gramerinin de yazarıdır. Bunlarla aynı sırada Türkmenceyi diğer Türk lehçelerinden ayıran uzun ünlüler konusunu gündeme getiren de Geldiyev'dir [Bkz. 2].



***Resim 1***



***Resim 2***

**Abdurahman Niyazî'nin ve Mahtumkulu'nun eserleri**

Rusya'nnın Astrahan şehrinde yaşayan, İstanbul Dar-ül-Fünun'de tahsil gören Türkmen Abdurahman Nurmuhammet oğlu Seyitniyazov (1870–1930) kendi soyadıyla ilgili olan Niyazî lakabını kullanarak 1905'te Tataristan başkendi Kazanda "İtil Boyı" (Volga Nehri Kıyısı) adlı kendi şiir kitabını (Resim 1),

1912’de ise Astrahan’da “Divan-e Mahtumkulu” adıyla büyük Türkmen klasik şairi Mahtumkuli Firakî’nin (1724–1808) 45 şiirinden oluşan kitabını yayınlamıştır. Klasik şairin kitabına bilimsel bir Önsöz ýazmış olan A. Niyazî’nin, Nogay yazar Basır Abdullin’e (1892–1937) hedye edirken üzerine kendi eliyle yazdığı yadigar yazısı bulunan bu kitabın bir adeti, Türkmenistan İlimler Akademisi’ne bağlı, Mahtumkulu adını taşıyan Dil, Edebiyat ve Millî Elyazmalar Enstitüsü’nde korunmaktadır (Resim 2). Abdurahman Niyazî’nin, Astrahan’da çıkarılan “İtil” gazetesi sayfalarında okuyucuya  sunulan cok sayıdaki makaleleri ise gelecekte öğrenilmesini bekliyor.




*Resim 3*




*Resim 4*

**Devletmammet Azadî’nin ve Mahtumkulu’nun eserleri**

İran Mazanderan doğumlu Türkmen Kurbanberdi Hocageldi oğlu Gürgenî (1867–1929) kendi hesabına 1914 yılında Buhara’da ilk “Divan-e Hezret-e Mahtumkuli” adlı 164 sayfalık şiir kitabını (Resim 4) ardından ise aynı senede Mahtumkuli’nin babası alim şair Devletmammet Azadî’nin (1705–1770) şiirle kaleme alınan “Behiştname” eserini bastırmıştır (Resim 3).  Şiirle yazılan büyük “Va’z-i Azad”  eserinden farklı olarak “Behiştname”nin yazması günümüze kadar ulaşmamıştır  ve  bundan dolayı 1914 yılı neşri bu güne kadar  eserin tek asıl kaynağı görevinde bulunmaktatır. Kurbanberdi Hocageldi oğlu Gürgenî’nin bir kitap bastırıcı olarak yaptığı başka işleri de gelecekte öğrenilmelidir.






*Resim 5* *Resim 6*

**Alişir Nevaî'nin ve Mahtumkulu'nun eserleri**

Türkçeyi yüksek bir sanat dili halinde işlemeye çalışan, bu görüşü savunan ve Türk diline değer kazandıran üstün bir bilgin ve devlet adamı Emir Alişir Nevaî'nin (1441–1501) Eski Kıyaslamalı Dilbilim tarihinde büyük önem taşıyan "Muhakemet ul-Lugateyn" eserini Sovyet döneminde ilk olarak, 20. yüzyılın başlarında ün kazanan Türkmen bilim adamı Abdülhekim Kulmuhammedov (1892–1931) kendinin kıymetli bir Önsözü'yle 1925 yılında Aşkabat'ta yayınlamıştır (Resim 5) [Bu konuda yine bkz. 3]. Bir sene sonra, yani 1926'da Aşkabat'ta, daha sonra önde gelen bir yazar olarak yetişen Berdi Kerbabayev'in (1894–1974) hazırlamasıyla "Mahtumkulu, Goşguları" adıyla klasik şairimizin şiirler kitabı basılmıştır (Resim 6). Klasik şairimizin en çok sayıdaki şiirlerinin Sovyet döneminde ilk olarak bir araya getirilen bu kitaba Türkmenistan'ın o dönemdeki Bilim Kurumu'nun Başkanı Bekgi Berdiyev (1898–1970) kisa Önsöz yazmıştır. Berdiyev 1926 yılında Bakı'da gerçekleştirilmiş olan I. Türkoloji kurultaya Türkmenistan'dan katılan delegasyona rehberlik etmiş ve bu kurultaya katılmak amacıyla Türkiye'den gelen delegeler özellikle Fuad Köprülü (1890–1966) ile görüşmüştür.






***Resim 7*** ***Resim 8***

Kısa bir sonuç olarak bunları belirtmekte önem vardır ki yukarıda sözü edilen ve XX. yüzyılın başlarında Türkmence olarak Arap alfabesiyle basılan diğer kitaplar, bir-iki adette günümize ulaşmış olduğu nedeniyle tek sayıda korunmakta olan elyazmalar gibi büyük değer taşımaktadırlar.

## EDEBIYAT

1. *Söyegov M.,* İlk Türkmen Alfabe Kitabının Yazarı Alişbek Aliyev, *UTTÜ Bülten Press,* 1999, Sayı 9. Sayfa: 9.

2. *Aynı Yazar,* İlk Türkmen Dilbilimcisi Muhammet Geldioğlu, *UTTÜ Bülten Press,* 1999, Sayı 6. Sayfa: 8.

3. *Aynı Yazar,* Sovyetler Devrinde Mazlum Bir Türkmen Aydını Abdülhekim Kulmuhammedov, *Bilig* Sayı 13. Bahar 2000. Sayı: 93-116.

4. *Yazberdiyev A.,* Abdırahman Nurmuhammet ogly Nıyazi ve onun neşiryat işi. *Edebiyat we sungat,* 2019, 8 fewral.

5. *Aynı Yazar,* Gurbanberdi Hojageldi ogly Gürgeni we onun neşir eden kitapları, *Edebiyat we sungat,* 2019, 15 fewral.

**Г.Н. МӨХӘММӘТГАЛЕЕВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА АНАЛИТИК ҺӘМ СИНТЕТИК ЧАРАЛАРНЫ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫ

**Аннотация.** Проблема приобщения к языку другого народа, глубокого изучения национальных культур и активного их пользования в системе педагогического образования

является наиболее актуальной. Использование нетрадиционных форм уроков, новейших технологий, современных методов приводит к тому, что учащиеся с интересом изучают данный язык, интеллектуально и нравственно взрослеют.

**Abstract.** The problem of familiarization with the language of another people, deep study of national cultures and their active use in the system of pedagogical education is the most urgent. The use of non-traditional forms of lessons, the latest technologies, modern methods leads to the fact that students are interested in learning this language, intellectually and morally grow up.

**Ключевые слова:** познавательная деятельность, обратная связь, творческая личность, игра, речевые умения.

**Keywords:** cognitive activity, feedback, creative personality, game, speech skills.

Туган тел ул – халыкның рухы, җаны, иң әһәмиятле билгесе. Телдә һәм тел аша халыкның милли характеры, психологиясе, фикерләү һәм иҗат үзенчәлекләре ачыла, шулай ук аның тарихы, мәдәнияте чагылыш таба. Шуңа күрә туган телне өйрәнү һәм саклау иң зарур эшләрдән санала.

Бүгенге көндә туган телебезне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен, шактый күп әһәмиятле эшләр эшләнә: татар теле Татарстанда яшәүче барлык милләт балаларына да укытыла, татар телендәге матбугат материаллары, интернет, радио-телевидение тапшырулары күпкә арттырылды, туган телдә бик күп чаралар уздырыла һ.б. Татар теленең абруе зур дияргә дә мөмкин. Әмма татар теленең бүгенге халәте, киләчәк язмышы тынычланып яшәрлек түгел.

Туган телне саклау, үстерү төшенчәсе аннан файдаланучыларның санын арттыруны гына түгел, телнең сыйфаты, ягъни дөрес кулланылышы тиешле дәрәҗәдә булуны да күздә тота. Шул ук вакытта һәр коллективтан, һәр укытучыдан рухи һәм физик сәламәт, югары эрудицияле, конкурентлыкка сәләтле, укырга теләге булган, бүгенге тормышта үз урынын таба, максатына ирешә ала торган балалар тәрбияләү өчен, төрле гамәли юллар табу сорала.

Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендә аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне өйрәткәндә кулланылырга мөмкин булган эш төрләре татар мәктәпләрендәге күнегүләр системасыннан әллә ни аерылмый. Шулай да, әлеге төркемнең татар телен азрак күләмдә укуын һәм укучыларның көндәлек тормышта күбрәк рус телендә аралашуын истә тотып, әлеге укучыларга җөмләләрнең гадирәген сайларга кирәк. Шулай ук рус теленнән тәрҗемә күнегүләре дә әлеге төркем өчен уңышлы булыр.

Заманча педагогика өлкәсендә яңа алымнар һәм методлар гаять күп. Дәреснең кайсы этабында нинди алымнар куллану, укучының белем һәм кызыксыну дәрәҗәсенә китереп кайсы методтан файдалануны билгеләү укытучыдан педагогик осталык таләп итә. Урта гомуми белем бирү

оешмаларында аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне өйрәткәндә, түбәндәге эш төрләре кулланылырга мөмкин:

**Грамматик бирем.**

1) Һәр мәкальне укып, мәгънәсе турында фикер алышыгыз. Дәфтәргә язып, иясен, хәбәрен табыгыз, җөмләләрнең схемасын сызыгыз.

*1. Кем намус белән хезмәт итә, шул зур хөрмәткә ия була.*

*2. Эш күрсәткәнне ил онытмас.*

*4. Җил кайдан иссә, болыт та шуннан килә.*

*5. Бер ялганласаң, икенче чын сүзеңә дә ышанмаслар.*

**Күчереп язу күнегүләре.**

1) Җөмләләр арасыннан аналитик иярчен җөмләләрне генә язып алыгыз.

*Тагын шунысы кызык: Наил бер сүз дә әйтми иде.* (Ә.Е)

*Ул үзе менә шунда утыра, ә күңеле әллә кайларда йөри.* (Г.Б.)

*Кояш чыкса, көн матурланыр иде.* (Ф.Я.)

*Кем тырышып укый, шул зур хөрмәткә ия.* (Г.И.)

2) Бирелгән җөмләләргә тиешле бәйләүче чараларны куеп языгыз.

*Идарәнең карары ... : бүгенге көннән башлап син ындыр бригадиры буласың.* (Г.Б.)

*Хикмәт тә ... : сүзләре пеште, серләре килеште.* (Җ.Р.)

*Көтүчесе ... , көтүе ... .* (М.)

*... берлек, ... көч.* (М.)

*Бүген көнозын кар яуды, ... вакытында очып китә алмадык.*

*Телең ... әйтсә, колагың ... ишетер.*

**Тест.**

1. Синтетик иярчен җөмләнең бәйләүче чаралары:

а) кушымчалар, фигыль формасы, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору;

ә) мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч сүзләр, күтәрү паузасы;

б) бәйлек һәм бәйлек сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр.

2. Аналитик иярчен җөмләдә нинди тыныш билгеләре куела:

а) сызык, өтер;

ә) ике нокта, өтер;

б) ике нокта, өтер, сызык.

3. Каршы кую интонациясе ярдәмендә нинди җөмләләр бәйләнә?

а) күренешләрне бер-берсенә каршы куйган җөмләләр;

ә) бер үк вакытта булган күренешләрне санап киткән җөмләләр;

б) бер-бер артлы килгән күренешләрне санап киткән җөмләләр.

**Уеннар.**

1) Укытучы әйткән фикерләр белән килешүче укучылар урыннан торып баса, килешмәүчеләр утырган килеш кала.

- *Ике яки берничә хәбәрлектән торган җөмлә кушма җөмлә була. (Әйе)*

- *Аналитик кушма җөмләдә гади җөмләләр үзара көттерү интонациясе ярдәмендә бәйләнә. (Әйе).*

- *Синтетик кушма җөмләдә бәйләүче чара булып санау интонациясе килә ала. (юк).*

- *Аналитик кушма җөмләдә гади җөмләләр арасына ике нокта куела ала. (Әйе).*

“Эшләпәдә ниләр бар?” уены. Аналитик иярчен җөмләләрне кабатлау өчен, нәфис эшләпә алырга һәм эченә җөмләләр язылган карточкалар салырга. 1 карточкада 1 җөмлә була. Укучылар карточканы ала, җөмләне укый һәм аналитик иярчен җөмләләрнең баш җөмләгә нинди чаралар ярдәмендә ялгануын аңлата. Әлеге уенны көй ярдәмендә уйнатырга мөмкин.

1 вариант. Аналитик җөмләләр:

1) *Оясында ни күрсә, очканында шул булыр.* (Мәкаль).

2) *Әнисе артык горур табигатьле кеше, шуңа күрә ул әтисеннән дә өстен.* (М. Әмир).

3) *Ул вакыт агышын югалтты, әйтерсең аның үз вакыты.* (Ф. Садриев).

2 вариант. Синтетик җөмләләр:

1) *Данилов яралану аркасында, отрядны җитәкләү Вәлитовка тапшырылган иде.* (Г. Бәширов).

*2) Ходай кушылдырганны кеше аера алмас*. (Мәкаль).

*3) Үзең тапмаган малның кадере булмас*. (Мәкаль)

**Карточкаларда эш.**“ТИК-ТЭК-ТОУ” структурасы.

“Театр” темасы буенча бер сүздән торган 9 карточка тәкъдим ителә.

Карточкалар 3 х 3 итеп таратып куела. Диагональ, өстән аска, уңнан сулга куелган 3 сүзне кертеп, иярченле кушма җөмлә төзергә кушыла.

| | | |
|---|---|---|
| *талантлы* | *спектакль* | *артист* |
| *ярату* | *рухи азык* | *танылган* |
| *тамашачы* | *моң* | *сәхнә* |

**Иҗади биремнәр.**

1. Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, Х. Сарьян, Ә. Еникиләрнең әниләр турындагы әсәрләреннән 3-әр синтетик (аналитик) иярченле кушма җөмләләр язып килегез.

2. Г. Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәреннән 5 аналитик (синтектик) җөмлә язып килегез.

3. Газета-журналлардагы мәкаләләрдән аналитик (синтектик) җөмләләр язып килегез.

**Трансформацияләү күнегүләре.**

1. Бирелгән җөмләләрнең урыннарын үзгәртеп аналитик яки синтетик җөмләләр төзү.

*Шул дәшми. Кем белми.*

*Без юлга кузгалдык. Кояш чыккач. Яңгыр туктап.*

*Ул аңлый иде. Әтисенең ачуланачагын. Икелене күргәч.*

*Чөнки кап-кара болыт килә иде. Ул тизрәк эшләрен бетерергә ашыкты. Кояш чыккан яктан.*

**Тәрҗемә күнегүләре.**

Рус теленнән татар теленә, җөмлә төрен саклап, тәрҗемә итәргә; иярчен җөмләнең төрен (аналитик, синтетик) күрсәтергә.

*Кто не работает, тот не ест* (пословица).

*Не копай другому яму, сам в нее попадешь* (пословица).

*Слово – не воробей, вылетит – не поймаешь.* (пословица).

*Кто рано встает, тому бог дает.* (пословица).

**Кроссворд.**

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1) | К | ө | т | т | е | р | ү | | п | **а** | у | з | а | с | ы | |
| 2) | | | | | | и | к | е | | **н** | о | к | т | а | | |
| 3) | | | | | | ш | у | н | д | **а** | | | | | | |
| 4) | м | ө | н | ә | с | ә | б | ә | т | **л** | е | | с | ү | з | |
| 5) | | | | | | | | | с | **и** | н | т | е | т | и | к |
| 6) | | | | | | | | | ө | **т** | е | р | | | | |
| 7) | | | | | | ч | ө | н | к | **и** | | | | | | |
| 8) | | | | | | с | ы | з | ы | **к** | | | | | | |

1) Бирелгән җөмләдә бәйләүче чараның төрен билгеләгез. “*Хәл ителде: Павел иртәгә китә* ” *(көттерү паузасы).*
2) Баш җөмләдән соң килеп, көттерү интонациясе белән бәйләнгән иярчен җөмлә алдыннан нинди тыныш билгесе куела? *(ике нокта).*

3) Тиешле бәйләүче чараны куегыз. “*Кайда берлек, ... көч*” *(шунда).*
4) Бирелгән җөмләдә бәйләүче чараның төрен билгеләгез. “*Дөнья өчен эшләсәң, шул яшәвең кадере* ” *(мөнәсәбәтле сүз).*
5) Синтетик кушма җөмләдәге иярчен җөмлә ничек атала? *(синтетик).*
6) Парлы мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә бәйләнешкә кергән баш һәм иярчен җөмлә арасына нинди тыныш билгесе куела? *(өтер).*
7) Тиешле бәйләүче чараны куегыз. “*Тукай артистларны хөрмәт итә, ... бу чорда халык театрны бик ярата* ” *(чөнки).*
8) Иярчен җөмлә алдан килеп, баш җөмлә ялгызак мөнәсәбәтле сүздән башланмаса, җөмләләр арасына нинди тыныш билгесе куела? *(сызык).*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, һәр дәрес тибы, дәреснең һәр этабы куелган максатларны тормышка ашырырлык итеп оештырылырга тиеш. Укучы һәр дәрестән, өйрәнелгән лексик һәм грамматик берәмлекләрне кулланып, программада күрсәтелгән темалар буенча аралаша алып, орфоэпик нормаларны белеп, сүзләрне дөрес әйтә белеп, диалогик һәм монологик сөйләм оештырып чыгарга тиеш.

## ӘДӘБИЯТ

Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2005. 399 б.

Мирзаһитов Р.Х., Шакурова М.М., Мусаяпова Н.Х. Татар теле. 9 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) Казан: Тат. кит. нәшр., 2017. 190 б.

Сәгъдиева Р.К. Хәзерге татар теле синтаксисы. Лекцияләрнең кыскача конспекты. Казан: КФУ, 2014. 129 б.

Татар теле. 8 нче класс. Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен укыту әсбабы / М.З. Зәкиев Н.В. Максимов. Казан: Тат. кит. нәшр., 2015.

Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен): 9 нчы сыйныф / Р.К. Сәгъдиева, Э.Х. Кадирова. Казан: Мәгариф–Вакыт, 2016.

**З.М. МУХАМЕТГАЛИЕВА**

*Казанский федеральный университет, Россия*

# О ЯЗЫКОВЫХ СРЕДСТВАХ ВЫРАЖЕНИЯ ЭМОТИВНОСТИ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

**Аннотация**. В данной статье анализируются языковые средства выражения эмотивности в татарском языке. К ним относятся лексические и грамматические (морфологические и синтаксические) способы выражения эмоций. В результате обзора фактического матриала

мы пришли к выводу, что наибольшую роль в передаче эмоций играют глаголы (35,2%), затем существительные (30,4%) и прилагательные.

**Abstract**. This article analyzes the linguistic means of expressing emotionality in the Tatar language. There are lexical and grammatical (morphological and syntactic) ways of expressing emotions. As a result of a review of the actual material, we came to the conclusion that the greatest role in the transmission of emotions is played by verbs (35.2%), then nouns (30.4%) and adjectives.

**Ключевые слова:** лексические средства, выражение эмотивности, татарский язык

**Key words:** lexical means, expression of emotion, Tatar language

В современной науке проблема эмоциональности стала рассматриваться с нового ракурса. Татарский языковед И. Б. Баширова считает слово многоаспектным явлением и на уровне функций значения лексем выделяет экспрессивную функцию, передающую чувства и переживания. На функциональном уровне лингвист также дифференцирует коммуникативные значения, отмечая, что последнее может быть присуще как минимум предложению [Бәширова, 2010: 15]. В «Татарской лексикологии» слово рассматривается как основная и самая маленькая информационная единица, реализующая ментальные образы, возникшие в нашем сознании. Слова вступают во взаимоотношения друг с другом и влияют на то, как адресат воспримет информацию. Поэтому слово занимает самое важное место в реализации основных языковых функций, таких как коммуникативная, когнитивная и эмоциональная функции. Слова являются основным средством формирования различных отношений между людьми, средством познания мира, влияния на других людей, оценки, хранилищем информации о национальной культуре и передачи информации через поколения [Татар лексикологиясе, 2015: 24].

К языковым средствам выражения эмоций относят лексические и грамматические (морфологические и синтаксические) способы выражения эмоций. В художественных текстах авторы, кроме названных, используют также стилистические способы представления эмоций и эмоциональных состояний.

В составе эмотивной лексики, относящейся к *лексическому способу выражения эмоций*, традиционно выделяются три группы. К первой группе относятся слова, в семантике которых содержится оценка фактов, явлений или признаков, характеризующих определенный объект или субъект. Так, эмоцию восторга передают слова *искиткеч, шәп (превосходно, восхитительно),* а эмоцию неодобрения можно передать с помощью таких слов, как *җирәнгеч, әшәкелек (противный, пакость)* и др. Такие слова, как правило, не употребляются в переносном значении. Ко второй группе относятся слова, которые используются в переносном смысле, получая при этом эмоциональную

окраску [Галиева, 2016]. К третьей группе относятся слова, передающие положительные или отрицательные оттенки отношения говорящего к чему-либо или к кому-либо: *әнкәй (мамочка), әбекәй (бабуля), кызым (дочурка)* (положительные эмоции); *хайван (животное), бирән (обжора), эчпошыргыч (нудный)* (отрицательные). Несомненно, лексический способ выражения эмоций доминирует над всеми другими способами. Выразить свои эмоции или воздействовать посредством выражения эмоций на слушающего говорящему легче всего именно путем отбора определенных лексических единиц. При рассмотрении лексического способа выражения эмоций при анализе эмотивной лексики в художественном произведении, необходимо учитывать контекст предложения или целого абзаца, поскольку, как уже было отмечено ранее, одно и то же слово может выражать разные эмоции. И наоборот: одна и та же эмоция может иметь разную лексическую манифестацию [Бабаева 1996: 27]. Для данной темы исследования интерес представляет, в первую очередь, лексический способ выражения эмоций. Так же в татарском языке эмоциональность выражается следующими лексическими единицами: *ләззәт* (удовольствие), *соклану* (восторг), *шатлык* (радость), *ышаныч* (уверенность), *күңелгә ошау* (симпатия), *мәхәббәт* (любовь), *ягымлылык* (нежность), *рәхәтлек* (блаженство), *кеше кайгысына сөенү* (злорадство), *үч алу* (месть), *борчылу* (тревога) *кызыксыну* (любопытство), *гаҗәпләнү* (изумление) и т.д [Галиева, 2016].

Морфологический способ относится к грамматическому способу выражения эмоций. Поскольку в предмет морфологии входит учение о частях речи, то морфологический способ передачи эмоционального состояния говорящего означает, что эмоции в татарском языке можно выразить с помощью практически всех частей речи. Наибольшую роль в передаче эмоций играют глаголы (35,2%), затем существительные (30,4%) и прилагательные (24,1%). 90% эмотивной лексики составляют эти три класса слов. *Эмотивные глаголы* отражают переживания и эмоции субъекта по отношению к объекту, эмоции, вызываемые этим объектом. Эмотивные глаголы, таким образом, связывают субъект и объект в эмоциональном плане. Эмотивная глагольная лексика способна выразить целый ряд эмоций: *фрустрационные эмоции* (*үпкәләргә (обижаться), кайгырырга (горевать), борчылырга (переживать), күңелсезләнергә (грустить)*), *коммуникативные* (*стыдить(-ся), веселить(-ся), презирать*), а также *интеллектульные эмоции* (*гаҗәпләнергә (удивиться)*). Кроме того, глаголы могут выражать внешние проявления эмоций *(кочакларга (обнимать), тибәргә (пинать), кыйнарга (бить))*. Среди существительных различают *мотивированные* (в основном производные от глагола или имени

прилагательного с суффиксами –лык -лек) и *немотивированные* (*өстәл, ак*) существительные. Большее количество *эмотивных существительных* являются мотивированными: например, *батырлык (смелость), ягымлылык, мөлаемлык (нежность), явызлык, усаллык (злость). Эмотивные прилагательные* по своим значениям подразделяются на прилагательные со значением свойства – *гаҗәпләнерлек* (*удивительный*), со значением качества – *горур (гордый),* со значением состояния – *йомык* (*замкнутый*). Кроме этого, эмотивные прилагательные могут отражать душевное состояние человека: *гашыйк* (*влюбленный), ялгыз (одинокий), унылый (моңсу)*. Если использование эмотивных прилагательных вместе с глагольной лексикой обусловливается ситуацией, то их использование вместе с именами существительными обусловливается причинами грамматическими. *Эмотивные наречия* так же, как и прилагательные, осуществляют функцию эмоционального сопровождения какого-либо действия (наречие + глагол) или характеризуют признаки предмета или субъекта (прилагательное + существительное). Например, *каты яратырга (сильно любить), моңсу карарга (печально смотреть), сагышлы күзләр (грустно-томные глаза)*. Эмоции, выражаемые с помощью эмотивных наречий, невозможно прямо соотнести с их носителем, поэтому связь с субъектом эмоций осуществляется в тексте через действия субъекта [Муллагаянова, 2010: 14]. Отдельно выделяются слова категории состояния, которые выражают в своем значении душевное, психическое, и др. эмоциональные состояния: *күңелсез* (*грустно), кызык (весело), кызганыч (жалко), күңелле (радостно), моңсу* (*печально), ямансу (тоскливо)*. Эмотивные наречия, а также слова категории состояния выражают как негативные эмоции (*начар* (*гадко), ачы (горько), авыр (тяжело),яман (худо)),*так и положительные чувства. Только около десяти процентов эмотивной лексики приходится на другие части речи, среди которых значительную роль играют *эмотивные междометия* и *частицы*.

К морфологическому (грамматическому) способу выражения эмоций относятся также использование созданных с помощью суффиксов и приставок новых слов, которые выражают различные эмоциональные оттенки [Ван, 2016:16]. Назовем только некоторые из словообразовательных суффиксов и приставок, чтобы продемонстрировать механизм создания новых слов для выражения эмоционального отношения говорящего: уменьшительно-ласкательные суффиксы -кай, -кәй, -чык, -чек (*дускай - дружок, йолдызчык – звездочка, кызчык – доченька*); образование превосходной степени сравнения с помощью приставок кып-, кап-, зәп-, ямь- и др.: *кып-кызык* (*весело–превесело), кып-кызыл (ярко-красный), ямь-яшел (зеленый-пре-зеленый).*

*Синтаксический способ* выражения эмоций связан с эмоционально-логическим соотношением и расположением слов в предложениях. С эмоциональной точки зрения синтаксические конструкции можно разделить на следующие типы: *именительные конструкции* определенного типа ("Моңлы Казан! Көчле җырларыңа Кушыла бит минем тавыш та."(Р. Харис)) *риторические вопросы* (например, "Кеше булып яшәргә Нәрсә кирәк кешегә?"(Ф. Яруллин)); *синтаксические повторы* ("Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген. Нәрсәдән бу? – Мин беләм: *бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!*"(Г. Тукай); *риторические восклицания* (например, "Ашкын, кешем! Сине җирдә Еллар көтә, юллар көтә." (Зөлфәт). Использование определенных типов сложных предложений также может выражать эмоциональное отношение или состояние говорящего. В качестве примера приведем только бессоюзный тип сложного предложения с обстоятельственным значением: *Сине югалткан көнне ук,* **мин үләрмен** *ахрысы (З. Хаким).*

Таким образом, эмотивная лексика выражается различными частями речи – это эмотивные глаголы, существительные, прилагательные, наречия и междометия. В функционально-семантическом поле выделяется 4 класса эмотивов: эмотивы со значением состояния, эмотивы со значение отношения, эмотивы со значением воздействия, эмотивы со значением характеризации, каждый из которых состоит из определенного количества микрополей.

Эмоции выражаются различными языковыми средствами: лексическими, грамматическими, морфологическими и синтаксическими способами.

## ЛИТЕРАТУРА

Бәширова И. Б. Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология. Казан: ИЯЛИ, 2010. 532 б.

Бабаева Е.В. Лексическое значение слова как способ выражения культурно-языкового концепта // Языковая личность: культурные концепты. Волгоград–Архангельск: Перемена, 1996. С. 25-33.

Ван Т. Эмотивная лексика в художественном тексте: функционально-семантический аспект (на материале повести Маши Трауб «О чём говорят младенцы»), 2016. 79с.

Галиева Н. Ф. Языковые способы выражения эмоциональности в современной татарской прозе: дисс ... канд. филол. наук, 2016. 289 с.

Муллагаянова Г.С. Экспликация эмоционального состояния говорящего в момент речевого общения: дисс ... канд. филол. наук, 2010.

Татар лексикологиясе: 3 томда / М.З.Зәкиев [һ.б.]; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1. 352 б.

**Д.М. МӨХӘММӘТҖАНОВА**
*Казан милли тикшеренү технология университеты, Россия*

# АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӘМ АЛАРНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ ГАДИ СӨЙЛӘМ СҮЗЛӘРЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** Просторечия нередки в татарской художественной литературе. В произведениях А. Гилязова можно обнаружить довольно много лексики данной группы. В статье на материале романа «Урамнар артында яшел болын» и повести «Җомга көн кич белән» и их переводах на русский язык рассматривается функционирование просторечных слов в творчестве А.Гилязова.

**Abstract**. Colloquial is not uncommon in Tatar fiction. In the works of A. Gilyazov, one can find quite a lot of vocabulary of this group. The article on the material of the novel “Uramnar Artynda Yashel Bolyn” and the novel “Zhomga kon kich belen” and their translations into Russian discusses the functioning of vernacular words in the creation of A. Gilyazov.

**Ключевые слова:** татарская литература, татарский писатель, Аяз Гилязов, просторечие, переводы.

**Keywords:** *Tatar literature, Tatar writer, Ayaz Gilyazov, vernacular, translations.*

Язучыларның әдәби әсәрләрдә гади сөйләм сүзләрен куллануы һәрвакыт кызыксыну тудыра. Тикшеренүчеләр аларның урынлы файдаланылуына, кулланылу ешлыгына, аңлашылу ягына, шулай ук авторның бу төркем лексиканы әдәби контекстка урнаштыру мөмкинлекләренә игътибар итә.

Гади сөйләм сүзләре матур әдәбиятта эмоциональ-стилистик төсмерләр, телдәге мәгънә нечкәлекләрен бирүгә ярдәм итәләр һәм җанлы сөйләм күренеше булып торалар. Алар еш кына геройларның телендә очрый. Аларның диалогларында, аралашуларында гади сөйләм сүзләре куллануы чынбарлыкны төгәлрәк тасвирларга ярдәм итә. Әдәби әсәрләрдә бирелгән персонажлар сөйләмендә мондый сүзләр элек-электән очрап тора.

Кайбер мисалларда гади сөйләм сүзләре автор сөйләмендә дә кулланыла.

Гади сөйләм сүзләренең барысы да әдәби телдә тотрыклы урын алмый. Шуңа карамастан ул халык телендә генә түгел, матур әдәбият әсәрләрендә дә киң таралган лексик берәмлекләр рәтендә карала.

Мәкаләдә Аяз Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» һәм «Җомга көн кич белән» әсәрләрендәге һәм аларның әсәрнең Э.Сафонова тарафыннан эшләнгән русчага тәрҗемәләрендәге гади сөйләм сүзләренең кулланылыш үзенчәлекләренә игътибар бирелә.

Аяз Гыйләҗевнең иҗаты тулысы белән халык тормышын, аның кичерешләрен тасвирлауга багышланган. Әдип әлеге әсәрләр тукымасына җайлап кына күп сандагы гади сөйләм элементларын, диалекталь лексиканы да кертеп җибәрә. Язма телгә сөйләү теленнән күчкән гади сөйләм сүзләре аеруча күп кулланылалар. Аларны В.Х.Хаков берничә төркемгә бүлеп карый [Хаков, 1999: 105].

Алынма сүзләрне әдәби телдән читләштереп, халыкның җанлы сөйләменә җайлаштырып әйтү гади сөйләм сүзләренең бер төрен тәшкил итә.

А.Гыйләҗевның «Урамнар артында яшел болын» һәм «Җомга көн кич белән» әсәрләрендә зур төркемне рус сүзләрен бозып куллану нәтиҗәсендә туган гади сөйләм сүзләре алып тора. Мәсәлән: закун, прәме, түлке, курмы, лутчы, парин һ.б. Аларны тәрҗемәчеләр үз вариантларында төрлечә чагылдыралар. Күп очракта рус телендә дөрес вариант килә: *Мужыт* минем сүзем бардыр аңа? *Мужыт* сиңа ярамыйдыр сүзем? (Гыйләҗев, 33). – *Может* это самая… своё слово у меня к нему! *Может* тебе доверить не могу, а? (Гыйләҗев, 36 б.); Эшне *закунлы* йөртергә яратасың икән, атла, – диде (Гыйләҗев, 138). – Шагай, шагай, раз любишь всё *по закону*! (Гилязов, 146); Рәхмәтне, *покранимир,* бүген сиңа мин әйтергә тиеш (Гыйләҗев, 147). – Сегодня спасибо, *по крайней мере,* должен говорить не ты, а я тебе (Гилязов, 155); Чабата киптерәбезме, *парин*? (Гыйләҗев, 296). – Что, *парень*, лапти сушим? (Гилязов, 309); Ә без *прастуй* кешеләр, таңнан торабыз, иртә ятабыз (Гыйләҗев, 327) – А мы люди *простые*: рано ложимся и рано встаём (Гилязов, 334).

Бу төркем гади сөйләм сүзләре фонетик яктан үзгәртелеп әйтеләләр, персонажларның индивидуаль тел үзенчәлекләрен бирү максатыннан кулланылалар. Әсәрнең рус теленә тәрҗемәсендә мондый сүзләр алдагы очракларда үзләре килгән. Бөтенләй кулланылмаган очракка да мисаллар җитәрлек: Син, Хәйдәров, күл буенда тик тора алдың, монда да *лутчы* дәшмә (Гыйләҗев, 332) – Ты, Хайдаров, мог помалкивать у озера – ну и здесь помолчи тогда! (Гилязов, 339).

Шулай ук кызыклы мисал: Әйдә инде, кем, *Питрәй* дус, ашап-эчеп утыр! (Гыйләҗев, 206) – Давай друг, *Агзам*, угощайся!.. (Гилязов, 206); Печәнле булдык бит болай булгач, курмылы иттем үзеңне! – диде Хәлил агай. *Питрәй* әйттеме, бетте! (Гыйләҗев, 208) Что, старушка, будем теперь с сенцом! – хвостливо бормотал отец. – Раз *Агзам* пообещал – точно, значит, будем! (Гилязов, 207).

Питрәй исеме рус теленә Агзам дип тәрҗемә ителгән. Чынлыкта Питрәй тәрҗемәдә Пётр булырга тиеш кебек.

Гади сөйләм сүзләре арасында кешене характерлый торган үзенчәлекле сүзләр еш очрый. А.Гыйләҗев әсәрендә персонажларга характеристика булып хезмәт итә торган тискәре мәгънәле сүзләр, тиргәү-сүгү сүзләрен еш очратырга туры килә: “Болгаткыч таяк! – дип сүгенде күңеленнән Идрис, – кеше арасын болгатырга да, чәй бутарга да ярата торган *ишәк!”* (Гыйләҗев, 85). – *“Ведьма”,* – ругался он про себя (Гилязов, 92); Кызлар: “Эш сәгате беткәнен аңламады бу *ишәк*!” – дигән кебек бер-берсенә караштылар (Гыйләҗев, 101). – Неужто ты, *осёл*, не понимаешь, что рабочее время закончилось!” – можно было прочитать в глазах у девушек (Гилязов, 110).

Мондый төркем гади сөйләм сүзләре тәрҗемәдә шулай ук төрлечә чагылыш таба. Бер ишеләренең мәгънәләре туры килсә, кайберләре башка сүзләр белән алышынган, ә кайберләре исә бөтенләй тәрҗемә ителмәгән. Мәсәлән, алдагы мисаллардагы бер үк *ишәк* сүзе рус теленә беренче очракта төшереп калдырыла, икенчесендә *осел* дип тәрҗемә ителгән.

Янәдән бер мисал: *Әтрәк әләм, салам сыйрак*! Гүр тактаңны сагындыңмы, *кәрәкә*! – дип акырды (Гыйләҗев, 137). – Тебе что тут надо, *падла*?! Сопля из рваного носа! (Гилязов, 145)

Түбәндәге мисал исә русчага тәрҗемәдә үз мәгънәсендә кулланылган: Әнкәсе аның йодрык кадәрле генә башын өстәлгә бәрә-бәрә: *“Аңгыра, сарык! Буш баш*! Буш булганга яңгырый башың!” – дип кич саен тирги иде (Гыйләҗев, 183) – И нещадно порола её мать, об стол лбом стукала. “*Скотина пустоголовая!”* – плача ругалась мать (Гилязов, 185)

Гади сөйләм сүзләрен сүз төркемнәренә аерып караганда, фигыль төркеменә караган гади сөйләм сүзләре күпчелекне тәшкил итә.

*Ашау* мәгънәсен белдергән *сыпырту, күшәү, умыру, ишү* кебек гади сөйләм сүзләре очрый. Сүзләр арасында бер-берсенә мәгънә ягыннан якынлык төрле күләмдә. Аларның семантикасы туры мәгънәдәге кулланылышыннан нык аерылалар. Алдагы мисалда *сыпырту* сүзе ашыгып һәм калдырмыйча ашау төшенчәләрен дә бирә. Шул рәвешчә, анда *ашау* сүзендәге мәгънә генә чагылмый, контекстта бу сүзнең семантик төсмерләре ачыклана. Мисаллар: *Сыпырта* гына!.. Туй сые диләр аны! (Гыйләҗев, 33) – Ещё как... эта самая... *жрал*! Это же свадебное блюдо, честное слово... (Гилязов, 36). Тәрҗемәче мисалны русчага тәрҗемәдә дә гади сөйләм сүзе белән бирә. Ә түбәндәге мисалда *суктылар* гади сөйләм сүзе тәрҗемәдә туры мәгънәдәге *иртәнге ашны ашау* ‘*завтракали’* аша бирелгән. Рус телендә дә гади сөйләм сүзе булып килсә,

ул *лопать, рубать* фигыльләре белән бирелергә тиеш [ТРС, 2002: 282]: Агач саплы табада күкәй куырдылар, ак күмәчкә май яктылар; күкәй тәбәсен нык кына *суктылар*, малайларга ияреп Идрис тә шәп кенә ашады (Гыйләҗев, 60). Втроем, топчась у плиты, на большой, с деревянной ручкой, сковороде жарили яичницу; потом *завтракали*, пили чай (Гилязов, 63).

Ә әсәрдән табылган *күшәү, ишү, умыру* сүзләре кергән мисаллар тәрҗемәдә бөтенләй бирелмәгән: "Ну *умырасың*!" – диде Әхәт, ирен читләрен пөхтәләп сөртә-сөртә (Гыйләҗев, 35); Өстәл тирәсенә тезелешеп утырдылар, куйган ризыкларны нык кына *ишкәч*, малайларның йөзләре алсулангач, Идрис учы белән яңагына таянды (Гыйләҗев, 53); Дельфинның җавабы хәтердә калмаган, – диде Идрис тәмләп *күши-күши* (Гыйләҗев, 235); Бүген тавышы-тыны юк, бакыр биш тиенлек хәтле генә коймакларны майга мана-мана *сыпырта* (Гыйләҗев, 295).

Шулай ук *эчү* мәгънәсен белдергән гади сөйләм сүзләре дә әсәрдә урын алган. Мәсәлән: *каплау, салу, авыз чылату, тондыру, кабу*: Спиртны стаканы белән *каплаган* чаклар да булды (Гыйләҗев, 260). – Стыдно сказать – стаканами *глушили* спирт (Гилязов, 249). Бу мисалларда *каплаган* һәм *глушили* гади сөйләм сүзләре. Һәм икесе дә аракыны *күп эчү* мәгънәсендә [ТРС, 2002: 110]. Ә менә түбәндәге мисалларда гади сөйләм сүзләре туры мәгънәдәге парларының тәрҗемәләре аша бирелә һәм бу очракларда автор китергән эмоциональ – стилистик мәгънә төсмерләре югала: Ашады, *салды*. Ике җамаякны *түнкәйтте*! (Гыйләҗев, 33) – Ел, *пил* (Гилязов, 36); *Салганда* да бер төсле, *салмаса* да кайчагында кызып-кызып сөйләшә (Гыйләҗев, 115) . – Ахат был похоже, порядком навеселе (Гилязов, 126); Чокыр эчендә елтыраган күзләренә нур тулды, сөенеченнән, үзе дә сизмәстән, тагын бер уймак коньякны *тондырды* (Гыйләҗев, 185); На радостях она не удержалась, *приняла* опять рюмочку (Гилязов, 187) .

Шулай ук тәрҗемәдә бөтенләй чагылыш тапмаган мисаллар да очрады: Идрис төшке аш вакытында йөз граммны *капмады*, кичен, әллә нинди маҗаралар вәгъдәләр ителсә дә, өенә кайтып китте (Гыйләҗев, 153); Башта бераз *салыйк* инде, – диде Әхәт, күзе белән официантканы эзләп, – аек баштан дөреслекне сөйләшә белмим (Гыйләҗев, 235); Сибайның дәү букчасында бер чистай малае да бар икән, чамалап кына *авыз да чылаттылар* (Гыйләҗев, 292).

*Кыйнау* мәгънәсен белдергән гади сөйләм сүзләре дә бик үзенчәлекле. Әсәрдә гади сөйләм сүзләре булган *тукмау, яру, сылау, кундыру, тондыру* кебек мисаллар урын алган. Шушы сүзләргә бәйле «Урамнар артында яшел болын» әсәрендә 19 мисал табылды. Бер үк гади сөйләм сүзләре төрле мисалда

төрлечә чагылыш таба. Мәсәлән: Зәйтүнә тирәсендә күзен шакмакландырып безелдәүче Чыпчык Ибрае Мөзәкир урынына килеп кунаклаган иде, шул көнне үк, кичке эңгердә, чана шуып кайтканда, Тугашлар тыкрыгында сагалап торып, Мөзәкир аны җир күмере ясаганчы *тукмады* (Гыйләҗев, 130). – А к Зайтуне тут же подсел сын Ибрая, прозванный в школе Воробьём. Музакир в этот же день, когда возвращались с уроков, крепко *отколошмотил* своего соперника (Гилязов, 139). Димәк, *тукмады – отколошмотил* – гади сөйләм сүзләре [ТРС, 2002: 330]. Калган очракларда да *тукмау – отлупить* параллельләре килә: Бер сәбәпсез *тукматып*, Бизрә елгаңны читләрдән пычраттырып, йомарланган йодрыкны кесә төбендә йөртү егет кеше эшемени?! (Гыйләҗев, 309) – Ни за что ни про что *отлупили* его, изгадили Бизри-реку... и теперь что толку носить сжатый кулак в кармане? (Гилязов, 320). Әлеге лексеманың башкача тәрҗемә ителгән очраклары да бар: тукмау – тумаков надавать, бить до полусмерти, едва не убить, замять. Бу очракларда А. Гыйләҗев уңышлы кулланган гади сөйләм сүзләрен тәрҗемәче дә күрсәтә алган. Бу – тәрҗемәченең уңышы.

*Яру* синонимын да тәрҗемәдә *отлупить* гади сөйләм сүзе белән бирәләр: Ул Сәхәби малаен бер *ярасы* булыр әле, такмакны шул чыгарды, тәкәрлек! (Гыйләҗев, 41) – Тут Музакир подумал, что эту злую дразнилку придумал сын Сахаби – и надобно бы его *отлупить* за это (Гилязов, 46). Икенче бер мисалда ул *бить* сүзе аша тәрҗемә ителгән: Варвара түти каеш белән *яра* (Гыйләҗев, 93) – Там бабка Варвара *бьёт* ремнём… (Гилязов, 101). Шулай ук *кундыру* сүзе дә *бить* сүзе белән бирелгән: Шофёр баш чайкады: “Ай-ай оста *кундырасың*!” (Гыйләҗев, 342) – Шофёр восхищённо помотал головой: “Ну *и бьёшь* ты, парень!” (Гилязов, 342).

*Сылау* фигыле дә тәрҗемәдә гади сөйләм сүзе белән бирелмәгән. Гади сөйләм сүзе булсын өчен *влепить, смазать* фигыльләрен куллану уңышлы булыр иде [ТРС, 2002:288]: Үзе мәче җитезлеге белән машинадан чыкты, ыргылып төркем янына барып җитте, ике аягын терәп кирәкле җай алды һәм егетләрнең иң тазасына алагаем берне *сылады* (Гыйләҗев, 341). – С ходу, что называется выбрав самого неистового из нападавших, он *ударил* в подбородок, и парень ойкнув отлетел в кусты (Гилязов, 344).

Күп очракта әсәрдә мисалларның тәрҗемәсе юк. Мәсәлән: Вася тап-таза ир, гарьләнеп сикереп торган иде, аның җилкәсенә тимер ишкәк белән *кундырдылар* (Гыйләҗев, 292) һ.б.

*Качу* мәгънәсен гади сөйләм сүзләре аша тәрҗемә иткән мисаллар шактый табылды: Кая *сызарга* җыенасың син? – диде Әхәт, бик нык аптырап (Гыйләҗев, 9). – *Рвануть* от меня хочешь? – Ахат по-прежнему зазывно, ловя

их взгляды, смотрел на девушек (Гилязов, 9); *Тай* моннан! *Аттыр*! (Гыйләҗев, 137) – *Рви* отсюда! (Гилязов, 145); Менә ул шыпан-шыпан гына чыгып *сыза*! (Гыйләҗев, 177) – Она даже обиделась: *удрал*, ничего не сказав (Гилязов, 181) һ.б. Авторның түбәндәге кызыклы мисаллары тәрҗемәдә бөтенләй бирелмәгән: Тамак астын дер-дер селкетеп, ко-ко-ко дип тавык бикәләренә арттан гына көч биреп торган явыз этәч чалгыны күргәч, шпорлы аякларын чалыш-чолыш атлап келәт астына *шылды* (Гыйләҗев, 176); Әйдәгез, әнә трамвай килә, шуңа эләгә алсак, *сызыйк*! – диде (Гыйләҗев, 51); Вася белән Идрис Займищега *элдерделәр,* юл уңаеннан “Тын Күл”гә дә кереп чыгарга булдылар (Гыйләҗев, 282); *Сыпырт* моннан! (Гыйләҗев, 342).

А. Гыйләҗевта *ычкыну* лексемасы, гади сөйләм сүзе буларак, еш кулланыла: Ике атнага *ычкына* алсаң, гаҗәп шәп булыр иде (Гыйләҗев, 6) – Ах, если бы смог ты *вырваться* на пару недель! (Гилязов, 5); Тиз генә бер хәйлә табып *ычкынасы* иде дә бит, Зәйтүнәнең анысына башы җитмәде (Гыйләҗев, 179) – Надо было поскорее, найдя причину, *сбежать* отсюда, но замешкалась она (Гилязов, 182).

Тәрҗемәдә чагылыш тапмаган мисаллар: Безгә иртәрәк *ычкынырга* кирәк, – диде Әхәт, карышып (Гыйләҗев, 36); Бир ачкычны малайларга, үзебез *ычкыныйк* (Гыйләҗев, 51); Суга ташлыйммы, үзең *ычкынасыңмы*? (Гыйләҗев, 137) һ.б.

Әсәрдә гади сөйләм сүзләренең төре булган халыкның сөйләм үзенчәлекләрен чагылдырган сүзләр, рус сүзләрен бозып әйтү күренешләре, эмоциональ–стилистик мәгънә төсмерләрен бирә торган сүзләр, сүз төркемнәренә караган гади сөйләм сүзләре кулланылган. Алар барысы да мисаллар белән дәлилләнде. Тәрҗемәгә килгәндә исә, гади сөйләм сүзе булып тәрҗемә ителгән мисаллар азчылыкны тәшкил итә. Күбесенчә гади сөйләм сүзләре рус телендә гади туры мәгънәдәге сүз белән бирелгән. Шулай ук тәрҗемәдә чагылыш тапмаган мисаллар да шактый тупланды.

## ӘДӘБИЯТ

Гилязов А.М. В пятницу вечером: Роман, повесть/ Пер. с татар. Э.Сафонова. М.: Современник, 1985. 496с.

Гыйләҗев А. Әсәрләр: Роман, повесть. Казан: Тат. кит. нәшр., 1994. 440 б.

Татарско-русский словарь: 25 000 слов/ Под ред. Ф.А. Ганиева. Казань: Тат. кн. изд-во, 2002. 488 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле: Стилистика. Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. 304 б.

**Г.И. НУРЕЕВА**
*Казанский федеральный университет, Россия*

# ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА И МЕДИА В СОВРЕМЕННОМ КУЛЬТУРНОМ ПРОСТРАНСТВЕ

**Аннотация.** Современные медиа и литература находятся в сложных взаимосвязях, глубоко не изученных с разных позиций и аспектов. Сегодня медийное давление на человека многократно усилилось. Литература также, в свою очередь, медиализируется. В сравнении с прошлыми временами медиализация литературы проявляется в том, что роль медиа (фото, пиар, Интернета, кино, СМИ) сегодня является все более значимой не только в популяризации, самопрезентации, но и в интерпретации и осмыслении литературных произведений.

**Abstract.** Modern media and literature are in complex relationships, not deeply studied from different perspectives and aspects. Today, media pressure on a person has multiplied. Literature is also in turn medialized. In comparison with past times, the medialization of literature is manifested in the fact that the role of the media (photo, PR, Internet, cinema, media) today is increasingly important not only in popularization, self-presentation, but also in the interpretation and comprehension of literary works.

**Ключевые слова:** медиа, литература, взамосвязь, медийная интерпретация, интернет, популяризация.

**Keywords:** media, literature, interconnection, media interpretation, the Internet, popularization.

Современные медиа и литература находятся в сложных взаимосвязях, глубоко не изученных с разных позиций и аспектов. На сегодня бесспорно одно изменение в их взаимосвязях – утрата литературой лидирующих позиций, доминирование СМИ, активное использование в масс-медиа литературных приемов и форм. В свою очередь происходит медиализация литературных средств и приемов, создающая иллюзию достаточной литературности СМИ, масс-медиа сегодня как бы замещают литературу. Сегодня медийное давление на человека многократно усилилось. Литература также, в свою очередь, медиализируется. В сравнении с прошлыми временами медиализация литературы проявляется в том, что роль медиа (фото, пиар, Интернета, кино, СМИ) сегодня является все более значимой не только в популяризации, самопрезентации, но и в интерпретации и осмыслении литературных произведений. Правда, медийная интепретация литературных текстов не отличается особой глубиной. Литература оказала и оказывает громадное влияние на развитие медиа. Современные СМИ сегодня развиваются в гораздо более свободном пространстве самовыражения, что позволяет им без всяких ограничений перенимать различные приемы, связанные с усилением и разнообразием повествовательности, воображения, игры. Но

в современных условиях масс-медиа должны больше «повернуться лицом» к литературе. Появление глубоких, интеллектуальных программ о культуре, литературе, искусстве в большем количестве и не только на специализированных каналах будет способствовать возрождению более тесного взаимодействия СМИ и литературы. Нужно помнить, что литература способна формировать не только эстетические вкусы, но исследовать и определять социальное поле реальности, причем, гораздо глубже и действеннее, нежели современные СМИ.

В этой статье мы рассмотрим взаимосвязь татарской литературы и медиа. Медиа, является успешным ходом для популяризации нашей литературы. Так как современная молодежь больше проводит время в интернет- пространстве, чем в библиотеках. Тем более нужную книгу можно найти в электронных библиотеках не выходя из дома. В сегодняшний день очень много интересных проектов, посвященные нашей литературе, которые тесно связывают литературу с медиа.

Второй международный фестиваль новой татарской культуры TAT CULT, в котором. принимали участие более 150 музыкантов. Миссией фестиваля являлась - показать самое интересное, что появилось за последний год в новой татарской культуре: музыка и литература, изобразительные и сценические искусства, медиа-арт, прикладное искусство, мода и гастрономия. Можно было увидеть социальный медиапроект к 100-летию ТАССР, дизайн-маркет, где представлена продукция татарских дизайнеров, театральную сцену, где проходили спектакли, например, «Салкын көн» Мензелинского театра, побывали в детской зоне, где можно узнать об интерактивной программе от «Шаян ТВ», о газете «Салават күпере», центре развития «Сабыйлар» и о Казанском Кремле.

Основу для большого мультиформатного мероприятия закладывали предыдущие локальные фестивали и маркеты – акция «Мин татарча сөйләшәм”, зимннй фестиваль городской культуры Jadid Fest и “Печән базары”, которые непременно знакомят нас с литературой татарского народа. Если в прошлом году темой проекта была творчество известного поэта Дәрдемәнд, а в этом мульфильмы на татарском языке. В литературном шатре можно было приобщиться к эпистолярному жанру. В мероприятие “Живая книга” татарскую классику читали актеры Тинчуринского театра. Альбина Абсалямова рассказала о формировании архива классика татарской итературы Абдрахмана Абсалямова, состоялась лекция о Каюме Насыри. Для молодежи прошел литературный квест “Абу Али Сина”, стихотворный баттл.

Значимую роль в популяризации литературы играют телеканалы. “Шаян ТВ” – это первый и единственный детский телеканал на татарском языке

с круглосуточным вещанием. Главная цель – привить детям культуру общения на татарском языке, познакомить с историей, литературой татарского народа. Передачи “Калеб”, “Акыл батл”, “Кичке әкиятләр”, “Тамчы-шоу”, “Тукай оныклары”, “Күчтәнәч” – кладезь полезной информации о литературе татарского народа.

Литература успешно находит свое место и в социальных сетях. В инстаграм существуют интересные аккаунты татарских поэтов, писателей, драматургов. Подписчики с радостью читают отрывки из произведенй, запоминают афоризмы великих талантов, участвуют в литературных марафонах. Излюбленные аккаунты пописчиков: @fanis jarullin, @robert minnullin poet, @intertat.tatar.

Лучший показатель развитости нашей республики – соответствующая периодическая печать. Ценным является тот факт, что пресса неоднократно знакомит нас с литературой. Журналы “Казан утлары”, “Безнең мирас”, газеты “Шәһри Казан”, “Мәдәни җомга” радуют читателей последними новостями литературы.

Несмотря на распространённый стереотип о том, что в XXI веке не осталось места для литературы, в медиапространстве книгам уделено много внимания. В веб сайтах можно найти нужное произведение за считанные секунды: Национальная электронная библиотека РТ http://kitap.tatar.ru/ru/ssearch/ecollection/; Татарская электронная библиотека - http://kitap.net.ru; Сайт "Шигърият" - http://shigriyat.ru/; Библиотека детских книг «Бала» - http://balarf.ru/ipad/index.html;

Значение медиа в популяризации и пиаре литературных произведений сегодня как никогда возросло. Появление литературного произведения, нового фильма предваряется телевизионной рекламой. Жест, музыкальное сопровождение, экранный образ, словесный звук, предваряя появление книги, во многом определяют отношение читателей к книге.

Дом татарской книги стал интеллектуальным пространством для всех, кто интересуется татарской литературой. Обновленная экспозиция музея рассказывает об истории развития книгопечатания со времен зарождения татарской письменности. Среди экспонатов – фрагменты каменных стел с письменами, рукописные книги со времен Золотой Орды, первые печатные книги и многое другое. За ними числятся много интересных проектов, к примеру, 25 августа состоялся «Дозор памяти», где вспоминали Джалиловцев.

Наглядно прослеживается связь литературы и медиа. Огромный плюс в том, что мы не забываем литературу своего народа, теперь она уже в более

легкодоступной форме, владеем всей новой информацией, в курсе последних новостей благодаря СМИ.

**З.В. САБИТОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# «ЯЛКЫН» ЖУРНАЛЫ МИСАЛЫНДА МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮДӘГЕ РОЛЕН АЧЫКЛАУ

**Аннотация**. В данной статье выявлена роль СМИ в обучении родному языку на примере журнала «Ялкын». «Ялкын» – ежемесячный татарский журнал для подростков. Журнал выпускается на литературном татарском языке, играет большую роль в совершенствовании родного языка, речевых навыков подростков.

**Abstract**. In this article, we have identified the role of the media in teaching the native language on the example of the magazine «Yalkyn». «Yalkyn» is a monthly Tatar magazine for teenagers. The magazine is published in the literary Tatar language, thanks to this it plays an important role in improving the native language, speech skills of adolescents.

**Ключевые слова:** «Ялкын», журнал, СМИ, татарский язык, литературный язык, речевые навыки, текст.

**Keywords:** «Yalkyn», magazine, media, Tatar language, literary language, speech skills, text.

Массакүләм мәгълүмат чаралары (алга таба – ММЧ) җәмгыять белән тыгыз бәйләнештә яши. Нәкъ менә ММЧ аша халыкка, ә димәк, җәмгыятькә тәэсир бара. Журналист текстлары аларны укыган кешегә җәмгыятьтә барган процессларга карата фикер булдырырга, бәя бирергә этәргеч ясый, ә кайчак хәтта шул фикер-бәяләрне укучы әзер килеш кабул итә. ММЧның тагын бер мөһим вазифасы – ул телгә карата мәхәббәт тәрбияли, аны тоярга, аңларга өйрәтә. Әлеге фәнни мәкаләнең максаты – «Ялкын» журналының туган телгә өйрәтүдәге ролен ачыклау.

«Ялкын» − урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларының айлык татар журналы. ММЧ − бүгенге дөньяда җәмгыятьнең бөтенлеген тәэмин итүче факторларның берсе. Аның балаларга ни рәвешле тәэсир итүен, нинди алымнар ярдәмендә үзаңнарын формалаштырырга ярдәм итүен ачыклау мөһим. Яшүсмерләрнең киләчәктә нинди шәхесләр булып үсүенә аларның бүген нәрсә укулары турыдан-туры йогынты ясый, чөнки әлеге вакыт − баланың формалашу, җитлегү чоры, нәкъ менә бу яшьтә яшүсмернең дөньяга үз карашлары туплана башлый, ул өйрәнә, үзе өчен яңа ачышлар ясый. Еш кына

үзе яратып укыган басма матбугат укучыда ышаныч тудыра, ул андагы фикерләрне һәм аларның бирелешен дөрес дип кабул итә, үзенә үрнәк итеп ала. Яшүсмерләрдә ышану һәм бар мәгълүматны сеңдереп бару бигрәк тә еш күзәтелә. Шуңа да аларның сыйфатлы һәм дөрес тәрбия бирә торган материал укулары аеруча мөһим.

Татар теленең үсеше яшьләрнең аны ни дәрәҗәдә белүенә бәйле. Әлеге эш турыдан-туры алар укый торган басма матбугат җилкәсенә төшә. Тел кануннарын формалаштыруда матбугат зур роль уйный. Татарда «ташка баскандай» дигән гыйбарә яши. Әлеге сүз бүгенге көн өчен дә акуталь: кеше Интернетка да, электрон газета-журналларга да түгел, ә нәкъ менә кәгазьгә басылган материалга ышана, аны дөрес дип саный. Бу чыннан да шулай: бастырып чыгарганчы, материал күп тапкыр тикшерү аша уза, хаталар минимиаль дәрәҗәдә очрый. Матбугатта тел проблемаларын, бигрәк тә анда киткән стилистик, орфографик, пунктуацион хаталарны тикшерү кирәк. Шуңа күрә вакытлы матбугатта чыккан хаталарны барлау, аларны юк дәрәҗәсенә җиткерү ММЧның төп максатларының берсе булырга тиеш.

«Ялкын» яшүсмерләр белән бер дулкында булу өчен, алар кебек «сөйләшә»: сленг, неологизмнар еш очрый. Без игътибар иткән тагын бер үзенчәлек: «Ялкын» битләрендә инглиз сүзләре еш күзәтелә. Рус сүзләре тәрҗемә ителеп тә, нәкъ менә инглиз сүзләренең шул килеш очравын күреп алырга мөмкин. Аларны баш исемнәрдә дә, язмаларның үзләрендә дә очратырга мөмкин. Әлеге алым, беренчедән, инглиз теленә өйрәтү өчен эшләнсә, икенчедән балаларны җәлеп итү өчен эшләнә, чөнки инлиз теле бүгенге көндә иң популяр тел, балалар Европага тартыла, аларның музыкасын тыңлый, китапларын укый. Мондый очраклар бигрәк тә замана технологияләренә кагылышлы язмаларда күп очрый. Мәсәлән: «Менә беркөнне бөтен редакция белән чәйләп утыра идек: элеккеге заманнардагы кебек, Old School Style таләпләренә туры китереп» («Ялкын», сентябрь, 2016).

Журнал битләрендәге неологизмнарны барлыйк. Энҗе Садыйкова, «Иң куркыныч жанр»: «минчек» – Энҗе Садыйкова үз язмасында «селфи» сүзен шулай тәрҗемә итә. «Минчек төшерергә ратучылар өчен яхшы хәбәр – бу портрет төре чит илләрдә сәнгать төренә әверелеп бара». («Ялкын», март, 2016).

Алынма сүзләр «Ялкын»да еш кулланыла. Алар арсында рус сүзләре дә, рус теле аша кергән чит ил сүзләре дә байтак. Икенчеләре аеруча күп очрый. Мисаллар: «Портретта кадровка мөһим», «Ракурс – кадрның төшерелү почмагы», «Портрет төшергәндә берничә план куллану фотографиягә кинематогра-

фик эффект өсти, чөнки тирәнлек тудыра», «Портрет жанрының танылган классиклары: Родни Смит, Арнольд Ньюман».

Күп язмаларда сүз тәртибе саклана, тик аның бозылу очракларын да күрергә мөмкин. Мәсәлән, Искәндәр Хәбибуллинның «Принц барын да күзәтә!» язмасында без шундый ике җөмләгә тап булдык: «Бер-бер артлы ретро-машиналар узып китә башламасынмы трассадан», «Кыскасы, авантюр холыклы булырга тиеш катнашучы» («Ялкын», август, 2016). Бу махсус шулай эшләнгәнме, әллә автор ялгышымы – билгесез. Тәэсирлелекне арттыру яки гади сөйләм теленә якынайту өчен сүз тәртибен бозу да булырга мөмкин. Шул ук язмада без ким җөмләләргә юлыктык: «Россия территориясе буйлап Пекин-Париж ретро-ралли ярышында катнашучы машиналар узып баралар. Перьмнән Казанга килешләре».

Журнал битләренә күз салсак, беренче карашка, журнал битләрендә хата юктыр кебек. Җөмләләр төзек, камил, орфографик һәм пунктуацион, стиль хаталары аз, тик шулай да бар. Иң беренче, пунктуацион хаталарны барлыйк. Чаткы Ялкынлы «Фотобум: безнең көн сурәтләре»: «Фотоларымны гомумән социаль челтәрләргә куймаска тырышам» («Ялкын», август, 2016). «Гомумән» – кереш сүз, ике яктан өтер белән аерылырга тиеш. Эльвира Һадиева «Синең мәчең акча эшлиме?»: «Ул – Ю каналында чыга, ди-джей булып эшли, һәркөн диярлек видео төшерә». («Ялкын», март, 2016). «Ул» сүзеннән соң куелган сызык кирәкми, ия белән хәбәр арасында сызык икенчесе исем яки алмашлык белән белдерелгән очракта кулланылырга мөмкин. Рәзилә Газизова «Чит илләрдә татарларны белмиләр?!»: «Мин нигездә индивидуаль рәвештә шөгыльләнәм». («Ялкын», март). «Нигездә» кереш сүз, җөмлә уртасында ике яктан өтер белән аерыла.

Хәреф хаталары. Чаткы Ялкынлы, «Ерактан гына булса да»: «Белеме буенча – икъдисадчы, ә күңеле белән – иҗатчы ул, әйтерсең, бу дөньяга моң таратыр өчен килгән...», «Тумышы белән Башкортостанның иң матур почмакларының берсе – салават районы Лаклы авылыннан Оксана». («Ялкын», август, 2016).

Энҗе Садыйкова «Фәтхулла хәзрәт кабат Казанда»: «Һәр аштан соң тарелканы ялаган булып, бөтен сакаллары, борыннары белән майга манчылу бик җирәнгеч тоелганлыктан, кызлар, бернәрсә дә ашый алмыйча, урыннарыннан торып киттеләр», «Болай гына буе җитмәгәч, бер скамьяга басып, картинаны әллә ничә җирдән «җәрәхәтләде». («Ялкын», гыйнвар, 2016). «Тарелка» сүзен татарча «тәлинкә», ә «скамьяны» «эскәмия» дип бирү кабул ителгән. Чулпан Мөхәмәтдинова, «Имтиханнарга әзерләнүче унберенчеләр»: «Ноябрь-декабрь

айлары олимпиадниклар өчен иң яхшы чор» («Ялкын», гыйнвар, 2016). «Олипиадниклар» сүзен «олимпиадада катнашучылар» дип язарга мөмкин. Айгөл Абдрахманова, «Галим буласың килсә, йокла!»: «Табипка күренергә ашыкмасагыз, йокысызлыкны үзлектән дәвалап карагыз». («Ялкын», сентябрь, 2016). Эльвира Һадиева, «Old School Style»: «Менә бер көнне бөтен редакция белән чәйләп утыра идек».

Татар теленә тәрҗемә итеп булып та, кайбер сүзләр куштырнак эчендә русча бирелә. Ләйсән Фәйзуллина, «Кайда яшәргә: тулай торак VS фатир»: «Риэлторларга мөрәҗәгать итәргә теләмәсәң, барсын да «вручную» эшләргә мөмкин». («Ялкын», август, 2016). Бу очракта әлеге сүз урынына «үзлектән» сүзен кулланырга мөмкин булыр иде. Йолдыз Миңнуллина, «Моң сүзен мин җырлап кеше елату дип аңлый идем»: «Эстрада кайвакыт җырларны заводтагы кебек «штамповать итү» белән шөгыльләнә». («Ялкын», август, 2016). «Штамповать итү» урынына «бертөрле итеп чыгару»ны куллану мөмкин булыр иде. Эльвира Һадиева, Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз»: «Водострой» оешмасында разнорабочий булып эшлим» («Ялкын», август). «Разнорабочий» урынына «төрле эштә эшлим» дию уңышлырак булыр иде.

Нәтиҗә ясап, «Ялкын»ның еллар буена формалашкан үз стиле бар. «Син» дип сөйләшү журналның төп үзенчәлекләренең берсе. Язма авторы укучысына да, язмасындагы әңгәмәдәшенә дә (әгәр ул яшь кеше булса, билгеле) «син» дип эндәшә. Әлеге алым журналны укучысына якынайту, «Ялкын»ның аның белән бер дулкында булып, укучысы аны дусты итеп кабул итү өчен эшләнә. Журнал әдәби, камил, яшүсмер өчен аңлаешлы һәм җиңел телдә чыгарыла. Шулай да аның битләрендә хаталар очратырга мөмкин. Иң еш очрый торган хата − сүз тәртибе бозылу. Аннан кала пунктуацион, орфографик һәм игътибарсызлык хаталарын атарга мөмкин. Журналда булган бар нәрсәне укучы дөрес дип кабул итә, шуңа да хаталарны булдырмау мөһим. «Ялкын» замана белән бергә атлый. Яңалыклардан һәрчак хәбәрдар булып, аларны үз эшчәнлегендә куллана. Аудиториясенә нәрсә кирәген белеп һәм тоеп эш итә, аңа бары тик сыйфатлы продукт тәкъдим итә. Журнал саф, чиста татар телендә чыгарылып, яшүсмерләрнең телен камилләштерүдә, әдәби сөйләм күнекмәләрен арттыруда, һәм гомумән, аларның белемле, зәвыклы шәхесләр итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

**ӘДӘБИЯТ**

Гарифуллин В.З. Журналист осталыгы: югары уку йортларының журналистика бүлеге студентлары өчен уку ярдәмлеге. Казан: 2004. 347 б.

Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 147 б.

Хаков В.Х.. Тел – тарих көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 234 б.

**И.М. СӘГЪДИЕВА, Л.Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА**

*МБОУ Гимназия № 20 имени*
*Абдуллы Алиша Советского района*
*Казань, Россия*

# ОСОБЕННОСТИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ КОМПЬЮТЕРНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ ПРИ ОБУЧЕНИИ ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ КАК НЕРОДНОМУ

**Аннотация**. Основным результатом своей деятельности считаем получение детьми прочных знаний, умений, навыков по татарскому языку и литературе, умение их применять на практике. Обучение будет успешным, если знания, умения, навыки усваиваются учащимися в строгой последовательности, постепенно в порядке вырастающей трудности и сложности с ним, чтобы школьник поднимался по ступеням.

**Annotation.** The main result of our activities we believe that children receive strong knowledge, skills in the Tatar language and literature, ability to apply them in practice. The teaching will be successful if the knowledge, skills are acquired by pupils in a strict sequence, gradually in the order of growing difficulty and complexity with it that the student climbed the stairs.

**Ключевые слова**: урок, методы, компьютерные технологии, процесс

**Keywords**: lesson, methods, computer technology, process

Мәктәптә татар теле һәм әдәбият укытучысының эш шактый катлаулы һәм җаваплы. Һәр дәрес кызыклы үтсен өчен, укытучы төрле методлар һәм алымнар куллана. Дәрес барлык таләпләргә дә җавап бирсен өчен, иң элек укытучы балалар күңеленә юл табарга, дәресне күңелле, кызыклы үткәрергә, татар теленә мәхәббәт уятырга тиеш. Шуңа күрә, һәр дәрес аермалы булырга тиеш. Бүгенге көндә татар телен өйрәтүдә компьютер техналогияләре күп кулланыла. Без дә үзебезнең практикабызда дәреснең нәтиҗәлеген күрсәтүдә заманча технологияләр – компьютер технологиясен файдаланабыз. Компьютер технологиясе – компьютер мөмкинчелекләрен файдаланып, өйрәнүчегә информацияне әзерләү һәм тапшыру процессы ул. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – укыту методикасының мөһим бурычы. Бүгенге көндә күп кенә мәктәпләрдә интрактив такта киң кулланыла. Шулай ук компьютер программасын файдаланып, төрле модель һәм таблицалар төзергә була. Интрактив такта укучыларга барлык мәгълүматны җиткерергә ярдәм итә, укучыларда татар теле дәресенә кызыксыну уята һәм дәреснең нәтиҗәлеген арттыра. Мәсәлән, татар теле дәресләрендә 6 сыйныфта “Алмашлык” темасын уткәндә компьютер технологиясен кулланырга мөмкин. Укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерүдә кулланыла торган алымнарның берсе – тестлар. Тестлар берничә төргә бүленәләр:

Тестларның төрләре:

- тәкъдим ителгән җавапларны сайлап алу;
- тест – схемалар;
- күп нокталар урынына төшереп калдырылган сүзләрне, кушымчаларны кую һ.б.

Без аларны гомумиләштерү дәресләрендә, катнаш дәресләрдә белемнәрне тикшерү өчен кулланабыз. Интерактив тактада тәгъдим иткән тестлар төрле авырлыкта була, чөнки класста барлык укучыларның да белем дәрәҗәсе бер үк түгел. Шуңа күрә, һәр укучыга дифферинциаль якын киләбез. Укучыларның эшләү темпына, зирәклегенә карап, тестлар төрле вариантта карала. Аннан соң укучылар, экранга карап, үз-үзләрен бәяли алалар. Информацион-белешмә программалар (сүзлекләр) кирәк булганда, сүзләрне интернет челтәре аша табарга була. Шулай ук дәресләрдә “Ана теле” онлайн ресурсын еш кулланабыз. Бу балаларга бик ошый һәм алар бик кызыксынып эшлиләр. Күргәзмә программалар (слайд һәм видео-фильмнар, презентаияләр) сөйләм теле үстерү дәресләрендә куллану өчен бик уңайлы. Мәсәлән, "Гаяз Исхакый иҗаты “Кәҗүл читек” хикәясенең бер өзегеннән алмашлыклар табарга" дигән бирем бирергә була.

1. **Шул** уйлар мине куркытканнан-куркыта бара.
2. **Бу** читек бөтенләй башка.
3. **Бер** иптәшемә серне сөйләдем.һ.б

Әлбәттә, укучылар мондый төр эшләрне бик яратып башкаралар. Дәрес уңышлы һәм нәтиҗәле булсын өчен барлык көчебезне куеп эшлибез. Шуңа күрә укучыларым да дәресләрдә актив катнашлар һәм теләп йөриләр. Дәрес укытучы һәм укучы бердәм – эзлекле эшләгәндә генә нәтиҗәле була.

**ӘДӘБИЯТ:**

Вәлиев Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Раннур, 2000, 330 б.

Вәлиев Ф.С. Татар теле дәресләрендә укучыларның сөйләү һәм язу телен үстерү мәсьәләләре. Казан, 1997.

Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр. – Мәгариф. – 2002. – №1. – 35-36 б.

**Р.Ф. САДРИЕВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# ХӘСӘН ТУФАН ИҖАТЫНДА МОТИВЛАР ТӨРЛЕЛЕГЕ

**Аннотация.** Татарская литература отличается богатством мотивов. Особенно в этом плане отличился великий татарский писатель Хасан Туфан. Сложный жизненный путь натолкнул писателя на разные темы и проблемы в произведениях. Так в начале своей писательской карьеры он использует такие мотивы, как вера в будущее, светлое настоящее. В плену в его произведениях наверх выходят мотивы грусти и раскаяния. В 50-е годы преобладает мотив горя.

**Abstract.** Tatar literature are rich for motives. Especially in this regard, the great Tatar writer Hasan Tufan distinguished himself. The difficult life path pushed the writer on different topics and problems in the works. So at the beginning of his writing career, he uses such motives as faith in the future, a bright present. In captivity, in his works, the motives of sadness and remorse come to the top. In the 50s, the motif of grief prevails.

**Ключевые слова:** мотив, Хасан Туфан

**Keywords:** motive, Hasan Tufan

Х.Туфан – татар поэзиясен лирик-фәлсәфи шигырьләр, югары сәнгати дәрәҗәдәге шигъри үрнәкләр белән баеткан шагыйрьләребезнең берсе. Укучыларны тирән фикер йөртергә өйрәтү, икенчел эчтәлекнең мәгънәсенә төшенергә өйрәтү, анализ үзенчәлекләренә төшендерү юлында Х.Туфан иҗаты иң үзенчәлекле шигъри мирасның берсен тәшкил итә.

Шагыйрь иҗаты мотивларның төрлелеге белән үзенчәлекле. Әлеге темага керешкәнче, мотивка фәнни яктан нәзари төшенчә биреп китү зарур. Мотив (фр. *motif*, лат. *moveo* – хәрәкәткә китерәм) – тексттагы мөстәкыйль һәм тотрыклы эчтәлек-форма компоненты. Ул бер әсәр чикләрендә дә, язучы иҗатында да аерып чыгарылырга мөмкин [Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге, 2007: 123]. Мотив (французча: көй) – хикәяләүнең иң кечкенә мәгънәви компоненты, кисәге [Әдәбият белеме сүзлеге, 1990: 107.]. Ул бер әсәр чикләрендә дә, язучы иҗатында да аерып чыгарылырга мөмкин. Бер мотивны үстерү, тулылындыру яки берничә мотивның кушып, комбинацияләр төзү юлы белән сюжет корыла. Мотив сюжетның схемасы, формуласы дип тә әйтергә мөмкин, ләкин аерым гына алганда ул әсәрнең тулы эчтәлеген, фикерен белдерә алмый. Детальләр белән тулыландырылган, конкретлаштырылган һәм, иң әһәмиятлесе, үзара бәйләнешләргә, мөнәсәбәтләргә кертелгән мотивлар гына сюжет хәрәкәтен тудыра.

Хәсән Туфан иҗаты исә мотивларның байлыгы белән аерылып тора. Шагыйрьнең иҗаты өч чорга бүлеп өйрәнелә. Һәр чорга үзгә мотивлар хас.

20нче еллар татар әдәбияты үзенең форма алмашынуы белән генә түгел, әэчтәлек һәм тема борылышы белән дә үзенчәлекле. Үзәктә – совет герое, сыйнфый көрәш, илебез хакына, киләчәк хакына якты көрәш күтәрелеп чыга. Шәхси тормыш, кешенең күңел кичерешләре икенче планга күчә. Х. Туфанның беренче чор иҗаты да әлеге сыйфатлар юнәлешендә язылган. Яшь шагыйрь киләчәккә ышанып, көрәш рухында иҗат итә. Димәк, язучының әлеге чорына көрәш, киләчәккә өмет мотивы ачык күренеп тора. Шагыйрьнең шушы мотив белән сугарылган шигырьләреннән түбәндәгеләрне санап китәргә мөмкин: "Зәңгәр бүре", "Еллар итәгендә", "Барабыз", "Аккордлар", "Урал эскизлары", "Башлана башлады" һ.б.

30 нчы елларда күп кенә язучылар иҗатында тематик үзгәреш сизелә. Әйтерсең, алар чынбарлыкның асылына төшенә. Туфан иҗаты исә әлеге юнәлештә беренче адым ясый. Ул совет җәмгыятен тәнкыйтьләп яза башлый, болай яшәү дөрес түгел икәнлегенә инандырырга тырыша. Шулай итеп, шагыйрь иҗатында яңа мотив калкып чыга: җәмгыятьтәге яшәеш кануннарын тәнкыйтьләү. Шушы нигездә иҗат ителгән иң күренекле әсәре – "Ант" поэмасы. Әлеге әсәрнең үзенчәлеге эзоп теле белән идеологияне тәнкыйтьләү, тәнкыйть утына тоту була. Шагыйрь шул дәвердә яшәп килгән идеологияне бәяли, ялган кыйммәтләр булуын дәлилләргә тырыша.

40-50 нче еллар әдәбиятта сугыш һәм сугыштан соң әдәбият буларак билгеләнсә, Х.Туфан иҗатында әлеге дәвер тоткынлык чоры буларак билгеләнә. 16 ел гомерен тоткын булып үткәргән шагыйрь лирикасында, әлбәттә, сагыш, кайгы, хәсрәт мотивлары алга чыга. Әлеге хисләр якын кешеләрдән һәм туган җирдән аерылу белән бәйле була. Шушы нигездә шагыйрь иҗатында мотивлар да шул юнәлешкә борыла: сагыш һәм үкенеч мотивы.

Әдипнең тоткынлык чор иҗаты аерым бер игътибарга лаек. Нәкъ менә әлеге чорда ул шигъриятнең югары мәйданына күтәрелеп, югары сәнгати эшләнештәге шигырьләр иҗат итә. Төп үзенчәлеге, әлбәттә, эзоп теле була. Әдәбияттагы читләтеп әйтү алымнары, бигрәк тә татар әдәбиятындагы «икенче эчтәлек тудыру» үзенчәлекле урын алып тора. Татар әдәби барышында үсеп-үзгәреп, әлеге күренеш «эзоп теле» әдәби алымына әверелә." [Заһидуллина Д.Ф, 2015: 3нче чыгарылыш.] Яшерен тел белән язучы күңелен бушата, нәфрәтен белдерә, ачы ялганны чишәргә тырыша. Әлеге чорда иҗат ителгән иң күренекле шигырьләреннән "Агыла да болыт агыла", "Илдә ниләр бар икән?", "Гөлләр инде яфрак яралар", "Каеннар сары иде", "Чәчәк сибелә җилдә", "Авырган минутларда" кебек шигырьләрне санап үтәргә була. Аларда нахакка гаепләнеп

кайгы эчендә гомер кичерүче лирик геройның тирән хәсрәт хисләре чагылыш таба. Шулай итеп хәсрәт мотивы калку чыга. Әлеге мотив шагыйрьнең “Кайсыгызның кулы җылы?” шигырендә үсеш ала. Хатының үлеме әдипне өметсез билгесезлектә калдыра. Хис-кичрешнең иң югары ноктасы шушы шигырендә җитә: “Вулканнарга керер идем..” Сөйгән ярын югалту нәтибәсен язучының тирән сагышлы, кайгылы шигырьләре пәйда була: “Сиңа”, “Тамчылар ни диләр” һ.б.

Тоткынлыктан азат ителгәч тә шагыйрь иҗатында сөйгәне белән бәйле сагыш мотивы дәвам итә. Шагыйрь үзенә юаныч, алга таба яшәргә өмет эзли, үткәннәрне бәяли. Алтмышынчы еллар шагыйрь иҗатын башка мотивлар белән баета. Х.Туфан милләт рухы белән яши башлый, әдәбиятыбызны тирән өйрәнә, туган телебезнең киләчәге турында борчылып иҗат итә. “Чәчәкләр китерегез Тукайга”, “Язгы авазлар”, “Халык төсе” кебек шигырьләреннән күренгәнчә, әдип иҗатында әдәби иҗат мотивы барлыкка килә.

### ӘДӘБИЯТ

Әдәбият белеме : Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбиятына хас милли үзенчәлекләр: икенче эчтәлек тудыру. Казан: Татарика, 3нче чыгарылыш, 2015.

Сабиров Р.Р. Шигырьләрдә – минем йөрәгем...‖ Хәсән Туфан поэзиясендә автор образы / Р.Р.Сабиров. Казан: РИЦ Школа, 2006. 190 б

Хәсән Туфан: сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр. 1964. 310 б

XX гасыр татар әдәбияты тарихы: 2 томда. Т.1 / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. 224 б.

**Л.И. САДРОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ҺӘМ РУС ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ ИР-АТ МАТУРЛЫГЫН ТАСВИРЛЫЙ ТОРГАН ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

**Аннотация.** В этой статье говорится о лексических единицах, описывающие красоту мужчины. Сравниваются татарские народные и русские народные пословицы.

**Abstract.** The article is devoted to lexical units describing men's beauty. The Tatar national and Russian national proverbs are compared.

**Ключевые слова:** татарские народные пословицы, русские народные пословицы, красота мужчины, лексическая единица.

**Keywords:** the Tatar national proverbs, Russian national proverbs, men's beauty, lexical unit.

Тарихта халыкларның үсеше, аралашу юлы белән барган кебек, телләр дә аралашу һәм бер-берсен тулыландыру юлы белән үскәннәр. Тик төрле чорларда бу төрлечә барган.

Мәкальне куллануның төп максаты - нинди дә булса бер хәбәр, мәгълүмат бирү түгел, бәлки, сөйләмне сәнгатьлерәк итү. Мәкаль текстындагы сүзләрне дә без терминнар дип түгел, бәлки әлеге шул сәнгатьләү максатын күздә тотып файдаланылган образлар дип карыйбыз.

Мәкаль-әйтемнәр яшь буынны, гомумән, халыкны, әхлакый тәрбияләүдә аеруча зур роль уйный.

Мәкальләрдән күренгәнчә, татар ир-атының тормышы ат белән тыгыз бәйләнгән. Ат татар тормышында мөһим рольне уйнаган хайван. Шуңа күрә ирне дә ат белән тиңләгәннәр. Мәсәлән, *Ир канаты - ат була; Агым судан ат кичәр, авыр көннән ир кичәр; Авыр йөктә ат тарта, авыр эштә ир тарта.*

1. Ир-ат матурлыгын ассызыклый торган мәкальләрне берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

а) ир-атның тышкы кыяфәтен тасвирлый торган мәкальләр. Татар халкы ир-атны имән, сөлек, бөркет белән тиңләгән. Гадәттә ир-атның тышкы кыяфәте эчке дөньясы белән тәңгәл килгән. Мәсәлән, *Егет булсаң, җилек бул, суда йөзгән сөлек бул!; Ирләр имән тамыры, кызлар бодай камыры.* Ә рус халык мәкальләрендә киресенчә, төс-кыяфәт белән рухи байлык капма-каршы куелган. *Молодец красив, да на душу крив; Личиком гладок, а делами гадок.*

ә) ир-атның акылын һәм зиһенен тасвирлый торган мәкальләр. Ир затының акылы турында болай диелә: *акыллы ирнең эчендә алтын иярле ат ятар; Акыллы ирнең эчендә бишекле олан ятар.*

Русларда мондый мәкаль бар: *“Молодец, что орел, а ума, что у тетерева”.*

б) ир-атның көчен, батырлыгын тасвирлый торган мәкальләр: *Батырлыкта матурлык; Батыр үз халкын яклый; Ефәк билбау бил күрке, батыр егет ил күрке;*

Татар ир-аты батыр булса, русларда батырлык төрки чыгышлы *богатырь* сүзе белән бирелә. *Щедрый не хвастается подарком, богатырь не отказывается от сказанного; Богатыря узнаешь на поле брани; Не родом богатырь славен, а подвигом;*

в) ир-атның яшь үзенчәлеген тасвирлый торган мәкальләр: *Ишәк авырганын белмәс, ир картайганын белмәс; Ир картая, күңел картаймый; күл*

*корыса сазлык булыр, ир картайса сызлавык булыр; Карт килсә, сүз бетәр, егет килсә, эш бетәр;*

г) ир-атның хезмәткә мөнәсәбәтен тасвирлый торган мәкальләр: *Ир асылы эштә беленә; Эштә булса батырлык — шунда була матурлык; Ир кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз; Егетнең асыллыгы кулыннан килгән эш белән; Кыз кылыгы белән, ир фигыле белән; Ир кулыннан, сылу буеннан билгеле.*

Рус халкында да хезмәт темасына киң урын бирелә. Ир-ат матурлыгы бу темага кагылышлы мәкальләрдә дә күренә. Мәсәлән, *сер мужичок, да сердит на работу; Мужик не живет богат, а живет горбат; Мужик умирать собирайся, а земельку паши; Думает плотник с топором; Мельник не бездельник, хотя дела нет, а топор из рук нейдет.*

д) Ир-атның туганнары һәм гаиләсенә карата булган мөнәсәбәтен тасвирлый торган мәкальләр: *Кызны бәхетле иткән кеше ир; Ир үз сүзе белән йөрсә, үзе дә ир булыр, каенана – ана, килен дә хатын булыр. Балага иң куәтле кеше — ата; Атаның кырыслыгы балдан татлы;Отцы наживают, а детки проживают; Каков батюшка, таков и сын.* Әлеге мәкальләрдән күренгәнчә, гаиләдә балаларны тәрбияләүдә ата өлге булып тора.

е) Егет кешене тасвирлый торган мәкальләр: Е*гетләрнең асылы, арысланнар нәселе; Егет байлыгы кесәдә түгел, йөрәктә була; Егет булса, арслан кебек булсын, күзләреннән җәннәт-җәһәннәм бар да күренеп торсын.*

Рус халык мәкальләрендә егетлек һәм ирлек *молодец* лексик берәмлеге аша бирелә: *знать сокола по полету, а доброго молодца по походке; Образец молодец, всяк на него взирает; Не хвались отцом, а хвались молодцом.*

Татар халык мәкальләрендә ир-атның матурлыгы тышкы кыяфәтендә дә, үз-үзен тотышында, кылган эш-гамәльләрендә. Ягъни, тышкы һәм эчке матурлык, батырлык берлектә бербөтен буларак карала. Рус халык мәкальләрендә исә, тышкы кыяфәт белән эчке дөньяның туры килмәве ассызыклана. Рус халык мәкальләрендә исә, ир-ат чибәр булса, акыл һәм көч ягы зәгыйфь булуын күрәбез.

## ӘДӘБИЯТ

Даль В.И. Пословицы русского народа. В 3 т. М.: Русская книга. Полиграфресурсы, Т.1. 1998. 638 с., Т.2. 1998. 701 с., Т.3. 1998. 734 с

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Казань: Тат. кит. нәшр., Т.I. 1959. 913 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Казань: Тат. кит. нәшр., Т.II. 1963. 959 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Казань: Тат. кит. нәшр., Т.III. 1967. 1013 б.

**А.Р. САЛАХОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# Ф.С. САФИУЛЛИНАНЫҢ ЛЕКСИКОЛОГИЯ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ХЕЗМӘТЕ

**Аннотация.** Лексикология – это раздел языкознания, изучающий лексику того или иного языка. Ф.С.Сафиуллина является одним из татарских ученых, сделавшим большой вклад в изучении этого раздела. В данной статье дается краткий обзор трудов татарского ученого в области лексикологии.

**Abstract.** Lexicology is a section of linguistics that studies the vocabulary of particular language. Safiullina is the Tatar scientist who made a great contribution to the study of this section. In this scientific work we made a brief review on the works of a tatar scientist in the field of lexicology.

**Ключевые слова:** лексикология, Ф.С.Сафиуллина, татарский язык.

**Keywords:** lexicology, Safiullina, Tatar language.

Лексикология буенча Ф.С. Сафиуллинаның беренче китабы 1979 елда басылып чыга. Бу – “Тел дигән дәрья бар ...” китабы. Татар теленең лексикологиясенә караган бүлек “Хәзерге татар әдәби теле” / (автордашы акад. М.З.Зәкиев, 1994) китабында да урын ала. “Хәзерге татар әдәби теле (Күнегүләр һәм кызыклы материаллар җыентыгы)” китабында (1992) да лексикологиянең барлык тармакларына караган бай материал тупланып бирелә.

1999 елда авторның “Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен)” дөнья күрә. Биредә лексикологиянең түбәндәге тармаклары карала:

- килеп чыгышы ягыннан хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы;
- кулланылыш сферасына карап хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы;
- кулланылыш активлыгына карап татар теленең сүзлек составы;
- хәзерге татар теле сүзлек хәзинәсенең экспрессив-стилистик катламнары;
- фразеология;
- октябрь борылышыннан соң сүзлек составындагы үзгәрешләр;
- этимология;
- ономастика;
- лексикография.

Хезмәт лексика төшенчәсенә аңлатма бирүдән башлана:

Лексика (грекча lexikos - сүз) – сүзләр җыелмасы. Лексика дип теге яки бу телнең сүзлек составын, җирле сөйләшләрдәге сүзләр җыелмасын, теге яки бу тел остасының сүзлек байлыгын, теге яки бу кешенең сүзләр җыелмасын, әдәби әсәрнең сүзлек составын атыйлар [Сафиуллина, 1999: 3].

Татар теле лексикологиясе буенча басылган хезмәтләрдә, башлыча дәреслекләрдә, лексик мәгънә типларын аерып бирү Ф.С. Сафиуллинаның дәреслегеннән башлана. Галимә әлеге хезмәттә лексик мәгънә типларыннан чынбарлыктагы әйбер яки күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә атау һәм сигнал, туры һәм күчерелмә, конкрет һәм абстракт мәгънәләргә зур игътибар бирә, аларның төп үзенчәлекләрен бәяли. Икенче тип буларак, аңга (фикерләүгә) мөнәсәбәтле терминологик һәм гомуми, образсыз һәм образлы, эмоциональ һәм эмоциональ булмаган мәгънәләрне күрсәтә. Тел структурасындагы лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга карап, синонимик, антонимик, монолексик һәм омонимик, мотивлашкан һәм мотивлашмаган, нигез һәм ясалма мәгънәләрне аера. Лексик мәгънә типларыннан Ф.С. Сафиуллина тагын ирекле һәм бәйле, вакытлы мәгънә типларына да туктала.

Ф.С. Сафиуллинаның 1999 елда дөнья күргән һәм бу төр дәреслекләр арасында шактый тулы һәм төгәл саналган “Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен)” хезмәтендә лексик мәгънәләрнең төрләре аерыла, күчерелмә мәгънәлелеккә зур игътибар бирелә. Галимә: “әгәр һәр яңа төшенчәне яңа сүз белән атый башласак, сүзләр шулкадәр күбәеп китәр иде, хәтта кеше барлык кирәкле сүзләрне хәтерендә саклап бетерә алмас иде. Шуңа күрә кеше акылы иң экономияле юлны – бер үк сүзне яңа мәгънәләрдә куллану алымын сайлаган”, – дип белдерә [Сафиуллина, 1999: 19-20].

Ф.С. Сафиуллинаның дәреслектә антонимнар буенча мәгълүматлар системага салынып, гомумиләштерелеп бирелә (*төче – ачы, салкын – җылы, ерак – якын* һ.б.). Галимә антонимнарның парлы сүзләр ясалуда нигез булып торуын искәртә (*юк-бар, азмы-күпме, кайта-килә* һ.б.), антонимнарның мәгънәләре ягыннан биш төрен аерып чыгара. Шулай ук ул сөйләмдә антонимнарның оксюморон, антитеза һәм катахреза кебек стилистик фигуралар ясауда әһәмиятен ачып бирә [Сафиуллина, 1999: 51-56].

Ф.С. Сафиуллина, фразеологик әйтелмәләргә билгеләмә биргәндә, күбрәк компонентлар арасындагы бәйләнешкә игътибар итә: “Фразеологизмнар – бердәмлеге, таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган тотрыклы сүз тезмәләре”, – дип яза [Сафиуллина, 1999: 135].

Ф.С. Сафиуллина фразеологизмнарның төп мәгънәләре буенча өч төрен аера.

Беренче төркемгә мәгънәләре атау характерында ирекле булган тезмәләр кертелә һәм *пәйгамбәр тырнагы* дигән мисал китерелә. Галимә фикеренчә, әлеге “чәчәк атамасын белдерүче фразеологизмда сүзләр чынбарлыкта логик яктан бик төрле. Бу үсемлек матур, сары, куе сары, биек булырга мөмкин; аны утыртырга, үстерергә, вазага куярга мөмкин, әмма бу үсемлек исемен белдергән сүзнең төп мәгънәсе нык үзгәргән” [Сафиуллина, 1999: 136].

Икенче төркем фразеологизмнарның башка сүзләргә бәйләнеше фразеологик бәйле була. Мәсәлән, *җан-фәрманга чабу* тезмәсендә беренче компонент *чабу* сүзе белән генә бәйләнешкә керә ала – *җан-фәрманга ашау* дип булмый. *Баш бармагым шикелле* дигән тезмәдә беренче өч сүз *беләм* сүзе белән генә кулланыла һәм аерым бер мәгънә белдерә. Бу сүзләрнең бәйләнешләре предметлы һәм логик бәйләнештән чыгып түгел, ә хәзерге телнең лексик-фразеологик системасыннан, аның тарихи үсешеннән килеп чыккан [Сафиуллина, 1999: 36].

Өченче төр фразеологизмнарның синтаксик бәйле мәгънәләре була. Ул мәгънәләр теге яки бу җөмлә кисәге (хәбәр) функциясендә генә реальләшә: *акча тора; ак сакаллы карт булыр идең; үзеңә дошман түгелсең; бәласеннән башаяк; син күр дә мин күр; акмаса да тама; акча җимеше түгел, бакча җимеше* [Сафиуллина, 1999: 36].

Омонимнарны төркемләүдә хезмәт авторының карашы түбәндәгечә:

1) лексик; 2) лексик-грамматик; 3) грамматик (омоморфемалар, омомодельләр) [Сафиуллина, 1999: 142]. Бу төркемгә фразеологик омонимнар кертелмәгән.

Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев тарафыннан төзелгән һәм 1994 елда басылып чыккан хезмәттә мондый фикерләр: “Увуляр (кече тел) к тартыгын тел арты к тартыгы белән алмаштыру да омографлар хасил итә: карта (географик) – карта (аш казаны)” бирелә [Сафиуллина, Зәкиев, 1994: 36]. Мәгълүм булганча, омонимнарның бер төре омографлар – төрлечә әйтелә, ләкин бер төрле языла торган сүзләр, шуңа күрә карта – қарта сүзләрен омографларга кертеп карарга мөмкин. Ләкин сүзләрне мәгънәви аеруда катнашкан кече тел һәм тел арты тартыклары татар телендә икесе ике фонема булуын да искә алмыйча булмас, шуңа күрә аларны охшаш яңгырашлы сүзләр дисәк дөресрәг булыр [Татар, 2015: 139]. 1999 елда басылып чыккан хезмәттә мондый фикерләр юк.

Аерым территориаль яки иҗтимагый төркем, конкрет стиль өчен генә актив сүзләр дә була. Яшенә, белем дәрәҗәсенә, һөнәренә һ.б.га бәйле рәвештә

төрле кешенең актив сүзлек байлыгы төрлечә булырга мөмкин [Татар лексикология, 2015: 309]. Мәсәлән, Ф. Сафиуллина билгеләвенчә, “аерым фән белгечләренең телендә актив кулланылыштагы сүзләр икенче бер фән белгечләре телендә, төрле катлам кешеләр телендә бөтенләй кулланылмаска һәм аларга хәтта таныш булмаска мөмкин. Физикларның бик катлаулы актив терминологиясен филологларның бөтенләй белмәве ихтимал; эмоциональ-экспрессив бизәкле сүзләр рәсми мөнәсәбәтләрдә, фәнни хезмәтләрдә бөтенләй урынсыз булырга мөмкин. Шулай да бу сүзләр хәзерге телебезнең актив сүзлеген тәшкил итә” [Сафиуллина, 1999: 100]. Башкача әйткәндә, телнең актив яки пассив фонды бу телдә сөйләшүче аерым кешенең сүзлек запасына тәңгәл түгел. Шуңа да сүзнең кайсы катламга каравын билгеләүдә төп критерий – аның бүгенге көн күзлегеннән карагандателдә кулланылу дәрәҗәсе. Аралашу инде аралашу өчен кирәге калмаган яисә әлегә киң кулланылышка кермәгән сүзләр пассив лексиканы тәшкил итә.

Китапта галимә этимология, ономастика; лексикография мәсьәләләренә дә туктала. Этимология бүлегендә этимологик принциплар (фонетик, сүзьясалыш, семантик) тикшерелә. Ф.С. Сафиуллина бик күп мисаллар китерә.

Ономастика бүлегендә төшенчә аңлатма бирә, өйрәнелү тарихы сөйләнелә, хәзерге көндә нинди эшләр башкарылуын тәфсилләп аңлата.

Шулай итеп, Ф.С. Сафиуллинаның “Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен)” (1999) хезмәте лексикологияне өйрәнү буенча бик зур хезмәт. Китаптагы ачышлар, билгеләмәләр, төркемчәләр бүгенге грамматикаларда да актив кулланылып килә.

**ӘДӘБИЯТ**


Сафиуллина Ф.С. Тел дигән дәрья бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 136 б.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Күнегүләр һәм кызыклы материаллар җыентыгы: (Педагогия училищелары һәм гимназияләр өчен). Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 319 б.

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: лексикология, фразеология, фонетика, графика һәм орфография, орфоэпия, сүз ясалышы, морфология, синтаксис: педагогия училищелары, колледжлар, гимназияләр өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1994. 320 б.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. Югары уку йортлары студентлары өчен. Ред. М.З.Зәкиев. Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

**З.Д.САЛИХОВА, Э.Н.ДЕНМУХАМЕТОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# ТАТАР СӨЙЛӘМЕНДӘ СИНОНИМНАРНЫҢ РОЛЕ

**Аннотация.** В работе рассматриваются вопросы синонимии в татарском литературном языке. Примеры из поэтических текстов и прозы сравниваются со словарными вариантами, и анализируются с точки зрения адаптации и реализации в устной речи.

**Abstract.** The article deals with the issues of synonymy in the Tatar literary language. Examples from poetic texts and prose are compared with dictionary options, and analyzed from the point of view of adaptation and implementation in oral speech.

**Ключевые слова:** синонимы, татарский язык, речь, литературный язык.

**Keywords**: synonyms, Tatar language, speech, literary language.

«Синонимнар – чын мәгънәсендә телнең байлыгын билгели торган сүзләр. Кешенең сөйләм культурасын үстерүдә аларның роле зур: туган телнең синонимнарын яхшы белгән кеше үз фикерен төгәлрәк һәм матуррак белдерә ала. Синонимнарны белмәү сөйләмне ярлыландыра, сүз куллануда ялгышларга китерә,» – дип яза Ф.С. Сафиуллина үзенең татар тел белемен өйрәнүгә багышланган хезмәтендә [Сафиуллина,Зщкиев, 2002: Б.50]. Чыннан да, элек-электән теге яки бу телне камил белү күрсәткечләренең берсе булып, мәгънәдәш сүзләрдән дөрес файдалану саналган. Шунлыктан синонимнарга күп тел белгечләре, язучылар һәм әдәби тәнкыйтьчеләр зур әһәмият биргәннәр, синонимнарның телне баету, фикерне төгәл һәм анык бирүдәге рольләрен күрсәтеп килгәннәр, сүзләрне үз мәгънәсендә, әйтәсе фикерне гади, җыйнак итеп бирерлек формада кулланырга чакырганнар.

Флера Садрый кызы Сафиуллинаның татар тел белемен өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә дә синонимнарга, аларны өйрәнүгә, теоретик һәм практик әһәмиятләрен күрсәтүгә зур урын бирелә. Галимә тел белемендәге мәгънәдәшлекне лексик берәмлекләр арасындагы синонимлык буларак та, грамматик, стилистик синонимлык рәвешендә дә өйрәнә, сүз ясалышында булган синонимлык күренешләренә мисал-дәлилләр күрсәтеп, бу өлкәдә дә мәгънәдәшлек барлыгын раслап тикшерә. Болар барысы да аның фәнни хезмәтләрендә, мәктәп укучылары һәм югары уку йорты студентлары өчен язган дәреслекләрендә чагылыш таба. Флера апа Сафиуллинаның тел белеменең бу өлкәсендә башкарган хезмәтләренең иң олысы буларак, Шифа Ханбикова белән берлектә төзелгән “Синонимнар сүзлеге”н атарга кирәк.

«Синонимнар сүзлеге» 1999 елда «Хәтер» нәшриятында басылып чыга [Синонимнар сүзлеге, 1999]. Шифа Ханбикованың моңа кадәр дә мәгънәдәш

сүзләрне өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләре, ике сүзлеге барлыгы мәгълүм. Әмма телне барлык нечкәлекләре белән камил белгән ике галимә тарафыннан төзелгәнгәме, бу сүзлек, теоретик һәм гамәли материалның синтезы рәвешендә, аеруча уңышлы хезмәт буларак дөнья күргән. Аңа 25 меңгә якын синонимик берәмлекне берләштергән 4500дән артык оя тәкъдим ителә. “Синонимнар сүзлеге” дөнья басылып чыгуга ук, киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнеп, аның хакында вакытлы матбугат битләрендә дистәләрчә мәкаләләр басыла, рецензияләр языла.

«Татар теле – синонимнарга бай тел. Бу, мөгаен, телебезнең борынгыдан ук яшәп, чарланып килүеннән, халкыбызның магъукымышлы тарихи халык булуыннан, үз теленә яратып, игътибар һәм ихтирам белән каравыннандыр. Дөрес, соңгы чорда телебезнең шактый зур байлыгы, рус һәм интернациональ сүзләр тарафыннан кысрыкланып, рус телендә генә сөйләшергә тырышкан яшь өчен бик сыегайды, газета-журналһәм дәреслек битләрендә русчадан тәрҗемә ителгән, инде шомарган, шаблонлашкан сүзләр генә урын ала, ә телебезнең иң нәфис, фикерне төгәл бирә торган сүз һәм сүз тезмәләре яшәештән төшеп кала башлаган иде. Халкыбыз, телебез тарихында булган менә шушы ялгышны төзәтү, җитешсезлекне киметү максатында синонимнар сүзлеге үзеннән өлеш кертер дигән өметтә калабыз, » – дип язылган сүзлекнең кереш мәкаләсендә. [Синонимнар сүзлеге, 1999, Б.3]. Әйе, авторлар ялгышмаганнар, алар максатларына ирешкәннәр. Басылуына ике дистәгә якын вакыт үтсә дә, аны алыштырырлык сүзлек юк әлегә. Шунлыктан “Синонимнар сүзлеге”нә ихтыяҗ зур. Гыйльми хезмәтләрләрдә, фәнни тикшеренү эшләре вакытында аңа сылтамалар еш бирелә. Бу исә сүзлекнең кирәклеген һәм файдалы булуын кабат раслый. Андагы берәмлекләрнең рус теленә тәрҗемәләре дә бирелү файдаланучыга уңайлык тудыра.

Галимнәр бер үк яки якын мәгънә белдергән сүзләр төркемен синонимик рәткә туплап өйрәнәләр. Аларның әйтүенчә, татар телендә синонимик оялар 15 меңнән дә артып китә. Бу сүзлеккә аларның барысы да теркәлмәсә дә, зур күпчелеге һәм иң активлары җыйнап бирелгән.

Күп төрле үзлекләргә ия булган мәгънәдәш сүзләрне аеруча әдип, шагыйрьләребез тел-сурәтләү чарасы буларак актив кулланалар. Бу сүзлеккә дә татар шигъриятендә зур урын алып торган шундый шәхесләр иҗатыннан шактый берәмлек тупланган. Аларны Ф.С.Сафиуллина һәрвакыт бик яратып һәм тирән ихтирам белән искә ала һәм яттан сөйли торган иде. Лекцияләренә мисалларны шигърияттән алып, телне, әдәбиятны камил белүе белән күпләрне таң калдыра иде.

Шигъри сөйләмгә, контекстка синонимнар рәте еш кына тулысы белән диярлек килеп керә. Ул я тезеп китү (амплификация), я каршы кую формасында, яисә төрле тезмәдә яки җөмләдә әле берсен, әле икенчесен файдалану рәвешендә кулланыла. Шигырьләрдә урнын алган мондый берәмлекләр авторның, шигъри аһәңлелеккә ирешү өчен, тон һәм семантик төсмерләрдән бик оста файдалануын, синонимнардан уңышлы комбинацияләр төзүен, сүзләр гармониясенә ирешүен күрсәтә. Мәсәлән, Г.Тукайның “Сөткә төшкән тышкан” шигырендә сабыр булу берәмлеге түбәндәгечә бирелә:

*И карендәш! Син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!*

***Ит сабыр**, күрсәт чыдамлык **һәм дә ит гайрәт, сөббат**!*

М.Әгъләмов исә «Сөю булып җиргә алма ява» шигырендә мәгънәдәш сүзләр тезмәсен түбәндәгечә куллана:

***Рәнҗүләргә, әрнү, үпкәләргә,***

***Кимсенүгә** хәтле*

*Тел тидереп сүз әйтүме әллә?*

Ш.Ханбикова һәм Ф.Сафиуллиналарның “Синонимнар сүзлеге”нә тупланган лексик берәмлекләр XX гасырның 90нчы елларыннан татар әдәби телендә актив лексика составында йөри торган берәмлекләрне тәшкил итә. Араларында, көндәлек сөйләмебездә сирәк кулланып, язма әдәбиятта гана очрата торганнары гына да (мәсәлән, *дәлия – георгин (б.34); җәйрәп яту – чайрап яту, чәйрәп яту, җәелеп яту, җәелеп китә (б.38); кәсләү – кәс җәю, кәс түшәү, кәс белән ябу, кәс белән каплау (б.54) һ.б.*), термин буларак кулланылышка кереп киткәннәре дә (мәсәлән, *вакыф – фонд (б. 30); дефис – сызыкча (б.35); мәдәният – культура (б.69)* һ.б.), үткән гасыр ахырында сөйләмдә кулланыла башлап, бүгенге көндә активлыгын югалтканнары да (мәсәлән, *карта – харита (б.53); карета – Берлин арбасы, көймәле арба (б.53); сәйфия – дача (б.83); шәкли – формаль* (б.114)) очрый.

Килеп чыгышы ягыннан да сүзлеккә теркәлгән берәмлекләр төрле телләргә карый. Араларында симнонимик рәтләрдәге берәмлекләрнең зур күпчелекне төрки-татар сүзләре (мәсәлән, *кую – урнаштыру, салу (б.62); нибары – бөтенләе, бар булганы (б.73); эссе – кызу, бөркү* (б. 118)) тәшкил итсә дә, алынма берәмлекләре булган рәтләр дә шактый (мәсәлән, *иганә – ярдәм, булышлык (б.42); ил – дәүләт, мәмләкәт (б. 43); номер – сан (б.74); тайфун – диңгез өермәсе ( б. 88)* һ.б. ). Шунысы игътибарга лаек: алдагы елларда чыккан синонимнар сүзлекләрендә алынмаларның күпчелеген рус-европа берәмлекләре алып торса, бу сүзлектә аларны гарәп-фарсы лексемалары алыштырган. Элек синонимик рәттә доминанта буларак рус сүзе кулланылган булса, әлеге

сүзлектә мондый берәмлекләр синонимик рәттә урын алсалар да, доминанта вазыйфасын үтәмиләр (мәсәлән, *кинжал – хәнҗәр (б. 107); авария – һәлакәт, бәрелеш, ватылу; үлем (б. 109); корылтай – съезд, конгресс (б. 59); матди – материаль, җисми, җисмани (б. 69)* һ.б.). Мондый үзгәрешләр телнең һәрвакыт үсеш-үзгәрештә булуын кабат раслый торган факт булып тора.

Татар теленең синонимик берәмлекләре арасында үзара мәгънәдәш сүзләрнең парлы сүз рәвешендә бер лексеме буларак кулланыла торганнары да бар. Алар сүзлеккә дә теркәлгәннәр. Мәсәлән *нәсел* доминантасы белән *нәсәп, нәсел-нәсәп, туган, туган-тумача, кардәш, карендәш, уру, кардәш-ыру, токым, зат, зат-кавем, кавем, ыруг-кавем, кавем-кабилә, кан, ата-баба, нәсел-нәсәбе* (б. 73) берәмлекләре; *кадер* доминантасы белән *кадер-хөрмәт, ихтирам, хөрмәт, олылау, гыйззәт* (б.49); *ару – хәлсезләнү, хәлдән таю, алҗу, ару-алҗу, ару- талу, талу, талчыгу, йончу, ялыгу, әлсерәү, йөгенү, мәлҗү, мәлҗерәү, бәлҗү, бәлҗерәх, куәтсез калу, куәттән таю* (б. 15) һ.б. берәмлекләр бирелгән.

Әлбәттә, синонимик рәттәге берәмлекләр мәгънә төсмере һәм стилистик кулланылышы белән аерылалар, әмма аларның синонимик рәттәгечә тезелеп бирелеше - поэзиядә еш очрый торган күренеш. Бу очракта автор, сүзнең эчке мәгънәсенә басым ясау, лексеманы тагын да тирәнрәк аңлату, синонимның яңа төсмерен белдерү һәм поэтик системада контекстуаль урынын билгеләү максатыннан, семантик мәгънәдәш сүзләрне күпләп куллануга өстенлек бирә. Мәсәлән Г.Тукай “Театр” шигырендә мондый юллар яза:

***Мөкаддәс** ул, **бөек** ул, **гали** зат ул,*
*Тәмам **хөр** ул, вә бик киң ул, **азат** ул.*

Мисалдан күренгәнчә, **мөкаддәс, бөек, гали** барысы бер уртак мәгънә белдерә, ә **хөр, азат** лексемалары ирекле дигәнне аңлата. Әмма алар мәгънәви һәм стилистик төсмерләре белән аерылалар. М**өкаддәс** сүзе дини семантикага ия һәм *изге* дип тәрҗемә ителә ала; **гали** киңрәк мәгънәдә *бөек, билгеле*, танылган дип аңлатыла, ә **бөек** сүзе бу синонимик рәттә доминанта ролен үти. Х**өр** лексемасында нәрсәдән, кемнән дә булса тулы бәйсезлек мәгънәсе өстенлек итә, ә **азат** сүзе ирекле семантикасы белән кулланыла.

М.Әгъләмов «Сөю булып җиргә алма ява» шигырендә исә

***Рәнҗүләргә, әрнү, үпкәләргә,***
***Кимсенү**гә хәтле*
*Тел тидереп сүз әйтүме әллә?*

*Сүз дә мәрхәмәтле,* дип синонимнарны кеше күңелендә генә була ала һәм саклана торган авыр хис – кичерешләрне тирәнрәк бирү өчен файдалана.

Эш, күренеш, процессның дәвамлылыгын, интевсивлыгын күрсәтү өчен дә, М.Әгъләмов бу алымны бик оста куллана.

*Яшәргә килгән буласың*

*Матурлык белән генә,*

*Мәгънәсез Вакыт*

...***Сындыра…***

***…Җимерә…***

***…Вата…***

***…Бөгә***... ( «Матурлык безнең белән»)

Бу синонимнар «Синонимнар сүзлеге»ндә түбәндәге тәртиптә бирелгән: *вату - туздыру; җимерү; бозу; зыян китерү; сындыру* (б.30) Әдип исә, синонимик рәтне кире тәртиптә кулланып, көчле сыйфатнамә бирүгә ирешә.

Мисаллардан күренгәнчә, синонимнар төрле максатларда кулланылалар. Нигездә, синонимнар фикерне төгәлләү, аныклау яки басым ясау, ассызыклап күрсәтү өчен тәкъдим ителәләр. Әмма ничек кенә булмасын, алар тел матурлыгын, төгәллеген тәэмин итәләр, һәм аларны өйрәнү, хәтерләү һәм белү зарур. Ә моңа ирешү өчен, Ш.Ханбикова һәм Ф. Сафиуллиналарның “Синонимнар сүзлеге” күпләрнең өстәл китабы вазифасын озак еллар үтәячәк әле.

**ӘДӘБИЯТ**:


Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан : Мәгариф, 2002.

Ханбикова Ш. С. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр. Казан: Тат. кит. нәшр., 1980.

Ханбикова Ш.Х., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999.



**К.Р. САФИНА**

*МБОУ «Гимназия №75» г. Казани, Россия*


## РЕНАТ ХАРИС ИҖАТЫНДА ТӨСЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ


**Аннотация.** В статье рассматривается проблема обозначения цветов в поэзии Р. Хариса. Своеобразное употребление цветовой гаммы в поэзии придает стихотворной форме особенные смысловые нагрузки.

**Abstract.** The article deals with the problem of marking flowers in the poetic speech of R. Haris. The flair use of colors gives the poetic form special semantic loads.



**Ключевые слова:** цвета, имена прилагательные, татарский язык, поэзия, стилистика.

**Keywords:** colors, adjectives, Tatar language, poetry, style.


Төсләр дигәч, күзалдына аллы-гөлле чәчкәле болыннар, урман буйлары, ләйсән яңгырдан соң гына чыга торган салават күперенең җиде төрле төсе һәм

шул төсләрдә ясала торган әллә нинди төс төсмерләре килеп баса. Төсләр үз төсләре белән күзләребезнең явын алырлык, үз мәгънәләре белән күңелләребезгә хуш килерлек сәләткә ия.

Төсләр тормышта кием-салым, табигатьтә чәчәкләрдә генә булмыйлар, төсләр әдәбиятта да кулланылалар, алар аша образ, геройларның эчке һәм тышкы характеры, халәтләре ачыклана. Нәкъ менә шушы күренешләрне һәм аның иҗатына гына хас сыйфатларны аңлар өчен, без Ренат Харис шигъриятенә тукталабыз һәм аның шигырьләрендә төсләр кулланылышын тикшереп карыйбыз.

Төсләр белән шигырьләр арасында нинди бәйләнеш бар икән, шагыйрь каләме төсләр белән нәрсә ясый икән, нәрсә буйый икән, әллә ул аларны яратканга гына кулланамы, әллә лирик геройның күңел түрен ачарга телиме – болар барысы да без анализлаган шигырьләрдә аңлатылып кителәчәк.

Үз заманында Ньютон, Гегель и Платоннар төсләр белән кызыксынганнар. Төрле озынлыктагы дулкыннарга ут яктысы төшкән вакыттагы күзнең күрүе, тоемлавы төсләр барлыкка китерә дип аңлата әлеге философлар. Кешеләрнең үз-үзләрен тотышы, халәте, кәефе төсләргә карап үзгәрүчән була − төсләр кеше кәефен начардан яхшыга үзгәртә алалар һәм киресенчә дә. Медицинада да төстерапиясе исемле дәвалау алымы бар.

Философиядә төсләрнең аңлатмалары яши. Мәсәлән, яшел төс – агач төсе. Яшел төс үстерә, алга этәрә, көч бирә. Кызыл төс – кан төсе. Кызыл төс тормыш агымына көч өсти, бәхет, шатлык, куаныч тели. Кешене тиз, өлгер булырга өнди. Сары төс − җир шары төсе, кояш төсе, ул безгә җылылык бирә, тынычландыра белә. Ак төс металл төсе дип санала, ул универсаль төс, башка төсләргә нигез булып тора. Ак төстә башка төсләрне яшереп булмый. Кара төс су белән бәйле дип аңлата философия, чөнки су төнлә кара төстә булып күренә. Кара төс башка барлык төсне дә җиңә ала. Кара төч серне, баш эшләүне, акыл йөртүне аңлата. Ләкин кара төстән киенү өметне кисә.

Җир үзенә барлык аксыл, саргылт, соры, ал төсләрне тарта. Ут кура җиләге, чия төсен, Металл көмеш, алтын төсләрен, Су кара, куе зәңгәр төсләрне үзенә тарта.

Кызыл-сары төсне хозурлану төсе, зәңгәр күк йөзе төсен салкынча төс, ал төсне йомшак төс, көрән төсен көчле һәм тынычландыра торган йомшак төс дип атыйлар. Куе зәңгәр төс үз-үзеңә ышану билгесе булып санала, соры төс канәгатьлек билгесе, көмеш төсе серне, көтү халәтен, алтын хакимлек мәгънәсен аңлата.

Ренат Харисның башка шагыйрьләрдән аермалы үзенчәлегенең берсе – төсләрне шигъри фикердә мул куллану. Төсләр шагыйрьгә күңелендә булган барлык хисләрне дөрес итеп ачарга ярдәм итәләр. Р.Харис, бигрәк тә ак, зәңгәр, яшел, алтын төсләрен кулланырга ярата. Бу төсләр аша кешеләргә ул тормыш ямен күрсәтергә тели. Ләкин тормыш гел уен-көлкедән тормаганлыктан, аның агымына кара төсләр дә килеп кушыла. Төсләр көрәшендә ак һәм аның дуслары һәрвакыт җиңүгә ирешә.

“Кар алды” шигырендә Ренат Харис табигатькә үз вакытында килеп җиткән көзне тасвирлый. Көзне алтын, мул итеп тә тасвирларга булыр иде, ләкин автор алай эшләми, туган ягына килгән көзне ак карларга күмми, кара төсләргә генә буйый, эле килеп кенә яткан көзнең инде тизрәк үтеп китүен тели, Җирнең аклыкка сусап аклык көтә башлавын белгертә.

“Алтын көзне Канадада күрдем...” шигыре күпмедер дәрәҗәдә “Кар алды” шигыре белән аваздаш. Туган иле, халкы өчен борчыла торган шигри җанлы шәхес, илләр язмышын төсләр аша ачып бирергә тели. Канададагы алтын көз, Россиядә алтынга түгел, ә кара төскә буялгандай тоела авторга, чөнки шигырьдә Канада иленең сәяси, социаль тотрыклылыгы, иреге, тынычлыгы Россиядәге 90 нчы елларда барган хөкүмәт алышынуы, илдә барган ызгышлар, сугышлар, Чечня вакыйгалары, халкыбызның күз яшьләренә каршы һәм чагыштырылып куела:

*Алтын көзне Канадада күрдем...*
*Россиядә кара көз иде —*
*шартлаулардан, сары яфрак кебек,*
*күпме-күпме гомер өзелде!..*

Автор тыныч тормышта җирнең хәтта җиде түгел, ә җитмеш төсен күреп алырга өлгерә, ә бездә, Россиядә кара төс хөкем сөрүе, аклыкның каралуы, күпме гомерләрнең сары яфрак кебек өзелеп төшүе йөрәкне әрнетә:

*Йа чуарлык! Җирнең җитмеш төсе!*
*Күз күрмәгән җәете купшылык!*
*Әллә ничек җаным-тәнем белән*
*купшылыкка киттем кушылып.*

Бар дөнья, кеше күңелләре гел аклыктан торса, нинди бәхетле булыр иде һәрбер җан, күз яшьләре дә, борчулар да, сугышлар да булмас иде!

Ренат Харис ак төсләрне ярата. Аклык сафлык, тынычлык билгесе икәнен белә ул. “Аклык вальсы” шигырендәге ак төс тирә-юнебездәге матурлыкны күрергә өнди, чөнки ап-ак кашкарыйлар, ак ромашкалар, ак дулкыннар, ап-ак

гөлләр тормыш матурлыгы да, күңел сафлыгы да – аларны күрү бәхете безгә бер генә тапкыр бирелгән гомер аралыгында гына, гомерләр ике килми:

*Ап-ак гөлләрдән ал гыйбрәт-ярдәм —*
*алар кояштан ала гүзәллек көче.*
*Җыр булып гөрлик, җил булып биик,*
*санап биргән гомерне матурлар өчен!*

Ренат Харис шигырьләре – чынлап та тормыш күренешләренең олы мәгънәсен ачучы әсәрләр. Бу иҗат дөньясында фикер һәрвакыт тирәнгә, фәлсәфи катламнарга кереп китә, кеше гомере, аның рухи яшәеше проблемаларына барып чыга һәм аларны шагыйрь тцслщргщ манып ала да, тагы да серле фәлсәфәгә, уйлануга, күзаллауга мәҗбүр итә. Шагыйрь иҗатының поэзия өчен төп кыйммәте дә шунда: ул бүгенге шигъри сүзнең көчен арттыруга зур өлеш кертә.

“Ак сөлге” шигырен авторның табышы дияргә була. Күргәнебезчә, әсәрдәге Ак сөлге – зур гомумиләштерүгә ия образ. Ак сөлге – татар кешесенең даими юлдашы. Ул сабан туйларында, беләкләргә куәт биреп, билгә ята, яшьләрнең туен бизи, ир-егетләрне көрәшкә озатып җилферди. Ул – халкыбыз тормышының бөтен якларыннан: кунак каршылау, илне саклап чит яуларга каршы тору, көрәш бәйрәмнәре, ниһаять, намуслы яшәп дөнья куйган кешене соңгы юлга озату кебек вакыйгалар эченнән уза. Һәр очракта катгый бер әхлакый сакчы булып йөри, яхшы белән яманны, хак белән ялганны, тугрылык белән хыянәтне бер-берсеннән килештергесез аерып торучы чик. Шигырьдәге бу үзәк образ олы нәтиҗәгә алып килә:

*Син бит үзең дә халкымның*
*Күңеле төсле –*
*Сөттән сеңгән бер пакьлекнең*
*Бер көзгесе.*

Зәңгәр күкләр, аяз күк йөзеннән дә җирдә матур нәрсә бар?! Зәңгәр төскә дә гашыйк шагыйрь, моның хаклыгын “Зәңгәр моң” исемле шигырь юлларыннан аңлап була. Үзенең зәңгәр төстәге күзләре аша микән әллә, ул дөньяны зәңгәр итеп күреп хозурлана: балачактан истә калга зәңгәр моң инде олы яшьтә дә шагыйрь күңеле түрендә, кичләрен яңгыраган гармун моңнары да зәңгәр төстә, гөлләр исе, тамчы чыңы да зәңгәр төстә, күк гөмбәзе зәңгәр кыңгырауны хәтерләтә, язлар, хәтта күзләр – барысы да зәңгәр төсләрдә, шагыйрь үзен шул зәңгәрлектә яшим дип тоя.

Зәңгәр янәшәсендә яшел, сары төсләрне күрү гаҗәп түгел, ә менә шул төсләр белән фәлсәфә йөртү бигрәк гаҗәп. “Төсләр алмашыну” шигырендә төп

образлар җәйне хәтерләткән яшел, көзне хәтерләткән сары төсләрнең көч сынашуын күзәтәбез. Яшел үз айларында гына көчле, вакыты җиткәч сары төс яшелне җиңеп хакимлек итә башлый, кичә генә әле яшел, яшел, яшел, сары, бүген инде яшел, сары, сары, сарыга әйләнгән − дөнья сары көзгә чумган.

*Яшел, яшел, яшел, яшел, сары.*
*Җәйнең кулы барлый яфракларны*
*онытмаска билге куя-куя...*
*Ләкин бик тиз яфрак санын җуя*
*һәм яңадан саный-саный барлый:*
*яшел, сары, сары, сары, сары...*

Тормышның яхшылыгы белән начарлыгы, матурлыгы белән шыксызлыгы көрәшкән кебек, Ренат Харис иҗатында да төсләр көрәшә, шагыйрь күңеле җылылык теләп, аксыл төсләрнең җиңүен өмет итә.

Төсләр дөньясы төс белгертү белән генә чикләнми икәнен Ренат Харисның шигъри буразналары аша атлагач белдек. Төсләр үзләре бер фәлсәфи дөнья икән, ләбаса. Чын тормышның үзендәге кебек төсләрнең дә үз аклыгы, үз сафлыгы, күңелләренең кара таплы мизгелләре дә була икән, шул ак белән кара көрәшенә башка төсмердәге төсләр дә кушылып уйлар, фикерләр, яшәеш агымы я матурлана, я тоныклана икән. Тормышны, яшәешне аңлау өчен шигырьләр белән дус булырга кирәк.

Ренат Харис шигырьләре һәрберсе диярлек салават күпере төсләреннән тора, төсләр аңа тормыш һәм кеше күңеленең бик нечкә, өзелергә торган җирләрен аңлатып бирергә ярдәм итәләр.

Ренат Харис төсләрдән оста файдалана, аларны урынлы куллана белә, шул нигездә укучыга ачык күзаллау барлыкка килә һәм шагыйрьнең тел төбен аңлау җиңелләшә.

Төсләр белән эш итү үзе бер могҗиза, төсләр белән шигырь язу үзе бер осталык, шул төсләргә үзеңнең саф хисләреңне ышанып тапшыру − үзе бер батырлык, шул төсләрне үзең белән соңгы чиккә кадәр алып бару – үзе бер ышаныч. Тормыш матур, кеше күңеле тыныч булырга тиеш – маңгай күзе белән түгел, җаны тыныч күңел күзе җиде төсне генә түгел, ә җитмеш төсне дә күрә алырга сәләтле.

**ӘДӘБИЯТ**

Харис Р. Хәл-әхвәл: Шигырьләр, поэмалар. Казан: Тат. кит. нәшр., 2001. 208 б.

**Н. ТИЛЕУОВА**
*Университет «Туран-Астана», Казахстан*
*«Тұран-Астана» университеті*
*«Қазақ тілі мен әдебиеті» мамандығының*
*білім алушысы, Қазақстан, Нұр-Сұлтан қ.*
*Ғылыми жетекшісі: «Тұран-Астана» университеті*
*доценті, ф.ғ.к С.О. Симбаева*

# АБАЙ МҰРАЛАРЫНДАҒЫ ФИЛОСОФИЯЛЫҚ ОЙЛАР: ЗАМАНМЕН ҮНДЕСТІГІ

**Аннотация.** В данной статье освещаются философские взгляды казахского писателя Абая.

**Annotation**. This article devoted to the religious and philosophical views of the Kazakh writer Abay.

Абай бар болғаны 176 өлең, 3 поэма, 45 қарасөз, 1 мақала жазған. Соның өзінде оның шығармашылығы – әдебиеттің, мәдениеттің ауқымынан асып, философия сияқты іргелі ғылым нысанына да йналып үлгірген ғажайып құбылыс. Ол - өзінің ақын , философ, аудармашы, композиторлығымен қоса, әр адамның жанына жақын, өмірдің кез келген сұрағына жауап алуға болатын тұлға

Кемеңгер боп жаратылған ұлы ақын – еліне пана боп, өз заманынан ойы озық ғұламалық тұлғасымен өз ұлтын өркендеген өнегелі елдің қатарында көруді көксеген ойшыл. Ұлы тұлға қазақ қоғамы, оның болмысы, келешегі туралы соншама толғана отырып; ұлтының табиғатын, жаратылысын дәл таныған; азапқа түсіп, қасірет шеккен, қазақтың кемшілігін жанға батырып бүкпесіз ашық айтқан. Өзі өмір сүрген заманның бүкіл болмысын Абайдай толғаған адам болған емес.

Оны оқыған сайын қазақтың табиғаты ашыла түседі. Заманында айтып кеткен өсиет-өнегесі сол кездің кемерінен асып, өзінен кейінгі екі ғасырға еш тосқауылсыз жетіп отыр. Жетіп қана қоймай, уақыт өткен сайын халқына жақындай түсуде

Адам бойындағы адамгершілік пен мейірімді, адалдық пен ар, ұят тәрізді ұғымдарды философиялық терең толғауларлар арқылы жеткізген. Абай идеясы өміршең, олай болмауы мүмкін емес те. Өзінің бойындағы талантын ұлтының рухани игілігіне қызмет етуге жұмылдырды. Адамзат пен дүние тарихына, мемлекеттер тарихы мәселелеріне зерттеуші ретінде қарады.

«Абай дүниеге келгеннен бергі бір жарым ғасырдан астам кезеңде қоғам неше мәрте өзгерді, саясат талай құбылды, соның бәрінде де Абай тұғырынан тапжылмай, қазағымен бірге келеді. Абай XIX ғасырда жасап, XX ғасырға төрт-ақ қадам басып, есігінен ғана қарап кеткенімен, өткен жүз жылдықтағы ұлттық мәдениетіміздің тұғыры болды. Абайдың ұлылығы осында» – деген. С. Шүкірұлы пікірін ақынның болмысына берілген әділ бағалардың бірі ретінде қарауға болады.

Ақынның көп жылдар бойындағы ойлары мен толғаныстары іргелі философияға ұласты. Ондай ойлар құрғақ уағыз, өсиет, дидактика түрінде қалып қоймай, жоғары көркемдік деңгейдегі поэзия үлгісінде беріліп, халық жанына жол тапты.

Абайдың бүкіл поэзиясы, оның жаңа лебізді, орамды өлеңінің, өмірлік қуатқа толы образдарының күші қазақ қоғамын ескірген идеялар мен сезімдер шеңберінен шығарды [1, 16] .

Қазақтың жаңа еркін ойының басында Абай тұрды. Білімсізбен алысып, елге сөзі өтпей, “Қадірлі басым, қайратты жасым, Айғаймен кетті, амал жоқ”; “Болмасқа болып қара тер, қорлықпен өткен қу өмір”, “Толды қайғы кеудеге, сырласа алмай, сөз аша алмай пендеге” - деп, өзі айтқандай, оның бүкіл өмірі қазақты ел болуға, өзге жұрттан кем қалмауға үндеумен өтті. “Жарлы емеспін, зарлымын, жұртым деуге арлымын өзге жұрттан ұялып”, “Мұндай елден бойың тарт, мен қажыдым, сен қажы”, “Ақылсыз би болмас, сәулесіз үй болмас, жүректе оты жоқ адамда ми болмас”, “Қазақтың қазақтан басқа жауы жоқ” дегенді де Абай жаны қиналған кезінде айтқан.

Жұртым-ай, шалқақтамай сөзге түсін,
Ойланшы сыртын қойып, сөздің ішін.
Ыржаңдамай тыңдасаң нең кетеді,
Шығарған сөз емес қой әңгіме үшін.

Халқын надандық шырмауынан азат етуге ниет қылған Абай адаммен де, заманмен де сырласты. Қазақтың жоғын жоқтай отырып, өз қазағын қатты сынады. Сынағанда жек көргендіктен емес, жаны ашығандықтан сынады. Өз халқын сынай отырып, сүйе білді.

Абай бір ғана қазақты емес, бүкіл адамзатты сүйді, сүюді уағыздады да, «Адамзаттың бәрін сүй бауырым деп ...», - деуі соның айқын айғағы. Көпвекторлық саясат ұстанған еліміз алыс-жақын шет мемлекеттермен дипломатиялық, сауда-саттық қарым-қатынас орнату үшін өзінің барлық күш-қуатын жұмсауда. Тек саяси талғампаз қоғам ғана өз тағдырын

кездейсоқтықтардан аман сақтап қала алады. Қазақстан қоғамы сондай талапқа шындап жауап бере алатын салиқалы қоғам екендігін танытып келеді. .

Саясаты сан қабатты осынау күрделі қоғамда сара жол салып, салиқалы саясат ұстану кімге болса да, оңайға түспесі анық. Қоғам тек экономикалық даму мен дипломатиялық қарым-қатынастан ғана тұрмайды. Бұның бәрі сыртқы форма, оның ішкі мазмұны да үлкен маңызға ие. Ішкі мазмұн көптеген факторлардан тұрады. Соның бірі – рухани тұтастық, рухани байлық. Осы тұста рухани байлықтың негізін біз тағы да Абайдан бастап, Абайдан тәлім аламыз.

Абай:

"Қалың елім, қазағым, қайран жұртым,

Ұстарасыз аузыңа түсті мұртың,

Жақсы менен жаманды айырмадың,

Бірі – май, бірі – қан боп енді екі ұртың" - деп, қазағы үшін қам жеді. "Күллі адам баласын қор қылатын үш нәрсе бар. Сонан қашпақ керек: әуелі – надандық, екіншісі – еріншектік, үшіншісі – залымдық" деп үйретті. Ақын ойы қазақша айтылғаны болмаса, әр тілде сөйлейтін бүкіл адамзат баласының замана өзгерген сайын құбылып отырған қалпын дөп басып айтып отырғандай. «Жақсы менен жаманды айырмадың» дегенін «Жақсы менен жаманды айырмайсың», - десек, қазіргі заман бейнесіне де үйлесіп шыға келмек.

Абай –ұлттық, халықтық ақын шеңберіне сыймайды, ол адамзат ақыны деген ұғымға толық жауап бере алады. Ол өз заманындағы қоғамдық қалыпты айна-қатесіз таныды. Ол қоғам сырқатын дөп басып, айығудың да амалын дәл тапты. Абайдың көптеген өлеңдерінде: "Қартайдық, қайғы ойладық", "Қалың елім, қазағым, қайран жұртым", "Күлембайға", т.б. надандық, даукестік, парақорлық, арамтамақтық, билеп-төстеушілердің рухани жүдеулігі жеріне жете сыналады.

Поэзияда, музыкада, даналықта, қоғамдық-азаттық ой-пікір саласында өлмес-өшпес шығармалар берген Абай қазақ халқының өткен замандағы өмірінің мағлұматнамасы іспетті болса, жаңа заманға жол көрсетіп тұрған темірқазық іспеттес. Ол заман ағымын сезіне білді. Ілгеріні болжады. Соған ыңғайлап қазақ халқын тәрбиеледі. Сөйтіп, ұлтының ұстазына айналды. Абайдың дана сөздері қазаққа ғана емес, бүкіл адамзатқа қызмет ететіні сөзсіз.

Абай туған топырағынан ұзап шықпай–ақ, жер-дүниені көріп-біліп отырды. Оның ойлары әлемдік ұғыммен, арғы-бергі замандардағы адамзат данышпандарының пікірімен сабақтастық тауып жатыр.

Шығыс жұлдыздарын жоғары бағалаған ақынның өзі де сол жұлдыздар ішіндегі ең жарығына айналып, әлемге нұрын төкті. Оның толғаныстары, ой-пікірлері әлем ойшылдарымен үндесіп жатады.

Кеше бала ең, келдің ғой талай жасқа,
Көз жетті бір қалыпты тұра алмасқа.
Адамды сүй, Алланың хикметін сез,
Не қызық бар өмірде одан басқа.

Адамзат – бүгін адам, ертең топырақ,
Бүгінгі өмір жарқылдар, алдар бірақ.
Ертең өзің қайдасың, білемісің,
Өлмек үшін туғансың, ойла, шырақ.

Туысқаның, достарың – бәрі екіұшты,
Сол себепті досыңнан дұшпан күшті.
Сүйсе жалған, сүймесе аянбаған,
Бұл не деген заманға ісім түсті, – деп мұңаяды Абай.

«Абайдың жұмбағы» атты романында Р. Тоқтаров: «Қазақ даласы ұзақ толғатты. … маңдайына ерекше тағдыр жазарында осылай толғатары хақ. Сондай ұзақ қиналыстан кейін Абайды тарту етті», - деп жазғаны бар еді [2, 14]. Бұл, әрине, көркем ойлау, көркем толғаныс жемісі, дегенмен, жазушы сол кездегі қазақ тағдырын айна-қатесіз беріп, Абайды пешенесіне жазылған таралғы-тарту ретінде көрсетіп еді. Ақиқаты да осы деуден басқа қосарымыз жоқ. Бұл жерде бір ғана қосатын ойымыз бар, ол – тағдыр қазаққа ғана емес, бүкіл адамзатқа ұлы тұлға сыйлағаны. Осындай ұлы тұлғаның болмысын А. Байтұрсыновша толғайтын болсақ: «сөзі аз, мағынасы көп, терең.... Не нәрсе жайынан жазса да, Абай түбірін, тамырын, ішкі сырын, қасиетін қармап жазды. Нәрсенің сырын, қасиетін біліп жазған соң, сөзінің бәрі де халыққа тіреліп, оқушылардың біліміне сын болып табылады» [3, 25.].

Абай сөз етпеген өмір саласы қалмаған. Қазақтың табиғаты, болмысына қаламын кең сермей отырып, сол арқылы бүкіл адамзат бітімін, қоғам ізгілігін сөз еткен. Ұлағатты сөздерін бойға, санаға сіңіру, ұлы ақынның бай мұрасынан ғибрат алу бұрынғыдан да бүгін маңыздырақ.

Материалдық байлықты мақсат етіп, рухани қазынаны місе тұтпайтындар саны көбейіп бара жатқан мына заманда ақын айтқан әрбір ғибраттың берер тағлымы мол. Ақынның өзі айтып кеткендей:

Базарға, қарап тұрсам, әркім барар
Іздегені не болса, сол табылар.
Біреу астық алады, біреу маржан,

Әркімге бірдей нәрсе бермес базар.

Әркімнің өзі іздеген нәрсесі бар,
Сомалап ақшасына сонан алар.
Біреу ұқпас бұл сөзді, біреу ұғар,
Бағасын пайым қылмай аң-таң қалар [4, 6]

. Абай осы сөзін өмірден еншісін алам деп келген адамзат баласының бәріне айтып отырғандай. Базарды өмірге теңесек, одан өзіне тиесілісін, шамасы жеткені мен мақсат тұтқанын алғысы келетіндер де ала-құла екені рас. Ол қашанда адамзатты тазаруға, адамдық атын жоймауға, бауырмалдыққа, әділеттілікке.шақырады:

Қулық, сұмдық, ұрлықпен мал жиылмас,
Сұм нәпсің үйір болса, тез тиылмас.
Зиян шекпей қалмайсың ондай істен,
Мал кетер, мазаң кетер, ар бұйырмас [4, 13]

Заман, қоғам жайында, адам жайында толғанған ойлары өзіне дейінгі ғұламалармен үндесе келіп, күні бүгін де өзектілігін жойған жоқ.

Махаббатпен жаратқан адамзатты,
Сен де сүй, ол Алланы жаннан тәтті.
Адамзаттың бәрін сүй, бауырым деп,
Және сүй, хақ жолы деп әділетті [4, 13].

Мазасы кеткен, М. Шахановша айтқанда: «даңғазалыққа бой ұрып, ұлттық рухты тәрк етіп отырған» мына заманда, болымсыз іске бола өзгеге әлімжеттік танытып отырған уақытта ақынның осы сөзі басу болатындай.

Абайдың өзі өлгенмен, сөзі өлген жоқ. "Өлді деуге сыя ма, ойлаңдаршы, өлмейтұғын артына сөз қалдырған", – деп кемеңгердің өзі айтқандай, Абай – артына өлмейтұғын сөз қалдырды. Ол сөзі ұрпақтан-ұрпаққа жалғасып, ғасырдан-ғасырға асып, туған халқымен бірге жасаса бермек.

Абай шығармалары Шығыс пен Батыс дүниесімен толықтай үндесіп, астасып жатыр, сол себепті де әрбір адамзат баласының жүрегіне жол табары сөзсіз. Ақын тағлымы оқыған адамның ойын оятып, оны адалдық пен парасаттылыққа, адамгершілік пен жақсылыққа, сұлулық пен нәзіктікке үйретеді.

### ӘДЕБИЕТ

Әуезов М. Абай. Энциклопедия. Алматы: «Атамұра», 1995. 720 б.
Тоқтаров Р. Абайдың жұмбағы. Алматы: «Атамұра», 1999. 321 б.
Байтұрсынов А. Шығармалары. I том. Алматы: «Жібек жолы», 2002. 186 б.
Құнанбаев А. Таңдамалы өлеңдер. Алматы: «Жазушы», 1985. 176 б.

**Е.С. УЛЬЯНОВА**
*Казанский радиомеханический колледж, Россия*

# АКТУАЛЬНЫЕ ПРОБЛЕМЫ СОВРЕМЕННОЙ ПЕДАГОГИКИ И ВОЗМОЖНЫЕ ПУТИ ИХ РЕШЕНИЯ

**Аннотация.** Данная статья посвящена проблемам педагогики, которые влияют на качество преподавания. К ним мы отнесли отсутствие условий для преподавания и форму для преподавания. В конце статьи представлены возможные пути решения данных проблем, которые поспособствовали бы повышению значимости учителя в обществе и самого образования в целом.

**Abstract.** This article is devoted to the problems of pedagogy that affect the quality of teaching. To these we attributed the lack of conditions for teaching and the form for teaching. At the end of the article the possible ways of solving these problems, which would contribute to increasing the importance of teachers in society and education in General, are presented.

**Ключевые слова:** педагогика, проблемы педагогики, образование.

**Keywords:** pedagogy, problems of pedagogy, education.

Педагог – тот, кто передает свои и наработанные прежними поколениями знания, опыт, умения поколению младшему, тот, кто воспитывает молодежь, на основах накопленных и проверенных. И всегда искались, и почти всегда находились, пути и способы наиболее доходчивых и эффективных методов передачи знаний. Но проблемы в педагогике были и есть, решались и решаются.

В современной педагогике существуют проблемы следующего характера: отсутствие условий для преподавания и сама форма преподавания.

Рассмотрим подробнее каждую проблему. К проблеме отсутствия условий преподавания можно отнести, недостаточную оснащенность в учебных заведениях необходимыми материалами, это относится как к школам, так и к СПО и вузам. К данным материалам относятся не только учебники, но и различные учебные пособия, таблицы, карты, словари, любой другой материал, которой мог бы поспособствовать более глубокому пониманию и усвоению материала. В этом плане учащимся приходиться рассчитывать только на имеющиеся в открытом доступе материалы и на самого педагога, который преподносит данный материал, через спектр своих знаний.

К этой же проблеме можно отнести и отсутствие достойной зарплаты, поощрений и вознаграждений преподавателям. Поэтому во многих учебных организациях возникает нехватка молодых преподавателей и перенасыщение преподавателей-пенсионеров. Это может привести к тому, что педагогические кадры оскудеют. Ведь в основном именно молодые преподаватели вносят в процесс обучения инновационные методы, способствующие тому, чтобы

учащиеся не отстали от ритма жизни, стремительно развивающихся технологий, наук.

Что касается второй проблемы – проблемы формы преподавания, то здесь можно отметить 3 формы взаимодействия преподавателя и обучающихся: пассивный метод, активный метод и интерактивный метод. Последний из них является, на мой взгляд, самым эффективным, хотя в школах он используется крайне редко. Это связано с отношением самих учителей к своей работе. Они порой равнодушны к ней из-за низкой зарплаты и своей значимости в обществе. Учителя не видят важность своей работы для будущего всех детей. Поэтому они и не обращаются внимания на излагаемый ими материал, который неважно доходит до обучающегося в полной мере или нет. Учителя в школах бывает просто отчитывают свой материал, не обращая внимания на то, понял материал обучающийся или нет, часы отработаны – работа выполнена.

Чтобы искоренить эти и многие другие проблемы необходимо стремиться к полному соответствию определения педагогики реальности. Ведь педагогика – это наука о развитии человека, о формировании личности, которая будет правильно реагировать на внешние раздражители, при отсутствии контроля извне. Поэтому именно педагогика и определяет это правильное поведение. А для этого надо повышать, прежде всего, статус педагога, поддерживая его материально, морально; оснащать учебные учреждения учебным материалом, всевозможными учебными пособиями тем самым подталкивать педагогов к добыче новой информации для себя и последующей передачи ее обучающимся.

### ЛИТЕРАТУРА

Коршунова, Н. Л., Юдина, Н. П. Проблема объективности знания в педагогике // Педагогика. 2009. №8. С. 122–126.

Кузнецова, А. Я. Философия образования в контексте проблем устойчивого развития общества / А. Я. Кузнецова // Философия образования. 2005. №10. С. 370–371.

**Л.Х. ФАЙЗУТДИНОВА**

*Казанский инновационный университет им. В.Г. Тимирясова, Россия*

## СКАЗКОТЕРАПИЯ КАК МЕТОД КОРРЕКЦИИ АГРЕССИВНОГО ПОВЕДЕНИЯ У ДЕТЕЙ ДОШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА

**Аннотация.** Сказкотерапия является эффективным методом психологической коррекции агрессивного поведения у детей дошкольного возраста. Сказка помогает решить любую психологическую проблему. Однако, только при условии последовательной, систематической и кропотливой работы можно увидеть результат.

Актуальность: именно в дошкольном возрасте закрепляется агрессивное поведение, поэтому так важно вовремя увидеть и решить проблему.

Цель: сказкотерапия как метод коррекции агрессивного поведения у детей дошкольного возраста.

**Abstracts.** Fairytale therapy is an effective method of psychological correction of aggressive behavior in preschool children. A fairy tale helps to solve any psychological problem. However, only with consistent, systematic and painstaking work can you see the result.

Relevance: it is at preschool age that aggressive behavior is fixed, therefore it is so important to see and solve the problem in time.

Purpose: fairy-tale therapy as a method of correction of aggressive behavior in preschool children.

**Ключевые слова:** сказкотерапия, сказка, дошкольный возраст, агрессивность, метод.

**Key words:** fairy tale therapy, fairy tale, preschool age, aggressiveness, method.

Сказка – это некий разговор автора с читателем. Сказки просто так не пишут, во всем есть смысл. Сказки пишут люди, которые в жизни видят прекрасное, могут этим делиться с другими. Такие люди умеют радоваться и всех вокруг заражают своей радостью. Ведь в сказках всегда есть что-то удивительное, чего нет в реальности, и всегда присутствует хорошее окончание, что дарит надежду на лучшее.

Благодаря сказке дети познают окружающий мир: узнают, что можно, а что нельзя, что хорошее, а что плохое. Дети учатся жить по правилам гуманности. К тому же сказка развивает воображение, мышление и связную речь.

Можно до бесконечности перечислять свойства этого средства, так как сказка выступает как метод профилактики, диагностики и коррекции. Также есть еще одно важное свойство у сказкотерапии – коррекция агрессивного поведения у детей дошкольного возраста.

Сказкотерапия как метод психологической коррекции, является одним из новшеств современной психологии. Недавно этот метод получил широкое распространение, однако его корни уходят к основателям данной науки. К.Г. Юнг и З.Фрейд также занимались толкованием и анализом сказок. Считалось, что в них скрыты все психотипы, а события, которые рассматривались в этих рассказах, помогали найти выход из аналогичной ситуации в жизни.

Однако сознательно сказку стали использовать для решения внутренних конфликтов только в наши дни. Сказкотерапия, являясь методом психологической коррекции детей, показала потрясающую эффективность. Как оказалось, наши предки занимались именно этим, только для данного процесса они не придумывали отдельный термин. Благодаря сказкотерапии человек может

погрузиться в сказочный мир, где в роли персонажа он может осознать свои проблемы и увидеть себя со стороны [Вачков, 2001: 143].

Основателем сказкотерапии стала Татьяна Зинкевич-Евстигнеева. Она предложила использовать фольклорные персонажи для психотерапии и превратила эту идею в науку. Затем многие психологи и психотерапевты этот метод стали использовать в своей практике (Е.Лисина, И.В. Вачков, Э.Фромм и другие) [Зинкевич-Евстигнеева, 2005: 80].

И все же, как любой другой метод практической психологии, у сказкотерапии есть своя специфика и особенности ее применения:

- возрастные ограничения. Конечно, сказки полезно читать детям всех возрастов, но процесс сказкотерапии с анализом и разбором ситуаций, которые поставлены в сказках, желательно проводить с ребенком, начиная с 3-4 лет. Сказку следует подбирать или сочинять в соответствии с возрастом, личностными особенностями ребенка и ситуации, чтобы формировать определенные свойства в зависимости от ведущей деятельности.

- следует соблюдать временное ограничение сказкотерапии. Ее не нужно проводить дольше 30-40 минут с ребенком до 6-7 лет, поскольку ему трудно воспринимать информацию в течение долгого времени, он начинает отвлекаться, так как его внимание рассеивается [Короткова, 2003: 124].

В сказкотерапии используют разные виды сказок: народные сказки, бытовые сказки, сказки с животными, авторские художественные сказки, медитативные сказки.

Психотерапевтические истории или психокоррекционные сказки помогают мягко проводить коррекцию поведения ребенка. Их можно использовать для детей до 13 лет. Они прекрасно помогают решить конкретные проблемы.

Психолог Разида Ткач дала классификацию с точки зрения проблем, которые они решают. Она выделила следующие виды сказок: для агрессивных детей; сказки для детей, у которых проблемы в семье (развод родителей, рождение второго ребенка и другие); сказки, направленные на искоренение расстройств поведения с физическими проявлениями.

Повышенная агрессивность у детей выступает одной из наиболее острых проблем, которая возникает в работе с детьми дошкольного возраста. В этом возрасте особенно важно изучение агрессивности, поскольку данная черта находится в стадии становления, когда еще можно своевременно скорректировать поведение.

Не деструктивная агрессивность выступает как механизм удовлетворения желания, способность к адаптации, достижение цели. Она побуждает ребенка

к конкуренции в окружающем мире, защите интересов и прав, служит для развития способности положиться на себя. Враждебная деструктивность – это не просто враждебное и злобное поведение, но также желание причинить боль и получить удовольствие от этого. Обычно результатом такого поведения бывают конфликты, снижение адаптивных возможностей ребенка, становление агрессивности как черты личности.

Непреднамеренная агрессия – это случайное нанесение вреда человеку. Она достаточно распространена в детском коллективе.

Агрессия как попытка самоутвердиться, у дошкольников проявляется в общении с родственниками и в игре. Ребенок в игре как бы «отрабатывает» рождающиеся лидерские тенденции, становится ситуативным лидером, у которого есть подчиненные, слушающие его распоряжения. Общаясь с родными, ребенок проявляет замашки диктатора, «тестирует» своих родных на устойчивость нервной системы и проверяет уровень дозволенного.

Оборонительная агрессия тоже типична для дошкольного возраста. Ее специфика в том, что она сопровождается гневом – это реакция ребенка на нарушение значимой для него системы ценностей. [Ткач, 2018: 543]

Психологи выделяют и «инструментальную агрессию». В качестве вида детской агрессии, она преследует определенную цель – получить то, что желаемо или необходимо.

По мнению Т.П. Смирновой, дети черпают знания о моделях агрессивного поведения из трех источников:

1. Семья, которая может демонстрировать агрессивное поведение.

2. Агрессии обучаются при взаимодействии со сверстниками, часто узнавая о преимуществах агрессивного поведения.

3. Дети учатся агрессивным реакциям как на реальных примерах, так и на символических. [Ткач, 2008: 116]

Итак, сказка помогает решить любую психологическую проблему, в том числе и агрессивность в дошкольном возрасте. Однако, только при условии последовательной, систематической и кропотливой работы можно увидеть результат.

## ЛИТЕРАТУРА

Вачков И.В. Сказкотерапия: развитие самосознания через психол. сказку / И.В. Вачков. М.: Ось-89, 2001. 143 с.

Зинкевич-Евстигнеева Т. Основы сказкотерапии. М.: 2005. 80 с.

Капская А. Ю. Подарки фей. Развивающая сказкотерапия для детей / А.Ю. Капская, Т.Л. Мирончик. М.: Речь, 2016. 543 с.

Короткова Л.Д. Сказкотерапия для дошкольников и младшего школьного возраста: метод. рекомендации для пед. и психокоррекц. работы / Л.Д. Короткова. М.: ЦГЛ, 2003. 124 с.
Ткач Р.М. Сказкотерапия детских проблем / Р.М. Ткач СПб.: Речь, 2008. 116 с.

**З.И. ФӘСХИЕВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАРЧА-РУСЧА СҮЗЛЕКЛӘРДӘ РИЗЫК АТАМАЛАРЫНЫҢ ТОТКАН УРЫНЫ

**Аннотация.** В данной статье исследуются названия пищи татарского языка, зафиксированные в татарско-русских словарях XX-XXI веков. На материале данных источников рассматриваются изменения лексики пищи в течение века. Дается краткая характеристика татарской кухни на примере названий пищи.

**Abstract.** This article examines the names of food of the Tatar language, which are fixed in the Tatar-Russian dictionaries of the XX-XXI centuries. The changes of “food” lexis during the century are considered on the material of these sources. A brief description of the Tatar cuisine on the example of food names is presented.

**Ключевые слова:** татарский язык, названия пищи, словари, татарско-русские словари, материальная культура.

**Key words:** Tatar language, food names, dictionaries, Tatar-Russian dictionaries, material culture.

Һәр халыкның үзенә генә хас милли мәдәнияте бар. Ул халыкның яшәү территориясенә, андагы климатка, тормыш шартларына, яшәү рәвешенә карап формалаша. Билгеле бер халыкның милли мәдәниятен өйрәнү – шул халыкның тарихын, үткәнен өйрәнү дә ул. Мондый тикшеренүләрдә милли мәдәният лексикасы төп объект булып тора. Ә бу лексиканың төп чыганакларыннан берсе – сүзлекләр. Сүзлекләрдә халыкның, милләтнең зур мәдәни байлыгы тупланганга бу төр хезмәтләрне еш кына тикшерену өчен база итеп алалар. Алар арасында ике телле сүзлекләр аерым бер урын тота, чөнки алар бер халыкның мәдәниятен икенче халыкка җиткерү, аңлатуда зур роль уйныйлар.

Татар халкының милли мәдәнияте бик бай һәм зур тарихка ия. Аның матди мәдәнияте дә, рухи мәдәнияте дә игътибарга лаек. Матди мәдәниятнең бер өлеше булган милли татар ризыклары аеруча халкыбызны киң җәмәгатьчелеккә танытуда төп рольне уйный. Алар халыкның үзенә генә хас булган иҗтимагый һәм рухи тарихын чагылдыра, башка милләтләр белән мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә.

Һичшиксез, күп кенә тугандаш һәм күрше булып яшәүче халыкларның аш-суында, аларның атамаларында уртаклык бар. Татарстан, Башкортстан,

Идел буе өлкәләре, Төньяк Кавказның берничә республикасы – Дагестан, Чечня, Ингушетия, Осетия, Карачай-Черкес, Кабардин-Балкар, Адыгей, Якутиядә Россиянең төрки телле халыкларының милли ризыкларында һәм аларны әзерләү рәвешләрендә бик күп охшашлык табарга мөмкин. Тик ничек кенә булмасын, һәр милләтнең ризык әзерләүдә үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Татар аш-суы да шундыйлардан.

Татар халкының милли традицияләргә бай ашлар әзерләү осталыгы бик күптәннән килә. Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән, алар үзләренә генә хас сыйфатларны әлегә кадәр саклаганнар. Аларда халык тормышының иҗтимагый, икътисади, табигый шартлары, аның этник тарихы чагыла.

Ләкин татар халкының милли ашлары үз этник традицияләре нигезендә генә үсмәгән, аңа күрше халыкларның – руслар, мари, удмурт һ.б., шулай ук Урта Азия халыкларының, аеруча үзбәк һәм таҗикларның ашлары йогынты ясаган. Татар халкы ашларына *пылау, хәлвә, ширбәт* кебек ашамлыклар, шулай ук рус милли ашамлыклары бик күптән килеп кергән. Шул ук вакытта башка халыкларга хас ашларны әзерләү, азыкларның төрләрен ишәйтү татар ашларының төп этник үзенчәлекләрен үзгәртмәгән [Әхмәтҗанов, 1987: 5].

Татар халкы элек-электән иген иккән, шуңа күрә күбрәк оннан, ярмадан ашлар әзерләгән. Арыш, бодай, борчак, арпа һәм солы онын, тары, карабодай һәм борай, соңрак дөге ярмасын киң кулланган. Шулай ук татарлар терлекчелек белән дә бик күптәннән шөгыльләнгән. Күбрәк сыер, сарык, кәҗә асраганнар, йорт кошларыннан тавык, каз, үрдәк үрчеткәннәр. Шуңа күрә татар-аш суы ит-сөт ризыкларына да бик бай.

Урманлы дала өлкәсендә яшәгән татарлар умартачылык белән дә бик күптәннән таныш булган. Бал һәм балавыз халык кеременең мөһим чыганагы булып торган.

Татар халкының мондый яшәү рәвеше телнең ризык лексикасында да чагыла. Ә сүзлекләр, алда билгеләп үтелгәнчә, әлеге лексик мирасны бер урында туплап, саклаучы, киләсе буыннарга тапшыручы ролен дә үти.

Сүзлекләрдә ризык атамалары шактый урын биләп тора. Без моңа XX-XI гасырларда басылып чыккан татарча-русча сүзлекләрдә теркәлгән ризык атамаларын барлап инандык. Бер гасыр вакыт эчендә телдә, мәдәнияттә үсеш-үзгәрешләр шактый булган. 1913-2007 елларда басылган 8 исемдәге татарча-русча сүзлектә (1913, 1927, 1931, 1950, 1966, 1988, 2002, 2007) 370тән артык төрдәге ризык атамасы теркәлгән. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, ризык атамалары бер гасыр эчендә төрле үзгәрешләр кичергән: кайбер ризык атамалары

вакытлар узу белән телдән төшеп калган, кайберләре яңа ризыклар белән телгә үтеп кергән, ә икенчеләре элек-электән бүгенгә кадәр телебездә актив кулланыла. Ләкин әлеге үзгәрешләргә карамастан, татар аш-суы үзенең милли үзенчәлекләрен югалтмаган.

Татар милли аш-суының камыр ризыклары белән дан тотуы һәркемгә мәгълүм. Һәм әлеге үзенчәлек тикшерелгән һәр сүзлектә чагылыш таба: бер гасыр дәвамында татар ризыклары арасында камыр ашлары беренчелекне бирми. Аларның күп өлеше һәр сүзлектә дә урын алган. Чөнки, мәгълүм булганча, татарлар элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгән.

Татар милли камыр ризыклары бик күп төрле. Эчлексез яки эчлек белән пешерелүләренә карап, барлык камыр ашларын ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төркемгә *ипи, күмәч, көлчә, кабартма, күзикмәк, юка*, *урама, күптермә, бавырсак, коймак* һ.б. керә, ә икенче төркем үз эченә түбәндәге ризыкларны ала: *сумса, бөккән, өчпочмак, бәлеш, гөбәдия*, *ләвәш, пәрәмәч, дучмак, кыстыбый* һ.б. Соңгылары өчен, гадәттә, эчлек буларак ит, ярма, яшелчә, җиләк-җимешләр кулланыла.

Шулай ук сүзлекләрдә элек-электән татар кухнясында яратып әзерләнгән ит-сөт ризыклары да шактый теркәлгән. Татарларның азык рационында ит ризыклары гасырлар буена төп азык булып саналган. Чөнки татарлар яшәгән территориядә һава торышының даими булмавы, ел дәвамында салкын көннәрнең күбрәк булуы сәбәпле, организм өчен рационда ит ризыклары булу бик мөһим. Шуңа күрә татар халкы гомер гомергә терлек, кош-корт асраган. Итне пешереп, кыздырып ашаганнар, аннан *тутырма, казылык, койка* кебек ризыклар әзерләгәннәр. Ит шулай ук кайбер эчлекле камыр ашларындагы (өчпочмак, бәлеш, бөккән) төп ингридиентларның берсе булып тора.

Сөт ризыкларын татар халкы элек-электән әзерләгән һәм кулланган. Хәзерге вакытта да алардан башка татар кухнясын күз алдына да китереп булмый. Сөт төрле ризыклар әзерләү өчен ингредиент булып кына калмыйча, үзе дә төрле формаларда кулланыла. Мәсәлән, сүзлекләрдә *сөт, угыз, каймак, атланмай, катык, сөзмә, эремчек, корт* кебек сөт ризыклары атамаларын күрергә мөмкин.

Ашлар, шулпалар да татар табынында зур урын тота. Ашларны, нинди шулпада әзерләнүенә карап, итле, сөтле, кысыр ашларга, ә нәрсәләр салынуына карап, камырлы, ярмалы, камырлы-яшелчәле, ярмалы-яшелчәле, яшелчәле ашларга бүләргә мөмкин. Халыкның культурасы һәм матди көнкүреше яхшыру, башка халыклар белән аралашу процессында милли ашларның төрләре тулылана барган. Ләкин татар табынының үзенчәлекле ягын әле хәзер дә

камырлы ашлар, барыннан да бигрәк токмачлы аш тәшкил итә. Сүзлекләрдә әлеге төркемгә кергән түбәндәге атамалар урын алган: *аш, шулпа, өйрә, салма, умач, чумар, куллама* һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, сүзлекләрдә милли ризык атамалары шактый теркәлгән. Әмма татар теленең ризык лексикасы милли ашлардан гына гыйбарәт түгел. Ул гел үсеш-үзгәрештә. Күрше халыклар белән аралашып яшәү әлеге лексик төркемне баетып тора. Вакыт узган саен рус теленнән, рус теле аша башка чит телләрдән төрледән төрле ризык атамалары татар теленә үтеп керә. Мәсәлән, *вермишель* сүзе 1931 елгы сүзлектән генә күренә башлый. *Борщ* сүзе беренче тапкыр 1950 елгы сүзлектә очрый. *Котлет, колбаса, сарделька, вафля* кебек сүзләр 1966 елгы сүзлектә пәйда була. Димәк, шушы вакытларда әлеге ризык атамалары телебезгә үтеп кереп, актив кулланыла башлый.

Тупланган ризык атамаларының кайберләре бер сүзлектә генә теркәлгән. Мәсәлән: *ак аш, ак ипи, ак ит, бавыр колбасасы, җәү икмәк* кебек аерым ризыкларның төрләрен атап килә торган сүзләр, яки *галушки, беф-строганов, бисквит, кулич, пирожки, пломбир* кебек башка телдән кергән атамаларны 2007 елгы сүзлектә генә очратырга мөмкин. Беренчедән, алда әйтеп үтелгәнчә, бу телгә яңа ризык атамалары үтеп керү белән бәйле булса, икенчедән, сүзлекнең күләменә дә бәйле. 2007 елгы ике томлык хезмәттә актив кулланылыштагы сүзләр генә түгел, ә кулланыштан чыкканнары да урын алган.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, татар телендәге ризык атамалары татарча-русча сүзлекләрдә шактый урын алып тора. Милли ризык атамалары татар мәдәниятен, тарихын чагылдырса, бу лексиканы үз эченә алган сүзлекләр әлеге мәдәниятне, тарихны югалтмый киләсе буынга тапшырырга ярдәм итә. Ризык лексикасының сүзлекләрдә теркәлеше еллар дәвамында төрле үзгәрешләр кичерсә дә, милли ризык атамаларының күп өлеше сүзлекләрдә теркәлүен дәвам итә. Чөнки әлеге ризыклар бүгенге көндә дә татар табынын бизи. Шул ук вакытта татар кухнясы яңа ризыклар, ә ризык лексикасы яңа ризык атамалары белән баеп тора.

**ӘДӘБИЯТ**

Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. / русчадан Камалова Р.Х. һәм Шәрипова В.Р. тәрҗемәсе. Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. 318 б.

Рахманкулов С.Г. Татарча-русча лөгать / С.Г. Рахманкулов. Казань: Лито-типография Харитонова, 1913. 210 б.

Татарча-русча сүзлек / М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов, И.Г. Кулиев. Казан, 1927. 219 б.

Татарча-русча сүзлек / М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов, И.Г. Кулиев. Казан, 1931. 428 б.

Татарча-русча сүзлек / Р.С. Газизов, Н.С. Исәнбәт, Г. Ишмөхәммәтов. Казан, 1950. 340 б.

Татарча-русча сүзлек. М.: Совет энциклопедиясе, 1966. 863 б.

Татарско-русский словарь / И.А. Абдуллин, Ф.А. Ганиев, М.Г. Мухамадиев, Р.А. Юналеева / Под ред. Ф.А. Ганиева. Казань: Тат. книжн. изд-во., 1988. 431 с.

Татарско-русский словарь / И.А. Абдуллин, Ф.А. Ганиев, М.Г. Мухамадиев, Р.А. Юналеева / Под ред. Ф.А. Ганиева. Казань: Тат. книжн. издат., 2002. – 488 с.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. Т.1. (А-Л) / Ф.А. Ганиев, М.З. Закиев, Ш.Н. Асылгареев, Д.Б. Рамазанова. Казань: Магариф, 2007. 726 с.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. Т. 2 (М-Я) / Ф.А. Ганиев, М.З. Закиев, Ш.Н. Асылгареев, Д.Б. Рамазанова. Казань: Магариф, 2007. 726 с.

**Р.И. ФИЛИППОВА**

*Казан федераль университеты, Казан*

# ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР ФОРМАЛАШТЫРУ ТЕОРИЯСЕ ҺӘМ АНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** В статье предлагается краткая характеристика термина «Общественное мнение» и анализируется теория «Спираль молчания» Элизабет Ноэль-Нойман.

**Abstract**.The article offers a brief description of the term "Public opinion" and analysis the theory of "Spiral of silence" by Elisabeth Noelle-Neumann.

**Ключевые слова**: Общественное мнение, теория, термин, спираль молчания

**Keywords**: Public opinion, theory, term, spiral of silence

Журналистика һәм социология фәннәрен өйрәнгәндә, «иҗтимагый фикер» төшенчәсен ачыклап китү зарур. Аңлатмалы сүзлектә күрсәтелгәнчә, иҗтимагый фикер ул – «с. кит. 1. Җәмгыятькә караган, шуңа бәйләнешле; 2. Бөтен кешелек катнашында тудырыла, үтәлә, эшләнә торган и. җитештерү. Бөтен җәмгыятьнеке, барлык кешеләрнеке, күмәк 3. "Зарур, әһәмият" сүзләре белән килгәндә: бөтен җәмгыять өчен и. зарур эш вакыты 4. Җәмгыятьнең политик, культура ихтыяҗларын үтәү белән бәйле 5. Кешеләрнең җәмгыятьтә тоткан урыннарын, үзара мөнәсәбәтләрен, сыйныфларга бүленүен чагылдыра торган һәм шуларга бәйләнешле; социаль 6. Иҗтимагый җитештерү мөнәсәбәтләрен үзгәртүне максат иткән, социаль и. программа» [Татар..., 2015] Социаль журналистика фәнендә исә бу терминга карата бераз башка яссылыкта бәяләмә бирелә. Иҗтимагый фикер – төрле төркем кешеләрнең мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына кагылышлы, вакыйгаларга һәм гамәлдәге тормыш процессларына мөнәсәбәттә (яшерен яки ачык) күрсәтелгән массакүләм аң формасы. Җәмәгатьчелек фикере ачыктан-ачык чагыла, җәмгыять һәм аның сәяси системасы эшчәнлегенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин. Иҗтимагый тормышның бик әһәмиятле булып торган

проблемалары буенча халыкның ачыктан-ачык фикерләү мөмкинлеге һәм иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләр үсешенә бу әйтелгән позициянең йогынтысы, иҗтимагый фикернең асылын, аерым социаль институт буларак чагылдыра.

Шул ук вакытта, җәмәгатьчелек фикере, кешеләр төркеменә кагылышлы конкрет мәсьәлә буенча күп кенә индивидуаль фикерләр җыелмасы да булып тора.

«Иҗтимагый фикер» элек-электән фикер йөртүчеләрнең игътибарын җәлеп итүче, иҗтимагый күренешләр исәбенә кергән.

Хәзерге вакытта бу караш күпчелек фәнни хезмәтләрдә чагылыш тапкан һәм гомумтанылган дип санала. Әлеге күренеш төрле тарихи дәверләрдә, борынгы заманнардан ук яшәп килә, әмма кешелек тормышының мондый уникаль феноменын билгеләүче термин үзе XII гасырда Англиядә барлыкка килгән, аны инглиз дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы Солсбери исеме белән бәйлиләр. Солсбери аны ил халкы тарафыннан, парламентка әхлак ярдәм күрсәтү өчен «Поликратик» китабында кулланган. Ул чакта «иҗтимагый фикер» термины «Public Opinion» дигән ике сүз кушылмасын турыдан-туры тәрҗемә итеп аңлаткан. Англиядән бу гыйбарә башка илләргә үтеп керә һәм XVIII гасыр азагыннан гомумхалык кабул ителә.

Элизабет Ноэль-Нойман (1916 – 2010) – Алман (Германия) социологы һәм сәясәтче, Алленсбахә шәһәрендәге Демоскопия институтына нигез салучы. “Спираль молчания” дигән теория төзи. Теориянең көче, динамик механизмда һәм иҗтимагый фикер концептуальлегенең иҗтимагый күренеш булуында чагыла.

Элизабет Ноэль-Нойман теориясе «Иҗтимагый фикер формалаштыру теориясе һәм аның үзенчәлекләре» дигән хезмәттә чагыла. Хәзерге заманның күренекле социологларының берсе, Элизабет Ноэль-Нойман – иҗтимагый фикер өлкәсендә белгеч, «Общественное мнение. Открытие спирали молчания»нең соңгы бүлегендә, түбәндәге билгеләмәне бирә: «Иҗтимагый фикер — ул кыйммәтле үзенчәлек, аерым алганда, әхлакый төсмергә ия булган фикер һәм үз-үзеңне тоту ысулы, әйтик, канун яки гореф-гадәт турында сүз барган очракта, изоляция хәлендә булмас өчен, кеше алдында, изоляциядән курыкмыйча, чыгыш ясарга кирәк».

«Общественное мнение — это ценностно окрашенное, в частности имеющее моральную окраску, мнение и способ поведения, которые, если речь идёт об устоявшемся, закрепившемся согласии, например, догме или обычае, следует демонстрировать прилюдно, если не хочешь оказаться в изоляции, или кото-

рые в проходящих состояниях можно прилюдно демонстрировать, не боясь изоляции» – дип яза автор.

Фәндә Элизабет Ноэль-Нойманның “Спирали молчания” дигән хезмәте дөнькүләм танылган. Аның нигезендә Массакүләм Мәгълүмат Чаралары яки аларның иҗтимагый даирәләре, үз позициясенә каршы килүне күреп, кешене позициясеннән мәхрүм итү нәтиҗәсендә, күпләрнең фикерен белдерүдә чикләнеп калулары турында. Алар дин күзлегеннән чыгып әйтелгән фикерләр таралганлыкны, шул ук вакытта тыйганнар. Коммуникатив идея хисабына гына “спирали молчания”не җиңеп, иҗтимагый куркуны бетереп була дип әйтелә теориядә.

Иҗтимагый фикер этаплары:

1. Шәхси фикер туу;
2. Фикер алышу;
3. Өстенлек итүче фикернең кристальләшүе;
4. Өстенлек итүче бер фикер, ягъни фикерне үзгәртеп коруга көчү халәте.

Иҗтимагый фикернең үзенчәлекләре:

1. Хәрәкәтчәнлек, тотрыксызлык — җәмәгатьчелек фикере тиз үзгәрергә мөмкин;
2. Иҗтимагый мөхиткә бәйле – җәмәгать тәртибен формалаштыруны, илдә сәяси, икътисади һәм иҗтимагый хәлнең барлык нәтиҗәләрен исәпкә алып, гамәлгә ашырырга кирәк;
3. Вакыйга – фикер, күпчелек очракта бара торган конкрет вакыйгалар хисабына үзгәрә;
4. Кызыксыну – аудитория фикере, кагыйдә буларак, аларның туры-дан-туры кызыксынулары белән билгеләнә;
5. Бер бөтен булмау – бөтен аудиторияләрнең конкрет группа аша йогынтысы.

Шул рәвешле, иҗтимагый фикер кешеләр төркеменә кагылышлы мәсьәләләр буенча күп кенә индивидуаль фикерләр җыелмасы да булып тора.

## ӘДӘБИЯТ:

Сабирова Л.Р. Иҗтимагый-сәяси тәрҗемә теориясе һәм практикасы: Программа. Казань: Казанский университет, 2010. 15 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г–Й. Казан: ТӘһСИ, 2016. 748 б.

**А.Р. ХӘБИБУЛЛИНА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# ФАТИХ АМИРХАН ПРОЗАСЫНДА КАЗАН ОБРАЗЫ

**Аннотация.** В данной статье рассматривается образ Казани в прозе Ф.Амирхана.
**Abstract.** This article discusses the image of Kazan in prose F. Amirhan/
**Ключевые слова:** образ, хронотоп, проблематика
**Keywords:** image, the chronotope, problematics

Татар мәдәниятенең үзәге булган мәһабәт башкалабыз Казан татар әдәбиятында зур урын били. XIX йөз ахырына кадәр милли әдәбиятта Казанга мәдхияләр дә, шәһәрне уңай һәм тискәре бәяләүләр дә, аны вакыйгалар бара торган урын буларак файдалану да бик еш очрый. Д. Заһидуллина фикеренчә, нәкъ менә XX йөз башында татарлар тупланган, татар мәдәниятенең үзәге булган Казанны нурлы мәркәз итеп караган миф мәйданга чыга [Мәгариф, №8, 2005, 20б.].

XX гасыр башы – татар әдәбиятының иң гүзәл алтын чоры. Бу вакытта милли әдәбият эстетик һәм фәлсәфи мөмкинлекләрен киңәйтә. Татар мәдәнияте кискен үсеш дәвере кичерә. Әдәбиятта яңару күренеше, татар җәмгыятенең үзәге булган Казанны яхшырту һәм камилләштерү, милләтнең рухын үзгәртү идеясе белән үрелеп бара. Әсәрләрдә милләткә, шул исәптән Казанга бәйле күп кенә мәсьәләләр күтәрелә [Заһидуллина, 2011:7б.].

Шулай итеп, XX гасыр башында татар җәмгыятендә әзерлекле яшьләр өлгерә. Аларның күпчелеге Казанда яши, иҗат итә. Нәкъ менә алар үз мәдәниятләрен иң алдынгы милләтләр яулаган биеклеккә күтәрергә омтыла. Мәдрәсәдә уку дәверендә бу яшьләр дөньяви белем туплый, рус һәм Европа телләрен өйрәнә. Алар соңрак укуларын университетларда дәвам итә, белем туплагач, үзләренә татар җәмгыятендә гыйльми, иҗтимагый-фәлсәфи, эстетик фикерне үзгәртеп кору бурычын максат итеп куя.

Бу чорда төрле мәдәни үзәкләр: туган тел, милли музыка һәм җыр түгәрәкләре, клублар һәм китапханәләр, нәшриятләр, китап кибетләре ачыла. Алар татар җәмгыяте үсешендә зур роль уйный. Мәсәлән, Шәрык клубы Казан шәһәрендәге татар зыялылары өчен мәдәни үзәккә әверелә. Клубта китапханә, кыллы оркестр, уку һәм тамаша заллары эшли. Анда әдәби кичәләр уздырыла, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал һ.б. чыгышлар ясый, лекцияләр укыла, татар һәм рус телләрендә спектакльләр куела, күренекле җырчылар концерт бирә, Казан музыка мәктәбе укытучылары опералардан өзекләр башкара. Шулай итеп, татар зыялылары төрле формаларда мәдәни агарту, мәгърифәт эшен җәелдерә.

Язучылар әсәрләрендә, тәнкыйть итү ысулы белән татар җәмгыятен “йокыдан уятырга” тырыша. Бу әсәрләр яшәп килгән тәртипләрне инкарь итү - татар җәмгыятендәге иске тәртипләрне юкка чыгару булып яңгырый. Татар әдәбиятында тәнкыйди реализм кире кагу һәм раслауның янәшәлегенә, ягъни синтезына ирешә. Аларда аерым шәхес тәнкыйтьләнми, киресенчә милләт, тирәлек, җәмгыятьтәге мәгълүм бер катламнар игътибар үзәгенә куела. Бу темаларны оста яктыртучы – Фатих Әмирхан.

Талантлы язучы һәм драматург, үткен тәнкыйтьче һәм ялкынлы публицист Фатих Әмирхан 1886 елның 1 гыйнварында Казанның Яңа татар бистәсендә дөньяга килә. Профессиональ тәнкыйтьче Җамал Вәлиди “Әдип Фатих Әмирхан” рецензиясендә мондый фикер әйтә: “Фатих Әмирханның һичбер вакыт авылда чын халык арасында булмавы, соңынан авыруы сәбәпле Казанга мәңгегә беркетелүе аның әдәби кырының киңәюенә юлны кискән иде дип әйтергә ярый. Ләкин аның каравы Казаннан чыкмыйча яшәргә мәхкүмлеге (хөкем ителүе), аның татарның мәдәни мәркәзе эчендә кайнавын, мондагы күренешләрне якынан күреп торып тәэмин итте. Һәрхәлдә, Ф.Әмирхан, Г.Камал кебек Казан шәһәренең иске һәм яңа тормышының эчендә кайнап үскән, шуның өчен аны бик яхшы белүче һәм шуны хикәядә, сәхнәдә күрсәтә белүче сирәк кешеләрдән”[Гыйлаҗев, 2008: 184 б.].

Фатих Әмирхан XX йөз башы татар әдәбиятында төрле юнәлешләрдә эзләнүләр алып барган, бер-берсенә охшамаган, ләкин әдәби осталык ягынан камил әсәрләр иҗат иткән әдип, драматург, тәнкыйтьче. Ул – гомерен милләткә хезмәт итүгә багышлаган зыялы талант иясе. Казанда туып үскән Фатих Әмирхан башкаладагы күренешләрне тулы итеп бәяли, шәһәр образын чынлыкка туры китереп сурәтли алган.

Резеда Ганиева билгеләп үткәнчә, Ф. Әмирханның төп идеалы озак гомерләр дәвамында феодаль торгынлыкта яшәгән татар кешесен «хакыйкый европеец», абруйлы репутациягә ия шәхес итеп тәрбияләү [Ганиева,2016: 30б.]. «Яшьләр колагына бер сүз» (1908) дигән чыгышында ул: «Бездән мәгыйшәт эш вә эшлеклелек таләп итә. Бездән мәгыйшәт хакыйкый (чын) европеец булуыбызны таләп итә», - дип яза.

Фатих Әмирхан 1907 елда иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Ул үзенчәлекле әдәби әсәрләре белән милли сүз сәнгатенең яңгарышын, үсешен һәм камилләшүен билгеләүче шәхесләрнең берсе буларак таныла [Гыйляҗев,2008:242б.].

Фатих Әмирхан проза әсәрләрендә Казан образына мөрәҗәгать итеп, татар милләтенең искен мәсьәләләрен калкыткан. Аның проза әсәрләрендә

Казанга уңай һәм тискәре бәяләр дә, вакыйгалар бара торган урын буларак сурәтләүләр дә күзәтелде. Тикшерү нәтиҗәсендә Фатих Әмирхан Казан образы аша татар халкын мәдәниләштерү, культурасын, зәвыгын үстерү, мәдәниятләштерү проблемаларын күтәрүен ачыкладык.

Гомеренең күп өлешен Казанда үткәргән әдип мәркәзебезне бик яхшы белгән. Ул әсәрләрендә Казан образын чынлыктагы кебек сурәтләргә омтылган. Беренчедән, проза әсәрләренең каһарманнары безгә таныш булган урамнарда, базарларда, сәнгать учакарында йөриләр. Икенчедән, әсәрнең күпчелек геройлары – безнең яшьтәшләребез. 100 ел элек яшәгән студентларның тормыш-көнкүреше, XX гасыр башында сәяси фикерләре, җәмгятьтәге үзгәрешләр, аларның әдәбият һәм сәнгать турындагы фикерләрен белү шул чор Казан күзаллавыбызны киңәйтте.

Фатих Әмирхан XX йөз башы татар әдәбиятында Казанның, милләтнең яңа дәрәҗәгә чыгуы өчен күп көч куйган. Казанны нәкъ Тукайдагыча нур, тарих, мәгърифәт үзәге итү омтылышы белән төрледән-төрле әсәрләр, мәкаләләр язган. Тикшерелгән әсәрләрдә Казан образы төрлечә чагыла. Автор “Кадерле минутлар”, “Рәхәт көн” хикәяләрендә, “Урталыкта” романында шәһәрне ничек бар шулай реаль итеп тасвирласа, “Гарәфә кич төшемдә” хикәясен, “Фәтхулла хәзрәт” повестен модернистик ысул кулланып язган. Анда автор алдагы гасырларда Казанның нинди булачагын шәрехли.

Казан шәһәре пейзажы әсәр геройларның эчке хис-кичерешләре белән бәйле: алар мәхәббәт утында янганда Казанның завод моржалары да гүзәл булып күренә (“Кадерле минутлар”), геройлар кайгы кичергәндә шәһәр караңгы, өметсез итеп тасвирлана (“Гарәфә кич төшемдә”).

Язучы XX гасыр татар әдәбияты өчен төп урынны алып торган татар милләтенең арталыгы мәсьәләсен кискен чагылдыра. Казан шәһәре вәкилләре арасында алдынгы фикер ияләре белән беррәттән иске тормыш вәкилләре дә сурәтләнә. Казан шәһәренең иске фикерле муллаларын, ишаннарын сурәтләп (“Фәтхулла хәзрәт”), язучы белемсезлек мәсьәләләрен чагылдыра. Татар милләтенең, мәдәниятенең начар якларын фаш итеп, тискәре бәяләр биреп, андагы кешеләрнең арталыгын күрсәтеп, автор татар милләтен мәгърифәтлелеккә өнди. Татар хатын-кызларының надан, дорфа булуларының сәбәбе – хатын-кыз ирексезлегендә икәнен ассызыклый (“Рәхәт көн”, “Урталыкта”). Автор рус телен, мәдәниятен, сәнгатен белү татар милләтен таныту өчен кирәк икәнен кат-кат дәлилли (“Урталыкта”, “Фәтхулла хәзрәт”).

Ф.Әмирхан әсрләрендә Казанга бәйле күп кенә мәсьәләләр күтәрелгәнлеге билгеләнде. Бу – надан һәм иске карашлы кешеләр булу, уку

йортларының бик акрынлык белән үзгәрүе, милләтнең әдәбият-сәнгатьне әһәмиятле санамавы, матди кыйммәтләрнең рухи кыйммәтләрдән өстен куелуы мәсьәләләре. Әлеге мәсәләләрне чишү өчен язучы үз геройларын тасвирлаганда, татар милләтенә хас булган сабырлык, юмартлык, мәрхәмәтлелек, намуслылык, малга табынмау, горурлык, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатларны аерып чыгара.

Фатих Әмирхан милли фикерләү аша дөньяга яңа караш, фәлсәфәне формалаштырырга тырышып язган. Милләтебезнең яшәешен яхшырту өчен үзенең мөмкинлекләреннән чыгып эш иткән әдибебез, милләтне үстерү эшендә актив катнашкан. Аяклары богаулы килеш тел, милләт өчен тырышып йөргән милләттәшебез безгә үрнәк. Туган телгә куркыныч янаган вакытта, шушындый шәхесләрнең иҗатын өйрәнү – безнең төп бурычыбыз.

### ӘДӘБИЯТ


Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Тат. кит. нәшр., 2008. 254 б.

Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. Казан: Казан ун-ты, 2011. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. 230 б.

Рухи мирас: эзләнүләр һәм ачышлар / И.Г. Гумеров ред. – Казан: ИЯЛИ, 2016. – №. 2. – 300 б.

Фәнни Татарстан. – 2016. – № 4. – 183 б.



**А.Ф. ҺАДИЕВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


## ХӘЗЕРГЕ ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ПРЕЦЕДЕНТ ИСЕМНӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ


**Аннотация.** В статье определяется сущность категории прецедентности, рассматривается история изучения прецедентных имен в языкознании.

**Abstract.** The article defines the essence of the concept category of precedence and deals with the history of the study of precedent names in linguistics.



**Ключевые слова:** татарский язык, прецедентные имена, прецедентный текс.

**Keywords:** the Tatar language, precedent names, precedent text.


Ономастика яшь фән булганга күрә, әлеге тел белеме тармагында өйрәнү өчен материал да җитәрлек. Аз өйрәнелгән, әмма инде галимнәрнең кызыксынуын уяткан тема буларак прецедент исемнәр дә тора. Шуңа күрә прецедент исемнәрне хәзерге татар тел белемендә, аерым алганда татар

матбугатында өйрәнү лингвистик һәм мәдәни яктан бик кызыклы һәм мөһим булып тора.

*Прецедент* төшенчәсе турында беренчеләрдән булып, 1986 елгы конгресс вакытында Ю.Н. Караулов әйткән. Галим фикеренчә, прецедент текстларга түбәндәгеләр керә: «1) танып-белү һәм хисси мөнәсәбәтләрдә теге яки бу шәхес өчен мөһим булган; 2) шәхестән өстен булган характерга ия, ягъни киң катламга мәгълүм булган; 3) әлеге тел дискурсында әлеге шәхесләргә берничә мәртәбә мөрәҗәгать итү» [Караулов, 2017: 216]. Галим прецедент текстны кертүнең дүрт юлын күрсәтә:

- Баш исем;
- Цитата;
- Персонаж исем;
- Автор исеме [Караулов, 2017: 218].

Ю.Н. Караулов прецедент текстларны «хрестоматия» төшенчәсе аша характерлый. Мәсәлән, рус мәдәнияте өчен «хрестоматия»ле текстларга А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов, Н.В. Гоголь төшенчәләре керсә, татар әдәбияты өчен, бу, һичшиксез, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил исемнәре кебек була. Шулай ук галим прецедент текстларга мифларны, халык иҗаты әсәрләрен, библия текстларын, тарихи-фәлсәфи һәм сәяси публицистика тестларын да кертә. Шулай итеп, прецедентлы текстларга мәктәп курсында өйрәнелүче әсәрләр генә түгел, ә «барысы да белә торган» текстлар керә [Караулов, 2017: 216].

Әлбәттә, барлык галим-белгечләр дә Ю.Н. Караулов белән килешмиләр. Мәсәлән, А.Е. Супрун мондый текстларга бүтән билгеләмә бирә һәм аларны текст реминесценцияләре дип атый: «Текст реминесценцияләре – аңлы яки аңсыз рәвештә, төгәл яки үзгәртелгән алдан иҗат ителгән әсәрләрнең цитаталары яки бүтән сылталмалар» [Супрун, 1995: 17]. А.Е. Супрун ассызыклап, болай дәвам итә: «... текст реминесценцияләрен тестның әйтелә торган элементлары буларак тел күренеше булып санарга нигез бар». [Супрун, 1995: 25]. Күргәнебезчә, әлеге билгеләмә Ю.Н. Караулов билгеләмәсе белән туры килеп бетми, әмма ул шулай да болай ди: «Прецедент текстны тел белән бирүдә цитатаның канатлы гыйбарәгә әверелүе мөмкин» [Караулов, 1987: 55].

Алда әйтеп узган галимнәрдән тыш, *прецедент* төшенчәсенә Ю.А. Сорокин, И.М. Михалева, Д.Б. Гудков, В.В. Красных, Ю.Е. Прохоров кебек галимнәр дә аңлатма биреп узганнар. Әмма алар прецедент текст түгел, ә прецедент гыйбарә, прецент текстлы реминесценция дип аңлаталар.

Гомумән алганда, *прецедент текст* төшенчәсе яңа терминнарга тууга ярдәм иткән. Мәсәлән: «прецедент исем» (Красных, 2008; Гудков, 1999; Сергеева, 2003; Прохоров, 2004; Вацковская, 2008), «прецедент онимнар» (Фомин, 2003), «прецедент топоним» (Березович, 2002); «прецедент гыйбарә» (Красных, 1998; Гудков, 1999; Прохоров, 2004), «прецедент ситуация» (Красных, 1998; Гудков, 1999; Прохоров, 2004), «прецедент феномен» (Красных, 1998; Гудков, 1999; Прохоров, 2004; Смирнова, 2008), «прецедент жанр» (Проскурина, 2004), «прецедент дөнья» (Красных, 1998; Слышкин, 2000; Балашова, 2008), «прецедент образ» (Чумак-Жунь, 2005) һ.б.

Шулай итеп, прецедент төшенчәсе шактый өйрәнелгән өлкә. Терминны Ю.Н. Караулов керткән. Ул элек булган хәлләргә нигезләп һәм дәлилләп һәм кеше ышандырырлык итеп бирелгән гыйбарә, сүз дигәнне аңлата.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, прецедентлык төшенчәсе татар тел белемендә өйрәнелмәгән диярлек, әмма шуңа карамастан, ул шактый кулланыла, мәсәлән, матбугат, реклама текстларында. Аларда прецедентлык күренеше, татар халкының яратып укый торган фольклор әсәрләренә ишарәдән гыйбарәт була ала:

*«Күп сүз – юк сүз. Кыскасы, 18нче июльдә «Яңа гасыр" теплоход сәфәренә чакыра. Калганын әйтеп тормыйбыз...Ниләр буласын әйтеп тормыйбыз, кемнәр буласын гына искәртәбез...».* Мисалдан күренгәнчә, сүз башындагы мәкаль сөйләмне ышанычлы, үтемле итә, интрига өсти.

Буа сатира театрының рекламасы үзенчәлекле: «*Ташка су сибү сездән — көлдерү бездән. Үтрически кызык булачак. Памперсларыгызны кияргә онытмагыз!»*. Әлеге рекламада әдәп ягы сакланмаса да, сүз җорлыгы театрның исеменә дә, җисеменә дә туры килеп тора.

Шулай ук реклама текстларында мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзтезмәләр, популяр җырлардан, күренекле әсәрләрдән сүзләр кулланыла: *«Әле мин сагынам сезне, соңрак сез сагынырсыз. «Шәһри Казан» үз укучылары белән менә шулай матур итеп җыр телендә сөйләшә белә»*. Сүзләрнең асылы, мәгънәсе газетага язылу вакытының бетеп килүен искәртүдән гыйбарәт. *«Вакыт җил кебек исә дә үтеп китә. Менә яңа ел да килеп җитәр. «Шәһри Казан»га язылмый калсак, киләсе елдан ул фатирыбызга килүдән туктар. Кайтар үткән көннәрне, дип Ходайдан ялварудан газеталы булмабыз, язылып куйыйк, җәмәгать!»*.

Шулай ук, реклама язучылар, әкиятләрдә күп очрый торган ситуацияләр, гыйбарәләр, аерым җөмләләрне бик теләп куллана. Мәсәлән: «*Менә балам, сиңа серле бер диск. Эстрада миченнән үк чыккан кап-кайнар «Супер яңа!»*

*җыентыгы! Яңа җырларны тыңлап шаккатырсың, биеп китәрсең, сөйгәнеңне табарсың, бәхетле булырсың! Яңа җырларны дус, туганыңа тыңлатсаң, дан-шөһрәт казанырсың. Сереңне кешегә сөйләмә, барын да югалтырсың. «Супер яңа!» җыентыгы синдә генә булырга тиеш»* (радио) реклама текстында без әкияти ситуация, төгәлрәк, нииндидер сихри көчкә ия әйберне (бу очракта музыкаль диск) башка бер кешегә биреп, аның сихри көче кеше тормышына үзгәрешләр (мәхәббәт, дан-шөһрәт, бәхет) кертә алуына ышандыру, һәм аның белән эш иткәндә сакчыллык таләп итү кебек прецедентлык ситуацияне күрә алабыз. Димәк, әлеге әкияти көчне ассызыклау дискны рекламалауның төп чарасы буларак күзаллана. Әлбәттә, бирелгән структура һәм эчтәлек реклама текстын игътибарны яуларлык итү өчен дә бик зур өлеш кертә.

Рекламаның бер төре булган афишаларда мәшһүр сәнгать әһелләренең, популяр җырчы, танылган язучыларның һәм күренекле шәхесләрнең исемнәре телгә алына:

Мәсәлән, *Илнар Сәйфиев үзенең иҗат театры белән Татарстан шәһәрләрен яулый. Иң яраткан җырлар, күңелләрне яулаган хитлар, кызыклы шоу-концерт программасы һәм күтәренке кәеф!*

Милли массакүләм элементлары исә аралашу процессында альтернатив мәгълүмати чыганаклардан алынган тәҗрибәгә нигезләнә. Реклама текстларында массакүләм мәдәният чаралары реклама кыйссаларында төрле яшьтәге кешеләргә, профессияләргә хас сленглар куллануда, реклама текстларын танылган артистлардан укытуда чагыла.

Мондый төр рекламалар хәзерге вакытта татарларда да күзәтелә. Әйтик, «Татарстан – Яңа гасыр», «Татар радиосы», «Курай» радиосындагы рекламаларны танылган театр артистлары, сүз осталары укый, кайберләре популяр җырчылар тарафыннан башкарыла. Әйтик, татар эстрадасының яшь җырчылары Дилә Нигъматуллина, Әлфинә Әзгәмова, Иркә, Фәрит Таишев, «Айфара» төркеме «Кәеф ничек?» газетасын халык арасына таратуда үз өлешләрен кертәләр:

*Ком сәгате, ком сәгате, ага гомерләребез,*

*“Кәеф ничек?” гәзитенә язылмыйча калмагыз, Язылмыйча калмагыз!*

Шулай итеп, татар тел белемендә прецедент төшенчәсе өйрәнелмәсә дә, актив кулланыла.

Прецедент төшенчәсендә прецедент исемнәр зур урынны алып торалар. Күп кенә галимнәр үз хезмәтләрендә исемнәрнең ялгызак һәм уртаклык исемнәрнең кушылуын да искәртәләр. Мәсәлән: *«Нәрсә миңа Герасим Мумуга караган кебек карап торасың»* җөмләсендә Герасим һәм Муму сүзләрен

уртаклык исемнәр дип атый алмыйбыз. Әмма ялгызлык исемнәрдән дә аерылып торалар, чөнки алар объектларның охшашлыгына ишарә ясыйлар.

Әлбәттә, прецедент исемнәр турында сөйләгәндә, теоретик яктан һәр ялгызак исем категориясе прецедентлы була ала, дип әйтә алабыз. Аларга түбәндәге оним төркемчәләре керә: антронимнар, топонимнар, кешенең интеллектуаль хезмәте белән тудырылган әдәби яисә бүтән әсәрләр, хрононимнар, бизнес объектлары, корабль исемнәре, хайван кушаматлары [Нахимова, 2011: 85-99].

Прецедент исемнәрне классификацияләгәндә, икенче яктан вакытка игътибар итәргә кирәк. Мәсәлән, *«Ник поезд туктамый, әллә мин бик күп фанта эчтем инде?!»,- дип уйлады Анна Каренина»* анекдотында вакытлы феномен буларак *Анна Каренина* исеме, ә прецедент исем *фанта* була.

Е.Ф. Косиченко прецедент исем классификациясенә түбәндәгеләрне китерә:

- яхшылык һәм түземлек эталоны (Иисус Христос, Мать Тереза), тикшерүче фикеренчә, иң аз санлы төркем;
- саранлык эталоны (Гобсек, Плюшкин, Кощей Бессмертный);
- алдау эталоны (Барон Мюнхгаузен, Пиноккио);
- кансызлык эталоны (Гитлер, Иван Грозный);
- матурлык эталоны (Венера, Аполлон, Афродита, Клеопатра, Эмма Гамильтон);
- интеллектуаль бәя (Аристотель, Моцарт, Спиноза, Чайковский), биредә автор иң күп исемнәр мисал була ала ди [Косиченко, 2006: 16-18].

Ясалышлары ягыннан прецедент исемнәр гади, катлаулы, кулланылыш сферасы буенча әдәбият, кино, балалар әдәбияты, анекдот, халык иҗаты һ.б. аерыла.

Шулай итеп, прецедент исемнәр һәрвакыт я прецедент вакыйга яки текст белән бәйле була. Прецедентның әлеге төре Г.Г. Сергеева, И.В. Привалова, Е.Ф. Косиченко хезмәтләрендә чагылыш тапкан. Прецедент исемнәргә ялгызак исемнәр дә, уртаклык исемнәр дә керергә мөмкин. Татар галимнәре тарафыннан әлеге феномен өйрәнелмәсә дә, В.З. Гарифуллин хезмәтләрендә әлеге төшенчәләргә ишарәләр бар.

Прецедент исемнәр җәмгыятьнең мәдәни мирас үлчәмен, уңай һәм тискәре геройларны билгелиләр, ягъни үрнәк булырлык билгеле бер тәртип манерасын күрсәтәләр. Прецедент исемнәр искиткеч төрле ассоциацияләр барлыкка китерә алалар, мәсәлән, Наташа Ростованың дигән очракта

кешелеклелек һәм ихласлык ассоцияцисе туса,  Кутузов дигәндә батырлык күз алдына килеп баса.


**ӘДӘБИЯТ**

Караулов Ю.Н. Русский язык и языковая личность /Отв. ред. Д.Н. Шмелев; АН СССР, Отд-ние лит. и яз. М.: Наука, 1987. 261 с.

Караулов Ю.Н. Русский язык и языковая личность. Изд. 6-е. М.: Изд-во ЛКИ, 2007. С. 216.

Косиченко Е.Ф. Прецедентные имена как средство выражения субъективной оценки: автореф. дис. …канд. филол.наук. М., 2006. 28 с.

Нахимова Е.А. Прецедентные онимы в современной российской массовой коммуникации: теория и методика когнитивно-дискурсивного исследования. Екатеринбург: ГОУ ВПО “Урал.гос. пед. ун-т”, 2011. 276 с.

Супрун А.Е. Текстовые реминисценции как языковое явление // Вопросы языкознания. – 1995. – № 6. – С. 17–30.



**И.Ф. ҺАДИЕВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


## З. ХӘКИМНЕҢ «ШАЙТАН КУЕНТЫГЫ» ДРАМАСЫНДА ЗАМАНА ПРОБЛЕМАЛАРЫН ЯКТЫРТУДА СИМВОЛЛАР РОЛЕ


**Аннотация.** В данной статье анализируется драма известного татарского драматурга современности Зульфата Хакима «Шайтан куентыгы», в которой автор часто обращается к образам-символам. Здесь выявляется роль символов (образ реки), мифологических образов (шайтанов-джиннов) в выявлении идейного замысла автора.

**Abstract.** This article analyzes the drama of the famous Tatar playwright of our time Zulfat Hakim «Shaytan kuentugu» in which the author often refers to images-symbols. The role of symbols (the image of the river), mythological images (shaytans-jinns) in identifying the author's intention is revealed.



**Ключевые слова:** Драма, символ, Зульфат Хаким, мифологические образы.

**Keywords:** drama, symbol, Zulfat Khakim, mythological image.


Зөлфәт Хәким, урта буын иҗатчысы буларак, сәхнәдә тормышны чагылдыру-сурәтләүнең башка төрле әдәбият һәм театр белемнәрендә «икенчел художество моделе» дип аталган формасына мөрәҗәгать итеп, бу юнәлештә актив эшли башлый. Әдәбият галиме Азат Әхмәдуллин әйтүенчә, XXI гасыр башында«…Сәхнә әдәбиятында гайре табигый хәлләр, пәриләр, су иyәләре, кеше ашаучылар, бичуралар, персонажлаштырылган Ай, җир, йолдызлар, роботлар һ.б. образлар күбәйде» [Әхмәдуллин, 2006; 25]. Мондый үзенчәлекләрне Зөлфәт Хәким иҗатында да табырга була.

З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» (1999) трагедиясендә вакыйгалар XX гасыр ахырында татар авылында бара. Драматургның әлеге әсәрендә ике дөнья ачык чагылдырыла: мифик һәм реаль дөньялар. Мифологик һәм реалистик катламнар бер-берсе белән параллель рәвештә сурәтләнә. Реаль тормышта – авыл, Фәнзилә һәм Разим мөнәсәбәтләре, аларның әниләре, мифик тормышта Фәнзиләнең күңеленә оялаган Илгиз-Шайтан, Рамизның күңелендәге Илгизә-Шайтан урын ала. Илгиз һәм Илгизә ярыммифик, ярымреаль образлар кебек кабул ителә. Әсәрдә Шайтан образы кеше күңелендәге кара яклар, явызлык символы буларак күтәрелә. «Мифы народов мира» энциклопедиясендә шайтан образына түбәндәге билгеләмә бирелә: «Шайтан– в мусульманской мифологии одна из категорий джиннов. По представлениям мусульман, каждого человека сопровождает ангел и шайтан, побуждающие его соответственно к добрым и нечестивым поступкам» [Сов. энцик.,1998.Т2; 625]. Ул теләсә нинди образда булырга мөмкин. Фольклор әсәрләрендә шайтанның төрле образларга керүен, язучыларның аңа карата игътибарның зур булуы аның катлаулылыгы, шулай ук явызлыкны гәүдәләндерүе белән аңлатыла. Мифологик сүзлекләрдә шайтаннар әллә нинди җирләрдә йөрергә, теләсә кайсы мизгелдә кеше тормышына тыкшынырга мөмкин, дип күрсәтелә. Алар кешене төрлечә котыртып, вәсвәсәләндерә алалар. Мәсәлән, спиртлы эчемлекләргә хирыс булган кеше шайтан коткысына бирелә. Шайтаннарның иң яраткан шөгыльләре–хатын-кызларның күңелләрен вәсвәсәләндерү[Сов.энцик.,1998.Т2; 625]. Шайтан, мифологик персонаж буларак, ислам мифологиясеннән килгән үзенчәлекләрне туплаган. З. Хакимнең пьесасында да нәкъ менә шундый образлар урын ала. А. Саттарова әйткәнчә, «чтобы передать внутренние состояния героев, писатель обращается к синтезу реального, фантастического, мифологического» [Саттарова,2003; 21].

«Шайтан куентыгы» пьесасында автор әсәрдә явызлык һәм яхшылык көрәшен сурәтли. Разим һәм Фәнзилә тормышындагы яхшы һәм якты як буларак– аларның сабый чактан бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре, уй-хыяллары сурәтләнә. Балачактан уйнап үскән, соңынннан бер-берсен яратышып йөргән Фәнзилә белән Разимнең мәхәббәте фаҗига белән тәмамлана. Мәктәпне бетергәч, Фәнзилә укырга дип, шәһәргә китә. Кызганычка каршы, ул акрынлап шәһәр тормышына кызыга башлый һәм ялтыравык тормышка кереп тә чума. Кызның җанына ир-ат рәвешендә шайтан кереп утыра. Кызны бүгенг яшәешнең яман якларын, байлыкка алданыпбозыклыккка бирелү гадәтләрен гәүдәләштергән Илгиз исемле шайтанны бары тик ул үзе генә күрә. Нәтиҗәдә ул аның белән аралашып кына калмый, хәтта гашыйк та була. «Зөлфәт Хәким

җирлеккә бәйле «Шайтан куетыгы» турындагы риваятьне отышлы файдалана. Шайтан куентыгында кычкырып сөйләшергә, шайтан исемен телгә алырга ярамый. Кем дә кем әлеге кануннарга буйсынмый, аңа шайтан ияләшә һәм ахыры үлем белән тәмамлана. Автор бу сюжетны әсәрнең нигезенә утыртып, вакыйгаларны ышандырырлык итеп тезә»[Юсупова,2014:43],– ди билгеләп үтәләр галимәләр Н.М. Юсупова һәм Г.Р.Гайнуллиналар. Шуңа күрә әсәрдә Разимның «Минем гаеп шунда: Фәнзилә белән ачулашканда мин аңа «шайтан алсын» дигән идем» [Хәким, 2000: 326] сүзләреннән соң кыз ике капма-каршы фикер иясенә әверелә. Разим да Илгизә-Шайтан белән танышканнан соң, аның котыртуы нигезендә аракы чоңгылына төшә. «Разим белән Фәнзиләнең күңелләрендә әйбәт һәм начар башлангычларның көрәше, ягъни геройларның ике ягы («двуединая сущность») турында сүз алып барырга мөмкин. Әсәрдә күңелләрендә ике башлангыч көрәше барган геройлар тагын бар. Ахырда төп геройларның әтиләре дә шул ук көрәш корбаннары булуы ачыклана» [Юсупова, 2014: 42], – дип билгеләп үтәләр Н.М. Юсупова һәм Г.Р. Гайнуллиналар.

Шулай да берникадәр вакыт алар өчен гел бозыклык какорылган рәхәт тормыш яшьләрнең изге хисләрен бөтенләй җиңә алмый. Алар бер-берсенә тартылалар. Әмма шайтани тормыш бик көчле, ул ахыр чиктә ике яшьне шайтан куентыгында яр убылып төшеп, батып үлүләре белән тәмамланганфаҗигагә илтә.

Шулай итеп, Шайтан куентыгы – кешеләрне үз чоңгылына тарта торган тормышның ямьсез якларын символлаштыра. Бу – хәзерге заманның чиренә әверелгән эчкечелек, эти-әниләрнең барлыгын оныту, байлыкка омтылу, алай гына да түгел, яшәүнең мәгънәсен шушы кыйммәтләр белән бутап ялгышу. Елгадагы Шайтан куентыгы – тормышның кешеләрне үзенә тарта торган ямьсез яклары буларак кабул ителә. «Гомумән, соңгы елларда шартлылыкка, символик образ-сурәтләргә, метафорик күренешләргә игътибар аеруча артты. Драматурглар ялгызлыкка дучар ителгән, якыннары белән уртак тел таба алмаган, яшәешкә үтеп кергән миһербансызлыклардан гаҗиз шәхесләрне әдәбият мәйданына чыгаралар» [Миңнуллина, 2018: 30-32], – дип яза Ф. Миңнуллина «Татар әдәбиятында трагедия жанры» дип аталган язмасында.

Драматург әйтергә теләгән фикерне укучыга җиткерүдә, геройларының рухи халәтен ачуда алтын балык символы образызур урынны алып тора. Алтынбалыкныңтөп үзенчәлеге – ул барлык теләкләрне дә тормышка ашыра. Әсәрдә алтын балык барлык теләкләрне дә тормышка ашыручы булудан бигрәк, өмет-хыяллар, якты киләчәк символы буларак кабул ителә. Пьеса барышында Фәнзилә өчен алтын балык элеккеге мәгънәсен югалта. Аны

тормыштагы башка төрле кыйммәтләр борчый, «шайтан куентыгы» – серле, ялтыравыклы тормыш-каршылыклары үзенә тартып ала. Әсәр ахырында автор тарафыннан әсәр башындагы эпизод кабатлана. Автор бу пычраклыклардан чыгу юлын үлемдә күрә, чөнки, ул ике яшьне дөреслек, яктылык, аклык, хыяллар юлына алып чыга, Фәнзилә белән Разим дә – балачактагы кебек саф, чиста күңелле.

Әсәрдәге елга образы да символ дәрәҗәсенә күтәрелгән, ул тормыш мәгънәсендә килә. Драматург әйтергә теләгән фикерне укучыга җиткерүдә, геройларының рухи халәтен ачуда елга символы зур урынны алып тора.

Бу әсәрдә бирелгән җыр белән дә раслана:

«Гомерләрне тоташтырып елдан елга,

Туктамыйча, офыклардан офыкларга,

Ирексездән бәргәләнеп ярдан ярга

Мәңгелектән Мәңгелеккә ага елга»[Хәким, 2000: 308].

Елга кеше таләбенә буйсынмый торган, тере организм кебек үз мәнфәгатьләре белән яшәүче җан итеп күз алдына килә. Тели икән муллык, шатлык бирә, тели икән, кеше гомеренә көтелмәгән үзгәрешләр алып килә. Елгада Шайтан куентыгы һәм шайтаннар яши, димәк, кешене төрле сынаулар һәм каршылыклар көтә. Әгәр дә берәүләр, әлеге каршылыкларны җиңеп, теләгән бәхетләренә ирешсәләр, икенчеләре өчен яшәү, тормыш шатлыгы, бәхет хыял булып кына кала яисә аларның гомерләре фаҗига белән тәмамлана. Әсәр ахырында Рәзим һәм Фәнзиләнең елга буенда уйнап йөргән балачак күренешләре укучыны автор белән диалогка чакыра сыман. Кеше туа, үсә, зур өметләр, якты хыяллар белән яши һәм бәхеткә ирешү теләге белән яна. Киләчәк һәркемнең үз кулында кебек тоела. Автор укучысын бары үзләренең рухи азатлыгын һәм бәйсез фикерләрен яклый алган, яшьлек хыялларына тугры калган, фаҗигагә илтүче шайтан куентыкларыннан, тирән чоңгыллардан сакланган көчле шәхесләр генә тормыш елгасында үзенең «алтын балыгын» тотарга сәләтле дигән фикергә китерә.

Шулай итеп, Зөлфәт Хәкимнең «Шайтан куентыгы» трагедиясе, мифологик образ, символларга мөрәҗәгать итү аша укучыга мәхәббәт темасын гаять үзенчәлекле, традицион булмаган рәвештә на тапшыра, заманга хас проблемаларны яктыртуга ирешә.

## ӘДӘБИЯТ

Әхмәдуллин А. Бүгенге татар драматургиясен өйрәнү һәм укытуның кайбер мәсьәләләре// Г.Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Яр Чаллы, 2006. Б.22-25

Миңнуллин Ф. Татар әдәбиятында трагедия жанры // Фәнни Татарстан. – 2018. – №2. – 30–34 б.

Мифы народов мира: В 2-х т. / А.С. Токарев. М.: Советская энциклопедия, 1988. Т. 2. 625 с.

Саттарова А. Современная татарская драматургия (1985-2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. 152 с.

Хәким З. Мин төш күрдем...: пьесалар. Казан: Тат. кит. нәшр., 2000. 367 б.

Юсупова Н.М Современная татарская литература. Конспект лекций / Н.М.Юсупова, Г.Р. Гайнуллина. Казань, 2014. Б.43–50.

**И.Ф. ҺАДИЕВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

# З.ХӘКИМНЕҢ «ТЕЛСЕЗ КҮКЕ» ДРАМАСЫНДА МИЛЛӘТЛӘР ЯЗМЫШЫ ПРОБЛЕМАСЫ

**Аннотация.** В данной статье анализируется драма известного татарского драматурга современности Зульфата Хакима «Немая кукушка», в которой раскрывается проблема национального самоопределения.

**Abstract.** This article analyzes the drama of the famous tatar playwright of our time Zulfat Hakim «The mute cuckoo», which reveals the problem of national self-determination.

**Ключевые слова:** Драма, Зульфат Хаким, проблема, эпиграф.

**Keywords:** drama, Zulfat Hakim, problem, epigraph.

З. Хәким 1980 еллар ахыры – 90 еллар башында татар драматургиясенә килә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар драматургиясен һәм театр сәнгатен үзенең күпсанлы пьесалары белән баеткан, аның үсеш-үзгәрешенә гаять зур йогынты ясаган, нигездә, әйдәп баручы драматург булып танылган әдипләребезнең берсе ул. Хәзерге драматургиянең үзәгендә торган проблема кеше һәм яңа җәмгыять мөнәсәбәте белән бәйле. Ул исә милли төсмерләр белән кушылып, яшәү мәгънәсе, шәхеснең үз-үзен табуы, милләт язмышы кебек гаять җитди мәсьәләләрне үз эченә ала. Әдип иҗатының заманчалыгы – чорның социаль-иҗтимагый сорауларын чагылдыруы һәм чишүе белән аңлатыла. Әлеге мәкаләбездә драматургның “Телсез Күке” әсәрендә күтәрелгән милләтләр язмышы проблемасына тукталып үтәрбез.

З.Хәким тарафыннан сайлап алынган эпиграфлар әсәрдә күтәрелгән проблемаларга, темаларга, сурәтләнгән язмышларга турыдан-туры бәйләнешле. Барыннан да бигрәк алар милли үзаң, милләт язмышы мәсьәләсе һәм геройлар язмышы белән бәйлелектә каралырга тиеш. Эпиграфларда үлем, әҗәл, кан кебек сүзләр еш кабатлана. Чынлап та, әсәрнең үзәгендә – канкойгыч сугышлар, штрафбатальоннары кичкән гаепсез кешеләр әрнүе, лагерь һәм төрмәләр, күз

яшьләре. Икенче яктан, эпиграфларда милләт, мәдәният, каләм кебек сүзләр дә урын ала, эпиграфларның яртысы үзләре халык мәдәниятенең бер өлеше – фольклор жанрларына карыйлар. Болар – әсәрдә шулай ук игътибар үзәгендә торган, даими кабатланып, лейтмотив дәрәҗәсенә ирешкән татар җыры, татар моңы һәм аңа нисбәтле ачылучы милли үзаң сыйфатларына ишарә. Вакыйгалар барышында үлем һәм күз яше алып килүче якның Россиянең (Советлар Союзының) империячел сәясәте, илдә хөкем сөргән тоталитаризм булуы ачыклана. Ул Зимин-Зиновьевлар кебек явыз, астыртын, ярымшизофреник кешеләр – НКВД вәкилләре, Севрюгин кебек үзенең милләтен генә өстен күрүче, әләкчеләр хисабына чәчәк ата. Аларга каршы рәвештә әсәрдә Чулман буе татары Зариф, Финляндия татары Зыятдин һәм аларның балалары, оныклары сурәтләнә. Шул рәвешле әсәрдә, Ә.Закирҗанов хаклы рәвештә язганча, Зариф белән Зимин каршылыгы һич тә ике кеше каршылыгы гына түгел, бәлки империячел караш белән милли рух бәрелеше, Зарифның тормыштагы гаделсезлекләргә каршы чыгуы, үз шәхесен һәм милләтен яклавы һәм саклавы. Ә инде соңгысының гаять мәгънәле чагылышы булып Җыр-моң тора" дигән фикер үткәрелә. [Закирҗанов, 2010: 19]. Югарыда язылганнардан әсәрнең төп проблемасы булып милли мәсьәлә торуы турында нәтиҗә ясарга мөмкин. Милли проблема – галимнәр тарафыннан аерып чыгарыла торган проблема төрләренең (мифологик, милли, социаль-мәдәни, романик) берсе ул. Драмада, әсәрне автор биргән жанр белән атаганда, театраль романда татар милләте язмышы проблемасы төрле аспектларда яктыртыла. Беренчедән, драматург татар уллары-кызларының бөтен дөнья булып чәчелгәнлегенең аяныч нигезен күрсәтә һәм аны барыннан да элек ил хакимлегенең сәясәте белән бәйле булуына да ишарә итә: "*Төрле сәбәпләр аркасында таралды безнең халык дөнья буйлап. Исән калыр өчен китүчеләр дә булгандыр, яхшырак тормыш эзләүчесе дә булгандыр, үзен кеше итеп хиситәр өчен китүчесе дә булгандыр. Халык язмышы халык язмышы инде ул. Аны без синең белән җырда гына җырлый алабыз. Ә сезнең илдә татар михнәтне күп күрде инде ул. Әле алда күрәселәр күпмедер*!" [Хәким, 2007: 91].

Финляндия татары исеменнән әйттерелгән әлеге сүзләрдә ачы хакыйкать ята һәм аны хәзерге галимнәр дә раслыйлар: "колониаль изү, сәяси һәм матди кысынкылык, бер-бер артлы булып торган инкыйлаблар, сугышлар, шәхес культы татарны тагын да таратты, илнең һәм җиһанның төрле почмакларына сипте," – дип яза Х.Миңнегулов XX йөзнең беренче яртысы һәм урталары турында. [Миңнегулов, 2007: 4]

Зөлфәт Хәким мөрәҗәгать иткән тагын бер проблемаларның берсе – илдә вак милләтләргә һәм халыкларга ихтирамсыз мөнәсәбәт. Билгеле булганча, шәхес культы елларында Сталин боерыгы буенча Балтыйк буе халыкларын, Кырым татарларын, Кавказдагы чеченнарны, Идел буе немецларын, калмыкларны туган җирләреннән аерып, Ерак Себергә, Казахстанга сөрәләр. Совет хөкүмәте алып бара торган барлык бөек төзелешләрдә менә шушы төрмәләрдә һәм сөргеннәрдә утыручы әсирләрнең кул көче кулланыла. Әлеге проблема чечен егете Рассуханов язмышы аша калку гәүдәләндерелгән. Ватан язмышы өчен ихлас көрәшкән, шушы көрәштә аягын югалткан әлеге егетнең язмышы аянычлы тәмамлана, иң элек аны, башка чеченнарны кебек үк кырык дүртенче елда әллә Казахстан ягына, әллә ераграк җирләргә сөрәләр, алтмышынчы елларда, ягъни сөргенлектә дистә ярым елдан артык гомерен үткәргәннән соң, ул гаиләсе белән туган якларына әйләнеп кайта, соңгы елларын уртанчы улы белән Грозный шәһәрендә үткәрә, әмма 1995 нче елны федераль авиация Грозныйны бомбага тотканда һәлак була, аның өч улы, тауларда качып, Россиягә каршы сугышалар.

Империячел рус хакимиятенең башка милләтләргә түбәнсетеп, хәтта нәфрәтләнеп каравы Севрюгин дигән персонаж аркылы гәүдәләндерелә. Астыртын, мәкерле, намуссыз әлеге герой тискәре мөнәсәбәтен яшереп торуны кирәк дип тә тапмый, аның кайбер репликаларына игътибар итеп үтик:

1) Зарифның сөйгәненең Кәшифә исемле икәнен белгәч әйткән сүзләре:

“*Севрюгин (мыскыллы елмаю белән): Ну и имена у вас. Язык можно сломать*”.

2) Яхно Севрюгинның татарларны яратмавын ачыктан-ачык белдергәч:

“*Севрюгин (ямьсез иттереп авызын кыйшайтып):*

*А вообще-то их есть за что не любить. Триста лет монголо-татарское иго было*”.

3) Рассуханов Севрюгинның үзенә карата шикләнеп каравы турында белдергәч, мондый диалог оеша:

“*Севрюгин (тавышын күтәреп): Да, угадал!*

*Рассуханов (шулай ук тавышын бераз күтәреп):*

*За то, что намаз читаю?*

*Севрюгин: (нәфрәтле тавыш белән):*

*Нет! За то, что совсем еще недавно всем народом мятеж поднимали*”.

Шунысы да игътибарны җәлеп итә: Севрюгинның сүзләре, гамәлләреннән анда милли үзаң үскән, хәтта артыгы белән үскән, дип уйларга җирлек бирә. Психологлар этникара мөнәсәбәтләрнең дискриминацион формаларының

мондый билгеләрен атыйлар: башка этник, милләт төркемнәргә реакция буларак аларга карата ярсучанлык барлыкка килү, башка милләтләрнең хокуклары киметеп күрсәтү сәясәте, аларга карата агрессия.

Геройларның әхлакый йөзен билгеләгәндә, З. Хәким милли үзенчәлекләрдән чыгып, рус чыгышлы персонажны – тискәре, чечен, татар һ.б. милләт вәкилләрен – уңай буларак кына сурәтләми. Автор геройларының әхлакый йөзенә дә игътибарлы. Севрюгин – рус булганы өчен тискәре герой түгел, яла ягарга сәләтле, үчле, башка милләтләргә карата түземсез булганы өчен тискәре герой. Одесса чыгышлы Шаталов кешелекле, сабыр булуы белән җәлеп итә, Ленинградтан килгән Лебедев гадел, кыю, үзенә зыян тиюе мөмкин булса да, Зарифны яклап чыгуы белән күңелне җәлеп итә.

Аңлашылганча, рус милләтеннән булган әлеге ике каһарман да уңай персонажлар исемлегендә каралырга хаклы, әмма аларның язмышлары катлаулы була: беренчесе – сугышта пуля тиеп һәлак була, икенчесен лагерьләр юлын үтәргә мәҗбүр итәләр.

Шулай итеп, З. Хәкимнең “Телсез күке” драмасы милләт язмышы белән бәйле проблемаларны укучы-тамашачы алдына куеп, гыйбрәтле чишү, хәл итү юлын тасвирлый. Татарның милләт язмышына һәм киләчәгенә битараф булмаган катламы телне, моңны, милли үзаңны саклап калу проблемасы өчен борчылып яши, чөнки моның өчен, чынлап та, тарихи һәм сәяси җирлек бар, һәм Зөлфәт Хәким әлеге җирлекне укучы алдына тагын бер кат китереп бастыра һәм киләчәгебез өчен уяу булырга чакыра.

### ӘДӘБИЯТ


Закирҗанов Ә.М. Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре: уку-укыту әсбабы. Казан: Казан ун-ы нәшр., 2010. Б. 18–19.

Миңнегулов Х. Чит илләрдәге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 4.

Хәким З. Телсез күке: пьесалар. Казан: Тат. кит. нәшр., 2007. Б. 6.; Б. 91



**Л.Б. ХӘМИДУЛЛИНА, Д.Х. ХӨСНЕТДИНОВ**

*Казан федераль университеты, Россия*


## СҮЗ ТӨРКЕМЕ БУЛАРАК БӘЙЛЕК


**Аннотация.** Морфологические группы слов в татарском языке изучаются учеными достаточно полно, исходя из их роли в организации речи, прежде всего, различаются по двум основным разделам: самостоятельной и вспомогательной, которые делятся на группы, называемые модальными, выражающими отношение говорящего к действительности, и связывающие слова и предложения с самостоятельными значениями в речи. Послелоги – это единицы, относящиеся к соединительной группе слов.

**Abstract.** Morphological groups of words in the Tatar language are studied by scientists quite fully, based on their role in the organization of speech, first of all, they differ in two main sections: independent and auxiliary, which are divided into groups called modal, expressing the attitude of the speaker to reality, and linking words and sentences with independent meanings in speech. Postpositions are units belonging to a connective group of words.

**Ключевые слова:** послелог, семантик, грамматик, падеж.

**Keywords:** postposition, semantics, grammars, case

Бәйлекләр – ярдәмлек категориясенә керә торган лексик берәмлекләр, аларның төп вазифасы – мөстәкыйль сүзләр арасында төрле-төрле мәгънә мөнәсәбәтен белдерү, аларны бер-берсенә бәйләү. Шуңа күрә бәйлек термины астында тел гыйлемендә “бер сүзне икенче сүзгә бәйләү өчен, нинди дә булса бер сүзгә ияреп килә торган ярдәмлек сүз”ләрне күзаллыйлар [Сәлимов, 2005: 23].

*Семантик* яктан бәйлекләр *грамматик* мәгънә белдереп киләләр, ягъни алар телдә сүзләр арасындагы бергәлек, корал, чагыштыру, сәбәп, максат, вакыт, урын һәм башка *мөнәсәбәтләрне* оештыруда катнашалар: *укытучы белән* (сөйләшү), *каләм белән* (язу), *таң кебек* (якты), *тау чаклы* (зур), *әни өчен* (әзерләдек), *төштән соң* (китте), *күпер аркылы* (чыкты) һ.б.лар.

Сүзләр арасындагы төрле-төрле мөнәсәбәтләрне белдерүләре ягыннан бәйлекләр килешләргә якын торалар, һәм асылда алар килеш формалары биреп бетермәгән грамматик мәгънәләрне белдерәлә. Мәсәлән, рус телендәге творительный падеж белдергән корал мәгънәсе татар телендәге *белән* бәйлеге белән бирелә: пишет пером – каләм белән яза; рубит топором – балта белән чаба һ.б.лар. Бәйлекләр шулай ук килеш мәгънәләрен ачыклап, төгәлләндереп тә киләләр: урманга *чаклы*, төштән *соң* һ.б.лар. Әйтелгәннәргә нигезләнеп, бәйлекләрне аналитик килешләр буларак карарга тәкъдим итү очраклары да бар, әмма килешләрдән аермалы буларак, бәйлекләр – аерым, тулы хокуклы ярдәмлек сүз төркеме, чөнки аларның даими аваз составы бар; бәйлекләр, кушымчалардан аермалы буларак, сингармонизмга, тартыклар ассимиляциясенә бирешмиләр; алар бер сүз төркеменә генә беркетелмәгән, күп төрле сүзләр белән килә алалар.

Бәйлекләр, шулай ук бәйлек сүзләр, мөстәкыйль лексик берәмлекләрнең формасын тәшкил итеп, ияртүче сүзнең составында торалар. Мисалга мөрәҗәгать итеп, әлеге фикерне тикшерик:

*Атаң белән сөйләштек әле* [Миңнуллин, 2002: 13].

Биредә үз эченә бәйлек сүз төркеменә караган сүзне дә алган сүзтезмәне аерып карарга мөмкин: *атаң белән сөйләштек*. Бу сүзтемәдә ияртүче сүз

*сөйләштек*, аннан чыгып, иярүче сүзгә сорау куерга мөмкин: кем белән? Җавап: *атаң белән*. Моннан күренә: бәйлек иярүче сүз составына кергән.

Бәйлекләрнең шул рәвешле үзләреннән алда килгән сүз төркеме белән тыгыз бәйләнештә торулары аларның синтетик чара икәнлеген дә күрсәтеп тора. С.М.Ибраһимов язуынча, “бәйлекләрнең барлыкка килүе дә аларның синтетик характерга ия булулары турында сөйли: мөстәкыйльлекләрен югалтып, алар тора-бара, ярдәмлеккә әйләнеп китәләр” [Ибраһимов, 2002: 352].

Иярченле кушма җөмләдә алар иярүче компонентны баш җөмләгә бәйләүдә катнашалар, шуңа күрә синтетик төрне формалаштыруга булышалар, бу яклары белән алар кушымча һәм фигыль формасына туры киләләр.

Кайбер очракларда бәйлекләр башкарган вазифаны кайбер мөстәкыйль сүзләр дә, әйтик, *ас, өс, ян, як, урта, төп, түр, тыш, эч, ара* һ.б. үти ала. Бәйлек сүзләрнең, аларны бәйлекләрдән аерып торучы мөһим үзенчәлеге бар. Бер очракта алар, бәйлекләр кебек үк, мөстәкыйль сүзләрне үзара бәйләүдә катанашсалар, икенче очракта, лексик мәгънәгә ия булып, мөстәкыйль сүз функциясен башкаралар. Мисалларга мөрәҗәгать итик:

1) “Безнең авыл моннан җиде-сигез чакрымда. Олы су *башында*” [Гыйләҗев, 2002: 353].

2) *Өстә* берәү шаркылдый бит. Калкынып карасам – җайдак, Рәхимҗан! [Гыйләҗев, 2002: 353].

Китерелгән беренче җөмләдә *башында* бәйлек сүзе *су* дигән мөстәкыйль сүз янында килә һәм аның белән бер җөмлә кисәген – урын хәлен (авыл кайда? – су башында) тәшкил итә. Икенче җөмләдә исә ассызыкланган сүз шулай ук урын хәле булып килә (кайда шаркылдый? – өстә), ләкин ул мөстәкыйль сүз рәвешен алган.

Мәктәп грамматикасында бәйлек алдыннан килә торган сүзнең нинди килештә булуына карап, аларны өч төркемчәгә аеру гамәлгә кергән. Баш килешне таләп итүче бәйлекләр исәбенә *белән, өчен, кебек, шикелле, төсле, кадәр, чаклы, хәтле, тикле* һ.б.лар керә. Болар алдыннан килгән сүз баш килеш формасында була:

«Сәет, асфальтка төшкән карбыз *кебек*, шартлап ярылды» [Галиуллин, 1998: 124].

«Хастаханәнең алан *хәтле* палатасыннан Сакманов Әхмәдиша картларга, “төп йортларына” төшәргә булды» [Галиуллин, 1988: 147].

Күренгәнчә, әлеге җөмләләрдә бәйлек алдыннан килгән *карбыз, алан* сүзләре баш килеш формасын алганнар.

Юнәлеш килешен таләп итүче бәйлекләр арасында *таба, күрә, каршы, кадәр, чаклы, хәтле, тикле* һ.б. булырга мөмкин:

«Энәсеннән алып җебенә *кадәр* җентекли-җентекли сораша» [Миңнуллин, 2002: 10].

Әлеге җөмләдә бәйлек алдыннан килгән сүз юнәлеш килеше кушымчасын алганлыгы күренеп тора.

Чыгыш килешен *башка, соң, бирле, элек* бәйлекләре таләп итәләр:

"Әмма ректор күрсәтмәсе буенча, бүген төштән *соң* унсигезенче группаны комсомол җыелышына җыйдылар" [Мәхмүди, 2003: 17].

Күренгәнчә, бәйлек алдыннан килгән сүзләр чыгыш килеше кушымчасын алганнар.

Үзләренең составлары ягыннан бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр ике зур төркемне тәшкил итә:

1. Гади төрләр.
2. Берничә сүзне үз эченә алган төрләр.

Беренчеләре – менә болар: белән, кебек, шикелле, чаклы, хәтле, аркылы, өчен, соң, карамстан, турында, хакында, таба, максаттан һ.б.лар.

Икенче төрне тәшкил итүчеләр: мөнәсәбәте белән, уңае белән, аермалы буларак, өчен дип һ.б.

Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр генетик яктан берничә төркемгә бүленәләр:

1. Фигыль сүз төркеменә бәйле төрләр: кала (Синнән кала беркем кирәкми), дигәндә (Китәбез дигәндә кар ява башлады).

2. Исем сүз төркеменә бәйле төрләр гаять күп: төсле (Синең төсле елмая), як (түбә янына барма).

3. Рәвеш сүз төркеме белән бәйле төрләр: соң (еллар узганнан соң ачыкланыр), каршында (синең каршыңда гаебем юк).

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: бәйлек һәм бәйлек сүзләр татар тел гыйлемендә шактый тулы дәрәҗәдә өйрәнелгән бәйләгеч сүз төркеме булып тора. Аларның, нинди сүз төркеменнән ясалуы, ияреп килгән сүзенең нинди грамматик формада булуына карап берничә классификациясе дә булдырылган.

**ӘДӘБИЯТ**


Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Тат. кит. нәшр., 2002. 5т.: пьесалар / төз. Н. Гыйләҗева. 447 б.

Галиуллин Т. Элмәк. Казан: Тат. кит. нәшр., 1998. 239 б.

Ибраһимов С.М. Бәйлек һәм бәйлек сүзләр // Татар грамматикасы: өч томда. Казан: Фикер, 2002. 2 т. Морфология. Б. 352 – 358.

Миңнуллин Т. Әсәрләр. Ун томда. 5 нче т.Казан: Тат. кит. нәшр., 2002. 399 б.

Мәхмүди З. Әче балан: кыйссалар, хикәяләр, фәлсәфи уйланулар. Казан: Тат. кит. нәшр., 2003. 206 б.

Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. Казан: Тат. кит. нәшр., 2005. 144 б.

**А. А. ХӘМИДУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФОНЕТИКАСЫН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫНА КҮЗӘТҮ

**Аннотация.** В данной статье рассмотрена история изучения фонетики татарского языка в разных аспектах. Рассмотрены и проанализированы труды ученых-тюркологов.Статья будет полезна и интересна студентам, магистрантам тем, что в тексте представлены все труды ученых-тюркологов, изучавших фонетическую систему татарского языка.

**Abstract.** This article describes the history of studying the phonetics of the Tatar language in different aspects. The works of scientists-turkologists are considered and analyzed.the article will be useful and interesting for students, undergraduates because all the works of scientists-turkologists who studied the phonetic system of the Tatar language are presented in one text.

**Ключевые слова.** Фонетика, аваз, грамматика.

**Keywords.** Phonetics, sound, grammar.

Татар фонетикасы буенча иң беренче фәнни мәгълүматлар К.Насыйриның «Кыскача татар нәхүе», «Татарча вә урысча үгрәнүчеләргә файдасы гам булсын өчен» (1860) китабында күренәләр. Бу китапта татар хәрефләрен (ул да әлегә “аваз” терминын кулланмый) сузыкларга һәм тартыкларга аера. Авазларны сыйфатлап тормыйча, ул сөйләм телендәге кайбер кайбер аваз үзгәрешләрен билгеләп үтә. Аның бу китабында, беренчеләрдән булып, басым хакында да мәгълүмат бирелә. Тамыр сүзләрдә ике иҗекле һәм күп иҗекле сүзләрдә басымның һәрвакыт кушымчага (ягъни сүз ахырында) төшмәвенә дә игътибар итә.

В. В. Радловның «Төньяк төрки телләр фонетикасы» (1883) төрки аваз төзелешен чагыштырып өйрәнү өлкәсендә зур әһәмияткә ия була. Галим, әдәби тел кысалары белән генә чикләнмичә, диалектлардагы авазларны да катыштырганлыктан ахырда күрсәтелгән [а], [ә] сузыкларын, алар вариант кына булсалар да мөстәкыйль фонема дип таный булса кирәк. Шул ук вакытта телдәге [ы] фонемасының алынмавы күренә. Тартык авазларга килгәндә ул татар телендә 23 тартыкны санап чыга. Ләкин [н] борын тартыгын искә алмый, ә [л] ның ике вариантын мөстәкыйль аваз буларак күрсәтә.

Җ. Вәлиди исә үзенең «Татар теленең грамматикасы» (1919) исемле хезмәтендә татар телендә барысы 53 аваз, шуның 10 сы сузык, 43 е тартык аваз

булуын яза. Хәреф белән авазны бутамаска куша. Хәрефләр фонетика таләпләрен үтәүдән ерак торалар, ди. Әлеге хезмәт бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмый, моңа мисал булып хезмәтнең 2007 дә янәдән басылып чыгыу тора.

Моңарчы чыккан грамматика китаплары беренче нәүбәттә дәрес китаплары буларак дөнья күргәннәр, аларда теге яки бу мәсьәләне фәнни тикшерү максат итеп куелмаган да. Г. Алпаровның "Шәкли нигездә татар грамматикасы" (1926) исемле хезмәте татар авазларын чын фәнни нигездә тасвирлап бирүче хезмәт булып тора.

Татар теле фонетикасына зур әһәмият биргән галим – профессор В.А.Богородицкий. Аның «Татар тел белеменә кереш» (1953) исемле хезмәтендә татар теленең вокализмы (сузык авазлары) һәм консонантизмы (тартык авазлар) мәсьәләләре карала. Шул ук хезмәтнең 32 нче битендә татар теленең фонетикасы эксперементаль яктан чыгып тикшерелә.

Профессор В.А.Богородицкий татар телендәге һәм башка төрек телләрендәге сузыкларга чагыштырма характеристика бирә, ул сузыклар өлкәсендә татар теленең башка телләрдән аерылып торганын билгели. Тартыклар бүлегендә автор башка төрки телләрендәге һәм татар телендәге тартыкларны чагыштыра.

Р.Ф.Шакированың «Хәзерге татар теле фонетикасына кереш» (1954) исемле китабы татар теленең авазларын тасвирлаучы беренче монографик хезмәт булып тора. Биредә авазлар беренче тапкыр фонологик яктан карала башлый, шулай ук татар әдәби теленең фонетик төзелешен өйрәнүгә нигезләнгән. Р.Ф.Шакирова татар телендә фонемалар системасының барлыгы 40 фонема булганлыгын исбатлый. Шуларның 28 е тартык, 12 се сузык фонема. Чыгышлары ягыннан 35 фонема татар теленең үз фонемалары, 5 фонема рус теленнән алынган фонемалар дип йөртә. Рус теленнән кергән фонемаларның өчесе ([ц], [в], [щ]) тартык фонемаларга, икесе (киң әйтелешле [о] һәм [э]) сузык фонемаларга кертелә.

Ф. М. Хисамованың татар филологиясе бүлеге студентлары өчен язган "Хәзерге татар теле фонетикасы" (1987) исемле методик күрсәтмәсендә иң беренче эш итеп сөйләм авазларының өч аспектта өйрәнелүе турында яза.

Г. Алпаров, Ф. Г. Исхаков үзләренең хезмәтләрендә тартык фонемаларның санын 46 дип күрсәтәләр. Бу очракта тартык фонемаларның калын һәм нечкә вариантта килүләре исәпкә алалар. Ә Ф. М. Хисамова үзенең хезмәтендә 28 фонема тартыкны күрсәтә. Ул татар телендә кайбер башка телләрдән аермалы буларак, тартыклар калынлык-нечкәлек буенча фонологик яктан каршы ку-

елмыйлар, ягъни тартыкларның калынлыгы-нечкәлеге фонематик роль уйнамый, ул тулысынча сузыкларга бәйле була. Соңыннан һәрбер тартык фонемага характеристика биреп чыга.

Г.М. Сөнгатовның татар диалектлары фонетикасын өйрәнүгә караган хезмәтендә татар теле диалектларында авазлар системасы, фонетик законча-лыкларның үзенчәлекләрен өйрәнә. Аңа кадәр Г.Ф.Саттаров, Ф.Ю.Юсупов һ.б. хезмәтләрендә диалекталь фонетикага игътибар ителгән булса да, Г.М.Сөнгатовның әлеге зур булмаган хезмәте бу юнәлештә эзлекле башка-рылган, нигезле фактларга таянган булуы белән хөрмәткә лаек.

Г.М.Сөнгатов диалектология өлкәсендә дә хезмәт куючы буларак, диалекталь сөйләм үзенчәлекләренең нечкәлекләренә игътибар биргән. Хезмәттә транскрипция тәкъдим ителә. Алга таба һәм сузык һәм тартык авазларның татар сөйләшләрендә кулланылган вариантларына күзәтү ясалган. Авазларга ясалу ысулы һәм урынына карап, фәнни әдәбиятта кабул ителгәнчә характеристика бирелгә.

Ф. Хәкимҗан “Татар әдәби теле: Фонетика” (2001) хезмәтендә иң беренче фонетиканың тел тармаклары һәм башка фәннәр белән бәйләнеше, фонетика-ның төрләре турында яза. Р. Ф. Шакированың фонема турында әйткән мәгълүматларны тирәнәйтеп Ф. С. Хәкимҗанов фонема турында үзенең өстәмәләрендә кертә, транскрипция һәм транслитерация турында мәгълүмат бирә.

Ф. С. Хәкимҗановның әлеге хезмәте бүгенге көндә югары уку йортлары студентлары өчен дәреслектә буларак кулланыла.

Татар фонетикасына багышланган соңгы хезмәтләрдән С.С.Сәлимовның тикшеренүләрен атарга була. Автор беренче мәртәбә спектраль анализ методын кулланып, татар вокализмын тикшерә, алынган мәгълүматларга таянып, татар сузыкларын акустик яктан тасвирлый, аларны рус һәм кайбер төрки телләрнең авазлары белән чагыштыра, комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләренең төрләрен ачыклый. Шул ук автор тарафыннан татар теленең беренче орфогра-фик сүзлеге төзелә, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен фонетика буенча кулланмалар языла. Әлеге авторның хезмәтләре объектив методка таянып баш-карылганга, алар икенче бүлектә карала.

Татар фонетикасына күпмедер өлеш керткән чит ил лингвистларыннан Н.Поппенны атарга була. Ул үзенең инглиз телендә басылган китабында татар теленең фонетик ситемасын инглиз, швед, норвег, гарәп телләре белән чагы-штыра.

Татар фонетикасың кайбер аерым мәсьәләләре төрле хезмәтләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, татар һәм рус телләренең фонетик системаларын чагыштыру, В.А.Богородицкийдан ук башланып, Р.С.Газизов, З.М.Вәлиуллина, Ф.С.Фасеев, Ә.М.Ахунҗановларның хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Д. Х.Бакеева хезмәтләрендә татар телләренең фонетик системалары чагыштырыла. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча Л. Җәләй башлаган тикшеренүләрне Л.И.Яфаров, В.Х.Хаковлар дәвам итә. Диалекталь фонетика буенча бик кызыклы күзәтүләр Л. Җәләй, Л. Т. Мәхмүтова, Д.Г.Тумашева, Ф.Й.Йосыпов, Г.Ф.Саттаровлар тарафыннан ясала. Татар теленең графикасы, орфографиясе, орфоэпиясе мәсьәләре Л.Җәләй, Х.Курбатов, Б.М.Мифтахов хезмәтләрендә яктыртыла.

### ӘДӘБИЯТ


Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Изд 2-е. Казан: Татгосиздат, 1953. 219 с

Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 108 б.

Сәлимов Х. Х. Татар теле фонетикасы / Х. Х. Сәлимов. Чаллы: Камаз нәшр., 1993. 31 б.

Сөнгатов Г.М. Татар диалектлары фонетикасы. Казан, КГУ, 2000. 44 б.

Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы. Казан: Казан ун-ты. нәшр., 1993. 325 б.



**Ф.Ф. ХАРИСОВ**

*Казан федераль университеты, Россия*


## ПОЛИЛИНГВАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ШАРТЛАРЫНДА УКЫТУЧЫНЫҢ ҺӨНӘРИ ҮСЕШЕ: ЛИНГВОДИДАКТИК АСПЕКТ


**Аннотация.** Статья посвящена исследованию проблемы профессионального развития учителя татарского языка и литературы в условиях полилингвального образования в Республике Татарстан. Особый акцент делается на вопросах самообразования и саморазвития, в том числе через курсы повышения квалификации учителей.

**Abstract.** The article is devoted to the study of the problem of professional development of teachers of the Tatar language and literature in the conditions of multilingual education in the Republic of Tatarstan. Special attention is paid to the issues of self-education and self-development including through teacher training courses.



**Ключевые слова:** профессиональное развитие учителя татарского языка и литературы, полилингвальное образование, самообразование и саморазвитие.

**Keywords:** professional development of Tatar language and literature teacher, multilingual education, self-education and self-development.

Хәзер Татарстанда полилингваль белем бирү мәктәпләре ачыла башлады. Мондый белем бирү оешмаларында укыту эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә, укучыларның белемле һәм тәрбияле булу дәрәҗәсенә педагогның шәхси, һөнәри осталыгы зур йогынты ясый. Димәк, укытучының көндәлек эше заман таләпләренә җавап бирү белән бергә, ул үзенең укучысын яратырга һәм аны югары дәрәҗәдә аңлый белергә дә тиеш була. В. О. Ключевский хаклы рәвештә: «Яхшы укытучыга үзе укыткан фәнне дә, укучыларны да яратырга кирәк», – дигән. Луций Анней Сенеканың «Башкаларны өйрәтеп, үзебез дә өйрәнәбез», – дигән фикерен дә истән чыгармаска иде, чөнки башкаларны өйрәтү өчен, укытучыдан бик күп белем таләп ителә. Шуңа күрә дә тырышлык, намуслылык, таләпчәнлек, күзәтүчәнлек, аралашучанлык, тиешле дәрәҗәдә үз-үзеңне тота белү, көтелмәгән хәлләрдә югалып калмау, камиллеккә омтылу, гуманлылык, инициативалылык, әдәплелек, саф күңеллелек, эчкерсезлек, үзлегеңнән укып, белемеңне арттыруга омтылу – хәзерге татар теле һәм әдәбияты укытучысының аерылгысыз сыйфатлары булып санала. Болар барысы да аның кабатланмас һәм үзенчәлекле шәхес булуы турында сөйли.

Педагогик эшчәнлекнең уңышы күп очракта даими рәвештә акыл эшчәнлегенә тартыла алуга, мөстәкыйль белем алуга һәм үз-үзеңне тәрбияли белүгә, хезмәтеңне төпле итеп оештыруга, кирәкле вакытта психологик киеренкелекне бетерә һәм хис-кичерешләр белән идарә итә алу осталыгына, авырлыкларны җиңә белүгә бәйле. Әлбәттә, бу сыйфатлар бары тик озак вакыт үз өстеңдә эшләү нәтиҗәсендә формалашырга мөмкин.

Үз-үзеңне тәрбияләү, үзлектән белем алу – кешенең шәхес буларак үсүгә юнәлтелгән аңлы-гамәли эшчәнлеге. Алар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә яши. Үз-үзеңне тәрбияләү һәм үзлектән белем алу нәтиҗәсе – шәхеснең уңай якка үзгәрүе, укуда һәм фән өлкәсендә алга китүе. Уңай нәтиҗәләрнең күбрәк булуы киләчәктә белем һәм күнекмәләр үстерү ихтыяҗының артуына да бәйле. Бу процесс төрле чыганаклар нигезендә мөстәкыйль рәвештә белем алуны күзаллый, һәм ул – укучының идарә ителә торган максатчан танып белү эшчәнлеге булып тора.

Һөнәри үсеш – үзенә куелган таләпләр нигезендә, шәхес һәм белгеч буларак үсүгә юнәлтелгән аңлы эшчәнлек. Һөнәри үсеш белән үзлектән белем алу шулай ук бик тыгыз бәйләнгән.

Атаклы шәхесләрнең тормыш һәм хезмәт юлын өйрәнү, үз-үзенә һәм хезмәт нәтиҗәләренә тәнкыйди күзлектән чыгып карау даими рәвештә шәхси, һөнәри үзүсешкә этәргеч ясый. Мәсәлән, Альберт Энштейн үзен талантлы шәхес дип кенә түгел, бәлки хезмәт сөючән кеше дип тә исәпләгән һәм фәндәге

уңышларын зур тырышлык һәм эшчәнлек нәтиҗәсе дип караган. Шуңа күрә, психологлар фикеренчә, үзеңне тәрбияләү уңышларыңны һәм җитешсезлекләреңне танудан, башкалар хезмәте белән чагыштырганда, үзеңнеке белән канәгать булмаудан, психик халәтеңне анализлаудан башлана.

Үз-үзеңне тәрбияләүнең алдагы этабы – максатны дөрес билгеләү, чөнки ул турыдан-туры нәтиҗәгә бәйле. Мәсәлән, уку эшчәнлеген нәтиҗәле оештырырга өйрәнү, тырышлык, аралашу осталыгы, оештыру сәләтен үстерү һ. б.

Үзлектән танып белү һәм үзбәя – шәхси үзенчәлекләрне өйрәнү һәм бәяләү вакытында күзәтү, махсус тикшеренү методларын куллану.

Укытучының мөстәкыйль белем алу чыганаклары: лингвистикага (филологиягә) караган хезмәтләр, махсус әдәбият (психологик, лингводидактик, педагогик һ. б.), Интернет һәм массакүләм матбугат чаралары, белем күтәрү курслары, мастер-класслар, конференцияләр, семинарлар, музейлар, театрлар һ. б.

Үзлектән белем алу формалары түбәндәгеләр:

- ❖ индивидуаль (үзең төзегән план нигезендә);
- ❖ төркем белән (мәсәлән, татар теле укытучыларының методик берләшмәсендә һ. б.).

Үзлектән белем алуның төп юнәлешләре:

- ❖ һөнәри юнәлеш (татар теле һәм әдәбиятын укытуга караган материаллар, норматив-хокукый документлар, заманча педагогик технологияләр, махсус курсларда белем күтәрү, мәкаләләр язып бастыру һ. б.);
- ❖ психологик һәм педагогик юнәлеш (бу өлкәгә караган әдәбият белән танышу һәм белемеңне үстерү);
- ❖ методик юнәлеш (яңа метод, алым, чаралар белән танышу, шул исәптән, башка фәннәрне укытканда кулланыла торганнарын да файдалану), хезмәттәшләрнең дәресләренә керү һәм тәҗрибә уртаклашу, ачык дәресләр үткәрү, мастер-класслар бирү, семинарларда һәм фәнни-методик конференцияләрдә чыгыш ясау, сәләтле балалар белән эшләү, һөнәри эшчәнлеккә үзанализ ясау, төрле берләшмәләр эшчәнлегендә катнашу һ. б.);
- ❖ мәгълүмати-аралашу технологияләре юнәлеше (Интернеттан тиешле материалны сайлап алу, электрон һәм Интернет чыганакларыннан файдаланып, әдәбият исемлеген булдыру, махсус курслар узу);
- ❖ укучыларның сәламәтлеген саклау юнәлеше (татар теле һәм әдәбияты дәресләренә сәламәтлек саклау технологияләрен кертү, сәламәт тормыш алып бару).

Һөнәри яктан үз-үзеңне тәрбияләү һәм үз өстеңдә эшләү өчен, түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

- шәхес өчен әһәмиятле булган максат һәм бурычларны сайлый белү, планлаштыру һәм программа төзү;
- үзеңә уңайлы метод һәм чаралар сайлау;
- һөнәри яктан үз-үзеңне тәрбияләү һәм үзлегеңнән белем алу программасын гамәлгә ашыру;
- үзтикшерү һәм үзбәя бирү аша программага кирәкле төзәтмәләр кертү.

Безнең фикеребезчә, рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары түбәндәге юнәлешләр буенча белемнәрен камилләштерә ала:

- психологик һәм педагогик юнәлеш;
- лингводидактик юнәлеш;
- полилингваль белем бирү юнәлеше;
- мәгълүмати-компьютер юнәлеше;
- хокукый юнәлеш;
- эстетик юнәлеш;
- укучыларның сәламәтлеген саклау юнәлеше һ. б.

Мөстәкыйль белем алу өчен, тема сайлау – җитди гамәлләрнең берсе. Ул укытучының шәхси тәҗрибәсенә, һөнәри осталыгына бәйле. Белем алу процессы һәрвакытта педагогның һөнәри осталыгын үстерүгә юнәлтелгән була.

Фәнни тема уку елы башында сайлана һәм методик берләшмә планында теркәлә. Шуны истән чыгармаска кирәк: һәрбер тема укыту эшчәнлеген яхшыртуга, яңа метод һәм алымнарны табып, гамәлгә кертү белән бәйле булырга тиеш. Үзлектән белем алу берничә елга да планлаштырылырга мөмкин. Гадәттә, шәхси план (программа) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- сайлап алынган теманың исеме һәм аның актуальлеге;
- һөнәри үсешнең максаты (эшчәнлегеңә тулы анализ ясау һәм үз мөмкинлекләреңне ачыклау, белемеңне күтәрү өчен, төп юнәлешләрне билгеләү: заманча технологияләр, яңа нәтиҗәле метод һәм алымнар белән танышу, гомумиләштерү һәм аларны укыту процессына кертеп җибәрү);
- үзлектән белем алуның гомуми концепциясе;
- үз өстеңдә эшләүнең төп юнәлешләре (этаплары);
- һәр этапның үтәлү вакыты (урыны);
- уздырылган чаралар;

❖ кителгән нәтиҗәләр (укытучының фәнни-методик яктан белеме тирәнәю, заманча технологияләрне куллану алымнарына ия булу, укучыларның татар теле дәресләренә карата кызыксынуы көчәю, сыйфатлы белем бирү, яңа форма һәм алымнарны сынап карау һ. б);

❖ балалар психологиясе, педагогика, татар теле һәм чит телләр методикасына караган әдәбият белән танышу;

❖ белем бирү процессын методик яктан тәэмин итү;

❖ белем бирү оешмасының (мәктәпнең, районның, республиканың) методик һәм идарә итү органнары эшчәнлегендә катнашу;

❖ эшчәнлегеңне анализлау һәм аңа бәя бирү, хисап ясау.

Укытучының һөнәри үсешен түбәндәгечә оештырып була:

❖ һөнәри үсешнең бурычларын һәм максатларын билгеләү;

❖ шәхси һәм һөнәри үсешкә уңай йогынты ясый торган Интернет челтәре мөмкинлегеннән файдалану;

❖ белемнең сыйфатын күтәрү максатыннан, укыту процессына заманча технологияләр кертү;

❖ презентация материаллары тупланмасын булдыру һәм хезмәттәшләр белән фикер алышу;

❖ мәгълүмати ярдәм банкын булдыру (татар теленнән тиешле мәгълүмат алу өчен, сайтлар исемлеген төзү, видеоматериаллар, вакытлы матбугат материаллары, өстәмә һәм белешмә әдәбият сайлау һ. б.);

❖ осталыкны мастер-класслар, ачык дәресләр бирү аша үстерү;

❖ төрле һөнәри конкурсларда катнашу.

Методик эшчәнлек формалары түбәндәгеләр:

❖ ачык дәресләр бирү, үзанализ ясау;

❖ үз тәҗрибәңә нәтиҗә ясау;

❖ сыйныфта, аерым төркемнәрдә дәрес бирү;

❖ хезмәттәшләрнең дәресләренә анализ ясау;

❖ чараларда активлык күрсәтү;

❖ хезмәттәшләргә киңәш бирү;

❖ хезмәттәшләр белән тәҗрибә уртаклашу;

❖ фәнни-методик әдәбият белән танышу һ. б.

Укытучы эшчәнлегенә бәя биргәндә, аның педагогик компетентлыгы һәм осталыгы, иҗат итүгә сәләтле булуы да әһәмиятле урынны алып тора. Укытучының педагогик компетентлыгы – укыту-тәрбия процессын дөрес оештыруга юнәлтелгән белем бирүнең осталык һәм күнекмәләрен нәтиҗәле гамәлгә ашыра белүе; педагогик эшчәнлекне уңышлы алып бару өчен кирәк булган һөнәри һәм

шәхси сыйфатлар җыелмасы. Һөнәри яктан компетентлы булган укытучы түбәндәге сыйфатларга ия:

- ❖ татар теле һәм әдәбияты дәресләрен югары дәрәҗәдә, нәтиҗәле уздырырга сәләтле;
- ❖ дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда төрле мәдәният вәкилләренә мәхәббәт, дустанә мөнәсәбәт тәрбияли, мөмкин булганда, телләрне һәм мәдәниятләрне чагыштырып өйрәтә;
- ❖ аралашу осталыгына югары дәрәҗәдә ия;
- ❖ дәрескә лингводидактика өлкәсендә булган яңалыкларны даими рәвештә кертеп бара;
- ❖ белем һәм тәрбия бирүдә югары нәтиҗәләргә ирешә.

Җәмгыятьнең иҗтимагый-икътисади һәм рухи үсеше укытучының һөнәри белем дәрәҗәсенә турыдан-туры бәйле.

Яңа Стандарт нигезендә укытучының педагогик компетентлыгын үстерүгә түбәндәге таләпләр куела:

- ❖ яңа фәнни-методик әдәбият белән даими танышып бару;
- ❖ иҗади төркемнәрдә, методик берләшмә утырышларында чыгышлар ясау;
- ❖ фәнни-тикшеренү һәм эксперименталь эшчәнлектә катнашу;
- ❖ төрле конкурсларда, мастер-классларда, олимпиадаларда һ. б. актив катнашу;
- ❖ заманча педагогик технологияләр белән таныш булу һәм аларны көндәлек эштә куллану;
- ❖ үзеңнең педагогик тәҗрибәңне киң җәмәгатьчелеккә җиткерү.

Һөнәри үсешнең алдагы этабы – психология, педагогика теориясендә һәм практикасында киң кулланыла торган методлар, алымнар, принципларны, заманча технологияләрне көндәлек эштә нәтиҗәле кулланып, укытучының белем һәм тәрбия бирү осталыгы (компетентлыгы). Хәзерге укытучының теоретик (яңа психологик һәм педагогик концепцияләрне белү), методологик (педагогик күренешләрне өйрәнүнең гомуми принципларын, укытуның һәм тәрбияләүнең иҗтимагыйлаштыру закончалыкларын белү) һәм технологик (традицион һәм инновацион белем бирү технологияләрен белү) белемнәргә ия булуы аеруча мөһим.

Шулай итеп, укытучының даими рәвештә үзлегеннән белем алуы, аны камилләштерүе көндәлек эшчәнлеге өчен әһәмиятле шарт булып тора. Җәмгыять һәрвакытта укытучыга югары таләпләр куйды, һәм ул киләчәктә дә шулай булачак. Бу таләп икетеллелек (күптеллелек) шартларында эшләүче

татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен аеруча мөһим. Димәк, укытучы даими үсештә булырга һәм үз өстендә эшләргә тиеш, чөнки, башкаларны өйрәтү өчен, син аларга караганда күбрәк укырга һәм белергә бурычлы. Бала шәхесен дөрес формалаштыру, аңарда гражданлык активлыгы тәрбияләү, иҗади мөмкинлекләрен ачу һәм үстерү өчен, укытучы өзлексез, үзлегеннән белемен күтәрергә, камилләштерергә тиеш. Аның өчен татар теле һәм әдәбияты курсларында укырга (хәзер аларны КФУның татар теле белеме кафедрасы да оештыра); төрле һөнәри семинарларда, мастер-классларда, ачык дәресләрдә ешрак катнашырга; психология, лингводидактика өлкәсендәге яңа фәнни әдәбият, журналлар белән танышып барырга һәм Интернеттагы белем бирү процессына караган, аеруча заманча технологияләргә кагылышлы мәгълүматларны тупларга һәм аларны дәресләрдә киңрәк файдаланырга кирәк.

Үзлектән белем алуга сәләтлелек укытучының акыл (интеллектуаль), психологик һәм педагогик күрсәткечләре буенча билгеләнә. Укымыйча, даими рәвештә белемен камилләштермичә торып, укытучы һөнәри яктан үсә алмый. Бу – аксиома кебек!

**ӘДӘБИЯТ**

Львова Ю. Т. Творческая лаборатория учителя. М., 1992.

Орлов Ю.М. Саморазвитие и самовоспитание характера. М., 1987.

Федеральные государственные образовательные стандарты общего образования (1-4, 5-9, 10-11 классы).

Харисов Ф.Ф. Татар теле: теория һәм практика. Монография. Казан: Ак бүре нәшр., 2018. 448 б.

**Г.Ф. ХАСБИУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ “БЕР” САНЫНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются особенности употребления имени числительного ”бер” в татарском языке. В работе описаны фонетические особенности его употребления в диалектах, функционирование в фразеологизмах и пословицах.

**Abstract.** The article is devoted to the features of the use of the number “one” in the Tatar language. The phonetic features of the number “one” in dialects, their functioning in phraseological units are described in this work.

**Ключевые слова:** имя числительное один, фонетические изменения, фразеологизмы, пословицы, словообразование.

**Keywords:** number “one”, phonetic changes, idioms, proverbs, word formation.

Сан төшенчәсе гомуми, абстракт төшенчәләрнең берсе. Шуңа күрә телдә сан төшенчәсен белдерә торган сүзләрнең тууы, аларның, арта-киңәя барып, билгеле бер системада стабильләшүе кешелек фикерләвенең үсеше белән бәйләнгән. Икенче төрле әйткәндә, теләсә нинди әйбер, вакыйга һәм күренешләрнең санын билгеләргә ярый торган универсаль сан исемнәре фикерләү һәм танып белү уңышларының телдә чагылышы булып тора.

**“Бер” саны.** Әдәби телдә “бер” дип йөртелгән санның сөйләшләрдә фонетик үзгәрешләре күзәтелә. Мисаллар: Урта диалект Казан арты сөйләмендә бер санының иренләшүе күзәтелә *[бӧр]*. Дүртөйле сөйләме һәм тау ягы сөйләменең Апас районы авылларында [б] авазы, регуляр булмаса да, [м] авазына күчә: *бер-мер*, б ~ м тәңгәллеге, шулай ук Дүртөйле сөйләмендә *бер-бир* формасы очрый (е ~ и тәңгәллеге). Туймазы, Барда, Касыйм сөйләмнәрендә *бер-мер-пер* формалары (б ~ м ~ п тәңгәллеге) кулланыла. Көнбатыш диалект Чистай, Бөре буе, Кузнецк, Хвалын сөйләмнәрендә : бер-бәр/пәр; б ~ п һәм е ~ ә тәңгәллекләре күзәтелә. Көнчыгыш диалект Тобол сөйләме: *бер-бир*: е ~ ә тәңгәллеге, *бер-пер-пир*; б ~ п тәңгәллеге очрый [Әхәтов, 1984: 194-196].

“Бер” саны татар телендә фразеологизмнар ясауда актив катнаша. Мисаллар Г.Х. Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлегеннән” алынды:

*Бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә* – бик карт; үлем хәлендә; *бер балык башын чәйнәү* – гел бер сүзне сөйләү; *бер басуда үскән тигәнәк* – бер фикердәге начар кешеләр; *бер дигән* – бик яхшы; *бер йөрәктән өзелгән* – үзеңнеке, бик кадерле; *бер канат сыну* – якын, кадерле кешене югалту; *бер кашык су белән йотарлык* – бик чибәр, сөйкемле; *бер тиен тормаслык* – бик начар; бер табактан ашау – дус булу һ.б.

“Бер” санының татар халык мәкальләрендә дә киң урын алуын билгеләп үтәргә кирәк. Мисаллар Н. Исәнбәтнең “Татар халык мәкальләре” дигән хезмәтеннән алынды.

*Күп һөнәр белгән кеше бер һөнәргә дә оста булмас. Бер агачтан миллион шырпы ясап була, бер шырпыдан миллион агач юк була. Бер агачтан унау үскән, ун агачтан урман үскән. Бер галим йөз наданны җиңәр. Галимнең бер көне наданның бөтен гомеренә тора. Йөз надан бер галимнең тырнагына тормас. Бер агачта ике кайры булмас. Бер шыгырдаган агач гомер буе шыгырдый. Җиде кат үлчә, бер кат кис. Йөз кат әйткәнче, бер кат эшләп күрсәт* һ.б.

Әгәр дә без татар әдәби тел тарихы материалларына мөрәҗәгать итсәк, “бер” санының борынгы һәм урта гасыр телендә кулланылуы күзәтелә.

Хезмәтебездә болгар дәүләте чорында язылган әсәрләрен тикшерү моның ачык мисалы булып тора. Әмма әсәр телендә төп мәгънәсенә караганда “бер” күбрәк билгесезлек алмашлыгы мәгънәсендә килгән.

Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасында да бер санының кулланылышы: *Мәүлем, сәңа сыгынурмен мән **бер** зәгиф, Тәүфик сәндән уманурмен мән **бер** нәхиф* [13, 48]; *Уйуркән **бер** гаҗәб дүш Йусеф күрди* [23, 52]; *Йусеф **бер** кол сатун алды* [937, 270] һ.б.

"Бер" санының тартым һәм хәбәрлек күрсәткечләре белән төрләнүе дә теркәлгән. Үрнәк: *берси Хәсән, берси Хөсәйен – ики шәһид* [7, 48].

Күргәнебезчә, Кыйссаи Йосыф әсәрендә “бер” саны күбрәк билгесезлек алмашлыгы мәгънәсендә килә.

Сан сүз төркеменең төп мәгънәсендә һәм башка яңа сүзләр ясауда кулланылуы күзәтелә.

Бертуган – сыйфат: 1. Бер ата-анадан туган; кан кардәш. – *Әнвәрнең әнисе Әсматтәй минем бертуган апаем бит.* (Р.Ишморат); 2. Бертуганнар кебек тату, үзара якын – *Эшче куллар – бертуган.* (Н. Исәнбәт).

Беравыздан – рәвеш: 1. Барысы бергә, бердәм рәвештә – *Балалар беравыздан җырлап җибәрделәр.*(Г.Гобәй); 2. Бертавыштан, каршылыксыз – *Бригада членнары Хәйдәрнең тәкъдимен беравыздан күтәреп каршы алдылар*. ( Р.Ишморат).

Бераз – рәвеш: 1. Аз гына, зур булмаган күләмдә, күп түгел – *Тордым бераз ишек төбендә мин.* (Б.Рәхмәт); 2. Билгеле бер дәрәҗәдә, беркадәр, җиңелчә генә – *Без, әлбәттә, бераз үсә төштек.*

Бергәлек – 1. Исем: дуслык, татулык, бердәмлек; 2. Сыйфат: бергә булган. *Ике ел бергәлек якты тормыштан соң, Нәфисәнең кияве тиф авыруыннан үлеп китте*. (Ш.Камал).

Бердәнбер – 1. Сыйфат: бары берәү генә, башка юк; 2. Исем: *Тик син генә куанычым, син генә бердәнберем.* (Ә.Ерикәй).

Берегү – 1. Фигыль: бер бөтен булып кушылу, ныгу – *Бүрәнә җепләре бер – берсе белән чыелдап үбешә-үбешә урыннарына ныграк берегә барды.* (А.Гыйләҗев); 2. Берләшү, оешу – *Сез берекkәндә нинди көч туачагын күз алдына китерергә тырыш син.* (Г.Коләхмәтов); 3. Туры килү (уй-фикер һ.б.), килешү. – *Патшаларның киңәшләр берексен иде дә, хәере белән тиздән... балаларыбыз кайтсын иде*. (М.Гали).

Димәк, “бер” саны төп мәгънәсендә, билгесезлек алмашлыгы мәгънәсендә һәм башка сүз төркемнәре ясауда кулланулы ачыкланды.

**ЛИТЕРАТУРА**

Әхәтов Г.Х. Татар диалектологиясе. Казан: Тат. кит.нәшр., 1984. 216б.

Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. 176 б.

Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре 3 томда. Казан: Тат. кит.нәшр., 2010. 799 б.

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Басмага әзерләүче Фассеев Ф.С. Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. 536 б.

Мөгътәсимова Г.Р. Татар халык мәкальләрендә саннар символикасы // Казан дәүләт университеты татар филологиясы һәм тарихы факультеты укытучыларының фәнни язмалары (2002). Казан: РПК Гарт, 2002. 197–202 б.

**Я.А. ХАФИЗОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР БАЛАЛАРЫ СӨЙЛӘМЕНЕҢ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются лексические особенности разговорной речи татарских детей. Исследование проводилось на основе аудиоматериалов, содержащих записи спонтанной речи детей от 6 до 13 лет, проживающих в Муслюмовском районе Республики Татарстан. Как показывает исследование, в большей степени лексические особенности в речи детей появились в результате интерференции. Это в первую очередь связано с тем, что дети растут и обучаются в билингвальной среде.

**Ключевые слова:** социальный диалект, лексические особенности, билингвизм, татарский язык.

**Abstract.** This article discusses the lexical features of colloquial speech of Tatar children. The study was conducted on the basis of audio materials containing recordings of spontaneous speech of children from 6 to 13 years old, living in the Muslyumovsky district of Tatarstan. As the study shows, to a greater extent lexical features in the speech of children appeared as a result of interference. This is primarily due to the fact that children grow and learn in a bilingual environment.

**Keywords:** social dialect, lexical features, bilingualism, the Tatar language.

Билгеле булганча, тел язма һәм сөйләмә формаларда яши һәм кеше сөйләме бик катлаулы процесс. Ул барлыкка килүдә, аның үсешендә, үзгәрүендә төрле факторлар роль уйный. Бер яктан - биологик, икенче яктан иҗтимагый факторлар. Сөйләм теле – алдан әзерләнмәгән, диалогик формада яшәеш тапкан, әзер клише, шаблоннар иркен кулланыла торган тел ул. Сөйләм теленең төп вазифасы – аралашуны тәэмин итү [1: 166]. Сөйләм теленең төп үзенчәлекләре булып аның алдан әзерләнмәве, кодификацияләнмәгән булуы һәм әдәби тел нормаларыннан читтә торуы. Сөйләм теле төрле яшьтәге һәм төрле социаль статустагы кешеләргә таралган. Без үзебезнең тикшеренүебездә яшь буенча бер катламны формалаштырган балалар сөйләмен тирәнрәк карап китәбез.

Безнең тикшеренүнең **максаты** хәзерге заманда татар балалары сөйләменең лексик үзенчәлекләрен ачыклау. Тикшеренү **объекты** буларак без – Мөслим төбәген, ә **предмет** буларак 6-13 яшьтәге алты баланың сөйләмен алдык. Җенесләренә килгәндә, икесе – малай, дүртесе – кыз. Әлеге балаларның гадәти көнкүрештәге сөйләмен аудиоязмаларга тупладык. Җыелган материалларны тикшереп, анализлап без түбәндәге үзенчәлекләрне ачыкладык.

Билгеле булганча, хәзерге татар балалары билингваль даирәдә тәрбиянәләр. Билингваль даирә – ул кешенең ике телле мохиттә көн күрү һәм ике телнең дә аның аерылгысыз өлеше булып тору. Мондый шартларда бер тел сүзләре икенчесенә үтеп кереп чынбарлыкның аерым күренешләрен атау өчен, эмоциональ-экспрессив максаттан кулланыла башлый. Элегрәк мондый үзенчәлекләр, ягъни рус сүзләрен татар сөйләмендә һәм киресенчә татар сүзләрен рус сөйләмендә куллану, шәһәр балаларына һәм гомумән шәһәрдә яшәүчеләргә генә хас булса, хәзерге көндә бу күренешне татар авылларында да күзәтә алабыз. Моның барлыкка килүенең сәбәпләре күп. Лингвистик күнекмәләрдән тыш, психологик һәм социомәдәни шартлар да моңа сәбәпле дигән караш бар [2: 31]. Туганнан алып ике телле үсү, һичшиксез, балаларның сөйләмендә чагылыш таба. Ләкин ике телне дә белү һәм аларның үсеш-үзгәрүе билингвның эчке конфликтына китерергә мөмкин. Мондый очракта төрле типтагы хаталар барлыкка килә. Әлбәттә, билингв ике телне дә бер үк дәрәҗәдә яхшы белмәскә мөмкин. Кайсы телне яхшырак үзләштерү беренче чиратта гаиләдән, әйләнә-тирә мохиттән, җәмгыятьтән тора. Гадәттә билингв туган телен камилрәк белә, әмма шәһәрдә яшәүчеләр, киресенчә, рус телен яхшырак үзләштерәләр һәм бу телдә ешрак сөйләшәләр [3: 17]. Күп кенә лексик үзенчәлекләр нәкъ менә балаларның билингв булулары белән бәйле.

Беренче чиратта, балаларның барысы да сөйләмләрендә күп кенә урыс сүзләре, ягъни варваризмнар куллана. Бу 6 яшьлек информантта да, 13 яшьлегендә дә бар. Мәсәлән, *Нигә* ***именно*** *мин чыгарга тиеш?* (13 яшьлек информант); ***Да, понятно, понятно*** (6 яшьлек информант).

Күпчелек очракта рус сүзләрендәге сыйфатлар татар балаларының сөйләменә әзер килеш керә һәм алар мужской родта булалар. ***Зелёный*** *белән и* ***ещё красный*** *төсләрне* (6 яшьлек информант); *Ну, например,* ***домашнийларны****.; Майнкрафт –* ***логичный*** *уен. (Әмма рус телендә бу сүзтезмә* ***логичная*** *игра)* (7 яшьлек информант).

Шунысы кызык, рус телендәге тышкы формасы белән сыйфатка охшаган исемнәрне дә (мәсәлән, животное, мороженое, существительное һ. б.) мужской родта кулланалар. Мәсәлән, *Синең нинди* ***животный*** *самый любимый?*

(7 яшьлек информант). Тагын бер күзгә ташланган үзенчәлек – ул рус фигыльләренә татар телендәге ярдәмче фигыльләрне кушып сөйләү: *Без күбрәк качелида **качаться итәбез*** (9 яшьлек информант); *Әни, кулың **мешать итә**!* (6 яшьлек информант); *Удочкага морковка **привязать итсәң** 〈...〉* (7 яшьлек информант).

Киләсе үзенчәлек балаларга бигрәк та хас. Ул шулай ук рус сүзләрен куллану белән бәйле. Без тыңлаган балалар сөйләмендә кайбер сүзләр рус телендәге иркәләү-кечерәйтү формасында әйтелә. Мәсәлән, ***Огурчикны** буйыйм* (6 яшьлек информант); *Чучкага седло куйсаң, **удочкага морковка** привязать итсәң〈...〉; **Цыплёнок** ошый миңа, ещё **овечка*** (7 яшьлек информант).

Иң киң таралыш тапкан үзенчәлек – ул татар теленә әзер килеш кергән рус сүзләренә татар аффиксларын өстәп килеш, тартым һ.б. белән төрләндерү. Мондый үзенчәлекне бар информантта да таптык: *Без күбрәк **качелида** качаться итәбез* (9 яшьлек информант); *Аны **розовыйга** буярга кирәк* (6 яшьлек информант); *Обычно гуляем, **самокатта** катаемся* (9 яшьлек информант); ***Коровалар** пшеница ашыйлар.; Привязать итсән **свиньяга**〈...〉; **Понида** йоргән бар.; Бу **выходнойлардамы**?* (7 яшьлек информант).

Тагын аерым әйтергә кирәк, күпчелек информантлар сөйләмендә рус телендәге “ну” ымлыгын кулланалар: ***Ну**, кыяр и помидор и всё* (9 яшьлек игформант); ***Ну**, как, кара ничек булды.*; ***Ну**, например, домашнийларны* (7 яшьлек информант*); **Ну**, Мөслимдә рәхәтрәк* (13 яшьлек информант); ***Ну**, икенче класста дүрт кеше, ә дүртенче класста дүрт кеше укый* (9 яшьлек информант); ***Ну**, белмим* (6 яшьлек информант).

Без игътибар иткән бер кызыклы күренеш – ул татар һәм рус мәктәпләрендә укыган балаларның сөйләмендә аерма сизелә. Без моны дәрес исемнәрен атаганда күрдек. Мәсәлән, 9 яшьлек татар мәктәбендә укыган кыз менә ничек әйтә: ***Рус теле,** инглиз теле, математика, әйләнә-тирә* (9 яшьлек информант). Ә рус мәктәбендә укыган информант: *Математика, **русский,** физкультура* (13яшьлек информант).

Әлбәттә, һәр кеше нинди дә булса территориаль диалект вәкиле. Безнең очракта балалар урта диалект, минзәлә сөйләшендә аралашучылар һәм шуңа бәйле рәвештә аларның сөйләмләрендә кайбер әлеге диалект, сөйләшкә хас лексика бар. Мәсәлән: ***Бәй** абый йокласын инде* (13 яшьлек информант).

Без караган үзенчәлекләр, әлбәттә, беренче чиратта баланың билингв булуларына барып тоташа. Бала кечкенәдән ике телне дә параллель үзләштергәнгә күрә аның аңында ике телнең дә лексик фонды бар. Шуңа бәйле балаларның сөйләме әдәби телдән читләшә һәм күп кенә хаталар барлыкка

килә. Алар үзләренә уңайлы булганча, яки бер телдә төшенчәнең атамасын белмичә, икенче телнекен кулланып сөйләшәләр. Шулай ук баланың тирәлегендә кешеләр нинди телдә сөйләшү дә мөһим роль уйный. Мондый күренешнең сәбәпләре күп: бер яктан - лингвистик, икенче яктан – психологик һәм социомәдәни сәбәпләр.

## ӘДӘБИЯТ


Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. 2018. – № 1 (10). – Б. 22–35.

Поливара З.В. Этнолингвистические дифференциации в формировании лексико-грамматических категорий у татар-билингвов и русских в системе преодоления речевых дисфункций (на материале Тюменской области). Автореф. канд. дисс. Тобольск, 2011. 23 с.



**З. Р. ШАҺВӘЛИЕВА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР СӨЙЛӘМЕНДӘ ТЕЛ КОДЛАРЫ АЛМАШЫНУЫ ҺӘМ КҮЧЕШЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


**Аннотация.** Мәкаләдә икетелле даирәдә кодлар күчеше проблемасы карала. Рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә аңлы рәвештә һәм аңсыз күчүгә йогынты ясый торган факторлар билгеләнә. Бер-берсенең туры тәрҗемәсе булып килгән сүзләрне кабул итү төрлелегенең лингвокультур аспектлары чагылдырыла.

**Abstract.** The article is devoted to the problem of switching language codes in a bilingual environment. The factors affecting the conscious and unconscious switching from Russian to Tatar and from Tatar to Russian are described; questionnaires are considered that reflect the linguocultural aspects of the perception of synonymous words in two languages.



**Ключевые слова.** Кодлар күчеше, кодлар алмашынуы.

**Key words.** Code-switching, code-mixing.


Җәмгыятьнең тизләтелгән үсеше һәм аның эчендә барган интеграцион процесслар төрле халыкларның тел һәм мәдәниятләренә зур йогынты ясый. Күпмилләтле илләрдә чит телдә аралашучылар белән тыгыз мөнәсәбәттә булу, катнаш никахлар саны арту, чит телләр өйрәнү – болар барысы да кешеләрнең менталь лексиконында чагылыш таба, аларның дөньяга карашын үзгәртә һәм билингваль һәм полилингваль халык формалашуга этәргеч ясый.

Күптеллелек шартларында лексик алынмалар, диффузия, күчеш, интерференция белән беррәттән, тел коды алмашыну һәм тел коды кушылу

кебек күренешләр дә барлыкка килә. Бу билгеләмәләрне аңлатуга карата бердәм фикер юк. Кайбер галимнәр, мәсәлән, Ж. Багана, код алмашыну терминын гына куллана яисә код алмашыну һәм код кушылуны синоним төшенчәләр дип карый [Багана, 2010, с. 66-68]. Икенче төркем галимнәр бу төшенчәләрне аерып карый, ләкин аңлатуда барыбер төрлелек саклана, мәсәлән, Мәсәлән, П. Мэйскен белән О.Н. Сычева код алмашыну үз эченә телдәге булган барлык үзгәрешләрне, шул исәптән код кушылуны да кертә дип саныйлар [Сычева, 2005, 196 с.]. Д. Вольф, киресенчә, код кушылу төшенчәсен киңәйтеп, код алмашынуны аның эчендә карый. Бу күренешләрне социолингвистик яктан өйрәнгән А. В. Жиганова исә түбәндәге фикерне белдерә: «Код алмашыну күренеше – мотивлашкан процесс, чөнки ул аралашу барышында билгеле бер функцияне үти. Код кушылу күренеше исә кинәт барлыкка килә, күпчелек очракта тыгыз бәйләнгән сүзтезмә эчендә була һәм функциональ яктан мотивлашмый» [Жиганова, с. 33-35].

Без дә ике төшенчәне аерып, код алмашынуны тышкы, социолингвистик шартлар үзгәрү сәбәпле, бер телдән икенче телгә аңлы рәвештә күчү, ә кодлар кушылуны аралашу вакытында психологик яисә иҗтимагый халәт үзгәрүгә бәйле, бер телдән икенче телдә аңсыз рәвештә күчү күренеше дип караячакбыз.

Код алмашыну һәм код кушылу күренешләрен социолингвистик, психолингвистик һәм гомумлингвистик яклардан өйрәнү аерылып чыгарылган. Фәнни эшебездә без әлеге күренешне тумыштан алып билингв булган, татар һәм рус телләрен камил белгән шәһәр яшьләре сөйләменә нигезләнеп тикшердек. Анализ сөйләм телен чагылдырган 400дән артык диалогка һәм телдән сорашуга нигезләнде.

Анализ нигезендә социо- һәм психолингвистик яктан, код алмашыну һәм код кушылу күренешәренә йогынты ясаучы түбәндәге факторларны аердык:

1. Коммуникация темасы үзгәрү, мәсәлән: *Тагын барабыз инде җәен тегендә. Ты занималась еще сегодня?* Әлеге мисалда сөйләмдә катнашучының иптәшеннән спорт белән шөгыльләнүе турындагы соравы рус телендә бирелә. Респондентлар билгеләвенчә, спорт темасына кагылышлы булган сүзләрне шәһәр кешеләренә рус теле ярдәмендә чагылдыру җиңеллерәк. Моны русча басылган реклама такталарында, рус каналларында спорт темасы күбрәк чагылыш табуына да бәйләп карарга мөмкин. Бу очракта сөйләм ситуациясенә психолингвистик факторның тәэсирен ассызыкларга кирәк. Шул рәвешле, сөйләшүче, ситуациядән чыгып, аралашырга уңайлырак булган телне сайлап ала һәм репликасын дәвам итә.

2. Дөньяны танып белү сурәтендәге төрлелекләр. Әлеге факторны раслау өчен без сорашудан файдаландык. Туган теле татар теле булып, рус телен камил белгән яшьләр арасында туганлык атамалары, реалияләр, мәдәнияткә, көнкүрешкә, хис-тойгыларга бәйле булган башта татар телендә, аннары рус теленә тәрҗемә ителгән сүзләр таратылды һәм бер төшенчәнең төрле телдә менталь яктан ни рәвешле кабул ителүе ачыкланды.

Нәтиҗәләрдә туганлык атамаларын кабул итүдәге аерымлык күзгә ташланды. Мисал өчен, *әни* сүзенә күпчелек җаваплар “өй”, “җылылык”, “авыл”, “чәй” булса, *мама* сүзен “добрая”, “лучшая”, “моя” дип сыйфат белән тасвирлау күбрәк булды. *Дәү әни* сүзе шулай ук “коймак”, “чәй” дигән ассоциация барлыкка китерә, ә *бабушка* сүзе исә “мудрая”, “старая” дигән, күбрәк әкият яисә китаплар уку барышында туган образны тасвирлый торган сүзләр белән тәңгәлләштереп карала. Димәк, рус телендә аралашкан вакытта *я к нәнә пойду сейчас* дип аңсыз рәвештә татар теленә күчеп, кодларны кушуны мәдәнияткә бәйле сүзне психологик яктан кабул итү аерымлыгы булуга бәйләп карый алабыз.

Кайбер сүзләр татар телендә яңгыраганда турыдан-туры мәдәният белән бәйләнеп карала, мәсәлән, *бәйрәм* сүзе кайбер сораштыручыларда “сабантуй”, “ураза”, “коймак” дигән ассоциацияләр тудыра, шул ук вакытта праздник сүзе “радость”, “торжество, “свет” кебек сыйфатлар белән тасвирлана. *Өчпочмак* сүзе геометрик фигура итеп түгел, ә милли ризык булып күзаллана һәм *әни, әби, тәмле* сүзләре белән ассоциатив рәт тудыра. *Треугольник* сүзенә исә ризыкка бәйле җаваплар күзәтелми, вариантлар арасында “школа”, “равносторонний”, “любовный” сүзләре киң таралган.

Димәк, мәдәният белән тыгыз бәйләнештә булган сүзләр (*да, испекла инде вот пирог, кунакка килегез),* топонимнар, реалияләр, ымлыклар *(абау, опять ты тут)* дини лексика кулланылу очракларының күбесендә кодлар кушылу күренеше пәйда була.

3. Цитаталар яисә кыек сөйләм куллану. Әлеге факторны шулай ук экономия принцибы белән бәйләп карарга мөмкин, мәсәлән, *через 2 часа дома буду, дигән иде. Ул миңа завтра приеду диде.*

4. Яхшырак аңлату өчен бер үк фразаны ике телдә кабатлау: *Сегодня суббота, каток до десяти работает. Так что эшли әле, эшли. Тиздән җәй җитә, абау, ышанмыйм. Лето…*

Код кушылу күренеше телнең барлык катламнарында да күзәтелә.

Фонетик яктан код кушылу күренешенә коммуникация барышында чит телдән килеп кергән сүзләрнең фонетик нормалары бозылу, сөйләм теленең

нормаларына ярашуын атый алабыз, мәсәлән, *Матурчик, ник буш сообщение җибәрәсең, [галасавой] җибәрдең бушны, нәрсә дә булса әйтәсең бар иде инде, ичмасам. Мин хәтере тулмасын дип, чистартып барам, ату [глющит] итә башлый телефон.*

Кайбер вакытта фонетик яктан код алмашыну күренеше дә барлыкка килә ала. Мисал итеп максатчан рәвештә телне бозып әйтү күренешләрен карап була. *[Пащиму] син алай дисеңдер, мин [ни панимаю].*

Морфологик яктан код кушылу күренеше дип чит телдән килеп кергән сүзләрнең грамматик категория ягыннан сөйләм теленә ярашуын әйтеп була. Кайбер очракларны карап китик. Килеш буенча ярашкан фразалар телдә еш очрый: *Ярыймы соң җибәрергә "группа для новичковның" ссылкасын.* Күплек саны формасының рус сүзләренә ялгануы: *Әгәр желающийлар булса, обналичим. Яхшы советлар бирә.* Тартым категориясен алган сүзләр: *Һәр этажын төрле-төрлесеннән, тестосын да, бер этажын "молочная девочка", бер этажын "красный бархат", бер этажын бисквитный иттереп ясыйм.* Фигыльләрдә аналитик формалар барлыкка килә: *И легкость: йөгереп йөрисең, пархать итәчәксең шуннан соң. Тоже можешь керергә.*

Лексик яктан кодлар кушылу күренеше алынмалар барлыкка килүгә этәргеч була. Аларны код алмашыну яисә код кушылу дип карап булмый, чөнки алынмалар тулысынча телгә ярашып керәләр.

Синтаксик яктан кодлар кушылу күренеше морфологик кушылу белән тыгыз бәйләнештә торалар. Бу күренеш күпчелек очракта кушма җөмләләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, *Менә әгәр теләүчеләр булса, җыелырга була инде, потому что теге 1-2 меңгә генә сатасылары килми, зуррак сумму хотят. Сиңа бер мең менә начислили бит инде, син шул бер меңне можешь сразу уже вывести, элек в конце месяца гына иде бит.*

Стилистик яктан код кушылу күренешен аерып булмый, эмоциональ халәтне яхшырак яктырту яисә иҗтимагый ситуациягә туры китерү максаты белән кулланылган чит тел фразалары күбрәк югарыда әйтеп үтелгән код алмашыну күренешенә карый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, код кушылу һәм код алмашыну күренешләрен бер-берсеннән аерып карауны уңышлырак дип санап була, алар билингваль яшьләр арасында киң таралган һәм моны тискәре яисә уңай күренеш дип бәяләп булмый. Бер яктан, ул тел кагыйдәләренең бозылуына китерсә, икенче яктан, телдә яңа закончалыклар, формалар барлыкка килүгә этәргеч булып тора ала. Ни генә булмасын, аңсыз рәвештә барлыкка килгән күренешләрне контрольда тоту мөмкин түгел.

## ӘДӘБИЯТ:

Багана Ж., Блажевич Ю.С. К вопросу о переключении кодов // Научные ведомости. Серия Гуманитарные науки. – 2010. – № 12 (83). – С. 63–68.

Сычева О.Н. Кодовое смешение и переключение на английский язык в среде русского социума : дис. … канд. филол. наук : 10.02.04. Владивосток, 2005. 196 с.

Жиганова А.В. Роль переключения языкового кода в рекламе, Нижегородский государственный университет // Вестник Нижегородского государственного лингвистического университета им. Н. А. Добролюбова. – № 13. – С. 33–41.

Г.Р. Галиуллина, Э.Х. Кадирова, Х.Х. Кузьмина, Г.К. Хадиева Коммуникативная ситуация и выбор языка в билингвальном социуме // Казанская наука, 2019. – №2 – С. 109-111

Ашрапова А.Х. Теоретические аспекты языковых контактов (на примере переключения кодов) // Современный мусульманский мир, 2018. – № 1. – С. 1.



**М.М. ШАКУРОВА, Л.М. ГИНИЯТУЛЛИНА**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*

*АН РТ Казань, Россия*


# ЯЗЫКОВОЙ АНАЛИЗ УЧЕБНИКОВ РОДНОГО (ТАТАРСКОГО) ЯЗЫКА ДЛЯ НАЧАЛЬНЫХ КЛАССОВ


**Публикация осуществлена в рамках мероприятия 4.1.3. Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014-2020 годы»**



**Аннотация**. В статье рассматриваются объем, структура и содержание учебников татарского языка в историческом и методическом плане, а также типичные грамматические ошибки при составлении учебников по татарскому языку для учащихся-татар XX века. Нами были проанализированы учебники по татарскому языку первого периода существования школы, а также советские и современные учебники XX в.

**Abstract**. The article deals with the volume, structure and content of Tatar language textbooks in historical and methodological terms, and typical grammar mistakes in the preparation of Tatar language textbooks for Tatar students of the XX century. We analyzed the Tatar language textbooks of the first period of school existence, and also Soviet and modern textbooks of the XX century.



**Keywords:** language analysis, native (Tatar) language, construction of textbooks, speech activity, primary classes.


Для того чтобы учащиеся могли пользоваться различными языковыми средствами при передаче своих мыслей, содержание учебников по обучению родному (татарскому) языку должно носить комплексный характер, то есть изучение языкового материала необходимо сочетать с работой над всеми вида-

ми речевой деятельности. В связи с этим ученик должен знать значение каждого слова, грамматические формы и конструкции татарского языка при обучении говорению и письму.

В учебниках предлагаются конкретные тексты по определенным темам (“Мин”, “Тирә-як, көнкүреш”, “Туган җирем”, “Татар дөньясы”), диалоги, материалы по татарской грамматике и упражнения, задания, игры. [Шәкүрова, 2019] Авторы учебников ставят перед учащимися серьезные задачи в овладении грамматическими явлениями татарского языка, разными видами речевой деятельности с целью обеспечения коммуникативной активности. Здесь учитываются страноведческий и психологический аспекты уроков татарского языка.

Интерес к предмету прежде всего связан с учебным текстом, поэтому тематика учебного материала занимает центральное место в учебниках и программах. В последнее время многие методисты и лингвисты интересуются содержанием и построением программ 20-х гг. С конца XVIII в. и в течение всего XIX в. азбуки, учебники, грамматики, самоучители, разговорники И. Хальфина, И. Гиганова, А. Троянского, А. Казем-бека, Г. Вагапова, И. Кондратова, М. Бекчурина, Н.И. Ильминского, М. Махмудова, М. Иванова, Г. Фаисханова, К. Насырова и др. оказали большое влияние на дальнейшее развитие методики преподавания татарского языка [Шәкүрова, 2012: 24]. Во многих самоучителях конца XIX – начала XX в. выдвигалась задача развития устной речи на базе диалогов и монологов. В содержание обучения вводилась определенная тематика. И в настоящее время в некоторых программах и учебниках по татарскому языку в иноязычной аудитории учебный текст дается на ограниченном лексическом материале в пределах отобранной тематики.

Необходимо заметить, что в этот исторический период представители Казанской школы тюркологов и их последователи сыграли огромную роль в разработке основных проблем татарского языка и его школьного преподавания и, как следствие этого, положение в школах и гимназиях, училищах, духовных семинариях, Духовной академии, Казанском государственном университете изменилось к лучшему. Исходной вехой лингвистической, а впоследствии и методической науки, без всякого сомнения, следует считать филологическую деятельность этих великих ученых (И.А. Бодуэн де Куртенэ, Н.В. Крушевский, В.А. Богородицкий и др.).

Большое внимание в учебниках татарского языка уделяется обучению разговорной татарской речи, работе над текстом, о чем свидетельствуют созданные в это время разговорники, охватывающие разнообразную тематику: *1) религия, 2) родня, 3) тело и его части, 4) стол, 5) огород, 6) одежда,*

*7) животные, 8) дом, 9) время, 10) погода* и т.д. В обучении татарскому языку может быть использовано многое из учебников М.Х. Курбангалиева (“Учебник татарского языка для русских” (1929), “Учебник татарского языка для нетатар” (1931) и другие: разнообразие приемов обучения, система упражнений, богатая тематика учебных текстов, связь занятий по грамматике с живой устной речью и фольклором (пословицы, поговорки, загадки, поучительные слова пожилых людей и т.д. [Корбангалиев, 1931: 33]

В 1940-80-е гг. XX в. было издано несколько учебников, в том числе учебник Р.С. Газизова “Татарский язык” (для самостоятельно изучающих, 1960 г.) и Nicholas Poppe “TatarManual. Indiana University Publications.Uralic and Altaic Series” (vol. 25.The Hagul, 1963). Учебник Р.С. Газизова состоит из четырех частей: теоретический материал (фонетика, морфология, синтаксис) с различными заданиями; материалы для перевода с русского на татарский язык (даются слова для справок); материалы для перевода с татарского на русский язык («Случай на границе», “Наша Родина”, “Два товарища” и др.), материалы для чтения (“Мои воспоминания“ Г. Тукая, “Пастухи”, “Старый слуга” Г. Ибрагимова, “Первый театр” Г. Камала, “Их было трое” И. Гази и т.д.) [Газизов, 1960: 19]. Согласно учебнику, сначала необходимо усвоить теоретическую часть татарского языкознания, а затем выполнить упражнения с целью закрепления полученных знаний и применить их в практике устной и письменной речи. В его основу по грамматико-переводному методу были положены перевод и чтение оригинального, большого по объему текста. Таким образом, одной из главных особенностей данной работы является обеспечение практической направленности обучения татарскому языку в школе. В ней наметился целый ряд положительных тенденций в преподавании татарского языка в русской школе: внимание к развитию связной речи учащихся, комплексный подход к активизации всех видов речевой деятельности учащихся, анализ текста, учет характера воздействия родного языка на процесс овладения татарским языком.

Учебник Николаса Поппе состоит из двух основных частей: теоретической и практической [Поппе, 1963: 9]. В теоретической части содержится морфология татарского языка на английском языке, а в практической — произведения татарских писателей. Использование на занятиях текстов художественной литературы и устного народного творчества помогало глубже усвоить грамматический материал, лексику, интонацию, произношение и, как следствие этого, глубже понять содержание произведения. Например, дан отрывок из произведения М. Гафури “Бедные или женщина-соквартирантка”, где глубокая человечность образов (Шараф, Джамиля, Бадри), созданных писателем, волнует

читателя: жизнь бедняков, заработки Шарифа, встреча Джамили с родственниками, радость детей Худайбирде и Гульжихан, смерть молодой женщины и т.д. Учащиеся должны выразительно читать текст, работать над словарем, отвечать на вопросы, составлять предложения и диалоги, пересказывать прочитанное, уточнять фонетические, орфографические, лексические ошибки и т.д. Огромные трудности возникают у учащихся тогда, когда формы принадлежности единственного числа образуются после основ на гласную при помощи аффиксов *-сы//-се*, после основ на согласную и на *-у//-ү, -ы//-е*: *йортында* (в его (ее) доме), *бакчасында* (в его (ее) саду) и т.д. Таким образом, автор устанавливает тесную связь между грамматикой и литературой для того, чтобы учащиеся могли использовать грамматические конструкции в татарской речи.

Итак, Р. Газизов и Н. Поппе, учитывая опыт составителей самоучителей XIX в., уделяли в своих учебниках большое внимание грамматике и переводу. Перевод текста с татарского языка на русский имеет огромное значение в концепции учебника татарского языка, поскольку он позволяет синтезировать грамматические явления языка в их функционировании, сопоставлять татарский и русский языки. В учебнике особое внимание надо обратить на такие формы, которые наиболее трудны при переводе для учащихся: категории принадлежности имен существительных, основы глагола, залоги и модальные формы глагола, субстантивированное причастие, склонение указательных местоимений, таких как *ул* (он, она, оно), *бу* (это, эта, этот, эти), построение синтетического предложения с аффиксами деепричастных форм глагола.

Особую трудность в учебниках для учащихся представляют причастия всех времен. Дело в том, что в татарском языке причастия всех времен часто употребляются без определяемого слова, то есть субстантивируются и выступают в формах различных падежей, принимают аффиксы принадлежности и числа: *Тырышкан табар* (пословица). – *Тырышкан (кеше) табар* (Тот, кто ищет, найдет). *Тырышкан* – причастие прошедшего времени на *-ган* употребляется без определяемого слова *кеше* (человек), субстантивируется и выступает в форме основного падежа. [Шәкүрова, 2012: 88]

Анализ учебников по татарскому языку в историческом и методическом плане XX в. позволил нам сделать вывод о том, что наличие целого ряда грамматических нарушений в устной и письменной речи учащихся объясняется следующими обстоятельствами: во-первых, в учебниках не разработана система комплексного изучения фонетики, лексикологии, грамматики

в их функционировании в процессе изучения текстов, диалогов, речевых образцов, которые позволяют сформировать все виды речевой деятельности; во-вторых, недостаточно тщательно и внимательно подбираются тексты страноведческого характера; в-третьих, не уделяется серьезное внимание переводу категории принадлежности имен существительных, изучению основы глагола, залоги и модальные формы глагола, деепричастия, субстантивированного причастия, склонения указательных местоимений (таких как *ул* (он, она, оно), *бу* (это, эта, этот, эти)), построения синтетического предложения с аффиксами деепричастных форм глагола. Значительные трудности у учащихся вызывает усвоение повелительного наклонения. Но главное внимание в учебниках должно быть обращено на возможность сознательного использования языкового материала в речевой деятельности.

Таким образом, проведенное исследование доказывает, что XX в. учебники татарского языка сыграли особую роль и в методическом, и лингвистическом плане, оставили богатое наследие в истории языка и методики преподавания татарского языка.

**ЛИТЕРАТУРА**

Газизов Р. Татарский язык (для самостоятельно изучающих) / Р. Газизов. Казань: Татгосиздат, 1960. 252 с.

Гыйниятуллина Л.М., Шәкүрова М.М. Туган телне укыту методикасының бүгенге көн проблемалары / Л.М. Гыйниятуллина, М.М. Шәкүрова. Казан: Вестфалика, 2018. 119 бит.

Корбангалиев М.Х. Татар теле дәреслеге: Татарлардан башкалар өчен, 5 нче уку елы өчен. – I кисәк / М.Х. Корбангалиев. Казан: Татиздат., 1931. 111 с.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр) / М.М. Шакурова. Казан: Ихлас, 2012. 144 б.

Шәкүрова М.М. Туган тел. 1 сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2019. 151 б.

Nicholas Poppe. Tatar Manual: Indiana University Publications. Uralicand Altaic Series. – Vol. 25. The Hagul, 1963.

**Й.Х. ШӘРӘПОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ *ИКЕ* САНЫНЫҢ СЕМАНТИК ТӨРКЕМНӘРЕ

**Аннотация.** Мәкалә татар халык мәкальләрендә урын алган ике санының семантикасын ачыклауга багышланган. Ике санының татар халык мәкальләре контекстында

семантик төсмерләре ачыклана. Теге яки бу семантиканы тудырырга ярдәм иткән чаралар анализлана, семантик төркемнәр аерылып чыгарыла.

**Abstract.** The article gives the definition of the semantics of the numerical two in tatar proverbs. The semantic meanings of the numerical two are analyzing in the context of the tatar proverbs. The auxiliary means which help to open different semantics are analyzed and semantic groups are distinguished.

**Ачкыч сүзләр:** семантика, татар халык мәкальләре, ике, семантик төркемнәр.

**Keywords:** semantics, tatar proverbs, two, semantic groups.

Мәкальләр системасында зур бер урынны сан сүз төркеме кергән мәкальләр алып тора. Сан сүз төркемен мәкальләр контекстында өйрәнү зур кызыксыну уята, чөнки саннар мәкальләрдә урын алган вакытта яңа семантик мәгънәгә ия булалар. Шул рәвешле саннарны хәтта төрле семантик төркемнәргә дә аерырга мөмкин.

Олуг фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең "Татар халык мәкальләре" өч томлыгында сан сүз төркеме кергән мәкальләргә күз салганда, берникадәр статистик мәгълүмат тупларга мөмкин. Тикшеренү эшчәнлеге вакытында мәкальләрдә очраган саннарның кулланылыш активлыгы санап чыгарылды. Куланылыш буенча беренче урында *бер* саны тора. Ул мәкальләрдә 1577 мәртәбә кулланылган, аннан соң *ике* саны бара – 629. *Өч* – 127, *дүрт* – 43, *биш* – 91, *алты* – 109, *җиде* – 96, *сигез* – 49, *тугыз* – 55 тапкыр очрый. *Ун* саны – 128, *егерме* – 32, *утыз* – 47, *кырык* – 118, *илле* – 49, *алтмыш* – 61, *җитмеш* – 28, *сиксән* – 30, *туксан* – 24, *йөз* –74, *мең* –105, *төмән* –1, *миллион* 1 мәртәбә күзәтелә.

*Ике* санына килгәндә, кулланылыш буенча ул *бер* саныннан соң икенче урында тора. Әйтергә кирәк, еш кына анализланган мәкальләрдә *ике* саны *бер* саны белән бергә килә. Мондый төр мисалларда *ике* саны һәрвакытта *бер* санына капма-каршы куела. Мондый мисалларда *бер* һәм *ике* саннары төрле семантикага ия түгел, киресенчә, аларның семантик вазифалары бергә үрелеп, яңа семантик төркем барлыкка килүенә этәргеч булып тора.

*Ике* саны кергән беренче семантик төркемгә "Ялкаулык" исеме бирелде.

*Иренгән — **ике** үләр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 328]*

*Иренгән — **ике** утырыр, итәген чүпкә тутырыр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 329]*

Әлеге мисалларда да *ике* саны лексик-грамматик төркемчә ягыннан микъдар санына керә. Өстәмә кушымчалар алмаган рәвештә *ике* саны беренче мисалда исемне ачыклап килә, калган мисалларда исә фигыль сүз төркемен ачыклый. Шулай итеп, *ике* саны эшнең үтәлү процессының ничә мәртәбә кабатланганлыгын белдерә. Хәрәкәт фигыльләре (*эшләр, утырыр, тутырыр*)

*ике* санына ялкаулык семантикасын тудырырга ярдәм итә. Эш процессы *ике* саны ярдәмендә ялкаулыкка, бер эш тә эшләмәүгә каршы куела. Шуны да искәртеп үтергә кирәк, әлеге мисалларда зур рольне паралингвистик чаралардан көттерү паузасы уйный. Пауза ярдәмендә (язма сөйләмдә ул тире ярдәмендә бирелә) *ике* санына синтагма басымы йөкләнә. Мәкальләр тискәре коннотациягә ия.

Икенче семантик төркем, "Капма-каршылык" төркеме, *ике* саны белән *бер* саны каршылыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән мәкальләрне үз эченә туплый.

*Бер санаганны* ***ике*** *санасаң, шайтан көләр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 392]*

***Ике*** *исәп — бер исәп, бер исәп — юк исәп. [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 393]*

***Ике*** *бер иткән, берне юк иткән [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 393]*

*Ике* саны белән *бер* саны мисалларда үзара чагыштырылалар, нәтиҗәдә капма-каршылык семантикасы туа. Беренче мисалда *бер* саны билгесезлек алмашлыгы вазифасын үтәп, билгесезлек артикле буларак кулланылган. *Ике* микъдар санына керә. Өченче мисалда капма-каршылык семантикасын тудыруда паралингвистик чара – көттерү паузасы зур роль уйный. Өстәвенә, бу мәкаль ике компоненттан тора. Бу шулай ук *бер* һәм *ике* саннарының үзара чагыштырылуына китерә. Соңгы мисалда *бер* саны исемләшеп, исем сүз төркеменә хас булган грамматик категорияне – килешне үзләштерә. *Ике* саны бер санына каршы куелып, күләме ягыннан гына түгел, ә семантик көче ягыннан да зуррак булып чыга.

Чираттагы семантик төркем исә, "Икеяклылык" дип атала.

*Комган* ***ике*** *авызлы [И.Н. Тат.хал.мәк.т.2: 555]*

***Ике*** *йөзле дус –* ***ике*** *яклы пычак[И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:32]*

*Таяк* ***ике*** *башлы була, юашы сезгә[И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:357]*

Әлеге төркемгә кергән *ике* саны барлык мисалларда да – микъдар саны. Мисалларда *ике* саны сыйфат сүз төркемен, исем сүз төркемнәрен ачыклап килгән. *Ике* саны сурәтләнә торган предметның данә исәбен генә белдерми, шуның белән бергә ул предметны ике яктан ачыклап күрсәтә, ике яклы булуына басым ясый дияргә була. Мисал өчен, комганның ике авызы бар, дус ике яклы пычак белән чагыштырыла, таякның ике башы барлыгы бәян ителә. Мәкальләрдә *ике* саны ярдәмендә раслау пафосы тудырыла. Мисаллар уңай коннотациягә ия.

Тагын бер семантик төркемгә "Эшнең өзлеклелеге" дигән исем бирелде.

***Ике*** *ишет, бер сөйлә [И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:491]*

*Ике* һәм *бер* саннарының саналмышлары фигыль булып тора. *Ике* саны эш процессын ачыклый. Фикерләү фигыльләре (*ишет, сөйлә*) турыдан туры

саннарга бәйле. Шул рәвешле, *ике* саны эшнең бер-бер артлы барырга тиешлелеген мәкальдә раслау пафосы аша күрсәтә.

Соңгы семантик төркем “Даимилек, үзгәрмәүчәнлек” исемен алды. Мисал итеп, алдагы мәкальне китерергә мөмкин. ***Ике*** *дөнья бер килмәс [И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:987]*

*Ике* саны тормыш тематик төркеменә кергән исем сүз төркемен ачыклап килә. *Дөнья* — *ике* санының саналмышы. Бу мисалда *ике* саны тормышның үзгәрмәүчәнлеген һәм даимилеген күрсәтә. Бу семантик төркемне тудырырга *ике* санына *бер* саны ярдәм итә.

Шулай итеп, *ике* санын семантик яктан тикшерү дәверендә алдагы семантик төркемнәр аерылып чыгарылды: “Ялкаулык”, “Капма-каршылык”, “Бердәмлек”, “Көрәш”, “Икеяклылык”, “Эшнең өзлеклелеге”, “Даимилек”. *Ике* санын семантик төркемнәргә бүлергә ярдәмче сүзләр булышты: хәрәкәт, фикерләү фигыльләре, тормыш (*дөнья*) һ.б. тематик төркемнәргә кергән исем сүз төркемнәре, нумератив сүзләр (*тиен*). Еш кына *ике* санының семантик төсмерен ачыкларга паралингвистик чаралар (көттерү паузасы) һәм мәкальнең төзелеше, структурасы ярдәм итте.

**ӘДӘБИЯТ**

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 1. Казан: Тат. кит.нәшр., 1959. 915 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 2. Казан: Тат. кит.нәшр., 1963. 960 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 3. Казан: Тат. кит.нәшр., 1967. 1014 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р.Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

Инновационные процессы в науке и образовании: монография. Под общ. Ред. Г.Ю. Гуляева. Пенза: МЦНС «Наука и просвещение». 2017. 204 с.

**Л.М. ШӘРИПОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП, УКУЧЫЛАРНЫҢ БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ (БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАР МИСАЛЫНДА)

**Аннотация.** Изменение в политике изучения языков этносов российской привели к необходимости пересмотра методов обучения. Еще острее стала задача отбора наиболее эффективных приемов, с ориентацией на интерактивность. Автор делает обзор современных методов и Интернет-платформ, направленных на изучение родного языка.

**Abstract.** The change in the policy of studying the languages of ethnic groups of the Russian Federation led to the need to revise the teaching methods. The task of selecting the most

effective techniques, with a focus on interactivity, became even more acute. The authors make an overview of modern methods and Internet platforms, study their native language.

**Ключевые слова:** родной язык, инновационные технологии, коммуникативный подход.

**Keywords:** native language, innovative technologies, communicative approach.

Тел – кешегә бирелгән иң зур могҗизаның берсе. Халык мәкалендә әйтелгәнчә, акыл – казна, күңел – йозак, тел – ачкыч. Бу ачкыч безгә башкалар күңелен аңларга, акылыбызның камиллеген, уй-фикерләребезнең ни дәрәҗәдә югары булуын күрсәтергә ярдәм итә. «Халыкның теле – аның бөтен рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә... аның Ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә», – дип язган К.Д. Ушинский. Иң әһәмиятлесе: телебез булганда милләтебез дә яшәр.

Тел, беренчедән, безнең күзаллавыбызны, уй-фикерләребезне белдерергә ярдәм итүче корал булса, икенчедән, безнең аңыбызның формалашуына, баюына, баланың киләчәктә белем алуына юл ача, аның фикер йөртү сәләтен үстерә һәм акыл үсешенә ярдәм итә. Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Укытучыларыбыз алдында бик тә җаваплы бурычлар тора. Беренчедән телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән укучыларда телне өйрәнүгә кызыксынуны арттыру һәм үстерү бурычы. Укытучының төп максаты – укучыларда фәнни фикерләү, иҗади эшләү сәләтен үстерү, тәрбия эшендә югары нәтиҗәләргә ирешү, җәмгыятьтә үз урыннарын таба алырлык толерант шәхес тәрбияләү.

Бүгенге көндә укытучыдан иҗади эшли белү сорала. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу беренче чиратта яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылуны күздә тота. Уңай нәтиҗәләргә ирешү өчен заман белән бергә атлап бару таләп ителә.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

– укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;

– укучының танып белү активлыгын арттыру;

– тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

– укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, инициативасын тагын да үстерү.

Соңгы елларда заманча укыту технологияләрен куллану турында күп сөйләнелә, языла. Билгеле, алар эченә яңа техник чаралар гына түгел, ә яңа формада төрле метод-алымнар кулланып укыту кирә. Белем бирүдә заманча

технологияләрнең берсе булган – информацион технологияләр санала. Информацион технологияләр – компьютер техникасы һәм төрле программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны укучыларга әзерләү, саклау, эшкәртү, җиткерү процессы ул. Заманча технологияләр күп төрле бурычларны хәл итәргә ярдәм итә: уку материалын аңлаешлырак итеп җиткерә; белемнәрне системага салырга булыша, укучыларның иҗади үсешен тәэмин итә, яңа темага җиңелрәк төшенергә мөмкинлек тудыра. Билгеле булгача, телнең мәгънәви һәм грамматик төзелеше буенча бербөтенне тәшкил иткән сөйләм бәйләнешле сөйләм дип атала. Анда сөйләүче үз фикерен белдерә. Хәзерге вакытта укучылар сөйләүче буларак үз фикерләрен белдергәндә, сөйләм формалаштырганда, күп кенә кыенлыклар кичерәләр. Балаларның еш кына эзлекле фикер йөртә алмаулары, аларның лексик-грамматик хаталар җибәрүләре дә бәйләнешле итеп сөйли белмәүләреннән килеп чыга. Әлеге күренеш укытучыларны борчыган проблемаларның берсе. Ә балаларда кызыксыну уяту икенче зур проблема булып тора. Әлеге проблемаларны берләштереп уңай нәтиҗәгә ирешү өчен заманча технологияләргә мөрәҗәгать итәбез. Интерактив такта мультимедияле ресурсларны кулланырга, презентацияләр ярдәмендә дәресне кызыклы үткәрергә мөминлек бирә. Шулай ук, укучыларның белемнәрен тикшерү өчен онлайн-кроссвордлар, төрле формадагы тестлар (логик тестлар, дөрес җавапны сайлап алу, төшереп калдырылган сүзләрне кую) куллану – укучыларның кызыксынучанлыгын арттырып кына калмыйча, аның танып-белү эшчәнлеген активлаштыра.

Әлбәттә, заманча технологияләр кулланып укыту укытучыдан күп вакыт, туктаусыз эзләнүләр, информатика өлкәсендә тирән белемнәр сорый. Ләкин зур нәтиҗәләргә кыска вакыт эчендә ирешү өчен әлеге таләпләрнең үтәлүе сорала.

Башлангыч сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп: дәрес материалы югары күрсәтмәле дәрәҗәдә була, укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар, контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары, төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә. Болар барысы да компьютер технологияләрен кулланганда, укытучы өчен алыштыргысыз ярдәм итүче сыйфатлар. Бу инде, һичшиксез, татар теле һәм әдәбияты фәненең эчтәлеген безнең әйләнә-тирәбездәге чынбарлык белән бәйләргә, шул мохитта шәхеснең үз урынын билгеләргә ярдәм итә.

Шулай ук башлангыч сыйныфларда иң отышлы технологияләрнең берсе булып уен технологиясе санала. Уен ярдәмендә балаларда зирәклек,

оешканлык, коллективта үзеңне тота белү, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә. Уеннарның бала психикасына уңай йогынтысы турында күренекле педагоглар Л.С.Выготский, А.Н.Леонтьев, Д.Б.Эльконин, А.В.Запорожец, А.П.Усов һ.б. хезмәтләрендә язганнар.

Баланы әйләнә-тирәдәге предметлар белән таныштырганда аның сөйләмен үстерүгә дә әһәмият бирергә кирәк. Предметлар, аларның исемнәре белән таныштыргач, сүзле уеннарда шул исем-атамаларны төрле вариантта куллану отышлы. Андый уеннар бала аңында сүзнең мәгънәви эчтәлеген киңәйтә, төрле сүзтезмәләр төзи белергә өйрәтә.

Сүзле уеннар тәрбия чарасы буларак отышлы, чөнки алар барышында күмәклек, дуслык, игътибарлылык, ярдәмләшү кебек матур сыйфатлар, шулай ук бала күңелендә туган телне, халкыбызның үткәнен, гореф-гадәт, йолаларын ихтирам итү, үз милләте белән горурлану хисләре тәрбияләнә. Сүзле уеннарның шигырь калыбына салынган булуы балаларда эстетик зәвык тәрбияли, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә.

Сөйләм телен камилләштерүдә төп бурычлар: сүзлек эше; сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру; авазларның дөрес әйтелешен төшендерү; бәйләнешле сөйләмгә өйрәтү; әдәби әсәрләр һәм халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру. Балалар белән эшләүдә сүзлек эше зур әһәмияткә ия. Беренче чиратта, сүзлек запасы гомуми кулланылыштагы сүзләр нәтиҗәсендә арта. Икенчедән, күп тапкырлар кабатлау рәвешендә сүзләрне ачыклау, конкретлаштыру. Өченчедән, сүзләрне активлаштыру.

Халык әйтемнәрендә, такмак-җырларында, мәкальләрендә тел, матур, дөрес итеп сөйләүнең әһәмияте турында күп әйтелә. Һәр сүзнең үз урынын белеп, аларны сәйләннәрдәй бөртекләп сайлап алып сөйләүченең сүзе колакларны иркәли, күңелгә барып җитә, җиңел аңлашыла. Сүзләрне төгәл, урынлы, дөрес куллану сөйләм культурасын билгели. Сүзлек бай булганда гына сүзләрне сайлап, нәкъ кирәклесен табып була. Шуның өчен дә балаларның сөйләмен үстерү бурычларның иң әһәмиятлеләреннән берсе сүзлекне аныклау, тулыландыру, активлаштыру.

Сүзлекнең байлыгы баланың нинди социаль шартларда тәрбияләнүенә бәйле. Балаларның берәүләре даими рәвештә эти-әнисеннән бай, дөрес сөйләм ишетә, ә икенчеләренә үрнәк һәм кабатлау өчен бик гади, ярлы һәм күп вакытта дөрес тә булмаган сөйләм туры килә. Әлбәттә, бу ике төркем балаларының сөйләм мөмкинлекләре бертигез булса да, сүз байлыгы тигез дәрәҗәдә була алмый.

Шулай итеп, заманча технологияләр күп төрле бурычларны хәл итәргә ярдәм итә: уку материалын аңлаешлырак итеп җиткерә; белемнәрне системага салырга булыша, укучыларның иҗади үсешен тәэмин итә. Ә иң мөһиме – әлеге технологияләр ярдәмендә татар халкының бай мирасын җиткерә алабыз.

**ӘДӘБИЯТ**

Назипова Э.Р. Татар теле дәресләрендә компьютер технологияләреннән файдалану / Э.Р. Назипова, Ф.Ф. Харисов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. 253–258 б.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. Казан: «Ихлас», 2012. 144 б.

**Е.Г. ШТЫРЛИНА**

*Казанский федеральный университет, Россия*

## ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ ПОДХОД В ОБУЧЕНИИ РУССКОМУ ЯЗЫКУ КАК ИНОСТРАННОМУ

**Аннотация.** Статья посвящена лингвокультурологическому направлению в преподавании русского языка как иностранного. Рассматриваются особенности работы с лингвокультурологическими материалами в процессе преподавания РКИ.

**Abstract.** The article is devoted to cultural linguistics as an approach to teaching Russian as a foreign language. The author describes features of language- and culture-specific data used for teaching Russian as a foreign language.

**Ключевые слова:** лингвокультурологический подход, русский язык как иностранный, учебный текст.

**Keywords:** linguo-cultural approach, Russian as a foreign language, educational text.

Идея взаимосвязанного изучения языка и культуры лежит в основе лингвокультурологического подхода в методике преподавания русского языка как иностранного. Изучение языка в контексте культуры его носителей, выработка не только языковой, но и коммуникативно-культурологической компетенции занимают важное место при обучении русскому языку как иностранному. Обучение русскому языку в рамках лингвокультурологического подхода формирует навыки межкультурного общения, способствует развитию ценностных ориентаций личности обучающихся с позиции диалога языков и культур.

Для лингвокультурологического подхода в преподавании русского языка как иностранного характерны две тенденции интерпретации языка и культуры в учебных целях: «от фактов языка – к фактам культуры» и «от фактов культуры – к фактам языка» [Щукин, 2015]. Согласно первой тенденции, культуроведческая информация извлекается из самих языковых единиц, а объектом рас-

смотрения на занятиях становятся особенности отражения в языке культуры его носителей. В рамках данного подхода основными объектами изучения становятся безэквивалентная лексика; фоновые знания, присущие носителям языка и отсутствующие либо иначе трактуемые в иноязычной культуре; невербальные средства общения, отражающие особенности национальной ментальности носителей языка; тактики речевого поведения в различных ситуациях межкультурного общения; отражение культурных традиций в художественной литературе. Вторая тенденция рекомендует строить образовательный процесс от фактов культуры к фактам языка, подчеркивая значимость и ценность изучения прежде всего культуры [Щукин, 2015]. Принимая во внимание всё вышесказанное, хочется отметить, что эффективная коммуникация возможна лишь в том случае, если иностранный учащийся овладевает не только языковыми средствами выражения информации, но и системой представлений о традициях, истории, культуре, реалиях страны изучаемого языка в целом, которая позволит ему «проникнуть» в национальную картину мира. Таким образом, культура через язык и язык через культуру – основной путь постижения русского языка иностранными учащимися.

Основным средством приобщения инофона к культурному наследию и духовным ценностям русского народа является учебный текст на русском языке, подобранный и адаптированный с учетом определенных языковых средств (лексических, грамматических, стилистических). Отражая ценностные основы русской культуры и являясь источником культурологической информации, тексты способствуют усвоению и закреплению языковых знаний обучающихся. Текстовый материал дает представление о важных явлениях российской действительности, помогает понять особенности русского самосознания, специфику менталитета, позволяет сформировать отношение к реалиям, традициям и обычаям народа изучаемого языка, рассматривает актуальные проблемы современности с опорой на историю и культуру.

При отборе и адаптации текстов культурологического содержания для занятий по русскому языку как иностранному следует придерживаться антропоцентрического принципа с опорой на нравственно-этические основы и гуманистические ценности. Использование дидактических материалов будет способствовать возможности сравнивать и сопоставлять материальные и духовные ценности разных народов мира, выявлять в культурах национально-специфическое и общечеловеческое.

Учебные тексты, отобранные для изучения в иностранной аудитории, должны представлять значимые для русской культуры явления и события, быть

актуальными для самих обучающихся, отражая социальные, исторические и культурные параллели, соответствовать интересам и потребностям обучаемых в зависимости от того, какие социальные роли придется им выполнять, в какие речевые контакты вступать в процессе реальной коммуникации.

Ориентация на реалии российской действительности обусловливает тематику учебных текстов, выбор тем для общения в аудиторное время. Релевантными в иностранной аудитории становятся темы, которые относятся к сферам социально-бытовой (здоровый образ жизни, проблемы молодежи и т.п.), социокультурной (женщина и мужчина, смысл жизни, богатство и др.), учебно-профессиональной (образование, профессия, успех), информационной (Интернет, телевидение, пресса), а также сфере отдыха (организация отдыха, хобби, путешествие, спорт и др.) [Теремова, 2007]. В рамках занятий по русскому языку как иностранному важным становится моделирование ситуаций речевого общения в самых различных сферах коммуникации. В этой связи особое значение приобретает не столько иллюстрация ситуаций, характерных для российской действительности, сколько попытка продемонстрировать ошибки, которые могут совершать инофоны в условиях российской социокультурной среды, обозначить пути разрешения конфликтных ситуаций и спорных проблем с учётом норм и правил поведения носителей русского языка. В процессе обучения важно предугадать, объяснить и предотвратить неадекватные ассоциации, которые обусловлены культурно-историческими и социально-психологическими особенностями русской культуры. Проблемное обсуждение вопросов, касающихся русской ментальности, системы мировоззрения и образа жизни русских людей, этике их поведения и общения, позволит иностранным учащимся понять и принять русских, избежав конфликтных ситуаций и недопонимания. Использование на занятиях актуального материала проблемного характера обеспечит не только коммуникацию, адекватную условиям общения, но и сформирует социокультурную компетенцию иностранных учащихся. Таким образом, учебный текст на занятиях по русскому языку как иностранному может рассматриваться не только как дидактическая единица, но и как единица моделирования культурного кода, как ключевой инструмент формирования духовной культуры личности обучающегося, работающий в обоих измерениях – от культуры к языку и от языка к культуре.

Важно отметить, что изучение русского языка и русской культуры должно строиться в контексте диалога с родным языком и родной культурой обучающихся, в контексте «встречи культур» разных народов (сравнение, сопоставление одних и тех же явлений в изучаемой и родной культурах). Сопостави-

тельный анализ в таком случае позволяет обучающимся лучше понять собственную, родную культуру и увидеть её роль в становлении мирового общекультурного пространства. В ходе подобной работы формируется ценностное отношение к культуре как таковой, преодолеваются мыслительные и культурные стереотипы, что помогает достичь взаимопонимания при иноязычном общении.

В этой связи особое значение приобретает подготовленность преподавателя русского языка как иностранного, сформированный им пресуппозиционный фонд знаний об обучаемых (учет специфики быта, образа жизни, национальных особенностей, духовных ценностей представителей разных инокультурных сообществ). На занятиях педагог выступает в качестве посредника между культурами различных народов, организатором межкультурной коммуникации. Эффективное взаимодействие между участниками образовательного процесса возможно лишь в условиях соблюдения принципов взаимного уважения, толерантности, открытости, ценности личности, гуманного межнационального общения и т.д. Важнейшей задачей преподавателя на уроках русского языка как иностранного становится воспитание уважения к другой, изучаемой культуре, обычаям, понимания и «приятия» того, что на первых порах кажется непонятным и чужим. Преодоление сложившихся стереотипов, проникновение в систему ценностей русской культуры, осознание культурного разнообразия окружающего мира подготавливает обучающихся к эффективной межкультурной коммуникации, развивает толерантное отношение к представителям и явлениям иной лингвокультуры.

**ЛИТЕРАТУРА**

Теремова Р.М. Учебник по русскому языку как иностранному нового поколения: каким ему быть? // Мир русского слова. 2007. №1–2. С. 69-7.

Щукин А.Н. Методика преподавания иностранных языков: учебник для студ. учреждений высш. образования. М.: Издательский центр «Академия», 2015. 288 с.

**А.А. ЯРУЛЛИН**

*ТР Буа муниципаль районы*

*Черки Килдураз урта мәктәбе, Буа, Россия*

## ЯКТАШЫМ – ТЕЛ ГАЛИМЕ ВАХИТ ХАКОВ

**Аннотация**. В данной статье дается биографическое описание жизни и научной деятельности нашего земляка – доктора филологических наук, профессора Вахита Хакова.

**Abstract.** This article offers a biographical description of the life and scientific activity of our countryman-doctor of Philology, Professor Vakhit Khakov.

**Ключевые слова:** филология, наука, профессор Хаков, стилистика

**Keywords:** Philology, science, Professor Khakov, stylistics

Һәркемнең үзенә якын һәм кадерле туган ягы бар. Минем дә туган авылым бик матур урында урнашкан. Ул үзенең челтерәп аккан чишмәләре, калын, шомлы һәм серле урманнары, гореф - гадәтле, эшчән, акыллы кешеләре белән атаклы.

Моннан күп еллар элек, бөек Иделгә барып кушыла торган Зөя буена Ураз бабай килеп йорт салган, җирләрен эшкәрткән. Ару-талуны белмәүче Ураз бабай шушы урынга нигез салган йортны Ураз килде дип атаганнар. Тора-бара бу җирләрне Килдураз дип йөртә башлаганнар. Авыл үскән, зурайган, көннән көн матурайган. Тирә-якта даны арткан. Килдураз белән чиктәш авыллар: Өчмунча, Күзби, Бәбки, Үгез куагы, Кабалан халкы элек-электән дус, тату яшәгән. Балалары Килдураз мәктәбендә белем алганнар. Бу хәзер дә шулай дәвам итә. Хәзерге вакытта авылларны «Коммуна» күмәк хуҗалыгы берләштерә. Бу авыллардан күп кенә күренекле һәм данлыклы кешеләр чыккан: Ренат Харис, Шәриф Хөсәинов, Марс Әхмәтов, Шамил Нигъмәтуллин, Вахит Хаков, Җәләлетдинов Рәшит, Әюпов Ренат, Скиргайло Тамара һ.б., шулардан иң өлкәне – Вахит Хаков.

Минем максатым:

1.Тел галиме - Вахит Хаков турында белемнәрне тирәнәйтү, ныгыту.

2. Якташымның хезмәтләрен өйрәнеп куллану.

Бурычым:

1. В. Х. Хаковның якыннарын, туганнары хакында белешмә бирү.

2. Солтания Закир кызы Хакова белән әңгәмә уздыру, мәгълүмат туплау.

3. Тел галиме В. Хаковның хезмәтләрен тикшерү.

Күренекле тел галиме, укытучы-педагог, Вахит Хөҗҗәт улы Хаков 1926 нчы елның 16 нчы августында Татарстанның матур урынында урнашкан Буа районының Күзби авылында дөньяга килә. Аның әтисе – Хөҗҗәтелислам акыллы, тырыш кеше була, бөтен гомерен балалар укытуга багышлый. Педагог әтисенә ияреп, малай да китап яратып үсә.

Башлангыч белемне Күзби авылында мөгаллимлек иткән әтисеннән ала. Бу мәктәпне ”5”ле билгеләренә генә тәмамлап, Вахит ага укуын Килдураз мәктәбендә дәвам итә, 8 нче классны бетергәч, Бөек Ватан сугышы башлана. Кечкенәдән укытучы булырга хыялланган малайның хыяллары җимерелә...

Әтисенең «Ничек кенә авыр булмасын, укый күр, улым», – дигән сүзләре колагында яңгырый.

1943 нче елда 17 яше дә тулмаган Вахитны армиягә алалар. Җиде ел хәрби хезмәттә булып, яраланып, сугышчан медальләр, Верховный Командующийның рәхмәт кәгазьләре белән бүләкләнеп, 1949 нчы елда яшь солдат тыныч хезмәткә исән-имин әйләнеп кайта.

Вахит Хөҗҗәт улы туган якларына әйләнеп кайткач, төрле мәктәпләрдә балалар укыта, үз белемен күтәрү өстендә эшли. Тәтеш педагогия училищесын ”бик яхшы” билгеләренә тәмамлый. Егет укуын дәвам итү өчен Казан дәүләт университына укырга керә, аны кызыл дипломга бетерә. Аспирантураны тәмамлап, «Татар әдәби теленең барлыкка килүе, үсеше һәм аның стильләре» дигән темага диссертация яклый, соңрак филология фәннәре докторы дигән югары гыйльми дәрәҗә ала, профессор исеме бирелә. Менә нинди тырыш, үҗәт булган безнең якташыбыз.

Вахит ага, чыннан да, әтисенә биргән сүзендә тора. Зур уңышларга ирешә, тел галиме дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул 40 ел дәвамында студентларга белем бирә.

Якташыбыз дүрт дистә елдан артык Татарстан радиосында «Тел күрке – сүз» тапшыруларының оештыручысы һәм алып баручысы булды, берничә буын бу тапшыруларны тыңлап, тәрбияләнеп үсте.

Галимнең 30 га якын монографиясе, дәреслекләре, уку-укыту әсбаплары 500дән артык фәнни һәм фәнни методик хезмәтләре басыла. Әле шулар янына төрле китапларны, җыентыкларны, шул җөмләдән чит ил басмаларын да мәсәлән, Төркиядә дөнья күргән 350 гә якын фәнни мәкаләләрне өстәргә кирәк.

Милләт язмышы, халык мәнфәгате турындагы уйлар егетне бу юлга китергәндер. Эшлекле, булдыклы ир-егет гомерен татар телен өйрәнүгә, аны баетуга, пропагандалауга багышлый. «Мәктәптә, югары уку йортларында тел укытуны ничек тә саклап калырга, газиз туган телебезне өйдә генә сөйләшергә ярый торган тел итеп калдырмаска! Дәрәҗәсен төшермәскә!» – ди галим. Халык туган телдән бизмәсен, сөйләшү-аралашуда, язуда күбрәк куллансын, матурлыгын, ләззәтен тойсын дип тырышты Вахит ага. Тел бит ул бер-берең белән аралашу коралы гына түгел, ул – фикерләү чарасы да. Тел кешенең фикерләвен, дөньяны танып белүен дә үстерә. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аны күз карасы кебек саклау – үз анаңны , илеңне хөрмәтләү дигән сүз.

Татар теле, катлаулы үсеш юлы үтеп, хәзерге көндә төрки телләр төркеменә керүче бай телләрнең берсе булып санала.

Татарстан Республикасы Буа районы Черки-Килдураз урта гомуми белем мәктәбендә Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның туксан яшьлек юбилеена багышланган «Казан университеты профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның фәнни-педагогик мирасы» дип исемләнгән республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде. Бу конференциядә Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның тормыш иптәше Хөррия ханым, кызы Ләлә Әхмәтвәлиева, бергә эшләгән хезмәттәшләре, галим-галимәләре, район җитәкчеләре, татар теле укытучылары һәм мәктәп укучылары актив катнашты.

В.Х.Хаковка Килдураз урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты кабинетында аңа багышлап стендлар чыгарылды, почмак булдырылды. Аның гаиләсе шәхси әйберләрен, китапларын һәм фотоларын безнең мәктәпкә бүләк иттеләр.

Вахит Хаков тәҗрибәле педагог, филолог-тюрколог, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Бөек Ватан сугышы ветераны белән без чын йөрәктән горурланабыз. Безнең күңелләрдә ул һәрвакыт олы җанлы, сабыр, тирән белемле туган тел сагында торучы, хөрмәтле остазыбыз булып сакланыр.

Мин эзләнү эшемне тагын да тулыландыру өчен, күренекле тел галименең киленнәре, Хакова Солтания апа белән әңгәмә оештырдым, күп мәгълүмат тупладым. Бу эзләнүләр мине канатландырып җибәрде. Үземә шундый нәтиҗә ясадым, бары тик тырышып укырга, куйган максатларга ирешергә кирәк дигән фикергә килдем.

**А.С. ЯРУЛЛИНА**
*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТКӘНДӘ ПРОЕКТЛАР МЕТОДЫНЫҢ БЕЛЕМ БИРҮ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮ

**Аннотация.** В статье рассматривается использование проектного метода в образовании.

**Abstract.** The article devoted to the use of the project method in education.

Тормыш үзгәрү белән яңа технологияләр барлыкка килде һәм җәмгыятьнең төрле өлкәләренә дә үтеп керде, шуңа бәйле рәвештә, мәгариф тә зур үзгәреш кичерә. Татар теле дәресләрен укытканда шәхескә якын килү, проблемалы укыту, аралашуга өйрәтү, интенсив белем бирү һ.б. шундый технологияләр кулланыла башлады. Бу технологияләрнең киң колач алуы бер

яктан, заман белән бергә атлау белән бәйләп аңлатылса, икенче яктан, аларның балаларда телгә кызыксыну уятуы, активлаштыруы укыту процессында киң кулланылуына китерде.

Билгеле булганча, методика фәнендә барлыгы берничә укыту технологиясе бар. Педагогик технология укытуны, белемнәрне үзләштерүне, идея-фикерне, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Алар арасында модульле укыту методы (Т.И. Шамова, П.И. Третьяков, И.В. Сенновский), үстерелешле укыту методы (И.С. Якиманская, Л.В. Занков, А.З. Закиев и др.), уен формасында укыту методы (Ш.А. Амонашвили, О.В. Канарская, Д.Б. Эльконин), проблемалы-эвристик укыту методы (А.В. Хуторской), кечкенә төркемнәрдә укыту методы, проект нигезендә укыту методы, мәгълүмат чаралары ярдәмендә укыту методы (Е.С. Полат), алгоритмнар нигезендә мәгълүмат чаралары кулланып укыту методы (Н.Н. Алгазина) һ.б бар [Шәкүрова, 2012: 25].

Татар телен өйрәтүнең педагогик технологияләре арасында проектлар методы аерым урын алып тора. Әлеге метод XX гасыр башында Америка Кушма Штатларында аерым метод буларак гамәлдә йөри башлый. Аны Дж. Дьюи һәм аның укучысы В. Клипатрик уйлап чыгара һәм киң кулланылышка кертеп җибәрә. Алар белем бирү процессын активлаштыру максатыннан, игътибарны баланың иҗади эшчәнлегенә, аның эзләнү, тикшеренү сәләтен үстерүгә юнәлтүне кирәк дип табалар.

Якынча шул ук вакытта безнең илдә С.Т. Шацкий проектлар методын кулланылышка кертергә теләүчеләр төркеме оештыра һәм ул мәктәпләргә актив кертелә башлый. Ләкин бу идеягә каршы булган галимнәр тәкъдиме буенча 1931 нче елда Үзәк Башкарма Комитеты карары нигезендә проектлар методы белән эшләү тыела [Харисов, 2015: 207]. Узган гасыр азагында гына педагог-метадистлар бу проблемага яңадан әйләнеп кайталар һәм ул хәзер белем бирү системаларында үзенең тиешле урынын тапты дип әйтергә буладыр.

Бу метод төрле фәннәрне, шул исәптән татар телен туган тел һәм чит тел буларак укытканда да уңышлы файдаланыла. Аны проект технологиясе дип тә, проект методы дип тә атыйлар. Ул укучының танып белү активлыгын, белемгә омтылышын үстерә; дәрестә алган белемнәрен гамәлдә куллану мөмкинлеге тудыра, бәйләнешле сөйләмен камилләштерә, иптәшләренә үз фикерен җиткерергә һәм әңгәмәдәшен тыңларга өйрәтә; белем һәм культура дәрәҗәсенең үсешенең үсешен күрсәтә.

Проектларның бик популяр булуы тагын шуңа да бәйле: теоретик белемнәрне гамәлдә куллана белү аерым проблемаларны чишү юлларын да

билгеләргә ярдәм итә; укыту эшен аерым шәхескә, бу очракта укучыга адреслы итеп алып барырга булыша, мөстәкыйль фикерләргә – теманы сайларга, кирәкле мәгълүматны эзләп табарга, аңлатырга һәм күрсәтергә өйрәтә. Болай эшләү коммуникатив күнекмәләр барлыкка китерә, татар телен өйрәтүгә формаль якын килүне киметә яки бетерә. Балалар бу вакытта сөйләмнең эчтәлегенә күбрәк игътибар итәләр. Әлеге метод предметара бәйләнешләрне тормышка ашырып, укучыларның белемнәрен интеграцияли, танып белү эшчәнлеген арттыра, аларның иҗади һәм тикшеренү күнекмәләрен үстерә.

Бу методика шәхескә юнәлтелгән, чөнки укыту гадәти аралашуга якыная төшә һәм татар теленә өйрәтүнең яңа технологияләре таләпләренә җавап бирә; баларның акыл эшчәнлеген төрле яклап үстерә, шулай ук проект методы мөстәкыйльлекне, инициативаны һәм өйрәнелә торган предмет белән кызыксындырган аерым тема буенча эшләргз мөмкинлек тудыра. Билгеле, ул вакытта аның активлыгын, кызыксынуын һәм гомумән уку-укыту эшчәнлеген җанландырып җибәрә. Бу вакытта кайсы китаплар белән эшләргә, Интернеттан нинди мәгълүматны эзләп табарга һәм аларны ничек кулланырга кирәклеген дә укучылар бергәләп хәл итәргә тиеш булалар.

Ул укытучының һәм укучыларның яхшылап әзерләнүләрен, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә. Проект турында фикер алышуда катнашып, укытучы да балаларның тигез хокуклы яшьтәшенә һәм ярдәмчесенә әйләнә. Укучыларның яшь үзенчәлекләренә, акыл үсешенә һәм сөйли белү сәләтенә карап, төрле дәрәҗәдәге проектлар булырга мөмкин.

Педагогикада проектлар эшен башкаруның түбәндәге этаплары мәгълүм: укытучы тәкъдим иткән теманың максатын, бурычларын билгеләү, планлаштыру (проблеманы анализлау, чыганаклар эзләү), рольләрне бүлешү, карар кабул итү ( мәгълүмат җыю, теманы чишү юллары турында фикер алышу, уңышлы вариантлар сайлау, планга төгәллек кертү), эшчәнлек (проектта куелган бурычларны хәл итү), нәтиҗә ясау (чыгышка әзерләнү һәм чыгыш ясау, ирешелгән нәтиҗәләрне аңлату) һәм бәяләү.

Үз проектын яклаганда, укучыга төрле фәннәргә караган белемнәрен искә төшерергә һәм кулланырга, үз фикерен якларга һәм иптәшләренекен тыңларга мөмкинлек туа. Болар өчен, билгеле, шактый гына сүзлек запасы һәм сөйләм калыплары да үзләштерелгән булырга тиеш. Димәк, проектны планлаштыру да укытучыдан шактый гына хезмәт таләп итә икән.

Татар теле дәресләрендә, түбәндәге проектларны кулланып була:

- тикшеренү (хезмәтнең актуальлеген нигеләү, тикшеренүнең максатын, бурычларын билгеләү, чишү юлларын ачыклау, кулланылган чыганакларны күрсәтү);
- иҗади (бәйрәм үткәрү өчен сөенарий төзү, сочинение планын төзү, газетага мәкаләләр язу һ.б.);
- гамәли юнәлешле (һәр укучының яки төркемнең бөтен эшчәнлеген яхшы нәтиҗәгәләргә ирешү максатыннан чыгып планнаштыру);
- мәгълүмати (тема буенча мәгълүматлар туплау, аны укучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, йомгаклау);
- рольле (проектның эчтәлегннән чыгып, укучыларның рольләргә бүленүе, аларга нәрсәдер әйтү, яки нәрсә турында булса да сорау теләгән булдыру);
- предметара (төрле фәннәр нигезендә) һ.б.

Бу уңайдан, түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк дип саныйбыз:

1. Эзләнү-тикшеренү характерындагы проект эшен башкару өчен, аерым бер фәнни-иҗади проблема билгеләнә.
2. Эш ахырында ирешелә торган нәтиҗәнең теоретик һәм гамәли әһәмияте ачыклана.
3. Укучылар аерым-аерым, парлап яки төркемләп эшлиләр.
4. Проект эшенең эчтәлеге гомуми планда күзаллана.
5. Эзләнү-тикшеренү методларын куллана белү: төп проблеманы (теманы) һәм аны үзләштерү бурычларын билгеләргә, проект эшенең максатын ачыкларга, аны чишү юлларын гипотеза формасында күрсәтергә, фәнни-тикшеренү методлары турында фикер алышырга, эш ахырында укучыларның нәтиҗәләрен тикшерергә, хатларын төзәтергә һәм йомгак ясарга, кирәк дип санаган төзәтмәләр кертергә мөмкинлекләр бирә.

Шәхескә юнәлтелгән укытуны тормышка ашырганда, проектлар методы зур роль уйный. Ул укучыларның иҗади сәләтен, танып белү эшчәнлеген һәм мөстәкыйльлеген үстерә. М.Е. Брейгина фикеренчә, алар күп төрле булалар: монопроект, коллектив проект, телдән сөйләм проекты, язма проект, интернет проектлар һ. б. Чынбарлыкта исә укытучы катнаш проект билгеләре дә ачык чагылыш таба. Проект эшләү татар телен төрле яклап өйрәнүгә ярдәм итә. Ул үз эченә укуны, тыңлап аңлауны, сөйләүне һәм грамматиканы ала, укучыларның актив рәвештә мөстәкыйль фикерләвенә китерә, аларны бердәм иҗади эшкә тарта. Проект ярдәмендә укыту балаларны хезмәттәшлеккә өнди, ә ул, үз чиратында, аларда үзара ярдәмләшү, бер-берсенә теләктәшлек итү, иҗады сәләтне үстерү кебек уңай сыйфатларны тәрбияли.

Гомумән алганда, проект ярдәмендә белем бирү укыту һәм тәрбия эшенең аерылгысыз булуын дәлилли. Бу метод укучыларның аралашу сәләтен үстерә, үз фикерләрен җыйнак һәм төгәл итеп белдерергә, иптәшләренең фикерләренә колак салырга, кирәкле мәгълүматны төрле чыганаклардан эзләп табарга һәм компьютер технологияләре ярдәмендә аны эшкәртергә, өйрәнелә торган телдә аралашу теләген тудырырга ярдәм итә. Сөйләшү темасы күп төрле була: дуслык, сәясәт, театр, кино, тарихи вакыйгалар һ.б., ләкин уйлау һәм сөйләшү өйрәнелә торган телдә, бу очракта татар телендә булырга тиеш. Проектлар методының педагогикада һәм методикада үз урыны бар. Проектлар методы – иҗатны танып белү эшчәнлеген һәм мөстәкыйльлекне үстерү ысулы.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз: татар теле дәресләрендә проектлар технологиясенә мөрәҗәгать итү, укучыларга материалны үзләштерергә булышлык итә. Проектлар технологиясе балаларның белем алуга, телгә карата кызыксынуын, игътибарын арттыра, аның эшчәнлеген активлаштыра. Проектны яклаганда, укучылар өйрәнелә торган телне тыңларга, бер-берсен аңларга өйрәнәләр, сүзлекләр, белешмә әдәбият компьютер белән эшлиләр, аутентик текстлар белән танышалар.

## ӘДӘБИЯТ


Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2001. 432 б.

Харисов Ф.Ф. Рус мәктәпләрендә татар теле укытуның дидактик нигезләре // Мәгариф, 2002. – № 2. – Б. 86–88.

Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар телен чит тел буларак өйрәтү: Заманча технологияләр. Казан: КДПУ, 2002. 27 б.

Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: Тат. кит. нәшр., 2015. 302 б.

Харисов Ф.Ф. Заманча белем бирү технологияләре: Аспирантлар, магистрлар һәм укытучылар өчен кулланма. Казан, 2015. 62 б.

Шәкүрова М.М., Йосыпов А.Ф. Татар телен укыту методикасы: Теория һәм практика. Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшр., 2009. 168 б.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры–XX гасыр) / Научное наследие методики преподавания татарского языка (конец XVIII–нач. XX вв.). Казан: Ихлас, 2012. Б. 15

Полат Е.С. Новые педагогические технологии (курс дистанционного обучения для учителя). М., 2001. 203 с.

**СОДЕРЖАНИЕ**

**ЭЧТӘЛЕК**


Кузьмина Х.Х. О жизни и научной деятельности заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова............. 3

Ахметвалеева Л.В. С любовью об отце – профессоре Казанского университета В.Х. Хакове........................................................................ 6

Абдуллаев С.Н., Эркебуланова Н.Ш. Линводидактический потенциал пословиц................................................................................ 8

Абейдуллова А. Т. Диалекталь лексиканы дәресләрдә куллану үзенчәлекләре. ......................................................................................... 13

Әбрарова А.Г., Һадиева Г.К. Казан шәһәре урам исемнәренә структур анализ................................................................................. 16

Айдарова С.Х., Яфарова Р.Ф. Имена прилагательные, обозначающие звуки, в арабском и татарском языках................................ 20

Арсланова Ч.Н. Н. Хөсәеновның «Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге» турында................................................................ 25

Әсхәдуллина Г.Г. Татар мәдәниятендә агач образының бирелеше.... 27

Болгарова А.Р. Междометия в татарском и английском языках......... 30

Вәлиуллина Р.И. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында «катлаулы кушма җөмләләр» темасын аңлатканда уен технологияләреннән файдалану................................................................ 34

Вилданова Ә.Ф. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында һәм аның рус теленә тәрҗемәсендә алыштыру юлы белән тәрҗемә ителгән синонимнар...................................................................................................... 37

Габдрахманова Ф.Х. Татар халык мәкаль-әйтемнәрендә *кунак* концептының бирелеше............................................................................ 40

Гайфуллина И. М. Ономастик материалны мәктәптә өйрәнүнең актуальлеге.................................................................................................. 43

Галиева А.А. Вахит Хаковның тормыш юлы һәм тел өлкәсендәге эшчәнлеге.................................................................................................... 46

Галимбикова И.И. Педагогика һәм психологиянең заманча алымнары һәм актуаль мәсьәләләре............................................................ 50

Галиуллина Г.Н. Луиза Янсуар иҗатында автологик һәм металогик алымнар....................................................................................................... 52

Галләмова Д. Р. Татар шигърияте теленең лексик катламнары

(1920-1930 нчы еллар поэзиясе мисалында) ............................................... 58

Гарипова Д.Р. Массакүләм мәгълүмат чаралары текстларында фонетик вариантлылык.............................................................................. 61

Гасанова Г.А. Отражение этнокультурной специфики в повести Л.Н.Толстого «Хаджи-Мурат»..................................................................... 65

Гатина А.М. Татар теле дәресләрендә эндәш сүзләрне кабатлау....... 69

Гатиятуллина Р.Г. Татар телевидениесендә лингвистик нормаларның сакланышы........................................................................... 72

Гафурова И.И. Ономастик материалны татар теле дәресләрендә проект ярдәмендә өйрәнү............................................................................ 76

Гыйльметдинова А.Д. Казан шәһәренең лингвистик ландшафты 79

Гыйләҗиева А.Н. Башлангыч сыйныф укучыларын татар теленә өйрәтүдә текст белән эш............................................................................. 83

Досанова А. Абайдың дiнни-философиялық ойлары және олардың мәнi...................................................................................................... 87

Җәләева Г.А., Харисов Ф.Ф. Белем бирүдә сәламәтлек саклау технологиясе............................................................................................. 92

Закирова Г.Р. А.С. Пушкин әкиятләренең казах һәм татар телләренә тәрҗемәләрендә лексик үзенчәлекләр....................................... 96

Зиннәтова А.И. Проблема одиночества в рассказах А.Еники............ 100

Ибраһимова Э.И. Татар сөйләм телендә редупликация күренеше..... 103

Идиятова Л.Ю. Хәзерге татар антропонимиясендә кулланылышта йөргән популяр исемнәр.............................................................................. 107

Ильясова Ә.Ф. Татар балаларын ана теленә өйрәткәндә фольклор һәм хәзерге заман балалар шигърияте нең роле........................................... 112

Ильясова Ә.Ф. Мәктәпкәчә яшьтәге татар балаларын туган телгә өйрәтүдә кулланылган алымнар, ысуллар һәм шартлар............................. 115

Камалова З.Ф. Проблема голода в произведении Г. Ибрагимова «Адәмнәр»............................................................................................... 119

Кәримова И.Ф. Рәвешләрне өйрәтүдә яңа метод һәм алымнар куллану..................................................................................................... 122

Куталмыш С.Л. К вопросу о содержании понятия «фонема»............ 126

Макаров И.М., Шакирова Г.Р. Туган тел дәресләрендә арт-технологияләр куллану үзенчәлекләре.................................................... 128

Мөбәрәкшина З.Н. Татар һәм рус телләрендә төс атамаларының мәгънәләре (фразеологизмнар мисалында) ................................................ 132

Мөбәрәкшина Л. Р. Татар теле дәресләрендә компьютер

технологияләренең кулланылышы........................................................... 136
Мөгътәсимова А.И. Мәхмүт Хәсәнов иҗатын өйрәнү барышында предметара бәйләнеш алымнарыннан файдалану........................................ 139
Муратгельди Сойегов, Чарыев Шамухаммед Палванович. О восьми книгах, изданных на туркменском языке арабской вязью в первых десятилетиях XX века (краткие изложения с рисунками их обложек или титульных листов)......................................................................................... 142
Мөхәммәтгалеева Г.Н. Урта гомуми белем бирү оешмаларында аналитик һәм синтетик чараларны өйрәтү методикасы............................... 146
Мухаметгалиева З.М. О языковых средствах выражения эмотивности в татарском языке..................................................................... 151
Мөхәммәтҗанова Д.М. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә һәм аларның рус теленә тәрҗемәләрендә гади сөйләм сүзләренең кулланылыш үзенчәлекләре.............................................................................................. 156
Нуреева Г.И. Татарская литература и медиа в современном культурном пространстве.......................................................................... 162
Сабитова З.В. «Ялкын» журналы мисалында массакүләм мәгълүмат чараларының туган телгә өйрәтүдәге ролен ачыклау................ 165
Сәгъдиева И.М., Гыйззәтуллина Л.Ф. Особенности использования компьютерных технологий при обучении татарскому языку как неродному. ............................................................................................ 169
Садриева Р.Ф. Хәсән Туфан иҗатында мотивлар төрлелеге.............. 171
Садрова Л.И. татар һәм рус халык мәкальләрендә ир-ат матурлыгын тасвирлый торган лексик берәмлекләр.................................... 173
Сәлахова А.Р. Ф.С. Сафиуллинаның лексикология өлкәсендәге хезмәте........................................................................................................ 176
Салихова З.Д., Денмөхәммәтова Э.Н. Татар сөйләмендә синонимнарның роле......................................................................... 180
Сафина К.Р. Ренат Харис иҗатында төсләр кулланылышы............... 184
Тилеуова Н. Абай мұраларындағы философиялық ойлар: заманмен үндестігі............................................................................................. 189
Ульянова Е.С. Актуальные проблемы современной педагогики и возможные пути их решения.......................................................... 194
Файзутдинова Л.Х. Сказкотерапия как метод коррекции агрессивного поведения у детей дошкольного возраста............................ 195
Фәсхиева З.И. Татарча-русча сүзлекләрдә ризык атамаларының тоткан урыны............................................................................................ 199

Филиппова Р.И. Иҗтимагый фикер формалаштыру теориясе һәм аның үзенчәлекләре........................................................................... 203
Хәбибуллина А.Р. Фатих Амирхан прозасында Казан образы........... 206
Һадиева А.Ф. Хәзерге тел белемендә прецедент исемнәр һәм аларның өйрәнелеше.............................................................................. 209
Һадиева И.Ф. З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» драмасында замана проблемаларын яктыртуда символлар роле............................................... 214
Һадиева И.Ф. З. Хәкимнең «Телсез күке» драмасында милләтләр язмышы проблемасы.......................................................................... 218
Хәмидуллина Л.Б., Хөснетдинов Д.Х. Сүз төркеме буларак бәйлек.. 221
Хәмидуллина А. А. Татар теленең фонетикасын өйрәнү тарихына күзәтү........................................................................................... 225
Харисов Ф.Ф. Полилингваль белем бирү шартларында укытучының һөнәри үсеше: лингводидактик аспект.................................. 228
Хасбиуллина Г.Ф. Татар телендә *бер* санының кулланылышы.......... 234
Хафизова Я.А. Татар балалары сөйләменең лексик үзенчәлекләре... 237
Шаһвәлиева З.Р. Хәзерге татар сөйләмендә тел кодлары алмашынуы һәм күчеше үзенчәлекләре..................................................... 240
Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М. Языковой анализ учебников родного (татарского) языка для начальных классов................................... 244
Шәрәпова Й.Х. Татар халык мәкальләрендә *ике* санының семантик төркемнәре........................................................................................... 248
Шәрипова Л.М. Инновацион технологияләр кулланып, бәйләнешле сөйләм телен үстерү (башлангыч сыйныфлар мисалында).......................... 251
Штырлина Е.Г. Лингвокультурологический подход в обучении русскому языку как иностранному............................................................ 255
Яруллин А.А. Якташым – тел галиме Вахит Хаков............................ 258
Яруллина А.С. Татар теленә өйрәткәндә проектлар методының белем бирү сыйфатын күтәрү.................................................................... 261

*Электронное научное издание*
*сетевого распространения*

# ХАКОВСКИЕ ЧТЕНИЯ – 2019

**Материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова**

# ХАКОВ УКУЛАРЫ – 2019

**Яшь галимнәрнең Казан университеты Атказанган профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаков истәлегенә багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары**

Подписано к использованию 26.11.2019.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times New Roman».
Усл. печ. л. 15,7.

Издательство Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 233-73-59, 233-73-28